# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Рүзәл МӨХӘММӘТШИН. Мохтарият. *Шигырьләр циклы*. ........................................3
Фоат САДРИЕВ. Сайрар чак. *Роман*. ........................................20
Марат КӘБИРОВ. Базарда үз хакың булмаганда... *Шигырьләр*. ........................................53
Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА. Кошлар оя корган җирдә... *Роман*. ........................................58
Әнвәр ШӘРИПОВ. Тәпи баскан җирем чирәм иде... *Шигырьләр*. ........................................115
Рәзинә МӨХИЯР. Кабатлана тарих... *Шигырьләр*. ........................................134
Айгиз БАЙМӨХӘММӘТОВ. Урын. *Хикәя*. ........................................138

«ИЛЕҢ ТУРЫНДА УЙЛА» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Айзирәк ГӘРӘЕВА-АКЧУРА. Гаҗизлек. *Хикәя*. ........................................118
Фәтхулла АБДУЛЛИН. Герман җирендә мәтрүшкәләр үсми. *Хикәя*. ........................................148

ЯҢА ИСЕМНӘР

Рәмзия ӘХМӘТОВА. Мин көтәм дә... гомер ашыга... *Шигырьләр*... ........................................145

ТУФАН МИҢНУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 85 ЕЛ

Минтимер Шәймиев: «Без – авыл балалары...». *(Әңгәмәдәш – Нурсөя ШӘЙДУЛЛИНА)*. ..152
*Фотоархив*: Туфан Миңнуллин тормышыннан мизгелләр. ........................................156
Марат ӘХМӘТОВ. Ил агасы иде ул. ........................................158
Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ. Җан иреге. *(Туфан Миңнуллинның иҗат портретына штрихлар)*. ...160
Туфан МИҢНУЛЛИН. Әти. Әни. *(Көндәлекләрдән)*. ........................................165
Илгиз ЗӘЙНИЕВ. Театрыбызның Әлмәндәре. ........................................177

КАЗАКЪ ӘДӘБИЯТЫ АКСАКАЛЫ АБАЙНЫН ТУУЫНА 175 ЕЛ

Лирон ХӘМИДУЛЛИН. Акын Абай иҗаты безгә бик якын. ........................................179

БӨЕК ҖИҢҮГӘ – 75 ЕЛ

Хат язар идем сезгә... Хатларны Камилә ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА әзерләде. ........................................182

*Кызыл кара белән.* Сәхифәне Рамил ХАННАНОВ алып бара. ........................................186

*Шаян сәхифә:* Уены-чыны бергә. Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде. ........................................188

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ........................................190

КАЗАН УТЛАРЫ
*(«Огни Казани»)*
*№ 8 (1174) 2020*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Ринат Закиров**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Данил Салихов**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Фирүзә Җамалетдинова, Айсылу Имамиева, Камил Кәримов.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Илгизә Сабирова.**
*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1617).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 30.08.2020, график буенча 30.08.2020, басылып чыгу вакыты 11.08.2020.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-1989. Тираж 4643.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2020 ел

Sigriət
Шигърият

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020



Рүзәл
Мөхәммәтшин

# МОХТАРИЯТ

## Башлам

*Җете төсләргә ерак әле.*

*Дөнья – сызгаланып ташланган соры рәсем гүя. Төксе[1] туфрак. Аксыл күк. Бетергечнең зыр кубуыннан гына йомры болытлар оешкан. Карандаш очы сыныпсынып киткән урын – кошлар.*

*Такыр тау башы. Андагы шәрә каеннар – күк белән җирне тарттырып ямаган тегәрҗепләр, диярсең.*

*Чынлыкта, киресенчә, чик сызыгы ул. Япан кырны урталай ярып үткән каенлык. Безнең бакча артында гына. Инеш аркылы. Кече як тәрәзәсеннән күренеп тора.*

*Без әтәй белән еш менә идек анда. Хәзер түгел. Җәйнең җете төсләрдә кабарынганбүртенгән чагында. Табигать тавышларының һәр чыңы миңгә теленгәндә. Җир яссы заманда. Дөньяда һәрнәрсә бары тик әтәй белән үлчәнә алганда: әтәйдән зуррак, әтәйдән кыскарак, әтәй кадәр...*

*Мин кәлтә сыман шуышып кына агач башына үрмәлим. Башта дөньяны барлап чыгам. Уңда – безнең авыл, сулда – безнеке түгел. Ләкин икесендә дә безнеңчә, татарча сөйләшәләр. Икесенә дә кул сузымы ара.*

*Аннары каен ябалдашларын ботарлый башлыйм. Артыгын тырышып ташлаганда, үзем дә егылып төшәм. Әтәй күргәндә, бер җир дә авыртмый, билгеле.*

*Ул пиннек әзерли.*

*Мин каенлыкның бер ягыннан икенче ягына чабулыйм:*

*– Татарстанда! Татарстанда түгел!.. Татарстанда!..*

*Кичә генә әле.*

*Бик күптән.*

## Кече Татарстан
***(1920 ел)***

Анамның сөте,
Тире атамның –
Кече Татарстан –
Минем Ватаным.

[1] Төксе (диал.) – төсен җуйган.

Рүзәл МӨХӘММӘТШИН (1989) – *шагыйрь һәм прозаик; М.Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты. «Каралама», «Бүре мин», «Мин дә китәрмен әле» дигән китаплар авторы. Казанда яши.*

Иманасы да,
Иманы да бар.
Тарихы гына –
Тоташ яралар.

Тураклаганнар.
Пычак – коралы:
Бусы – Иделе,
Бусы – Уралы,

Бусы – бавыры,
Бусы – үпкәсе...
Авызын җимер –
Теше үтмәсен!

Пычак очында
Җаным күшегә:
Бусы – күршегә,
Бусы – күршегә!..

Тунаудан артып
Калганын таны:
Кече Татарстан –
Минем Ватаным.

## Сәхибгәрәй Сәетгалиевнең[2] поезд кузгалыр алдыннан Татарстан АССР белән хушлашуы
***(Казан, 1921 ел)***

*Татарстан Республикасын булдыру мәсьәләсендә Сәетгалиев соң чиктәге аумакайлык, тотрыксызлык һәм умырткасызлык күрсәтте. Башта ул җаваплы татар хезмәткәрләрен «үзәк белән килешеп... Олы Татарстан (Идел-Урал штаты яисә Татар-Башкорт республикасы) оештыруга ирешәчәкмен» дип ышандырды...*
Мирсәет Солтангалиев[3] кулъязмасыннан

*Эш шунда ки, өлкә комитеты һәм партконференция Сәетгалиев җитәкчелегендәге хөкүмәтнең эшкә яраксызлыгын билгеләп үтте һәм аның кайбер әгъзаларын алыштырырга карар кылды...*
Кәшшаф Мохтаров[4] чыгышыннан

Китәр өчен –
Егерме дүрт сәгать.
Шундый сәер, шундый гаҗәп нәрсә:
Әле кичә генә түрдә идем.
Бүген бәхилләшәм.
Кыйблам – Мәскәү.

---

2 Сәхибгәрәй Сәетгали улы Сәетгалиев – 1920 – 1921 елларда Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы рәисе. Соңыннан Кырым АССРны җитәкли.

3 Мирсәет Хәйдәргали улы Солтангалиев – милли дәүләт төзелеше теоретигы, 1919 – 1921 елларда Шәрык халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк бюросы рәисе, 1920 – 1923 елларда РСФСР Милләтләр эше буенча халык комиссариаты коллегиясе әгъзасы, 1922 – 1923 елларда Татарстан АССРның Мәскәүдәге вәкиле.

4 Кәшшаф Гыйльфан улы Мохтаров – 1921 – 1924 елларда Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы рәисе. Аңарчы – тәүге Сәламәтлек саклау халык комиссары.

Миңа изге бурыч куйды фирка:
Ныгытырга Октябрьнең данын
Икмәк кирәк, диде, икмәк кирәк,
Бик күп кирәк! –
Һәм мин таптым аны.

Һаман сугыш бара,
Дошман яный,
Һәм инкыйлаб уты сорый мәгъдән[5]! –
Шундый чакта шомландырсын, имеш:
Татар авыллары авыр хәлдә...

Дөнья
Үте белән
Тойган чакта
Тынычлыкта нинди давыл барын,
Ыңгырашу сискәндерсен, имеш:
Ачтан үлә татар авыллары...

Шуның өчен нәгърә-ләгънәт орды
Чыраема күпме тел бистәсе.
Үзе дурак! –
Урыс кебек әнә
Чөгендерен чәчсен,
Кәбестәсен...

Туземецлар – мәгъдән генә ләса
Инкыйлабка!
Һәм шул булды сәбәп:
Дүрт ягың да кыйбла, диде алар.
Китәр өчен –
Егерме дүрт сәгать.

Большевикка һәр үкенеч – язык!
Җинаятьче данын йөртим, юкса, –
Арабызда
Бөек Октябрьне
Җинаять дип танучылар булса.

Җирләр, сулар тетри!
Планетаны
Ялмый бара һаман кызыл ялкын!
Ни син монда, мескен республика?
Ни син монда, аның мескен халкы?

Һай, татарлык-тарлык!
Шаккатарлык:
Шундый чорда
Мышык-мышык һаман! –
Эче җыелмаган чебеш сыман,
Коры кабыгына ышыклана.

[5] Мәгъдән – руда.

Тураерга,
Зураерга вакыт –
Кереп зуррак ыру исәбенә! –
Бер юл!
Бер ил!
Бер тел!
Ә гайресе –
«Правый уклон» вәсвәсәсе генә.

Бөек Идеягә тугры калып,
Туры юлдан барып сөрлекмәскә!..
Дүрт ягың да кыйбла, дип лаф ору –
Бушбугазлык.
Безнең кыйбла – Мәскәү.

Бәхилләшәм мәңгелеккә, гелгә!
Монда кысан, һава кыса, тыгыз...
Гаепләшмик:
Мин беренче түгел.
Һәм соңгысы булмам,
Ышаныгыз!

## Җир эшләре комиссары Юныс Вәлидинең[6] Халык Комиссарлары Советы рәисе Кәшшаф Мохтаров алдында тәүге исәп-хисап тотуыннан өземтә
***(Казан, 1921 ел)***

*Ахыр чиктә хакимияткә «уңнар» килә һәм алар республика белән 1921 – 1924 елларда идарә итә... «Кәшшаф Мохтаров хөкүмәте» оеша.*

Тарихчы Рәмзи Вәлиев хезмәтеннән

*...Мохтаров җитәкләгән Татарстан Республикасы хөкүмәте Казан читендә һәм Идел-Чулман ярларында татар торак пунктларын тергезергә керешә. (Билгеле булганча, XVI гасырда, Казан ханлыгы юкка чыгарылганнан соң, татарлар бу җирләрдән сөрелә.) Шул рәвешле картада Чыңгыз, Кызыл Байрак, Бакчасарай, Гаспралы исемендәге, Яңа Болгар ише атамалар барлыкка килә... Казанның «урыс ягында» 1552 елдан соң беренче мәчет төзелә...*

Журналист Михаил Бирин мәкаләсеннән

*«Уңнар» бу эшләрне «тарих мәхрүм иткән өлешне кире кайтару» дип атый иде...*

Микъдәт Борындыков[7] язмасыннан

Төп чыгышым тәмам.
Инде болай,
Беркетмәсез-нисез, дисәңме...
Кул кушырыр көнгә ерак әле.
Саулык кына җитсен,
Исәнлек.

[6] Юныс Нуриман улы Вәлиди бу вазифаны 1920 – 1924 елларда башкара.
[7] Микъдәт Юныс улы Борындыков – 1922 – 1924 елларда Татарстан АССР Мәгариф халык комиссары.

Аппаратлар яртылашка якын
Карагруһтан тора.
Андыйлар
Нинди генә эшкә алынсаң да,
Баланс юк, дип, бармак яныйлар.

Баланс юк, дип!
Тигез хәлдәме без?
Беләк чагыштырыр хәлдәме?
Башкаларның, кайгыртырга әнә,
Мәскәве бар –
Үгез кадәрле!

Безнең ни бар?
Без – үзебез генә.
Инкыйраздан йолып коткару
Татар халкын – синең, минем бурыч!
Изге бурыч, иптәш Мохтаров!

Без зур.
Безнең туфрак кына азрак.
Коры калдык – янып, көеп тә! –
Иңгә-янга үсеп булмый икән,
Тирәнлеккә үсик,
Биеккә!

Гөлбакчадай корыйк йортыбызны,
Авыр чынбарлыктан куптарып! –
Без куәтле!
Бу эш безнең кулдан
Килер кебек, иптәш Мохтаров!

Кара-каршы күк җәйрәгән чакта
Туфрак әллә кысыр калырмы? –
Җиде кат тиремне салсам салыйм,
Туфрак барда –
Орлык табылыр!

Кинә белән башын чайкамасын
Ил агасы, кызыл башкала,
Кайсы кырга ни чәчәргә кирәк –
Хәл итәрбез –
Аннан башка да.

Артка карамыйча,
Алга карыйк –
Тарихыбыз бөек килеш тә! –
Сулган сылулыкны сагынып елау
Фахишәгә генә килешә.

Безнең күрәчәктә –
Гүзәл көннәр!
Өметемдә – күпме кыюлык:

Күк астында үз туфрагы барда
Безнең халкыбызга үлем юк,
Үлем юк!..

Нигә сөйлим моны?
Белмим хәтта.
Синең килү җанны актарып,
Куанычка чыдый алмыйм, ахры.
Бары тик шул...
Кәбәм Мохтаров.

## Ислам дине кабул ителүнең 1000 еллыгы шәрәфенә Кабан артында мәчет төзү турындагы мөрәҗәгатькә РСФСР Милләтләр эше буенча халык комиссариатыннан җавап алынганнан соң Гасыйм Мансуровның[8] шәхси көндәлегенә теркәгән язмасы

***(Казан, 1922 ел)***

*...Алар ураза гаете көнне партиясез кара крестьян массасының күз алдында тәгъбир догасына каршы «антитәгъбир» җырлаганнар. Мондый эш чыннан да башкарылган булса, һичшиксез, контрреволюциядән башка бернигә дә китермәячәк.*

Шаһивәли Башкиров[9] чыгышыннан

*...Күренекле идеолог һәм дәүләт эшлеклесе Гасыйм Мансуров «кызыл муллалар» белән ачыктан-ачык хезмәттәшлек итәргә, руханиларны халыкка мәгърифәт тарату эшендә файдаланырга кирәк, дип белдерә.*

Тарихчы Булат Солтанбәков хезмәтеннән

Шөкер!
Шөкер!
Озакламый,
Кяфер җиргә иман чәчеп,
Казанның урыс ягында
Күтәрелер тәүге мәчет.

Кяфер җиргә...
Иман чәчеп...
Ата-баба илендәме? –
Чи яраның әлегәчә
Әрнүе бу күңелдәге.

Нишлик соң? –
Шушы сораудан
Мең ел элек ата-баба,
Ислам белән җанын юып
Кузгалган бүгенгә таба,

Кузгалган бүгенгә таба,
Ышанып:

[8] Гасыйм Гата улы Мансуров – 1922 – 1924 елларда Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы рәисе урынбасары.

[9] Шаһивәли Гали улы Башкиров – 1922 – 1923 елларда Буа кантон башкарма комитеты рәисе һәм Буа партия комитетының җаваплы сәркатибе.

Юл – үзе савап.
Һәм гап-гади җавап тапкан,
Һәм дөрес булган ул җавап...

Морадына барган чакта
Күпме тузан, кер кунгандыр.
Кем дип дәшим? –
Милләтемне
Сафлану белән куандыр!

Җиде юл чатына җитте,
Җиде яктан җилләр исә.
Азатлыкка ирешү юк
Коллык хисе җилләмичә!

Нишлик соң? –
Яңа дәвергә
Ак якадан узу лязем...
Давыл гына купмасын да
Ишелмәсен күк гөмбәзе.

Һәм йөрәктән китмә, китмә...
Юкса, куркыныч уй ала:
Синнән бушаган урынга,
Һичшиксез,
Иблис оялар.

Тәүбә!
Тәүбә!
Озакламый,
Җаннарны шөбһәдән әрчеп,
Казанның урыс ягында
Нур таратыр яңа мәчет.

Казанның...
Урыс ягында...
Оксюморон түгелмени? –
Милләтемә тулаемлык
Һәм иманлы гомер телим.

## Мәгариф комиссары Микъдәт Борындыковның Җир эшләре комиссары урынбасары Гариф Енбаевка[10] хаты
***(Казан, 1922 ел)***

*Татарлар урыслардан мәдәнирәк булган, дип кыстыра Солтангалиев, бу сүзләр профессор Баллодның[11] Олуг һәм Кечек Алтын Урдага багышланган соңгы ачышлары белән раслана, имеш, ә совет хакимияте кечкенә милләтләрнең мәдәниятен бөтенләй җимереп ташларга тели.*
ГПУ хезмәткәре рапортыннан

[10] Гариф Мөхәммәтҗан улы Енбаев – 1920 – 1924 елларда Татарстан АССР Җир эшләре халык комиссарының урынбасары һәм, шул ук вакытта, РСФСР Милләтләр эше буенча халык комиссариатының Татарстан АССРдагы вәкиле.

[11] Күренекле галим Франц Владимирович Баллод 1922 елда Алтын Урданың мәркәзләре булган Сарай-Бату һәм Сарай-Бәрәкә шәһәрләрендә археологик тикшеренү эшләре алып бара.

*...Безнең эш, нигездә, ВУЗларны һәм техникумнарны татарлаштыру хакында җәмәгатьчелек фикерен оештырудан... дәүләт ярдәме алып укучы татар шәкертләре санын мөмкин кадәр арттырырга тырышудан һәм, сыйнфый чыгышына игътибар итмичә, татарларны бүтән шәһәрләрдә дә (Мәскәү, Ленинград кебек) укытуны җайга салудан гыйбарәт иде.*

Микъдәт Борындыков «тәүбә»сеннән

*Шуны әйтәсем килә: Енбаев һәм башка иптәшләргә уяулык һәм сизгерлек җитенкерәми. Алар... хәвефнең берсенә, һичшиксез, зуррагына, өстенрәгенә һәм җитдирәгенә – бөекдержавачылыкка – игътибар итә, әмма... үзгә хәвефне – җирле милләтчелекне – күрми...*

Лев Троцкий[12] чыгышыннан

Сәлам!
Саумы?
Хатың өчен рәхмәт.
Хуплап һәрбер сүзен,
Актык тыныш билгесенә кадәр
Мин килешәм үзе.

Өстәрем юк, диеп, нокта куям.
Аннан ясап өтер,
Яңабаштан яза башлыйм сиңа,
Яза башлыйм...
Никтер.

Шулай инде,
Тәкъдиребез – гаярь,
Караш ташлап, аһ ит:
Көч-куәте, малы булган көе –
Тарих үзе шаһит –

Киләчәкне уйлау булмаган ич!
Төшмәсме дип күктән,
Гафил татар нидер көтә-көтә
Бүгенендә беткән...

Безнең идеология –
Дәригъ! –
Гомер бакый – тырма.
Милләтебез әле дә тын гына
Кашын уып тора...

Кабер төзәтәчәк, диләр, ансы,
Без тумабыз кире,
Безгә милли мәктәп озакламый
Затлы алмаш бирер!

Сабый чактан ана сөте белән
Сеңгән гүзәл гамьне,
Кай тегермән тарта һәм кай иләк
Или алган әле?

[12] Лев Давидович Троцкий – 1919 – 1926 елларда РКП(б) Үзәк Комитетының Политбюросы әгъзасы.

Алар – милли умырткалы буын! –
Алар – яңа татар! –
Торган җирдә тораташтай торыр,
Абынмыйча атлар.

Һәм үткәнгә
Кара үпкә белән
Караш атмас ары...
Тарих үзе шаһит: киләчәкне
Бүген кору зарур.

Кимсетмичә
Авыл хуҗалыгын,
Әйтәм кире катып:
Безгә күптән тырма хезмәтеннән
Арынырга вакыт!

Безгә маңгай кирәк булыр әле!
Болай юкка туза.

Сырхаулама, дустым!
Тагын бер кат –
Сәлам!

Дата.
Имза.

## Татар телен гамәлгә кертү комиссиясе утырышы өчен Татарстан АССР Үзәк Башкарма Комитеты рәисе Рәүф Сабировның[13] тезислары
***(Казан, 1922 ел)***

*...Татар теле белән беррәттән урыс теле дә дәүләт теле хокукына ия.*
«Татар телен республика совет оешмаларында делопроизводствога кертү турында»гы декреттан

*Эшебезне шулай даими һәм максатчан төстә дәвам итсәк, бер елдан без барлык вулысларга, кантоннарга һәм Татарстан Республикасының барлык үзәк оешмаларына татар телен урнаштырып бетерә алачакбыз.*
Рәүф Сабиров чыгышыннан

*...Хәзер ачыктан-ачык: «Безгә, урыс аборигеннарына, сезнең (татарларның) урыс шәһәрендә үз телегезне гамәлгә куюыгыз чиктән тыш ошамый»... «артта калган мәдәниятне культивацияләүнең һәм аны ничек тә сакларга тырышуның хаҗәте юк», – диләр.*
Мәскәүгә юлланган «39 җитәкче хаты»ннан

Безне,
Гаепле таныса,
Оныклар ачуланыр:
Бу республиканың теле
Татарча ачылмады.

[13] Рәүф Әхмәтсабир улы Сабиров 1921 – 1924 елларда Татарстан АССР Үзәк Башкарма Комитеты рәисе сыйфатында Татар телен гамәлгә кертү комиссиясен дә җитәкли.

Инде бүген,
Буй үскәндә,
Ныгыган чакта нигез,
Төкерек чәчеп,
Юанабыз:
Икесе дә бертигез!

Сискәнәбез,
Әйткән сүзнең
Кайтавазыннан
Каушап:
Бу тигезлек торган саен
Бер яккарак авыша.

Бугазлап ала шулвакыт
Намусым,
Эшем,
Яшәү:
Сабиров, татар түрәсе,
Әйт, ирешкән бәйсезлегең
Нинди телдә сөйләшә?

Ил-иләтең
Хокук даулап,
Давыллап кузгалганда,
Тел – иман ул!..
Хәер, иман –
Ят сүз безнең заманга.

Безнең заман –
Йодрыкныкы.
Һәм йодрык суллап сугар:
Бәхетле киләчәк өчен
Күпме кан коясы бар...

Күпме
Татыйсы аннары
Җиңүләрнең мазасын! –
Оныкларга җансыз-җүнсез,
Телсез-чукрак дәүләт кенә
Калдырырга язмасын.

## СССР төзелү турында Шартнамә имзаланган көнне Гариф Енбаевның кәгазьгә күчергән халәте
***(Казан, 1922 ел)***

*Безгә... милли мәсьәләнең гаять зур әһәмияткә ия булуын истән чыгарырга ярамый, гадел рәвештә «халыклар төрмәсе» дип аталган илдә – бигрәк тә...*
Владимир Ленин[14] хезмәтеннән

[14] Владимир Ильич Ленин – 1917 – 1924 елларда РСФСР (СССР) Халык Комиссарлары Советы рәисе.

*...Икенче юл... дөресрәк төсле: аерым республикалар Союзга федераль берәмлек составында түгел, ә турыдан-туры керергә тиеш... Безнеңчә, милләтләрне... үз улларыңа һәм үги улларга бүләргә ярамый.*
Мирсәет Солтангалиев чыгышыннан

Мин бу илдән
Бөтенләйгә өмет өздем...
Ишеп-ишеп яуган карга йөзне терәп,
Җан туралган,
Калтыранган килеш,
Яңа елга керәм.

Яңа илдә
Элеккечә һаман:
Бөтерелеп куна күбәләкләр –
Җирен танып...
Һәр гамәле ялган була торып, бүген генә
Нәрсәсенә ышанырга иде аның?

Солых, диде – сугыш ачты.
Икмәк, диде – нәтиҗәсе: ачлык.
Туфрак, диде – өч аршыны насыйп безгә.
Иң күбендә,
Иң күбендә –
Аермачык!

Хәзер менә –
Котлы йортка нигез салдым, диеп,
Күкрәк төйгән чагы –
Тагы!..
Тагы!..

Бактың исә,
Барысы да шул ук:
Чикләр – дивар,
Кара-кучкыл болыт –
Иңгә басып торган түшәм.
Ай нурында бары китек һава аша
Яңа төрле бизәк төшә...

Бәхет
Вәгъдә иткән
Яңа елда, яңа илдә
Кар көртенә баткан килеш торам үксеп –
Нигә?
Нигә?
Мин –
Мәңгелек төксе ил-ананың,
Ачыкланганча,
Мәңгелек
Бер үгисе...

## Татарстан АССРда хөкем сөргән иҗтимагый-сәяси вазгыять турында ГПУ агентының рапорты
***(Казан, 1923 ел)***

*...Төгәл һәм реаль эчтәлеге, билгеләнгән чикләре, нинди дә абруй-мәртәбәсе булмаган... мохтарият. Без бүген азмы-күпме дәрәҗәдә шуңа ирештек.*
Кәшшаф Мохтаров чыгышыннан

*...Читтәге төбәкләрнең яшь буын коммунистлары бәйсезлек уенын уен итеп кенә аңлаудан баш тарта һәм мөстәкыйльлек турындагы сүзләрне үҗәт рәвештә асыл хакыйкать буларак кабул итә...*
Иосиф Сталинның[15] Владимир Ленинга язган хатыннан

Яшерен!

Яшерен
Җиткерер сүзем шул:
Субъектта хәл шомлы, карасаң күз ачып.
Аларның нияте, тәгаен, сөзешү –
Йә маңгай,
Йә Мәскәү дивары тузганчы.

Аларча,
Инкыйлаб онытты бурычын.
Кәгазьдә – тигезлек: юк хадим, юк түрә...
Тик алар үзләрен бу илне коручы
Халыкка тиң күрә.

Аларга
Һәрдаим ясалган ташлама –
Сеңерсез сөяктәй – тоела аз булып.
Тамагы туйган эт хуҗага ташлана!
Тезгенсез ирекнең асылы –
Азгынлык!

Алар чал тарихын өйрәнә башлады.
Баш мие чайкалган тотрыксыз мәннәргә[16]
Нинди уй салырлар,
Ничек ул ашланыр,
Мәгәр дә?..

Мәгәр дә
Игътибар йомшара барган чак,
Отыры аңнарны ят тәгъбир сугарыр:
Кешелек хыялы – безнең ил! – аларча,
Держимордалыкның игезәк сыңары.

Аларча,
Ширпының кодрәтен белмичә,
Дөньяга кизәнү – ахмаклык, саташу.

[15] Иосиф Виссарионович Сталин 1917 – 1923 елларда РСФСР Милләтләр эше буенча халык комиссары, 1922 – 1925 елларда РКП(б) Үзәк Комитетының генераль сәркатибе булып тора.
[16] Мән – кеше.

Һәм шуңа күрә дә үзләре һәмишә
Ут теле үрләгән чабуга –
Шап та шоп!

Хәтердә яңартыр чак җитте, ватаным,
Бабалар укыткан сабакны татарга:
Ырласа, дигәннәр, танавын ват аның,
Бәеннән ычкынса –
Атарга!
Атарга!

Югыйсә
Субъектта
Хәл артык шомлы шул:
Мең танып Мәскәүнең бер карыш чикмәвен,
Аларның нияте – ташка баш орышу! –
Һәм мин белмим кайсы чыдамрак икәнен.

## РКП(б) Үзәк Комитетының милли мәсьәләләргә кагылышлы киңәшмәсендә Кәшшаф Мохтаров ясаган чыгыштан өземтә
***(Мәскәү, 1923 ел)***

*Барлык төрки-татар автономияле республикалары арасында... үзара идеологик бәйләнеш һәм, бердәм төрки-татар федерациясенә оешып, «бәйсезлек»кә омтылу хыялы бар... Иптәш Сәетгалиев җитәкләгән... Кырым Республикасы гына мондый эшләрдән читтә тора.*

Кызыл Армия хәрби академиясе шәкерте
Крымов[17] белдермәсеннән

*Солтангалиев берүзе... куркыныч түгел, нәкъ менә солтангалиевчелек куркыныч.*

Киңәшмәдә Борис Нимвицкий[18] чыгышыннан

*Юлыбыз бер.*

Киңәшмәдә Иосиф Сталин репликасы

Сүз алыймчы.
Һәрбер чыгыш – камчы,
Һәр фикердә – ялкын, хәтәр бар.
Тыңлаганда, чәчләр үрә тора:
Милләтчелек, дисез,
Татарлар...

Фаш итәргә кирәк!
Башбаштаклык
Азып ташлаганчы башаяк! –
Большевистик иманнары, юкса,
«Сөембикә» сыман чалшая.

Бар дөньяны яулап килгән чакта
Хәрәкәтнең иң-иң алкыны,
Юлыбыз бер, дисез,

[17] Мәгълүмат табылмады.
[18] Борис Николаевич Нимвицкий – 1920 – 1923 елларда РКП(б)ның Башкортстан АССР өлкә комитеты сәркатибе.

Юлыбыз хак,
Долой уңга-сулга талпыну!

Сүз алыймчы.
Һәрбер чыгыш – яшен,
Аңгы-миңге уйлап карасаң,
Барысы да шундый дөрес кебек...
Тамырыннан ялгыш лабаса!

«Правый уклон» – нахак!
Шовинистлар,
Муеннарын борып ян-якка,
Күркә сыман кабарынган саен
Алгысынып кую таякка –
Табигый ул!

Һич акланмыйм хәзер.
Ачыклыйк та,
Шуның белән шул:
Милләтчелек була алмый – юк, юк! –
Шовинистлык белән көрәшү.

Күпме гасыр хәрәкәтсез яткан
Дәүләт хисен мүктән кубарып,
Үзебезнең җирдә
Үзебезгә
Үзебезчә яшәү нибары –
Максатыбыз.

Кайда бире гаеп?
Үтте баскыннарга куштан чак!
Артык түгел һәм ким түгел – төгәл –
Барысы да Ильич кушканча.

Без бу илдә хаклы!
Аяк асты –
Болгар,
Олуг Олыс ташлары.
Безнең кан-яшь юдырганга гына
Күк йөзенең аяз акшары...

Инкыйлабның терәвенә кадәр
Татар сөягеннән корылды:
Монда вагон-вагон икмәк килде,
Без ираулап ачтан кырылдык...

Ни ул Казан?
Сезнең күбегезгә –
Җанын чекрәйтеп карасын! –
Картадагы кара нокта гына,
Безгә исә –
Күзнең карасы.

Татар иле –
Савым сыеры да,
Сугым үгезе ул берьюлы! –
Сугымчыга тын алышы аның
Һәрвакытта шомлы тоелыр...

Күп нәрсәгә караш төрле безнең,
Шул сәбәпле суык арабыз...
Ә юлыбыз бер үк:
Барыбыз да
Ахирәткә таба барабыз.

## Тоткын Мирсәет Солтангалиевнең соңгы сәламе
***(Мәскәү, 1940 ел)***

*Бу – Сталин ихтыяры нигезендә беренче тапкыр күренекле партия әгъзасын кулга алу булды. Зиновьев*[19] *белән без, кызганыч ки, аны хупладык. Шунда Сталин, әйтерсең, беренче тапкыр кан тәмен татыды...*
Лев Троцкий хезмәтеннән Лев Каменев[20] хатирәсе

*...Татарстан Республикасының элеккеге хезмәткәрләре Мохтаров Кәшшаф, Енбаев Гариф, Мансуров Гасыйм һәм Сабиров Рәүф... Солтангалиев белән тыгыз элемтәдә торуын дәвам иткән... һәм партиянең милли сәясәтенә каршы көрәшер өчен... актив рәвештә көч туплаган, дип табылды.*
Генрих Ягода[21] һәм Яков Петерс[22] белдермәсеннән

*Солтангалиев һәм башка бандаларга килгәндә, мин сезнең белән килешеп бетмим... Хәзер милли өлкәләрдә һәм республикаларда марксист рухлы кадрлар үсеп җитте, алар буржуаз милләтчеләрне тулаем тар-мар итеп ташларга сәләтле.*
Иосиф Сталинның Лазарь Кагановичка[23]
юллаган хатыннан

Миңа
Кысан иде.
Мескен анам
Шабыр тирдә кара йөзен чытты,
Ыңгырашты, шашты... һәм, ниһаять,
Канга батып,
Мин ireккә чыктым.

Кендек әби
Тәүге богауларны
Ботарлады, иске дәвер үлде,
Бер мизгелдә – җаным, тәнем белән! –
Чиксез инкыйлабка әверелдем.

Офыгымда –
Бөек еллар янды,

[19] Григорий Евсеевич Зиновьев – 1917 – 1926 елларда РКП(б) Үзәк Комитетының Политбюросы әгъзасы.
[20] Лев Борисович Каменев – 1917 – 1925 елларда РКП(б) Үзәк Комитетының Политбюросы әгъзасы.
[21] Генрих Григорьевич Ягода – 1926 – 1934 елларда ОГПУ рәисе урынбасары.
[22] Яков Христофорович Петерс – 1923 – 1929 елларда ОГПУның Шәрык бүлеге башлыгы.
[23] Лазарь Моисеевич Каганович – 1924 – 1925 һәм 1928 – 1939 елларда РКП(б) Үзәк Комитеты сәркатибе.

Барыр юлым, дидем, бары шунда! –
Баскан урынымда туфрак көйде,
Ут дөрләде салкын карашымда.

Андый чакның
Чал Дөньялык өчен
Тиңе дә юк иде, юк сыңары.
Мин яктылык илтәм сезгә, дидем,
Мин җылылык илтәм,
Юксылларым!

Фал ачтылар:
Озакламый түнәр.
Күпмеләргә каза булды бу фал! –
Минем ялкыныма чыдамыйча
Янды Шәрык,
Янды Казан,
Уфа...

Кан кызуы
Бераз сүрелүгә,
Каударлану-ярсу хисем үтеп,
Җилкә аша караш аткан идем:
Кара корым күреп, исем китте...

Пожар тынды.
Исән бураларны
Алты почмак итеп тезә-тезә,
Үз йортымда ут тергезим, дидем...
Хаин, диеп, көл сиптеләр йөзгә.

Үз халкыма чыраг бирим, дидем,
Яшәмәсен туңып, гел күшегеп! –
Милли нәфес дигән яла басты
Тигез хокук өчен
Көрәшүне.

Кем мин бүген?
Гади ристан гына.
Җан асраган җирем –
Менәтерә:
Ана карыныдай караңгылык,
Ана карыныдай кысан төрмә.

Ахырмыни?
Юк, юк, ялгышмагыз! –
Исәнгерәп абайламассыз да:
Гаделсезлек куенында һәрчак
Инкыйлабның яңа кузы кыза...

Бу юлыга...
Озакламый, беләм,
Онытмыйча соңгы эше барын,

Мин кабызган ялкын, төерләнеп,
Муен тамырыма ышыкланыр.

Әмма үлмәм!
Үлем түгел әле –
Фани дөнья белән сүзгә кереп,
Яшәешнең кинәт – бер мизгелдә! –
Капма-каршы якка үзгәрүе.

Үлем юк ул!
Шуны ихлас танып,
Ике дөнья чиген җиңел кичәм.
Кәфенлексез китәм – ак әләмсез!
Ак әләмсез! –
Димәк, җиңелмичә.

## Бетем

*Минем өстәлдә – узган гасырның егерменче елларына кагылышлы документлар, китаплар, газета-журнал кисемтәләре...*

*Алар янына әле генә карандаш сырлаган тезислар өстәлде.*

*Менә, мәсәлән.*

*«Мохтаров» белән «мохтарият» сүзләре – бер үк тамырдан.*

*Эчке мәгънә эзләрлек бит?*

*Партия юлыннан уңга авышканнар да, сулга авышканнар да, ахыр чиктә, туптуры сәяси золым авызына барып керә.*

*Аңарчы, 1927 елда ук, Фатыйх Мөхәммәдьяров*[24] *«телне гамәлгә кертү программасы урыс сүзләрен татар хәрефләре белән күчереп язуга кайтып калды» дип сызлана.*

*Ул вакытта татар хәрефләре була әле...*

*Без бүген Казан читендәге Чыңгыз бистәсен тәрҗемәсез-нисез генә Нагорный дип атыйбыз.*

*Ярый ла Кабан арты мәчетеннән яңгыраган азан тавышы бераз юата.*

*Ишетсәк мәгәр...*

*Мин кече як тәрәзәдәге чагылышымны күзәтәм. Күз турысында – кызыл кояш. Каш урынына каенлык сызылып киткән. Алсу шәүлә йөземне пешерә... Иртәнге шәфәкъмы? Кичкеме? Аңлашылмый.*

*Эчемнән генә берүк таң атсын иде, дип ялварам. Таң – башлам ул. Баеш – бетем. Һичшиксез, бетүеңә караганда башлануың хәерле.*

*Бетүеңдә хәтта фанфаралар озата барса да...*

*Кичерегез, юк урында моңсу булып китте.*

*Үзем аермачык беләм: хәзер анда, каенлыкның теге ягында, сабый бала шулай ук тәрәзәгә сөялгән дә, урман сызыгыннан күзен алмыйча, бу тарафны күзәтә.*

*Аңа күпкә моңсурак.*

*Казан – Татар Толлысы – Казан*
*26 апрель – 12 июнь, 2020 ел*

[24] Фатыйх Гариф улы Мөхәммәдьяров – 1922 – 1927 елларда Татарстан АССР Сәламәтлек саклау халык комиссары. «Кәшшаф Мохтаров хөкүмәте»нең соңгы вәкиле.

*Бу QR-код аша сез авторның үзе укуында аудио һәм видео өзекләрне тыңлый һәм карый аласыз. Моның өчен смарт җайланмаларыгызга (телефонга яки планшетка) QR-код укый торган махсус кушымта йөкләгез. Шуннан соң камераны журналдагы тамгага якынайтырга һәм экранда чыккан сылтама аша үтәргә кирәк.*



Фоат
Садриев

# САЙРАР ЧАК*

РОМАН

**Әйләнә дөнья, әйләнә...**

Бу Ислам бигрәкләр дә тәмле итеп йоклый инде. Көн саен бик нык арый ул. Иртәдән кичкә кадәр шатлык эзләп чаба да чаба. Чаба гынамы сиңа! Туктаусыз уйлый, сөйли, иптәшләрен кузгата, ияртә, бөтенесен ниндидер шөгыльгә туплый. Әнә челтәрле шкатулкасында биш камка йөри. Аларны минем өчен әзерли ул. Никме? Үзеннән сорарга кирәк. Аңа бу кызык. Ул бит җорланудан, шаярудан, көлүдән һич тә туя белми. Аның өстендә яткан мәчесе минем нурларымның җылысына күзләрен ачмакчы булды да кабат йомды. Әнә теге Уссури юлбарысы төсле. Ул да керфекләре арасыннан гына үзенең әле бер ай гына элек туган балаларының уйнаганын горурланып күзәтә. Башта аларның имгәннәренә изрәп ятты. Өч баласы хәзер бергәләшеп тәгәрәшә, куыша, тырмаша, шаяра, тешләгән булып кылана. Исламны мәчесе белән бергә күтәреп алып килеп, шуларны күрсәтергә иде. Уйнасыннар иде бөтенесе рәхәтләнеп. Юлбарыс балалары, әнә, бергә укмашып тәгәрәшә башладылар. Уятыйм әле малайны. Борын тишегенә берике кайнаррак нур гына җибәрәм. Әһә, сипкелле борын очы астан вулкан эткән җир кабыгы шикелле селкенеп-селкенеп алды. Ике табаны юрган кырыеннан күренеп тора, аларны да кытыкларга иде дә, булмый шул. Агач кайрысыдай каты бу табаннарны минем нурларым гына түгел, пыяла, чыра ише очлы нәрсәләр дә тишеп керә торган түгел. Бер аягын юрган эченә тартып алды, борын яфраклары киерелде, җыерылды да борын тишекләреннән бөке аткандай шартлау яңгырады:

– Һә-ә-әп-те-е-ччи-и!

Исламның өстендә яткан мәче койрыгын торгызып, мыекларын тырпайтып идәнгә сикерде. Исламның авыз-борыныннан икенче «Һәптеччи» дә чыгып очты...

Ә тегендә көрәш мәйданы юлбарысның өстенә күчкән иде. Бер баласы әнисенең колагын чәйни, икенчесе борынын, күзләрен тырный, өченчесе койрык

* «Тургай» китабының ахыры. Журнал варианты

Фоат САДРИЕВ (1941) – *прозаик, драматург; Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. «Таң җиле», «Бәхетсезләр бәхете» романнары, «Шаһзаманов эше» һ.б. повестьлар авторы. Мөслимдә яши.*

очын тешләп тарткалый. И гөнаһсыз сабыйларым! Ничек матур, йомшак сезнең буй-буй йоннарыгыз! Исламнан да, аның мәчесеннән дә ерак шул бу дөнья.

Менә Ислам болдырга килеп чыкты. Шкатулкасын ачып, болдыр култыксасына куюга, камкалар берәм-берәм үрмәләп чыга, оча башлады. Ул, кулларын югары күтәреп, һәр көндәгечә миңа дәште:

– Исән-саумы, кояшкаем! Сине ничек сагынганымны белсәң иде!

Ислам көнгерә төсле сикергәләп куйды. Ул минем барлык нурларымны җыярга теләгәндәй, ике кулын ерактан ук кара-каршы китереп, үзенең күкрәген коча да күзләрен кысып көлеп җибәрә.

– Бүгенге көнең матур үтсен, улым!

Ә хәзер игътибарымны океандай кайнаучы сары халыклар иленә юнәлтим әле...

– Улым, казларны инешкә илтеп кайтасыңмы?

Әнисе кай арада чыккан, кай арада аның иңбашларына йомшак кулларын салып өлгергән диген! Ислам әнисенең бит очыннан үбеп алгач, казларга «ка-ка-ка» дип бер генә дәште. Тегеләр бердәм каңгылдашып җавап бирделәр, Ислам капканы ачуга, аның белән сөйләшә-сөйләшә инешкә төшә торган тыкрыкка ашыктылар. Шушы минуттан ул җәйнең бер көнен гомер буе искә алырлык кызыклы вакыйгалар белән бизәү өчен эшкә тотыначак. Бүген алар Ыкка балык каптырырга барырга сөйләшкән иде. Ишегалдындагы тавык-чебешләрне, Акбайны, абзардагы бозауны карагач, әнисе пешергән гөбәдия белән чәй эчеп, аңа өстәп бер йомырка да ашаганнан соң, ул кармакларын алырга ишегалдына чыкты. Шул арада шау-гөр килеп колга токкан Фаил, Рөстәм, Риф, Мансур шау-гөр килеп керде.

– Суалчаннар булды, – диде Риф. – Мансурның әтисе шәһәрдән алып кайткан әзер җим дә бар. Шул җимне тотып яр буена килүгә, балык өере белән җыела, ди!

– Велосипед беләнме, җәяүме? – дип сорады Ислам.

– Велосипед белән. Мин скутерда, – диде Фаил.

***

Ул су буеннан әллә ничек икенче кеше булып кайтты кебек. Бакчада бәрәңге сабакларын җыеп йөргәндә дә, Акбай белән уйнаганда да ул үзен акыллырак, бер башка үскәнрәк итеп тойды. Бу тойгы шундый рәхәт иде, ул аның күңелендә искиткеч җылы нәрсә булып аерым урын алды. Кичен бар дөнья шәфәкъ нурларына күмелеп барган мәлдә нишләптер тагын Галимҗан абыйсы янына кереп чыгасы итте. Ислам иң элек абзарга Чаптар янына килде. Ат аны күрү белән койма өстеннән башын сузды. Ислам кесәсеннән алып, аңа бер прәннек каптырды. Ул арада кычкырып ак кәҗәнең дә шул турга килгәне күренде. Ислам аның алдына кәбестә яфрагы куйды. Аннары өйгә кереп китте. Кече якка үтеп, сәлам бирде. Әмма сәламне алучы булмады. Түр як ишек ярым ачык һәм аннан көлгән тавышлар ишетелә иде. Ислам ишек ярыгыннан эчкә карады һәм гаҗәеп күренешкә тап булды. Галимҗан абыйсы белән Нәбирә апасы идәнгә тезләнгәннәр, урталарында бер атна элек кенә бәрәнләгән ак кәҗә бәтие басып тора. Галимҗан абыйсы кәҗә бәтиенең әле маңгаеннан, әле ике яңагыннан үбә, Нәбирә апа акрын гына сыртыннан сыпыра. Алар икесе дә көлешәләр. Галимҗан абыйсы әллә нинди ягымлы, җылы тавыш белән:

– И матуркаччаем! – ди.

– Галимҗан, менә бит, ничек йомшак аның йоннары! – дип, соклануын белдерә Нәбирә апа.

Галимҗан абыйсы аңа каршы пышылдауга охшаган ишетелер-ишетелмәс тавыш белән:

– Күзләренең акыллылыгын кара әле! – ди. – Адәм акыллары бардыр монда.

Аларның сүзен аңлагандай, кәҗә бәтие туктаусыз өскә күтәрелгән кыска койрыгын селкетә. Аның селкеткән койрыгына әле Галимҗан абыйсы, әле Нәбирә апа учларын куеп торалар һәм бер-берсенә карап куанышалар.

– Син аны кич имезгән идеңме соң әле? – дип сорады Галимҗан абыйсы.

– Аның нәрсәсен имезәсең инде? Ул бит гел әнисе янында, – диде Нәбирә апа.

Галимҗан абыйсы бәрәннең башын тотты да аның колагына:

– Чинең тамагың тукмы чоң? – диде.

Кәҗә бәтие аның сүзләрен аңлагандай, нечкә генә итеп кычкырып куйды.

– Кая, мин дә карыйм әле күзләренә, – диде Нәбирә апа. – Хәзер аркасын син сыпыр.

– Гел шулай инде син. Мине гел аның белән сөйләштермисең, – диде Галимҗан абыйсы, чынлап ачуланган кебек итеп. – Син бит көн саен аның янында. Ә мин көне буена аны сагынып кайтам. Шулаймы, матуркаччаем? – дип, тагын бәрәннең колагына эндәште.

Алар урыннарын алышып, бәрәнне иркәләүләрен дәвам иттеләр. Ислам керергә дә, кермәскә дә белмәде. Аның нишләптер тыны кысылды, күзләре, тамак төпләре әчеткән кебек булды. Галимҗан абыйсын ул дөньяда иң көчле кеше дип йөри иде. Әгәр теләсә, ул үзе бөтен дөньяны буйсындыра да, кызгана да ала, дип уйлый иде. Менә ул хәзер аның нишләптер көчле түгел икәнен күрде. Әфганстанда дошманнар белән көрәшкән Галимҗан абыйсы кәҗә бәтие белән уйнарга тиеш түгел кебек тоелды Исламга. Ә уйнаса, ни булган? Берни дә булмаган, тик ул олы кеше. Кәҗә белән дә, башка маллар белән дә Ислам уйный, Исламга ярый. Нигә олы кешеләргә кәҗә бәтие белән уйнарга ярамый? Андый закон юк бит. Кинәт аның эченнән ниндидер кайнар нәрсә күтәрелде дә, ул тавышсыз гына үкси башлады. Галимҗан абыйсы белән Нәбирә апа кәҗә бәтиенең берсе муеныннан, икенчесе биленнән кочаклап, аңа әллә нинди җылы сүзләр әйтәләр иде. Ислам өйдән чыгып йөгерде, күңелен әллә нинди авыр сагыш биләде. Йөгереп, тыкрыктан инешкә төшеп китте. Инеш белән күктән алып, агачларның соңгы яфрагына кадәр алсу шәфәкъ нурына манчылган иде. Күңеленә дә әллә шушы алсу шәфәкъ, әллә башка сагыш тулып, ул кайнар күз яшьләренә тулы ирек бирде һәм җиргә капланып еларга кереште. Ул ник елаганын да аңламады. Ул тынычланырга теләп, күз яшьләрен сөртте. Әмма эчтәге теге кайнар нәрсә күтәрелеп түгелде дә аны тагын үксетеп җибәрде. Шул чакта Исламның күңелендә Галимҗан абыйсын юату теләге уянды. Бу теләктән ул сискәнеп китте. Ничек инде ул аны юата алсын? Ник юатырга? Шундый көчле кеше юатуга мохтаҗмыни? Ислам иңбашларына коточкыч авыр йөк салган кешедәй, аякларын көч-хәл белән сөйрәп, тыкрыктан өйләренә таба атлады... Урамга чыккач, Галимҗан абыйларының өенә борылып карады. Аларның тәрәзәләре кичке шәфәкътән кып-кызыл булып яна иде. Карамаса, әйбәтрәк буласы булган. Шул янган тәрәзәләрне күргәч, аның күзләренә тагын яшь бәреп чыкты, Ислам ул якка карамаска тырышып, үзләренең өенә атлады...

## Аңлашу

Энҗенең Исламга эндәшмәве тора-бара аның сыйныфташлары арасында ничектер берүзе бертөсле булып аерылуына китерде. Ул иптәш кызларына да төртмә сүзләр әйтте, сорасалар, юньләп җавап бирмәде. Укытучыга биргән җаваплары да тулы булмады. Энҗенең йөзе аксыл төскә керде, сөйләшкәндә,

иреннәре калтырый иде. Ул Исламның уеннан гел китмәде. Ни булды, нишләп үзгәрде ул, моның сәбәпләре нәрсәдә, дигән сораулар аны гел борчып торды. Бүген Ислам бакчада Илдар Каюмович кушкан рәсемне ясап бетерде. Агач башындагы ак фил чыннан да бик матур чыккан иде. Шуны карап торганда, капкадан Энҗе килеп керде. Аны күрүгә, Исламның бөтен тәненә җылылык йөгерде. Энҗе алсу курткасын кигән, башында да алсу башлык иде. Ислам рәсемен беседкага куеп, аның каршына йөгерде. Аларның күзләре очрашты. Энҗе кыенсынып кына елмая, иреннәре җиңелчә генә калтырый, дулкынланганы бөтен йөзенә чыккан. Алар бер-берсенә дәшә алмыйча шактый вакыт карап тордылар.

– Энҗе, – дип пышылдады Ислам.

– Нәрсә?

– Үлә яздым бит инде мин.

Ислам шуннан соң сүзен дәвам итә алмады. Энҗенең битенә кызыллык йөгерде, иреннәре бер ачылды, бер ябылды, ахырда бер генә сүз әйтте:

– Нишләп?

– Синең миңа Ислам дип эндәшүеңне көтеп үлә яздым.

Энҗенең күзләре яшьләнде.

– Менә бит хәзер дәшәм: Ислам... Ислам...

Энҗе шунда туктап калды.

– Рәхмәт, – диде Ислам. – Мин сине шундый сагындым, Энҗе.

– Көн саен мәктәптә күрдең бит.

– Мин күрдем, син күрергә теләмәдең.

– Юк, Ислам, – диде Энҗе уйчан тавыш белән. – Мин сине элеккедән дә ныграк күрдем. Мин үзем өчен нуль идем.

Энҗенең карашы җылынганнан-җылына барды, ләкин әле элеккечә туктаусыз шатланып сикергәләүче күз алмалары ничектер бик акрын кыймылдады. Бу аның күңеленә ниндидер авыр нәрсә кереп оялаганлыгы турында сөйли иде.

– Әйдә, өйгә керәбез, – диде Ислам, аның кулыннан җитәкләп.

Энҗенең боз кебек салкын кулы калтыранып куйды.

– Син бит туңгансың, – диде Ислам, аның кулын ике кулы белән кысып.

– Ә синең кулларың шундый кайнар...

– Алар да салкын иде, – диде Ислам акрын гына. – Сине күргәч, кайнарландылар.

Аның бу сүзләреннән Энҗе сәер итеп елмаеп куйды.

– Әйдә, кереп чәй эчәбез, җылынырсың.

– Юк, Ислам, мин чәй эчәргә килмәдем, – диде Энҗе бик җитди кыяфәт белән. – Безгә хәзер бер җиргә барырга кирәк.

– Әллә район үзәгенәме? – дип сорады Ислам.

– Район үзәгенә бару җиңелрәк ул, – дип куйды Энҗе. – Бу бик авыр...

– Аңлатып сөйлә әле.

– Диләрә Ахуновнага барырга кирәк.

Ислам сискәнеп китте. Бу бөтенләй уйланмаган, көтелмәгән нәрсә иде. Шуңа күрә ул аптырап сорап куйды:

– Аңа нәрсәгә?

– Нәрсәгә икәнен син бик яхшы беләсең. – Энҗе башын читкә борып, каядыр тау ягына таба карап торды. – Безгә икәү барып, барысын да сөйләп бирергә кирәк.

Ислам ни әйтергә белмичә аптырап калды. Әллә кайчан булган бу әйберне нигә кузгатырга, дип уйлады.

– Кирәкме соң ул? – дип куйды Ислам.

Энҗе кинәт аның ике иңбашыннан куллары белән тотып алды, кайнар сулышын тоярлык дәрәҗәдә йөзен Исламның йөзенә якын китерде:

– Син мине хайван дип уйлагансыңдыр. Мин бит шул вакыттан бирле авырыйм, өзгәләнәм, тыштан гына тыныч булып күренергә тырышам. Шушыны барып сөйләмәсәм, миңа нидер булачак. Ул әйбер чир булып минем эчемә урнашты. Укыган дәресем башыма керми, әйтәсе уйларым башымнан очып чыга, аяк-кулларым мине тыңламый. Син аңлыйсыңмы мине, Ислам?!

Исламның аның бу сүзләреннән йөзе генә түгел, ул тоткан ике иңбашы да уттай кызышты. Бу элекке Энҗе түгел иде. Димәк, ул кар астындагы кайнар чишмә кебек берүзе кайнаган да кайнаган. Ислам аның янәшәсендә булып та берни сизмәгән.

– Авыр булгандыр сиңа, Энҗе. – Ул аны тынычландырырдай сүзләр эзләде. – Нишләп ичмасам миңа әйтмәдең?

– Әйтә алмадым, – диде Энҗе, авыр сулап. – Мең мәртәбә әйтергә тырыштым, ә әйтә алмадым!..

– Инде шулай уйлагансың икән, бар син аның янына.

– Ә син? – дип кычкырып җибәрде Энҗе.

– Минем дә бару кирәкмени?

– Икебез пешергән ботка бит, – диде Энҗе, ничектер бераз тынычланып. – Берүзем барырга куркам.

– Кыйнар дип уйламыйсыңдыр бит? – Ислам шаяртты, әмма үзенең бу сүзләрен ошатмады.

– Кыйнаса, әйбәтрәк булыр иде. Шундук котылыр идем. Ул кыйнамаячак.

– Нишләтәчәк соң?

Энҗе йодрыгын кысып. Исламга таба сузды да болай диде:

– Йөрәкне менә шушылай итеп кысачак.

– Барыйк алайса, – диде Ислам.

Бер-бер артлы капкадан чыктылар да Диләрә Ахуновналар ягына атладылар. Аларга якынайган саен, икесенең дә күңеле тынычлыгын югалта барды.

Алар кибет янына килеп җиттеләр.

– Бәлкем безгә берәр күчтәнәч алыргадыр? – диде Энҗе, адымнарын акрынайтып.

– Аны кимсетү булыр ул.

– Әйе шул.

Алар Диләрә Ахуновналарның капкасын курка-курка гына ачып кергәч, ишегалдындагы чисталыкка, тәртипкә хәйран калдылар. Бер генә урында да артык әйбер юк, барысы да кирәккә куелган иде. Ап-ак итеп юып алынган болдыр баскычына килеп җиткәч, патша сарае алдында туктап калган чит ил илчеләре кебек, кыюсыз басып калдылар. Аяк киемнәрен салып, өйалдына үттеләр һәм ишек шакыдылар. Ачучы булмагач, кыюсыз гына ишекне тартып, өй эченә атладылар. Диләрә Ахуновна зал ягында телефоннан сөйләшеп утыра икән. Ул Ислам белән Энҗене күргәч, үтегез дигән мәгънәдә кулы белән ишарәләде. Өйдәге пөхтәлеккә дә сокланмый мөмкин түгел иде. Алар тупсаны атлап, залга үттеләр дә ишек турында туктап калдылар. Буялмаган бу сап-сары нарат идәннәргә басуы да кыен иде. Ниһаять, алар Диләрә Ахуновнаның сөйләшүенә дә игътибар итәрлек хәлгә килделәр.

– Син нәрсә әйткәнеңне аңлыйсыңмы соң? – диде Диләрә Ахуновна трубкага кырыс тавыш белән. – Әллә кичәгесенә тагын өстәдеңме? – Бүген эшләмичә булмый. Сәгать икедән дә калмыйча кайтып җит.

Ул трубкасын куйгач, куллары белән ике чигәсен ышкып алды да торып басты.

– Әллә берәр нәрсә булдымы? – дип сорады ул борчулы тавыш белән.

– Булмады, – диде Ислам, башын аска иеп.

– Без килгән идек, – дип өстәде Энҗе, шулай ук директор урынбасарының йөзенә карарга базмыйча.

– Килгәч узыгыз, – Диләрә Ахуновна аларга урын күрсәтте.

– Без узып тормабыз... – Ислам сүзне нәрсәдән башларга белмичә тынып калды.

Шул арада Энҗе дә телгә килде:

– Без озакка түгел...

– Йә, мин әзер сезне тыңларга, – диде урынбасар, аларга якын ук килеп.

Ислам белән Энҗе ялт-йолт бер-берсенә карашып алдылар. Кемдер ничектер сүз башларга тиеш иде. Әмма аларның башларында каушаудан барысы да буталган, хәлне ничегрәк итеп аңлатырга икәнлеге уйланылмаган иде.

– Без рәсем буенча килдек, – диде Ислам акрын гына.

Алар һаман Диләрә Ахуновнага күзләрен күтәреп карый алмадылар.

– Әйе, рәсем буенча, – дип өстәде Энҗе дә.

– Нинди рәсем?

Ниһаять, икесе дә Диләрә Ахуновнаның аптырау билгеләре чыккан йөзенә күтәрелеп карадылар һәм шундук карашларын түбән төшерделәр.

– Стенага ясаган рәсем, – дип, Ислам башын читкә борды. – Теге мин ясаган рәсем.

– Юк, мин ясаган рәсем, – дип аны төзәтте Энҗе.

Урынбасарның кашлары югары күтәрелде, маңгаенда тирән җыерчыклар барлыкка килде, күзләренә ачу билгесе чыкты.

– Сез минем белән шаярырга килдегезме әллә?

– Туктале, Энҗе, үзем аңлатам, – диде Ислам.

Энҗе ярсулы нечкә тавыш белән:

– Юк, үзем! – дип Исламны читкә кугандай, ике кулын селтәп куйды. – Ул рәсемне... ул рәсемне... ясаучы... мин ясадым... ясаган идем!..

Соңгы сүзләрен әйткәндә, Энҗенең күзләрендә яшь күренде, иреннәре калтыранды, ул кулларын кая куярга белмәде. Аларның әйткәне Диләрә Ахуновнаның зиһенենә һаман барып җитә алмый иде. Ул әле Исламга, әле Энҗегә аптыраулы караш ташлады, берни дә аңламаганын белдереп, башын чайкады, йөзендә, ачык кына итеп әйтә аласызмы, юкмы, дигән сорау ярылып ята иде.

– Диләрә Ахуновна... – Энҗе сүз башлады да тагын туктап калды. – Рәсемне мин ясадым... Ә Ислам нишләптер гаепне үз өстенә алды.

Урынбасар Исламның күзләренә туп-туры карар өчен каршысына килеп чүгәләде:

– Дөрес әйтәме ул?

– Әйе...

Исламның тавышы бөтенләй диярлек ишетелмәде. Диләрә Ахуновна торып басты һәм үз-үзе белән сөйләшкәндәй:

– Менә ничек?! – дип куйды. – Сезгә мондый хәлләргә төшү нигә кирәк булды соң?

Ислам моңа үзе башлап, үзе җавап бирергә тиеш икәнен ачык аңлады, тик тиешле сүзләр таба алмады:

– Мин бит... минем... тизрәк кайтып китәсем килде.

– Тизрәк кайтып китәсең килде?!

– Юк, юк, мин ялгыш әйттем. Аларның тизрәк кайтып китүен теләдем.

– Ник? – диде Диләрә Ахуновна.

– Белмим... Интекмәсеннәр дип бугай.

– Һәм син шушыны яшереп йөри алдыңмы?

– Йөрдем... йөрдем бит... мин әшәке, әйеме, Диләрә Ахуновна?

Директор урынбасары бу сорауга җавап бирмәде. Аның үзенең башында хәзер мең төрле сорау бөтерелә иде. Һәм ул аларның кайсыннан башларга белмәде. Аныңча, Энҗе бу эшне һич тә эшли алмый, моның сәбәпләре юк иде. Ләкин хәлне ачыклап бетермичә калдыру аның үзенә дә, балалар өчен дә мөмкин түгел иде. Шуңа күрә ул сорау бирмәде, барысын да аларның үз ихтыярына куйды:

– Әйдә, сөйләгез, аңлатып сөйләгез...

– Сез мин ясаганга ышанмыйсыз бугай, – диде Энҗе, Диләрә Ахуновнага туп-туры карап.

– Ә ышансам? Ник ясадың, дип сорасам?

– Мин шуны сөйләргә дип килдем. – Энҗенең күзләрен тагын яшь каплады, ләкин ул сүзен дәвам итәрлек көч тапты: – Мин сезне күралмый идем. Шуңа күрә сезгә охшатып ясадым.

Аның туктап торуыннан файдаланып, Диләрә Ахуновна сорап куйды:

– Мине нишләп күралмадың соң, бала?

Энҗенең тавышы беткән иде, ул ярым пышылдауга күчте:

– Минем апам әллә ничә мәртәбә аерылып кайтты, энегез кыйнап, түзәрлеге беткәч...

– Монда минем ни гаебем бар? – диде Диләрә Ахуновна кырыс кына.

– Апам сөйләде, сез килгән саен, җизни аны канга батырып кыйный, аны сез котыртасыз, диде. Сез китү белән әллә нинди булмаган гөнаһларымны, кимчелекләремне табып бәйләнә башлый, аннары кул күтәрергә керешә, диде. Мин сездән үч алырга теләдем...

– Канәгатьләндеңме соң? – диде урынбасар, өстәлдәге әйберләрне бер урыннан икенче урынга шап-шоп алып куеп.

Энҗе елап җибәрде:

– Зинһар кичерегез мине, Диләрә Ахуновна. Кичерәсезме?

Диләрә Ахуновнаның нәкъ мәктәптәгечә тимер тавышы аны бүлдерде:

– Син минем сорауга җавап бирмәдең. Кабатлап әйтәм: тынычландыңмы соң?

– Юк, юк, юк!!! – диде Энҗе, тәмам ярсып. – Мин ялгышканмын. Мин сезнең йокыгызны качырыйм дип ясадым ул рәсемне, ә үземнең йокым качты. Сезне күргән саен йөрәгем кысылып, тибүдән туктагандай булды. Мин шулкадәр гаепле, зинһар гафу итегез. Итәсезме?! – ул яшьле күзләре белән тилмереп Диләрә Ахуновнага төбәлде.

– Гафу итәм, Яруллина. Гафу итәм! – диде Диләрә Ахуновна. – Анысы өчен борчылма. Тик бер нәрсәне аңламыйм: нишләп моны шул вакытта ук әйтмәдең?

– Мин буталдым, – диде Энҗе, елаудан коры үксүгә күчеп. – Барысын да ул бутады...

– Кем?

– Ислам... Әгәр ул үз өстенә алмаган булса... Сезне интектереп тәм тапмакчы

булдым... үзем чиргә сабыштым... Шул кадәр ялгыштым... Үкенү мине кимереп бетерә язды...

– Борчуларыңны оныт, Яруллина. Соң булса да уң булсын, ди бит безнең татар. Килергә көчегез җиткән бит.

– Ә мине? – дип куйды Ислам кинәт.

– Нәрсә сине?

– Мине гафу итә аласызмы, Диләрә Ахуновна?

Урынбасарның җитди чыраена мөлаем яктылык җәелде. Ул көлеп куйгандай итте:

– Мин ни әйтергә дә белмим инде, Нуруллин. Сине мактаргамы, гафу итәргәме, әллә җәзага тартыргамы? Үзең ничек уйлыйсың?

Ислам аптырап калды. Әлбәттә, ул күңеле белән Диләрә Ахуновнаның аларның икесен дә кичергәнен аңлады. Шулай да тәҗрибәле укытучының кистереп үз сүзен әйтүен ишетәсе килгән иде.

– Миңа мактау кирәкми, – диде ул. – Гафу итсәгез, шул җитә. Җәзага тартудан да курыкмыйм. Миңа тиештер дә ул. Арттырып җибәрүләрем күп булды.

– Җавабың егетләрчә, – диде Диләрә Ахуновна көлеп. – Өмет бар синдә, Нуруллин.

Исламның күзләрендә шаян очкыннар кабынды. Башын ярым кыегайтып, астан директор урынбасарына хәйләкәр караш ташлады да:

– Өметсез шайтан гына! – дип куйды.

– Инде, балалар, шушындый зур эш белән килгәнсез икән, бер утырып чәй эчми ярамас.

– Юк, юк! – дип, Ислам белән Энҗе икесе дә ишеккә таба атладылар.

– Нуруллин! Яруллина! Өстәл янына килеп утырыгыз! – диде Диләрә Ахуновна теге тимер тавышы белән.

Бу тавыштан аның чынлап әйтәме, әллә шаяртамы икәнлеген аңларлык түгел, әмма аңа буйсынмый булмый иде. Алар икесе дә өстәл янына килеп утырдылар. Диләрә Ахуновна чәй әзерләргә кереште, духовкадан кайнар бәлешен алып, өстәл уртасына утыртты, бөтен өйгә аның тәмле исе таралды. Күз иярмәс тизлек белән ул аның өстен ачты, өч тәлинкәгә салып, бәлешне алларына куйды. Ислам белән Энҗегә бу сәхнәдән күрсәтелгән фокус кебек тоелды. Диләрә Ахуновнаның хәрәкәтләнгәне дә күренмәде, ул шул бер урында басып торган кебек тоелды, әмма табын тозлы кыяр, тозлы кәбестә, помидор белән тулды. Энҗе белән Ислам, Диләрә Ахуновнаның туктаусыз кыставына карамастан, кып-кызыл булып, кашык-чәнечкеләренә үрелергә кыймыйча утыра бирделәр. Ул ашау коралларын икесенең дә кулына мәҗбүри тоттырды. Бәлеш искиткеч тәмле иде, аны бер кабуга оялуларын оныттылар, һәм кашыклары бәлеш белән авыз арасында бик тиз урап йөри башлады.

– Ә шулай да сине, Яруллина, апаң ялгыш юлга керткән, – диде Диләрә Ахуновна тыныч кына.

– Әйе шул, – диде Энҗе. – Соңыннан гына белдек. Сезнең бернинди гаебегез булмаган. Апа белән җизни аңлашкач, алар моны безгә кайтып җентекләп сөйләп бирделәр. Гафу үтенергә батырчылыгым җитмәгәч, усаллыгыгыз өчен үч алу булсын, дип акландым.

Ислам аңа астан гына төртеп куйды. Бу төртү, кем бәлешен ашаганыңны оныттың бугай, дигәнне аңлата иде. Энҗе аңа борылып карады да шып туктады.

– Төртмә, Нуруллин, Яруллинага, – диде Диләрә Ахуновна. – Мин барысын да күрәм бит. Турысын әйтүеңә рәхмәт, Энҗе үскәнем. Менә хәзер мин дә,

шушы кайнар бәлешне ачкан сыман, үземнең күңелемне ачыйм әле сезгә. Бәлкем, аның минем өчен кирәге дә юктыр, усал исемне күтәреп, гомер узган да киткән. Аның кирәге сезнең өчен. Әле сезнең барысы да алда. Мин үземә дә, башкаларга да иң югары таләпләр куйдым һәм куячакмын. Моны мәктәптә генә түгел, авылда да аңлаган кешеләр сирәк. Ә менә еллар үткәч, кайберләре авылдан чыгып китеп, инде картаеп кайткач, миңа рәхмәт сүзләре әйткәннәре булды. Кешене харап итә торган ике нәрсә бар: беренчесе – аны туктаусыз гафу итү, икенчесе – аны туктаусыз мактау, күкләргә чөю. Икесендә дә кеше үзенең кем икәнен оныта. Аеруча бала вакытта сез дөньяны гел матур яклары белән генә күрәсез. Сез дәрестә динозаврлар турында үттегез. Адәм баласын мактаган саен ул динозаврга әйләнә, әз генә тәнкыйть сүзе әйтүчеләрне буып ташлый, таптый. Аның күз алдында үзенең зурайтылган сурәте генә йөри. Мисалларны үзегез күзәтегез. Сак булыгыз, ул малайлар, кызлар сезнең янычызда да бар. Менә мин сезгә әйтәм, беркайчан да мактау көтмәгез. Тиеш булса да, көтмәгез. Дин буенча да Мөхәммәт пәйгамбәр мактаучының йөзенә туфрак сибәргә кушкан. Нишләп шулай икәнен дини кешеләрдән сорап карагыз.

Алар бик озаклап әңгәмә корып утырдылар. Ислам белән Энҗе чыгып киткәч, Диләрә Ахуновна өстәл янында таш сын кебек хәрәкәтсез утырды. Табында һәммә нәрсә бар, ул япа-ялгыз. Бу балалар чыгып киткәч, ялгызлык сагышы бөтен барлыгын көйдереп алды.

Диләрә Мөхтәрне сайлап, бик нык ялгышты. Ул баш күтәрмичә эчә торган кеше булып чыкты. Ире белән икесе арасында бернинди уртаклык юклыгын аңлаганда, соң иде инде. Баштарак каты кулым белән төзәтермен, кеше итәрмен, дигән өметләре пыскып сүнде. Каты кул да, үгетләүләр дә, күз яшьләре дә төзәтми икән. Ә Диләрәнең күз яшьләре тозлы диңгез булып акты. Ул диңгезнең давыллары да, бөтерелеп килгән дулкыннары да Мөхтәргә бернинди йогынты ясамады. Эчүен ташлаучылар турында ишетсә дә, күрәсең, аның ире андыйлар рәтенә керми иде. Директор урынбасары буларак та, ялгыз ул. Илдар Каюмович ни аның кичерешләрен, ни уйларын аңламый. Директор үзе дә япа-ялгыз, өйләнү турында да уйламый, хатын-кызларга да мәхәббәткә сусаган затлар итеп карый аламы икән ул – бусы да караңгы. Ике ялгыз ничә еллар янәшә эшлиләр, директорга урынбасар кирәк, урынбасарга директор кирәк, икесе бер-берсеннән аерылгысыз һәм ике ялгыз... Бик тә, бик тә сәер бу дөнья... һәм гаделсез.

***

– Әйдә, безгә керәбез, – диде Ислам, үзләре турына җиткәч.

– Кермим.

– Алайса Ык буена төшик.

Аны шаккатырып, шулчак Энҗе болай диде:

– Минем бүген рәсем ясый торган көнем...

– Вәт әйттең син! Нинди була соң ул?

– Белмим, шундый көннәрем бар минем. Рәсем ясамыйча түзә алмыйм. Өч зур альбомны тутырдым инде.

– Анда нәрсә ясап бетердең? – диде Ислам, гаҗәпләнеп.

– Укытучыларны, укучыларны, авыл кешеләрен...

– Мине дә ясадыңмы соң?

– Ясамыйча!

– Күрсәт әле!

– Юк, мин аларны беркемгә дә күрсәтмим.

– Миңа дамы?

– Ачуланма, Ислам, сиңа да күрсәтә алмыйм. Ул альбомнарда минем иң кадерле серләрем. Нух тавын да ясадым.

– Нух тавына мендеңмени?

– Син ясаган Нухка охшатырга тырыштым.

Ислам бераз уйланып торгач:

– Бер әйбер әйтер идем, ышанмассың, – дип куйды.

– Син әйткәннәрнең мин барысына да ышанам.

Ислам көлеп җибәрде:

– Кәҗә белән үгез сугышына дамы?

– Әйе, син сөйләгәч, дөрес инде ул. Нәрсәдер әйтәм, дигән идең.

– Мин Нух тавына мендем.

– Китчәле! – диде Энҗе, элеккечә чыркылдап. – Ниләр бар соң анда?

– Челтерәп чишмә агып ята, чишмә янында ташка әйләнгән егет басып тора. Нух маңгаендагы тишектән озын елан чыгып, җиргә ята. Ул Нухны саклый.

– Мине дә алып мен әле.

– Алып менәрмен.

– Алдамыйсыңмы?

– Алдамыйм.

– Менә хәзер тереләчәгемә ышандым мин, Ислам.

– Ышан, Яруллина, – диде Ислам көлеп. – Тик рәсемнәреңне аерым кешеләргә генә багышлама.

– Ә кемгә багышлыйм соң? – диде Энҗе, каш астыннан гына елмаеп.

– Дөньяга дәшәргә кирәк, Яруллина. Дөньяга дәшсәң, биеккә күтәрелерсең.

– Ай-яй-яй-яй!!! – диде Энҗе. – Каян алып әйтәсең син бу сүзләрне?

– Битеңне иркәләгән җилләрне сизәсеңме? – диде Ислам, аның бит очына сак кына кулы белән кагылып. – Шул җилләрне тыңласаң, алар әллә ниләр алып килә.

– Синең миңа ни өчен аерым кешеләрне ясамаска кушуыңны аңладым! – диде Энҗе, кулларын чәбәкләп.

– Әйт, ни өчен?

– Син бит үзең аерым кешеләргә карикатуралар ясыйсың! Нигә шуларның берсен дә безгә күрсәтмисең?

– Мин бит аларны концерт вакытында күрсәтәм, – диде Ислам. – Алдан күрсәтсәм, кызык булыр идеме соң?

Энҗе аның белән килеште:

– Әйе шул, син бит әле ул карикатураларың белән район смотрларында да чыгыш ясыйсың.

– Димәк, мин хаклы?

Энҗе дәшмәде.

Алар бер-берсенә карап, елмаеп, шактый озак тордылар. Аерыласылары килмәсә дә, беренче булып Энҗе үз өйләренә таба атлады...

## 1 апрель, шаяр да көл

Бүген мәктәптән Ислам, Риф, Мансур, Рөстәм бергә кайттылар. 1 апрель көне шул кадәр кызык булды. Малайлар кызларны алдадылар, кызлар малайларны алдады. Беренче дәрестән соңгысына кадәр кемне алдау, көлешү җаен эзләделәр. Ислам барысыннан да ныграк уздырды. Аның үзен дә алдадылар.

Китапханәче алган китабыңны сорый дип, китапханәгә йөгерттеләр. Көне буе көлешеп тә малайлар һаман күңел ачудан туймаганнар иде. Тагын ничек итеп кемне алдау турында кызып-кызып сөйләштеләр. Әхияр абыйлар турына җиткәч, Риф имән бармагын югары күтәреп:

– Малайлар, таптым! – диде.

– Йә, әйт, нәрсә?

– Әнә тегендә, – дип, Риф имән бармагын Әхияр абыйларның абзарына таба төбәде. – Аларның чуар бозавы тора. Без хәзер койма яныннан шуның янына барабыз да, Ислам, син бозау булып кычкырасың. Шул тавышка йә Әхияр абый, йә хатыны Маһинур йөгереп чыгачак.

– Кызык була бит бу, малайлар! – диде Рөстәм, күзлеген апрель кояшы астында ялтыр-йолтыр китереп.

– Олы кешене алдарга ярармы соң? – дип сорады Ислам.

– Көне шундый бит, – диде Риф, шул якка атлый башлап.

– Мондый көнне кызык ясау кешеләрнең күңелен ача, аларның нервыларын тынычландыра, – диде Мансур, акыл сатып. – Шулай булгач, без файдалы эш эшлибез, дигән сүз.

Бозауга бакча ягына ук тимер челтәр белән әйләндереп, урын ясалган иде. Уң ягы такта белән эшләнгән. Малайлар шул урга килеп, һәрберсе аерым ярыктан бозауны карадылар. Ул инде бик зур үскән, симергән, муены сыер муены кадәр булып килә иде. Бозау ашыкмый гына алдындагы улактан печән чемченә.

– Әйдә, башла, – диде Риф.

Ислам ике учын авыз читенә китереп, кара-каршы куйды, куыш ясап, бармак очларын бер-берсенә терәде һәм озын итеп «Өмм-м-мүүү!» дип кычкырып җибәрде. Кычкырган чакта учларын акрын гына як-якка аерды. Шулай итеп өч мәртәбә кычкыруга, бозау янына аксаклап, Әхияр абый килеп керде. Аның башы да озын, ияге белән маңгае да озын, борыны да озын, аяк-куллары да озын булганга, «Колга» дип йөртәләр иде. Шул озын гәүдәсен чайкалдырып, ул бозауга таба иелде:

– Ник кычкырасың? Ни булды? – диде ул, бозауга төксе генә эндәшеп.

Бозау башын күтәреп, гөнаһсыз күзләрен аңа юнәлтте. Нининдидер тәмле әйбер бирәдер дип, кулын яламакчы булды.

– Әллә берәр җирең авыртамы? – диде Әхияр абый, бозауның чуар битен сыпырып.

Әлбәттә, бозау аңа берни дә эндәшә алмады. Шуннан соң Әхияр абый өенә кереп китте. Малайларның авызлары ерылган иде.

– Әйдә, тагын кычкыр инде! – дип пышылдаштылар алар.

Ислам тагын ике мәртәбә, сузып-сузып, бозау тавышы чыгарды. Бу юлы Әхияр абый җәһәт-җәһәт атлап керде. Аның борын астындагы чаларган мыегы ачудан песи мыегы төсле тырпайган иде.

– Ник акырасың, юньсез?! – диде ул карлыккан тавыш белән.

Бозау мескен берни белмәгәнлектән, телен сузып, хуҗасына якынлаша башлады.

– Яшел печән кирәкмени? – диде Әхияр абый.

Ул чиннеккә менеп, яшел печән алып төште. Бозау тәмләп печәнне ашый башлады. Әхияр абый тынычлап, өенә кереп кенә барганда, тагын бозау кычкырган тавыш ишетелде. Бу юлы ул хатыны Маһинурны да ияртеп алып чыкты. Маһинур апа бик юан, бик кыска буйлы, йөзе кып-кызыл, зәңгәр күзләре гаҗәпләнүдән зурайганнар иде.

Хуҗаларын күргәч, тагын да тәмлерәк нәрсәдер бирәләр, дип, бозау аларга таба атлады. Мәһинурның камыр басып маташкан чагы булган икән, чүпрәле тәмле камыр исенең борынын ярып керүенә чыдый алмыйча, бозау түтәсенең кулын ялый башлады. Шунда ул ялгыш Әхиярнең болай да авырткан аягына каты тоягы белән китереп басты. Әхияр абый кинәт кычкырып җибәрде һәм бозауның борынына сукты. Малайлар, тавыш чыгармаска була, авызларын куллары белән каплап, пырх-пырх көлештеләр. Аягының авыртуына да, бозау тавышына да ачуы килгән Әхияр абый аның маңгаена йодрыгы белән төя-төя:

– Ник кычкырасың син, ә?! – дип, өзгәләнде.

– Туралган бәрәңге бар иде, он сибеп шуны биреп кара әле, – диде хатыны.

Әхияр абыйның йөзе бозылган иде. Карап-карап торды да:

– Ник кулыңны аның авызына тыгасың? – дип, хатынын ачулана башлады.

– Сөт эчерергә үзең шулай өйрәттең бит, – диде хатыны, акланып. – Хәзер янына килгән саен бармакларны имә.

– Әйтәм җирле, кая озаклап югаласың, дисәм, бозауга кулыңны имезеп йөрисең икән, оятсыз! – диде Әхияр абый ачуын баса алмыйча.

Хатыны аңа «Надан!» димәкче иде дә тыелып калды, бары тик:

– Нишләп оятсыз булыйм мин? – дип кенә куйды.

– Ир хатыны була торып, бозау тикле бозауга кулыңны имезеп йөргәч, бер дә әйбәт түгел инде бу, – дип куйды ул.

– Әйдә, бәрәңгене бирәм, – диде хатыны кискен генә һәм өйләренә таба юнәлде.

Аңа Әхияр абый да иярде. Алар күздән югалуга, Ислам тиз-тиз бозау тавышы белән кычкырырга тотынды. Ишегалдында тагын Әхияр абыйның озын гәүдәсе күренде, ул чиләк белән бәрәңге күтәреп, бозауга якынлашты. Битенә, тез башларына он тигән иде.

– Никләр акырасың син, әрәмтамак?! – дип бозауның улагына бәрәңгесен аударды.

Бозау көтмәгәндә, мондый тәмле ризык килүенә кем сәбәпче икәнен уйлап та тормастан, кетер-кетер китереп, бәрәңгене ашарга тотынды. Әледән-әле аның тәменә рәхәтләнеп, авызын өскә күтәрде, кояштан күзләрен кыса-кыса, бәрәңгене тәмләп чәйнәде. Аны бераз карап торгач, Әхияр абый тынычлап кереп китте.

– Әйдә инде, әйдә, тагын кычкыр! – дип көлеште малайлар.

– Җитмәс микән? Интектерүгә китмәсме? – диде Ислам, Әхияр абыйны кызгана башлап.

– Беренче апрельдә алдану теләсә кемгә тәтеми ул, – дип көлде Риф.

– Әйдә, тизрәк кычкыр инде, кычкыр! – дип ялына башлады Мансур да.

Ислам аларга каршы килә алмады. Үзенең дә күңелен гел кытыклап тора иде бу уен. Тагын да сузыбрак кычкырырга тотынды. Әхияр абый атылып килеп чыкты да, ике ботына ике кулы белән шапылдатып сукты һәм шундук борылып кереп китте.

– Хәзер суярга пычак алып чыга, – диде Мансур, көлеп.

Ләкин Әхияр абыйлары пычак алып чыкмады. Ул заманында ветфельдшер булып эшләгән Закирга дәште. Ислам өч мәртәбә кычкыруга, алар парлашып абзарга килеп керделәр. Бозау тыныч кына бәрәңгесен ашап бетереп килә иде.

– Кая, кычкырмый бит, – диде Закир.

– Һи, аның хәтле хитрый! – диде Әхияр абый, озын кулларын болгап. – Янында чакта кычкырмый ул дошман. Ну, чыксаң, шундук акыра башлый.

Алар сөйләнә-сөйләнә ишегалдына чыгып китүгә, Ислам кызганыч итеп «Мууу! Мууу!» дип сузды. Тегеләр шундук, юлларыннан кире бөкләп, йөгерешеп керделәр. Закир бозауның бүксәсенә баскалап карады, колак эченә бармагын тыгып капшады, әллә үпкәсендә микән, дип, колагын бозауның күкрәк турына куеп, сулышын тыңлады.

– Барысы да тәртиптә, – диде ул аптырап. – Әйдә, тагын бер чыгып карыйк әле.

Алар тагын чыгып киттеләр. Бозауның кычкырырга уйлап та караганы юк, рәхәтләнеп бәрәңгесен ашап бетерде дә печәненә үрелде.

– Әйдә инде, әйдә, тизрәк кычкыр, – диеште малайлар.

Алар тыелып көлә торгач, күзләреннән яшьләр бәреп чыккан иде. Ислам каһәр ару итеп тагын ике мәртәбә кычкыруга, Әхияр белән Закир йөгерешеп килеп керделәр. Закир озак кына баш чайкап торгач:

– Моңа аракы эчереп карарга кирәк, – диде. – Эчендә аскарида-мазар бардыр. Шул тешләгәнгә, түзә алмыйча кычкыра бу. Бер дә бүтән түгел.

Закир бозауны капшаштырып, сыпыргалап караштырган арада, Әхияр бер ярты аракы, калай кружка тотып килеп чыкты. Әхияр аракыны Закирга биреп, озын куллары белән бозауны алгы аяклары ягыннан кочаклап алды, тегесе кружкага шешәдән аракы агызды да уң кулының баш һәм имән бармагы белән бозауның борын тишегеннән эләктереп, авызын югары күтәрде һәм кружкадагы аракыны аз-азлап кына аның авызына салды. Бозау пошкырмады, салган берен йотып барды. Шуннан соң Закир белән Әхияр тып-тын гына мунчага таба киттеләр. Алар күздән югалгач, Ислам әллә ничекләр итеп кычкырып карады, әмма ник икесенең берсе күренсен. Ул инде кычкырып арыды һәм ял итәргә туктады. Берзаман бурлаттай кызарышкан Закир белән Әхияр абыйлары бозау янына килеп керделәр.

– Синең бу бозавың дуракланган, – диде Закир, имән бармагы белән бозауның маңгаена төрткәләп.

– Бозау дураклана, димени?

– Дураклана, котыра, – диде Закир. – Шизофрения. Күрәсеңме син аның ничек карап торуын?

Бу вакытта бозау, чыннан да, болар мине тагын интектерергә килмиләр микән, дип, башын өскә күтәреп акаеп карап тора иде.

– Бәй, нишләтәбез соң инде аны? – дип сорады Әхияр, аптырап.

– Бозаулар өчен юләрләр йорты юк, – диде Закир бик белдекле тавыш белән. – Казанга гына илтеп кайтыр идең дә. Син ни булмаска бер яртыңны әзер тот әле. Кичкә күз күрер.

Шулай дип, Закир бозауның эченә баскалый башлауга, ул мәхлукның, ахрысы, кытыгы да килде, шаярасы килеп китте бугай. Шулай булмый җае да юк. Күктән апрель кояшы бөтен җирне иркәли, алдында печән, дисәң – печән тора, яларга, дисәң – сибелгән он тора, бәрәңге, дисәң – туралган бәрәңге дә нәкъ тиешле урынына кереп утырды. Әле генә эчерелгән шайтан суы ашказанындагы бәрәңге, печән, оннар белән кушылып, чуар бозауның чуар күңеленә, күрәсең, шагыйранә илһам иңдергән иде. Ул илһам тиз арада зур теләккә әверелде. Бозау шайтан суының шешәдә калган өлеше хуҗаның кулында икәнен хәтерли иде, әлбәттә. Шуны сорап, ул борынын сузган хәлдә хуҗасына якынлаша башлады. Әхияр аңа таба чүгәләбрәк иелгән, ә аның иңбашы аша Закир карап тора, өйдән бер кисәк ипи тотып чыккан Маһинур Закир артына килеп басып маташа иде. Бозау онлы авызыннан телен сузып, тагын бер атлауга, хуҗасының теге авырткан аягына китереп басты. Әхияр

шундый әшәке итеп кычкырып җибәрде, ишегалдындагы каз-үрдәкләр, тавыклар куркуларыннан бөтенесе берьюлы бакылдап, кыткылдап дәһшәтле тавыш чыгардылар. Әхияр ыңгыраша-ыңгыраша, озын кулын селтәп, мескен бозауның яңагына чабып җибәрде. Бозау, шуны гына көткәндәй, читкә сикерде һәм койрыгын тырпайтып, арт санын үрле-кырлы сикертә-сикертә, абзар буйлап чабарга тотынды. Бозау «А-а-ак! А-а-ак! А-а-ак!» дип кычкыра-кычкыра аларның каршына ук килде дә, ал аякларын җиргә терәп, кинәт туктап калды. Бу аның теге шайтан суын бирүләрен көтүе идеме, әллә башка сәбәптәнме – белмәссең – әмма ике күзе ике тавык йомыркасы кадәр булып акайган иде. Аннары бозау кинәт ыргылды да каты маңгае белән хуҗасының бүксәсенә быкылдатып китереп төртте. Әхияр үзенең җилкәсе өстеннән карап торган Закирны да аударып җиргә барып төште. Закир белән бергә аның артындагы Маһинур да чалкан ауды. Бозау үзенең бу эшеннән бик канәгать иде. «А-а-ак! А-а-ак!» дип кычкыра-кычкыра, ярым ачык капкадан башта ишегалдына, аннары урамга ук чыгып чапты. Күп көлүдән эчләре авыртканлыктан, малайларның тавышлары да чыкмый башлады. Әхияр белән Маһинур торып аның артыннан йөгерделәр. Закир егылган урынында шактый вакыт мәрәләп ятты. Озын аяклары белән ыргылып йөгергән Әхияр бозауның каршысына төште. Ул ике кулын ике якка сузган килеш озын аякларын сажень кебек як-якка аерып, бозауны кочаклап алырга теләгәндәй, аның каршында сикергәләп тора башлады. Маһинур урамга чыккан малайларга ягымлы итеп кычкырды:

– Бозауны куышыгыз әле, үскәннәрем!

Малайлар йөгерешеп килеп җиттеләр. Маһинур бозау каршында кулларын канат кебек җәеп сикергәләүче Әхиярга чәрелдәп кычкырып җибәрде:

– Нәрсә бакча карачкысы төсле аңгыраеп басып торасың?! Куала, надан тәре!

Әхиярның аракы эчкәч кыза торган бәрәңге канына шул сүз генә җитмәгән иде. Ул буыла-буыла:

– Хәзер наданны күрсәтәм мин сиңа! – дип кычкырды.

Ах, шул сүз! Ул сүз аны пычаксыз суя иде! Мәрхәмәтсез иде кәнтәй Маһинур! Әйе, Әхияр – шыр надан! Ул үзенең надан икәнен мәктәптә укыганда ук белә иде. Аны укытучылар да сыйныф саен әйтә килде. Әхиярның мәктәптә алган иң зур белеме бәлкем әнә шул үзенең надан икәнен аңлау булгандыр. Тик хатын кешегә нигә дип ул сүзне әйтергә иде соң?! Маһинур гомере буе шул сүзне әйтеп, Әхиярның җанын ашады. Шул сүзгә котырганын белгәнгә күрә махсус әйтте. Әйткән саен алар дөнья кубарып талаштылар. Һәм иң кызыгы шунда: алар ничек дары кебек дөртләп кабынсалар, дары шундук янып беткән шикелле шып туктап та калалар иде.

Әхияр бозауны ташлап, йодрыкларын болгый-болгый Маһинур өстенә килә башлады:

– Чупай ябалагы! Хәзер күрсәтәм мин сиңа наданны!

Маһинур иренең гадәтен яхшы белгәнлектән, ишегалдына йөгерде. Әхияр Чупай ябалагына тагын әллә нинди сүзләр өстәп, акыра-акыра аңа якынлаша барды. Маһинур туры лапас өстенә менде дә артыннан баскычны үзе янына күтәрде. Әхияр, озын сәнәк алып, аңа төртмәкче булып, туктаусыз сикергәләде, өскә укталды. Маһинур ераккарак басып, авызыннан телен чыгарды да аны:

– Бә-бә-бә! – дип үртәргә тотынды.

Алар артыннан мышлап килеп җиткән Закир Әхиярның кулындагы сәнәген тартып алды.

– Диваналанмагыз инде! – диде ул, ярсып. – Син дә төш сәндерәңнән, бозауны кертик!

Маһинур апаларына ире сәнәк белән кадар дип, малайлар да куркуга калды. Маһинур апа төшкәндә, Әхияр абый баскычны тотып торды, шуннан соң икесе дә бозау янына ашыктылар. Кызык иде аларны карап тору! Бөтенесе бергәләп бозауны керткәч, малайлар кайтып киттеләр. Аларның тәмам күңелләре булган, шундый кызык күрсәткән өчен Исламны мактап туймадылар. Беренче апрельнең иң күңелле мизгелләре булып, бу вакыйга аларның хәтерендә мәңгегә калды.

## Август аеның нурлы көне

Башта сизелер-сизелмәс кенә булып моңлы көй ишетелде... Әллә җирнең читеннән, әллә күкнең иң биек ноктасыннан килә иде көй. Ул акрын гына битләрне иркәли торган яшел җилгә әверелде. Җилгә сарысы, зәңгәре, шәмәхәсе кушылды һәм алар дулкын булып каядыр тәгәрәделәр. Ислам Нух маңгае янында басып торуына нишләптер гаҗәпләнмәде. «Мин монда кайчан килдем, нишләп йөрим?» дип тә уйламады, бу аның өчен табигый халәт иде. Шушы моң, төсләр тирбәлешендә ул тирә-юньне күзәтте, еракта җәелеп яткан болыннар-күлләр, елгалар, гөлбакча, әйлән-бәйлән уйнагандай, әйләнә, хәтта йортлар да үз урыннарыннан күчеп, акрын гына уңнан сулга таба әйләнәләр. Ислам моңа гаҗәпләнмәде, аны үзеннән бер-ике метрда гына торган бармак юанлыгы каен агачының эндәшүе гаҗәпләндерде: «Син мине үзең белән ал, миңа бер ялгызыма бик кыен», – диде каен. «Ничек син ялгыз буласың, ди, монда күпме агач, челтерәп чишмә агып ята, янәшәңдә Нух маңгае», – дип җавап бирде Ислам. «Алар барысы да миннән олылар, картайганнар, миңа иркен җир кирәк, алып кит үзең белән!» Төрле төстәге җилләр ничектер куерып киттеләр, алардан ишетелгән моң Исламны каен янына этәрде. Ул аның кәүсәсеннән тотып, җиңелчә генә өскә тартты һәм каен бернинди авырлыксыз җирдән суырылып чыкты. Шул чакта Ислам үзләренең очып китүләрен тойды. Төсле җил, төсле музыка аның өчен түшәк кебек йомшак һәм җылы иде. Менә алар Әйләнмә күл буена төштеләр. «Мин сине шушында утыртам», – диде Ислам. «Юк, миңа тауның да иң биек урыны кирәк», – диде каен. «Киттек алайса», – диде Ислам. Кулын гына селтәве булды, алар парлашып күтәрелеп киттеләр. Үзенең маллары белән көтү көткән Галимҗан абыйсына Ислам кул болгады, Галимҗан абыйсы да аны таныды һәм эшләпәсен селкеп җавап бирде. Менә алар авыл янындагы Мәтәлчек тавының иң биек урынына килеп төштеләр. Аларны көтеп торгандай, шул урынга көмештәй ялтырап торган көрәк кадап куелган иде. Ислам каенны чабыр үләне өстенә салды. Бу төштә һәрвакыт чабыр үләне куе булып үсә, авыл халкы чәй эчәргә, дәваланырга аны шушыннан килеп җыя. Ислам күтәрелеп карагач, авылның да, күлләр-елгаларның да, әйләнүдән туктап, үз урынын алуын күреп куанып куйды. Ул көмеш көрәк белән чокыр казырга кереште. Туфрак шулкадәр йомшак, көрәкнең очы тиюгә җиңел генә бата, каенның тамырлары сыярлык итеп, киң чокырны ул «эһ» дигәнче казып ташлады. Су да кирәк булыр, дип уйлап бетерергә өлгермәде, чокырның төбендә көмештәй чиста су күренде. Ул агачны чокырга төшерде һәм көрәк белән күмәргә кереште. Бу вакытта яшел, зәңгәр, сары, шәмәхә җилләр йөрәктән ала торган мең төрле моң булып, Исламны әйләндереп исәргә тотындылар. Җилнең шулай түгәрәк булып хәрәкәтләнгәнен

аның өермә вакытында гына күргәне бар иде. Бу нишләп болай икән, дип уйлап та бетерә алмады, моның сәбәбен дә аңлаган кебек булды: ул соңгы көрәк балчыкны салганда, каенның кәүсәсе инде беләк юанлыгы булган иде. Күрәген куйды да, читкә китеп, аңа күз ташлады һәм хәйран калды: каенның ябалдашы шул кадәр яшел, шул кадәр куе һәм шул кадәр зур иде. Әлеге музыка көчәйгәннән-көчәйде, каен бер генә мизгелгә төсле җилләр астында калды. Менә җил түбәнәйде һәм аның күз алдында искиткеч күренеш барлыкка килде: каенның урта бер җиреннән кояш нурлары сибелә, ә яфракларында, ботакларында җем-җем итеп йолдызлар яна иде. Бөтен тирә-юнь илаһи нурга күмелгән, илаһи көй хакимлек итә. Бу көйне әллә күк, әллә җир, әллә шушы каен, әллә шул каендагы йолдызлар тарата иде... Кинәт каен башына ниндидер кара кош килеп кунды. Исламның котын алып, каен уң якка авыша башлады. Ул аны барып тотмакчы булды, әмма аяклары тыңламады. Шунда үзенең артында көлеп җибәргән тавыш ишетте. Ялт итеп борылып караса, алсу күлмәк кигән, битләре алсуланып янып торган, чәчләренә алсу бантик кадаган Сөмбел басып тора. Ул Исламга бер сүз дә дәшмичә, көлә-көлә аның янынннан үтеп китте дә авышып маташкан каен янына барып, аның кәүсәсен җиңел генә турайтып куйды. Аннары бераз чигенеп, имән бармагы белән теге кошка күрсәтеп, «Көш!» диде: кара кош очып китте. «Син каян килеп чыктың?» – диде Ислам, куанычыннан нишләргә белмичә. «Нух тавыннан», – диде Сөмбел, елмаеп. «Син анда юк идең, алдама», – диде Ислам. «Бар идем, син мине күрмәдең. Каен булып мин сөйләштем синең белән.Җырлы җил булып та мин истем.» Алар сөйләшеп торганда, каен тагын авыша башлады. Карасалар, очына кып-кызыл бер кош килеп кунган икән. Ул кош баягы кара коштан ике-өч мәртәбә зуррак. Сөмбел тагын йөгереп барып, каенны турайтты һәм «Көш!» дип кычкырды. Кызыл кош куркыныч зур канатларын җилпеп очып китте. «Нигә син безнең авылга гел килмисең?» – диде Ислам аңа. Сөмбел елмайды һәм нидер сөйли башлады. Ислам аның сүзләрен ишетергә теләп, колагын якынрак китерде, әмма Сөмбел юкка да чыкты һәм ул уянып китте.

Ислам айный алмыйча шактый ятты. Аның Сөмбел белән сөйләшәсе килде. Иртәнге эшләрен бетергәч, ул телефоннан Сөмбелләрнең номерын җыйды. Сөмбелнең әле йокыдан уянып җитмәгән тавышы ишетелде:

– Але-е.

– Нишләп йоклап ятасың сыртыңа кояш төшкәнче? – диде Ислам, көлеп.

Сөмбелнең көлгәне ишетелде:

– Әләй, Ислам!

– Мин шул. Сине сагынып шалтыратам.

– Әй, шаяртма инде, – диде Сөмбел.

– Мин сине төштә күрдем.

– Былтыр мин дә сине күргән идем.

– Ә мин сине хәзер генә күрдем.

– Ничек итеп күрдең?

– Менә анысын телефоннан сөйләмим. Әйдә, кил безгә.

– Юк, мин бүген район үзәгенә барам, – диде Сөмбел.

– Анда аю биетми торганнардыр бит?

– Минем китап кибетенә барасым бар.

Аның бу сүзләреннән Ислам уйга калды.

– Син кайчанрак барасың соң?

– Автобус безнең авылдан сәгать уннарда үтә.

– Алайса мин дә велосипед белән генә барам әле, – диде Ислам. – Күптән китап кибетенә кергәнем юк.

– Төшеңне сөйлә инде, ничек итеп күрдең мине?

– Әйттем бит телефоннан сөйләмим дип. – Ислам елмаеп, телефон трубкасын куйды.

Сәгать ярымнан ул китап кибетенә барып җиткән иде инде. Велосипедын баганага йозаклап куйды да кибеткә керде. Сөмбел күренмәгәч, Ислам ишек төбенә чыгып басты. Ниһаять, Сөмбел дә күренде. Ул зәңгәр күлмәк белән зәңгәр эшләпә кигән иде. Алар бер-берсенә кара-каршы килделәр дә елмаешып карап тордылар.

– Велосипедың матур икән, – диде Сөмбел, елмаеп.

– Әти яңа алып бирде.

Алар эчкә кереп, озаклап китап сайладылар. Сөмбел бик матур әкият китабы, буяу карандашлары, дәфтәрләр алды. Ислам балалар өчен чыгарылган шигырьләр җыентыгы, җәнлекләр рәсеме төшерелгән альбом алды. Алар китапларын букчаларына салып чыкканда, велосипедның йозагын кемдер тарткалап шалтыр-шолтыр китерә иде.

– Нигә кагыласың аңа? Ул бит минем велосипед, – дип, Ислам теге малайның йөзенә карады.

Ул шактый озын гәүдәле, ким дигәндә тугызынчы классларда укучы малай булырга тиеш иде. Йөзе саргылт, кашлары чем-кара, күзләре кысык, тешләре сирәк бу малай велосипед яныннан китәргә уйламады да. Аның киеме дә ничектер ят кебек тоелды. Күлмәге эре шакмаклы, костюмы җыерылып беткән, башында түбәтәйгә охшаган кара берет, аягына, көн эссе булуга карамастан, ялтырап торган читеккә охшаш ниндидер кием кигән.

– Велосипедыңны биреп тор әле, тиз генә аптекадан дару гына алып киләсем бар иде, – диде ул, һаман велосипедны тарткалап.

Сөмбел Исламга арттан төртеп куйды: бирмә, диюе иде.

– Юк, без ашыгабыз, – диде Ислам. – Безнең автобуска өлгерәсебез бар.

– Ярар, – диде теге малай, бер адым гына читкә китеп. – Ашыккач булмый инде.

Ислам йозагын ачып велосипедын баганадан алды. Шул вакыт теге малай килде дә аны төртеп җибәрде. Исламның кулы ычкынып китте, велосипед ауды. Ислам шундук сикереп торды, теге малай озын кулы белән аның иңбашыннан эләктереп алды. Ислам күз ачып йомганчы аңа сырты белән борылды да малайның беләктән өстән кулын эләктереп, гәүдәсен кинәт аска иде. Малай аның өстеннән атылып китеп, җиргә барып төште. Берәр төше авырттымы, ул кычкырып җибәрде:

– Үтерәм, маңка!

Ул Исламның өстенә ташланды. Ислам ялт чүгәләүгә, ул ике кулы белән тагын җиргә барып төште.

– Әле син шулаймыни, хәзер күрсәтәм мин сиңа! – дип, тагын сикереп торды малай.

Бу юлы Ислам читкә тайпыла алмады, ул аны ике иңбашыннан эләктерде дә селтәп җибәрде. Ислам канауга ук тәгәрәде, шул арада теге малай, велосипедка атланып кузгалып та китте.

– Тукта, тукта! – дип кычкырып, Ислам аягүрә басканда, Сөмбел велосипедны куып җитте дә теге малайны кырдан төртеп екты. Бу вакытта кибеттән озын гәүдәле бер абый чыгып килә иде. Мөгаен, ул тәрәзәдән нәрсә булганын күргән, йодрыгын селки-селки туп-туры малайга таба атлады.

– Хәзер милициягә тотып илтәм мин сине! – дип кычкырды ул, аңа якынлашып.

Малай дүрт аякланып торды да җан көченә урам буйлап чапты, аннары ниндидер өйләр арасына кереп югалды.

– Син белә торган кешеме соң бу? Каян очраштыгыз? – диде әлеге абый, Исламга иелеп.

– Ул минем велосипедны алып китмәкче булды, – диде Ислам, тузанга баткан өстен кага-кага. – Рәхмәт инде, абый.

– Ә син молодец! – диде ул абый, аның башыннан сыпырып. – Бәләкәй булсаң да, бирешмәдең. Спорт белән шөгыльләнә торгансыңдыр, шулаймы?

– Әзрәк бар инде, – дип куйды Ислам, елмаеп.

– Менә бусы бик начар! – диде абый, аның иңбашына авыр кулын салып. – Ныклап шөгыльлән. Ир кеше үз-үзен яклый белергә тиеш. Безгә үзебезне генә түгел, илне дә сакларга туры килә. – Шулай дип абый китеп барды.

Ислам Сөмбелгә карап баш чайкап торды.

– Нигә баш чайкыйсың? – диде Сөмбел.

– Мин сине мондый батыр кыз дип белми идем.

– И, көлмә инде, – диде Сөмбел. – Син хәзер нишлисең?

– Кайтырга иде инде. Ә син?

– Автовокзалга барам да автобус көтәм.

– Ул кайчан килә?

– Берәр сәгатьтән.

– Әйдә, мин сине велосипед белән илтеп куям, – диде Ислам.

– Сиңа бик авыр булыр, – Сөмбелнең кыенсынганы күренеп тора иде.

Ислам икесенең дә букчасын велосипед руленә элде дә, алар җәяүләп, авыл башына юнәлделәр. Юлга чыгып җиткәч, Ислам Сөмбелне алга утыртып, акрын гына авылга таба кузгалды. Ул шаяртып, Сөмбелнең колагына өрде, Сөмбел «Кытыгымны китерәсең, егасың!» дип чыркылдады. Бернинди җил юк, күк йөзе аяз, кояш алтын нурларын сибә, ике якта урып алынган кырлар кала. Кап-кара итеп сөрелгән басуларда рәт-рәт салам эскертләре тора. Еракта җир эшкәртүче тракторлар күзгә ташлана. Менә алар алтын төсле булып җәелеп утырган көнбагыш басуына килеп җиттеләр.

– Күрәсеңме күпме кояш! – диде Ислам, велосипедын туктатып.

Алар басу читенә килеп, иң матур, иң сары ике баш көнбагыш өзеп алдылар. Аны Сөмбелнең кулына чәчәк урынына тоттыргач, велосипедка утырып, юлларын дәвам иттеләр. Кап-кара басу уртасындагы сап-сары эскертләргә күрсәтеп, Ислам:

– Әнә нинди чәкчәкләр тезеп куйганнар, – диде.

Сөмбел кычкырып көлеп җибәрде:

– Әйе шул, гел чәкчәк төсле икән. Буханкалы ак ипигә дә охшаган.

Ул арада ике якта ямь-яшел булып җәелгән чөгендер басуына килеп җиттеләр. Сөмбелләрнең авылы да инде якында гына иде.

– Бу безнең авылның шикәр чөгендере, – диде Сөмбел. – Шушыннан шикәр ясыйлар.

– Харап икән! – дигән булды Ислам, велосипедын акрынайтып. – Безнең авылда шоколад чөгендере үсә.

Сөмбел кычкырып көләргә тотынды.

– Нигә көләсең? Конфет чөгендере дә үсә.

– Әйдә, алда инде, алда, – диде Сөмбел, башын аңа таба борып.

Ислам аның күзенә өрде.

– Авылның теге ягында азык чөгендере үстерәбез, – диде Сөмбел, мактанган кебек итеп.

– Менә син азык чөгендере, дисең. Бездә тавык чөгендере үстерәбез.

– Анысы нинди була соң аның?

– Орлыгы тавык йомыркасы төсле була. Менә шушындый сөрелгән җиргә күмеп чыгалар. Шуннан тишелеп, тавыкның башы белән койрыгы күренә. Койрык турыннан яфраклары чыга, тездән биек булып. Үсеп җиткәч, көз көне көрәк белән шуны казыйлар, тавык яшел яфраклы койрыгын селки-селки йөгерә.

Сөмбел көлүеннән тыела алмыйча, йөзен тагын аңа борды. Ике күзе дә йомылып беткән иде. Ислам тагын аның күзенә өрде. Шулай шаярышып, алар авыл башына килеп тә җиттеләр.

– Туктат, туктат! – дип кычкырды Сөмбел.

– Нигә?

– Мин төшәм, үзем генә керәм.

– Нигә? – диде Ислам гаҗәпләнеп.

– Оялам, малайлар үртәр.

– Чәй белән сыйлап җибәрерсеңме, дип уйлаган идем. Болай авыл башыннан борылып китәсемне белгән булсам, мин сине китереп тә йөрми идем, – дигән булды Ислам, аңа хәйләкәр караш ташлап.

– Ярар инде, Ислам, үртәмә. – Сөмбел велосипедтан төшәргә ашыкмады. – Ислам, мин бит быел сезнең мәктәпкә күчәргә җыенам.

– Китчәле?! – Ислам шатлыгыннан чак велосипеды-ние белән авып китмәде.

– Болынкырдан әбине үзебезгә алып килдек. Йөри алмый, нык авырый. Әби анда булмагач, район үзәгендә укыйсым килми.

– Ярый, без сине шатланып кабул итәбез!

Сөмбел өйләренә кереп китте, Ислам Гөлбакчага юнәлде, алар шулай аерылдылар.

Икенче көнне төштән соң, күрше Нурия апага ияреп, теге малай килеп керде. Исәнлек-саулык сорашкач, аларны әти-әниләре табынга чакырдылар.

– Юк, юк, без ашыгабыз, – диде Нурия апа. – Сез беләсез, Үзбәкстанда сеңлем белән киявебез яшәгән иде. Бу шуларның малае Әсгать. Кодагый тәрбиясендә әйбәт кенә торганда, ул да гүр иясе булды. Әсгатемне чакыртып кайтардым. Директорга барган идем, документлары белән килергә кушты. Ул көтеп тора, ашыгабыз. Ислам белән Әсгать кергәннән бирле бер-берсеннән күзләрен алмадылар. Әсгатьнең күз алмалары тозакка эләккән җәнлек кебек сикереште. – Сез инде, Ислам, Әсгать белән бергәрәк булсагыз, рәхмәт әйтер идем. Ят малайлар тия күрмәсен. Ул бит әле монда беркемне дә белми.

– Ярар, ярар, – диделәр өйдәгеләр. – Исламга да уйнарга иптәш булыр.

– Хәере белән генә булсын инде, – дип куйды бабасы. – Бу бала детдом тәрбиясе дә алды бугай...

## Сыйныфка яңа малай килә

Исламның тынычлыгы югалды. Нурия апага ул Болынкырда булган хәлләрне сөйләп бирмәкче булды. Аннары кире уйлады. Әтисе баштук кисәтте: район үзәгенә-мазар велосипед белән барсаң, велосипедыңны алып

калачаклар, диде. Ислам бармыйм дип, сүз биргән иде. Әгәр Нурия апага ул китап кибете каршында булган хәлне сөйләсәң, этисеннән эләгәчәк иде. Ул ике көн буе шушы турыда баш ватты. Өйдә чакта Нурия апаның ишегалдына күз ташлады, әмма Әсгать күренмәде. Әллә берәр җиргә китте микән, дип уйлады Ислам. Аның белән аралашу аны борчыды. Әсгатьнең күзләре уйнап тора, йөзендә нур юк, аңардан барысын да көтәргә була. Шулай аптырап йөргәндә, бүген Нурия апа үзе килеп керде. Әти-әниләре белән хәл-әхвәл белешкәч, зарланырга тотынды:

– И аллам, бу баланы кайтаруыма үкенә дә башладым. Сезгә кереп чыкканнан бирле капланып ятты, иңбашлары сикерә, сизәм инде – елый. Кыстап торгызам да ашатырга маташам. Әллә авыруы көчле, ютәлли-ютәлли ашый да тагын барып ята. Медсестра Нәсимәне чакырган идем, хроник бронхит, ди. Температурасы юк. Дарулар калдырып китте. Ә ул аларны эчми, ата да бәрә. Мин аларны потлап ашадым инде, бер файдасы да юк, ди. Үзеннән тәмәке исе килә, тышка чыкканда тартып керә. Син аны, Ислам улым, иптәшләрең янына алып барып кара әле, иярәндерергә кирәк бит инде аны.

– Бар, улым, кер, сөйләшегез, дуслашырга тырыш, – диделәр өйдәгеләр беравыздан.

– Минем белән кермә инде, әллә нәрсә уйлар, – диде Нурия апа. – Үз вакытың белән кагылырсың әле.

Ул чыгып киткәч, Ислам шактый уйланып йөрде. Ничек итеп сүз башларга, кая алып барырга, малайлар белән уртак тел табармы ул? Бу сорауларга җавап юк иде. Бер сәгатьләп вакыт узгач, ул җаны-тәне белән куырылып, Нурия апаларның бусагасын атлап керде. Әсгать тәрәзәгә карап басып тора иде.

– Исәнмесез, – дип сәлам биргәндә үк, Ислам «бу үзенең туган җирләрен сагына бугай», дип уйлап куйды.

– Исәнме, апаем, әйдә, түрдән уз, – дип, Нурия апа аны җитәкләп өстәл янына алып килде.

Әсгать күзен ялтыратып карап кына куйды, бер сүз дә дәшмәде, урыныннан да кымшанмады.

– Әйдә, улым, утырыгыз, – диде аның янына барып Нурия апа. – Мин сезгә бик тәмләп итле бәрәңге пешердем.

Ул аларның икесенә дә тәлинкә белән бәрәңге куйды. Әсгать теләр-теләмәс кенә ашады.

– Хәзер чәй ясыйм, – диде Нурия апа, урыныннан торып.

Әсгать баш чайкады:

– Мин чәй эчмим.

Ул ютәлли-ютәлли чыгып китте, Ислам аның артыннан иярде. Әсгать койма янына барып иелде дә шунда чиләккә салып куйган суны учына алып авызына капты һәм тамак төбен гырылдатып чайкап, җиргә төкерде. Икенче мәртәбә учына алганын йотып җибәрде һәм ютәлләүдән туктады. Исламга таба тураеп борылгач, аның күз карашыннан ул сискәнеп китте. Әсгатьнең күзе ут яна, яңаклары кысылган, менә хәзер Исламның өстенә ташланыр төсле иде.

– Велосипедта йөрисең киләме? – диде Ислам ни әйтергә белмичә.

Әсгать аңа шактый вакыт сынап карап торганнан соң:

– Әйдә, – дип куйды.

Урамга чыккач, Ислам йөгереп кенә велосипедын алып килде.

– Бар, әйләнеп кил, бик кызу йөрмә, – диде.

Әсгать велосипедка атланып, кибет ягына таба элдерде. Ислам аны шактый көтте, әллә берәр җиргә китеп барды микән, дип тә шикләнде, машина астына керә күрмәсен, дип тә хафаланды. Ниһаять, Әсгать күренде. Велосипедтан җитез генә сикереп төшкәч:

– Әйбәт икән синең бу машинаң, – дип куйды.

Исламның борынына тәмәке исе килеп бәрелде. Күрәсең, Әсгать кибеткә кереп, тәмәке алган иде.

– Әйдә, берәр аулак җиргә барабыз.

– Велосипедны кертеп куям да Бормалы буена төшәбез, – диде Ислам. – Синең анда булганың бармы соң әле?

– Каян булыйм мин анда, – дип куйды Әсгать ачулы тавыш белән.

Тыкрыктан Бормалыга төшкәндә, Әсгать йөгерә-атлый ашыкты. Төшеп җитү белән куе тирәк төбенә барып чүгәләде һәм кесәсеннән сигарет кабы чыгарды. Бер сигарет алды да Исламга сузды:

– Син тартасыңмы?

– Юк, – диде Ислам.

– Тартмагач, бик әйбәт. Мин күптән тартам. Монда килгәннән бирле сигарет ала алмый идем. Кесәмдәге җыйган төпчекләремне тарткалап маташтым, үләм дип торам.

Ул сигарет кабызып, тирән итеп суырды да төтенне авызыннан чыгармыйча тамак төбен нәрсәдер йоткан кебек хәрәкәтләндереп торды. Шактый торгач, авыз-борыныннан әз генә төтен чыкты.

– Күрдеңме, йоттым, – диде.

Ислам Бормалы буйлап аңа үзләре уйнаган урыннарны күрсәтеп йөрде.

– Әйдә, иптәш малайларны күрик, – диде ахырда Ислам.

– Иптәш малайларың кем соң синең?

– Сыйныфташ дусларым.

– Җыен ыбыр-чыбыр икән.

– Бездә югары сыйныф малайлары да күп, – диде Ислам. – Ә син ничәнчедә укыйсың?

– Мин җиденчене бетердем, – диде Әсгать, аңа җавап итеп. – Әле бер ел укуым калды да.

– Ничек калды?

– Калды инде шулай.

– Барабызмы соң малайлар янына? – дип сорады Ислам.

– Барырбыз, – диде Әсгать. – Тагын бер тартыйм инде туеп булмый бит.

Ул бер сигаретны уты иреннәрен пешерер дәрәҗәгә җиткәнче тартканнан соң, алар Рөстәмнәргә киттеләр. Рөстәм күзлеген югалткан булып чыкты.

– Мин сезне юньләп танымыйм да, – дип көлде дә көлде.

Танышып кул кысышканда, Ислам Рөстәм белән Әсгатьнең буйлары тип-тигез булуга игътибар итте. Менә бит, «р» хәрефен әйтә алмаса да, алардан ничә сыйныф югары малай биеклегенә үрләгән! Рөстәм бакчаларына алып чыгып, аларны эре, баллы алмалар белән сыйлады. Аларның помидорлары да әллә ничә төрле икән. Рөстәм күзлексез күрмим, дип зарланса да, «менә бусы итле помидол, менә бусы баллы помидол, менә бусы негл солты, дип барысыннан да авыз иттерде. Аннары алар өчәүләп Зөлфәт янына керделәр. Анда кергәндә, Ислам Әбүзәр өйдәдер дип, бик шикләнгән иде, Әбүзәр булган җирдә сугыш була. Әсгатьнең дә сугышырга әзер торганын белгәнгә, ул бу бәрелешне ничек булдырмый калу турында аларның

ишегалдына кергәндә үк төрле-төрле план корды. Аларның бәхетенә Шүкә каядыр еракка үрләгән иде. Болдырдагы звонокка басуга, моряк тельняшкасы кигән Зөлфәт килеп чыкты. Ул олы кешеләрчә иң элек Әсгатькә кул биреп:

– Зульфат, – дигән булды. Аннары: – Сәлам, сәлам! – дип Рөстәм белән Исламга кул бирде.

Тик шунда Зөлфәт үзенең беркатлылыгы белән ярамаган сүз әйтеп ташлады:

– Ай-яй, тәмәке исе бик нык килә, әллә тарта башладыгызмы? – диде, зәңгәр күзләрен уйнатып.

– Зөлфәт, синең борының бозылган, – диде Ислам, бу күңелсез сөйләшүне бүтән якка борып. – Менә бу минем дус Әсгать була. Минем дус булгач, синең дә дус. Безнең белән мәктәптә укыячак.

Зөлфәт рәхәтләнеп көлеп җибәрде:

– Синнән тәмам туйган идем, – диде ул, Исламга төрткәләп. – Алдыйсың да алдыйсың, тыңлыйбыз да тыңлыйбыз. Дөрес сүз сөйләүче дә кирәк бит.

Аның сүзләренә кушылып, барысы да көлделәр. Әсгать кенә авызының уң як читен әз генә ачып, очлы тешләрен күрсәтте.

– Безгә иярәсеңме? – диде Ислам.

– Иярмичә!

Алар җыйнаулашып, Рифләргә юл тоттылар. Риф өйдә булмады. Мансур малайларны капка төбендә каршылады. Әсгать белән таныштырып кул биргүгә, ул:

– Беләм, беләм, ишеттем. Еराклардан килеп чыккансың икән, – диде, Әсгатькә туп-туры карап. Ул кинәт кенә елмайды да: – Синең Габдулла Тукайның «Шүрәле» шигырен укыганың бармы? – дип сорады.

Ислам шушы урында үзенең ялгышканлыгын аңлады: малайларны кисәтәсе булган икән, монда нинди Шүрәле кайгысы? Әле монда Әсгатьне ияләштереп булмый. Аны гаҗәпләндереп, Әсгать бер-ике ютәлләп алды да:

– «Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл – Кырлай, диләр,

Җырлаганда көй өчен тавыклары җырлай, диләр», – дип сөйләп китте.

Ислам хәйран калып:

– Сез дә Габдулла Тукайны үтәсезмени? – дип сорады кабаланып.

– Юк, – диде Әсгать. – Мин аны үзем ятладым.

– Каян алдың соң син аны?

– Үзбәкстанда Тукайны белмәгән татар сирәк.

Бу сүз малайларны шаккатырды... Аннары Фаилләргә юл тоттылар. Ул район үзәгенә киткән булып чыкты. Тау буйларыннан сөйләшә-сөйләшә, сызгырып утырган йомраннарны карый-карый йөрделәр дә таралыштылар. Әсгатьнең беркем белән аралашасы килмәве, сөйләшергә теләмәве барысына да ачык аңлашылып тора иде. Малайлардан аерылгач, ул пышылдап:

– Әйдә инде, тегендә барып, бер тәмәке тартып кайтыйк. Алайса мин үләм, – диде.

Ислам ризалашмый булдыра алмады. Әсгать берьюлы ике сигарет тартып бетерде. Ислам аны бераз читкәрәк китеп, кинода караган кебек карады. Әсгать аңа авызыннан йоп-йомры, бөҗра-бөҗра төтеннәр чыгарып күрсәтте. Ике борын тишегеннән өзек-өзек итеп төтен чыгаруы да Ислам өчен цирк караган кебек кызык булды. Тыкрыктан кайтканда, Әсгать кулын Исламның иңбашына салып:

– Синең белән яшәп була икән, – диде.

Алар кайтып җиткәнче тып-тын гына атладылар. Берничә көннән, инде

укулар башланырга әз генә вакыт калганда, мондый хәбәр килепиреште: Әсгать аларның алтынчы сыйныфында укыячак икән! Илдар Каюмович быел пенсиягә китеп, аның урынына математика укытучысы Шәүкәт Җәмилевичны куйганнар иде. Яңа директор аның белән бик озаклап әңгәмә үткәргән, аннары укытучыларны чакырып, һәрбер фән буенча белемен тикшергәннәр һәм бишенче сыйныфка гына алып була, дигәннәр. Әсгать кайтып, бу хакта әйткәч, Нурия апа аны җитәкләп, кабат мәктәпкә киткән. Халыкның сөйләве хак булса, Шәүкәт Җәмилевичның алдына тезләнгән, диләр.

– Ул ничек оялмыйча алар белән йөрсен. Зинһар, югарырак сыйныфка күчерегез, – дип ялварган, елаган.

– Бу мөмкин түгел, – дигән директор. – Аның белем дәрәҗәсе шундый. Без дә бит югары органнар алдында җавап бирәбез.

– Һич югы Исламнар сыйныфына куегыз.

Шәүкәт Җәмилевич бүлмәсе буйлап әрле-бирле йөргән дә:

– Ярар, бәлкем, сез хаклыдыр, – дигән.

Бу хәбәр авылга яшен тизлеге белән таралды. Әлбәттә, яңалыкны иң дулкынланып кабул итүчеләр сыйныфташлар булды. Бер көнне Энҗе Ислам янына килеп җитте:

– Безгә Үзбәкстаннан бер хулиган кайткан, дип сөйлиләр. Син инде аның белән аралашасың икән. Сыйныфның тынычлыгы китмәс микән? – диде ул, маңгаена төшкән чәчләрен сыпыра-сыпыра.

– Мин ни әйтим соң инде? – диде Ислам. – Ул Нурия апаның туганы, без аны кабул итәргә тиеш.

– Үзебез генә чакта рәхәт иде, – дип куйды Энҗе.

– Рәхәт, рәхәт, – дип үртәде аны Ислам. – Ә кеше нишләргә тиеш? Ул каян кая кайткан. Ә үзе «Шүрәле» шигырен синең белән миннән әйбәтрәк сөйли.

Бу сүзләрне әйткәч, Энҗенең йөзе ачылып китте:

– Алайса ул безнең кеше була бит инде?

– Шулай шул, – диде Ислам.

– Минем янга кызлар килсә, гел аның турында сораштыралар.

– Сине миңа шымчы итеп җибәрделәрме?

– Ярар инде, – дип кул селтәде Энҗе, чыркылдап.

– Энҗе, син аларга әйт, «Шүрәле»не дә сөйли, башка шагыйрьләрне дә белә, безнең малай, – диген.

## Маңгаемнан бер генә сыпыр әле...

Ислам кичкырын Актырнакны йөртергә алып чыкты. Алар тыкрыктан төшеп, Бормалы буеннан бик озак йөреп кайттылар. Актырнакның муенчагын эләктереп маташканда, капкадан Мансур белән Риф килеп керде. Рифнең борыныннан туктаусыз кан ага, ул аны кульяулыгы белән сөртеп тора. Мансур да кып-кызыл булган. Ислам аптырап, алар каршына килде.

– Синең теге дурагыңны ярдык, – диде Мансур, авызындагы канын карга төкереп.

– Нәрсә булды?

– Ындыр артында Шәрифуллина Гөлсемне пычак белән куркытып, акча сорап маташа. Гөлсемнең кычкырып елавына йөгереп барсак, пычагы белән безгә ташланды. Күрмәгәнен күрсәттек без аның, – диде Риф.

Аңа Мансур ялгап китте:

– Бу малайдан котылмыйча, авылда тынычлык булмас. Имансыз ул. Кем күренә, шуңа барып ябыша.

– Куарга кирәк, эзе булмасын, – диде Риф.

– Кайда соң әле ул? – дип сорады Ислам, ни әйтергә белмичә.

– Белмибез, тауга таба йөгерде. Кирәген бирдек без аның, – диде Мансур.

– Малаеның нишләп йөргәнен Нурия апага әйтергә кирәк, – диде Риф, Исламга карап.

– Сез кыйнагансыз бит, сез әйтегез.

– Бәладән баш-аяк, – диде Мансур. – Син бик яклый идең бит. Тәрәлеп торган күршегез, кер дә әйт. Киттек, Риф.

Алар капкадан чыгып киткәч, Ислам ишегалдында шактый вакыт уйланып йөрде. Шулай да хәзергә Нурия апа янына кермәскә булды. Иң элек Әсгатьнең үзе белән сөйләшергә кирәк иде. Инде караңгы да төшеп өлгерде. Ислам тыкрыктан ындырга күтәрелде дә тау битеннән кар ерып уңга таба атлады. Шулчак аның колагына ниндидер елауга охшаган тавыш ишетелде. Шыңшумы бу, елаумы, зарланумы – аерырлык түгел иде. Ул кояш баеган яктагы шәфәкъ кызыллыгында склад почмагына сөялгән Әсгатьне күрде. Ул шыңшый-шыңшый елый иде.

– Монда нишләп сөялеп утырасың? Әйдә, кайтыйк, – дип Ислам аңа якынлашуга, Әсгать дөпелдәтеп күкрәгенә китереп төртте, ул чак кына егылып китмәде.

– Нишлисең син?!

Ул сүзен әйтеп бетерә алмады, Әсгать елый-елый аның өстенә ташланды:

– Үтерәм, күземнән югал! Берегезне дә күрәсем килми! – Ул иелеп, җирдән нәрсәдер алды. Ислам читкә йөгерде, үзе аңа таба борылып, һаман тынычландырмакчы булды:

– Әсгать, туктале, нишлисең син?!

Аның колак төбеннән генә таш очып китте.

– Ычкын, үтерәм, дидем бит!

Аны тынычландыра алмаячагын аңлап, Ислам тау итәгенә йөгерде. Тыкрыкка төшеп җиткәч, артына борылып карады – Әсгать юкка чыккан иде. Ул эченнән гарьләнеп, берни эшли алмаганына гаҗиз булып, үзләренә таба атлады. Капка төбендә туктап, Нурия апа янына кермәкче булды, аннары нигә борчып йөрергә, йөрер-йөрер дә барыбер шушында кайтып керер, дип уйлады. Иртән елый-елый Нурия апа килеп керде. Әсгать кайтмаган булып чыкты.

Ислам ашыгып мәктәпкә китте, Әсгать килеп кермәсме икән, дип көтте, әмма ул күренмәде. Дәрес башланыр алдыннан Ислам бу хакта укытучылар бүлмәсенә кереп әйтергә мәҗбүр булды. Дүрт дәрес укыганнан соң, директор барлык укучыларны, укытучыларны җыеп, Әсгатьне эзләргә чыгарды. Кайсы сыйныфның кайлардан эзләргә тиешлеге билгеләнде. Бу хакта район эчке эшләр бүлегенә дә хәбәр иттеләр. Җирле Совет рәисе белән участок полиция инспекторы да яшьләрдән ике-өч төркем җыйнап, су буйларыннан, әрәмәләрдән Әсгатьне эзләүне оештырдылар. Караңгы төшкәнгә кадәр барлык җирләрне карап чыксалар да, Әсгатьнең эзен таба алмадылар. Икенче көнне озын тәнәфес вакытында аны Чаллы янындагы аэропорттан тотып алып кайтканлыклары турында хәбәр килеп иреште. Мәктәп директоры Шәүкәт Җәмилевич, Раушан Салихович, Нурия апа, участок полиция инспекторы эчке эшләр бүлегенә төшкәннәр. Әсгать

аэропортта кемнеңдер куеп торган сумкасына кереп маташканда эләккән. Эчке эшләр бүлеге начальнигы, килгән вәкилләрнең ялваруларына карамастан, аны биреп җибәрүдән баш тарткан. Гөлсем Шәрифуллинаның әнисе дә Әсгать өстеннән гариза язган. Аны Диләрә Ахуновна полиция инспекторына биргән булган. Шул рәвешле Әсгатькә җинаять эше ачарга барлык материаллар әзерләнеп беткән. Болар турында Исламнарга кереп, Нурия апа елый-елый сөйләде, әгәр Әсгатьне җаваплылыкка тартсалар, ул баланың бетүе булачак, диде. Эшеннән иртәрәк кайткан әтисе шактый вакыт уйланып утыргач, Исламга болай диде:

– Мондый очракларда, улым, аны сез – сыйныфташлары гына коткара алырсыз. Ятып калганчы атып калырга кирәк. Иптәшләреңне тиз генә җый да директор янына барыгыз. Бергәләп район эчке эшләр бүлегенә кабат төшәргә кирәк. Хәзер мин дә машинаны алып чыгам.

Ислам тиз генә киенде дә урамга чыгып йөгерде. Ярты сәгать үттеме-юкмы, бер-берсенә телефоннан шалтыратышып, алар мәктәпкә җыелып беткәннәр иде. Тик фикерләре генә төрлечә булып чыкты. Айгөл, Ләйлә, Энже, Рөстәм белән Ислам Әсгатьне ничек булса да алып кайтырга кирәк, дип өзгәләнсәләр, Риф белән Мансур, Фәйрүзә белән Сөмбел катгый каршы килде. Фаил бер якка да дәшмәде. Шулай да күп тарткалаша торгач, алар Исламның үгетләвенә түзә алмадылар: «Ярар, синеңчә булсын. Без риза, алып кайтыйк», – диделәр. Машинасына директор белән Нурия апаны һәм Раушан Салиховичны утыртып, Исламның әтисе дә килеп җитте. Җәһәт кенә мәктәп автобусына төялеп, район үзәгенә юл тоттылар. Эчке эшләр бүлеге начальнигы янына кергәч, беренче булып Ислам сүз башлады:

– Без аның белән кайтканнан бирле дус. Ул хәзер сыйныфташлар белән уртак тел тапты. Кайтканда, бөтенләй өметсез кебек иде. Апасы Нуриягә хуҗалык эшләрендә ярдәм итә. Без үзебезнең сыйныфыбыз белән аны тәрбиягә алабыз. Зинһар, җибәрә күрегез, – диде.

Шәүкәт Җәмилевич та, полиция инспекторы белән Раушан Салихович та баланы бары тик мәктәп шартларында гына тәрбияләп булачагын, аның әле генә детдом тормышында яшәп кайтканлыгын бәйнә-бәйнә дәлилләделәр. Эчке эшләр бүлеге начальнигы алар белән килеште. Сыйныфташлар исеменнән тәрбиягә алу турында үтенеч язылды, барысы да кул куйдылар. Тагын нindидер документлар тутырылды. Бу мәшәкатьле эшләрне башкарганда, Әсгатьнең үзен полиция начальнигы бүлмәсенә алып керделәр, аңа туктаусыз сораулар яудырдылар, ул төзәлермен, кабат тәртип бозмам, дип кат-кат вәгъдә бирде. Автобуста ул ялгызы бер почмакта кайтты, беркемгә дә башын күтәреп карамады. Әле кайткач та, Әсгатьне Шәүкәт Җәмилевич, Раушан Салихович, Нурия апа директор бүлмәсенә алып кереп киттеләр. Шуңынчы түзеп кайткан Нурия елый-елый Әсгатьне кочаклап алды:

– Нишләпләр алай эшләдең, улым?! – диде ул, аның битләреннән үбеп. – Матур гына укып йөри идең бит.

– Бер дә матур түгел, – диде Әсгать. – Бөтенесе дә миңа шакалга караган кебек карыйлар. Китмичә котылу юк миңа.

– Тагын ни сөйлисең?! – диде Нурия, аның күзләренә төбәлеп.

– Их апа! – дип куйды Әсгать авыр сулап.

Шулчак Шәүкәт Җәмилевич аның каршына килеп, күзләренә туп-туры карады һәм:

– Әйт, сине кем кыерсыта? – дип сорады.

– Мин бирүзем! – дип ярсып кычкырды Әсгать. – Минем беркемем дә юк. Әти-әнием дә, өем дә, акчам да юк. Миңа үзем кебек шундый кешеләр кирәк. Бөтен байлыгым – үпкәмдәге чирем, башымның авыртуы, ашказаны җәрәхәте...

– Ләкин боларның берсе дә монда кайткач килеп чыккан нәрсәләр түгел бит, – диде Раушан, сүзгә кушылып. – Без сине ялгызлыгыңнан да, авыруларыңнан да коткарырга тырышабыз.

Әсгать өметсезлеген белдереп, кул селтәп:

– Сез мине коткара алмыйсыз, – диде. – Мин бит күреп торам, бөтенегезнең дә яшәвегезне бозам. Тыштан мине юатасыз, мине якын иткән булып кыланасыз, ә үзегез эчтән бу афәттән ничек котылырга микән, дип баш ватасыз.

– Синең болай дип әйтергә бернинди нигезең юк, – диде Шәүкәт Җәмилевич. – Кайтканнан бирле без сиңа уңайлы шартлар тудырырга тырышабыз...

Аның сүзләрен Әсгать юньләп тыңламады, чөнки ул сүзләр дөрес иде. Әсгать үзенең хаксыз икәнен эченнән сизеп торды. Әмма ерткыч хайван кебек ырылдау, тырнакларын күрсәтү аның өчен отышлы сыман тоела иде...

Директор сөйләп бетерүгә, ул аның ниләр әйткәнен колагына да элмәстән:

– Кагылмагыз миңа, мәктәбегез дә кирәк түгел. Анда бәхетле малайлар, бәхетле кызлар укысын! – дип чыкты да йөгерде.

Мәктәп ишегеннән атылып килеп чыкса, каршысында сыйныфташлары басып тора. Ул арада арттан йөгереп чыккан Раушан аны иңбашыннан эләктерде. Бер генә мизгелгә Әсгать сыйныфташларының күзләренә ялт-йолт карап алды.

– Әйдәгез, сыйныф бүлмәсенә керәбез, – диде Раушан һәм Әсгатьне кулыннан җитәкләп, алдан атлады.

Кызлар-малайлар дөбердәп кереп урыннарына утырдылар. Раушан Салихович ишек янына басты, ә Әсгать түрдә барысына да каш астыннан карап тора бирде.

– Йә, нәрсә әйтәсең иптәшләреңә? – диде Раушан.

– Тотып кыйнагыз мине, – диде Әсгать, башын аска иеп. – Аннары җибәрегез. Сез өстә, мин аста. Чиста белән пычрак бергә була алмый.

– Мондый уйлар ничек башыңа килә синең? – диде моңа кадәр дулкынлануын яшерергә азапланган Айгөл.

Әсгать аңа ялт кына карап алды да карашын аска төбәп, сүзен дәвам итте:

– Сезнең бөтен әйберегез бар. Минем бернием дә юк. Шулай булгач, без ничек бергә булыйк?

Кинәт Фаил сикереп торды:

– Әллә без сине киендермәдекме? – диде ул, Әсгатьнең каршына ук барып. – Сумка да алып бирдек. Бүген без сиңа әти-әниләребезне бирә алмыйбыз бит. Әкренләп бар да җайланыр. Нигә син безгә эт сыман ташланасың?

Әсгать аның бу сүзләренә каршы бер генә сүз әйтте:

– Мин сездән берни дә сорамыйм. Мине җибәрегез генә.

– Кая бармакчы буласың син? – диде Ислам, урыныннан торып. – Без синең якын дустың, дип полиция начальнигы алдында ант итеп, имзаларыбызны куйдык. Ә син шуны кире кагасың.

Әсгатьнең әллә нинди усал сүзләр әйтәсе килде, тик теле әйләнмәде. Ул үзе дә сизмәстән елап җибәрде.

– Мин кызганырлык кеше түгел, – диде ул күз яшьләре аша. – Эчем тулы

явызлык. Мин үземә ышана алмыйм. Күңелемә генә юньле орлык та төшми. Файдалы үсемлекләр урынына усал еланнар, чаяннар ярала. Аны ничек рәткә китерергә икәнен белмим. Зинһар, ярдәм итегез миңа. – Ул озак итеп күз яшьләрен сөртте. – Эчемдәге явыз еланнар ысылдап күтәрелгәнче, әйтеп каласы сүзем шушы. Гафу итегез, димим. Гафу итә торган кеше түгел мин. Кайтып китәргә рөхсәт итегез, зинһар...

– Бар, тынычлан, – диде Раушан.

Әсгать акрын гына чыгып китте. Аның артыннан башкалар да кайтырга кузгалдылар. Шулчак Айгөл Исламның җиңеннән тартты, ул адымнарын акрынайтты, алар арттарак калдылар.

– Нәрсә бар?

– Теге чакта минем өчен акча түләгәнеңә ачуым килгән иде. Мин хаксыз булганмын. Зинһар, гафу итә күр инде, – диде Айгөл, карашын аңардан яшереп.

Ислам җиңелчә генә көлеп куйды һәм болай дип сүзне бетерде:

– Беләсеңме, Айгөл, без икебез дә хаксыз булганбыз. Син дә мине гафу ит инде.

Әсгать кайтып ашау белән сузылып урынына ятты һәм шундук йоклап китте. Нурия апасы янына килеп, аның күгәргән, шешеп чыккан, сыдырылган йөзенә карап торды. Уч төбе белән йомшак кына кагылып, маңгаена орынды. Әсгать йокламаган булган икән. Ул күзләрен ачмыйча гына:

– Нурия апа, маңгаемнан бер генә сыпыр әле, – диде.

Нурия аның теләген үтәде.

– Рәхәтме?

– Әнием сыпырган кебек...

– Син аны хәтерлисеңмени?

– Хәтерләмим, – диде Әсгать һәм шактый вакыт дәшми торды. – Мин йокларга яткач, бәләкәйдән үк аның кул җылысын сизә идем... Битемнән үпкән кебек тә тоела иде... Төшемдә дә әнине шулайрак күрә идем... – Ул бик озак уйланып ятканнан соң, әллә нинди сагышлы тавыш белән сүзен дәвам итте: – Төштә түгел... өндә... Их!.. Әллә ничә елга бер генә килә шул әни... Шундый сирәк... Әти бөтенләй килми...

Нурия апасы күзендәге яшьләрен сөртеп, пышылдап кына сорап куйды:

– Син аны чыннан да күрәсеңме?

– Күренми ул... кулының җылысын гына сизәм... Беренче сыйныфта укыганда, кулларымны сузып, тотып карамакчы булган идем... шундук юкка чыкты... Яңадан әллә ничә ел килмәде...

– Башыңа начар уйлар кертмә, балам, – диде Нурия апа. – Әгәр күңелеңдә игелек булса, әниеңнең рухы килми калмас. Йөрәгем сизә: бүген киләчәк ул сиңа.

Бу төндә Әсгать бик тыныч йоклады. Таң атканда, нindидер серле дөнья аны үз кочагына алды: имеш тә, ул шушында Нурия апаның ишегалдында басып тора, янәшәдәге коймалар, капкалар, йортлар, агачлар – һәммәсе җем-җем итеп торган чәчәккә төренгәннәр. Шунда Әсгать әнисенең тавышын ишеткән кебек булды. «Балам, сине җиһан тәбрикли. Син бүгеннән мәңгелек бөек рух белән кушыласың. Син гомереңне чәчәкле якты юлдан дәвам итәрсең». Әсгать бу сүзләрдән изрәп, күзен йомды һәм әнисенең башыннан, аркасыннан йомшак итеп сыпыруын тойды. Ул Гөлбакча авылы кочагында төш күрә-күрә йоклап ятканда, барачак юлының башкалар белән бергә булуына ышанды...

## Беләктән йөрәккә үткән чеметү

Өченче дәрес математика иде. Тәнәфестә Энже Айгөл янына килде.

– Мисалны эшләдеңме?

– Әйе.

– Ул бит әллә нинди. Ничек эшли алдың?

– Ислам ярдәм итмәсә, эшли алмый идем.

– Күчерергә биреп тор әле, – диде Энже, пышылдап.

Айгөл аңа дәфтәрен бирде. Математика дәресенә кадәр булган ике тәнәфестә Энже шуны күчерү белән мәшгуль булды. Өченче дәрескә кыңгырау шалтырап, ишектә Шәүкәт Җәмилевич күренгәндә, Энже Айгөлнең дәфтәрен китереп куйды да «Рәхмәт» дип, беләген бик каты чеметеп алды. Айгөл беләгенең авыртуыннан чак кычкырып җибәрмәде. Иреннәрен тешләп, ул ачу белән Энҗегә карады, тик ул башын читкә борып утыра иде. Айгөл игътибарын дәрескә юнәлтә алмады. Күңелендә рәнҗү дә, ачу да кайнады. Энҗенең үзен хәзер үк барып чеметеп аласы килде.  Утыра торгач тынычлангандай булды. Аның ник чеметкәнен аңлагач, Айгөл үзен аннан өстен итеп тойды. Ислам белән дус булуына көнләшеп эшләде ич ул моны. Әйдә, эшли бирсен. Ислам Энҗегә түгел, Айгөлгә булыша бит әле. Дәрес әзерләгәндә генә дә түгел. Ул бөтен ихтыяр көчен җыеп сабыр итте. Энҗегә бер сүз дә әйтмәде, хәтта аңа ачулануын да тешен кысып яшерде. Исламга да бер сүз дә әйтмәде. Чеметү шуның белән бетәсе, онытыласы иде. Әмма һич көтелмәгән хәл килеп чыкты.

Ял көнне Айгөл гадәттәгечә әнисен мунча кертте. Аның чәчләрен, тәннәрен әйбәтләп юышты. Хуш исле үлән сулары сибеп пар чыгар-чыгара, мәтрүшкәле каен себеркесе белән чапты. Шунда әнисе кинәт кычкырып җибәрде:

– Кызым, ни булды беләгеңә?! Беләк мускулын тартып карагач, Айгөл үзе дә хәйран калды: уч төбе кадәр урын кара янып чыккан иде.

– Нәрсә эшләде ул?

Айгөл башта «бәрелде» димәкче булды, тик ул урын кая бәрелергә мөмкин бу дәрәҗәдә? Әнисе моңа ышанмаячак.

– Әй, берәү уйнап кына чеметкән иде шунда.

Әнисе моны яңадан кабатлап тормас, дип уйлавы белән Айгөл нык ялгышты.

– Кем чеметте? – әнисе кулындагы сабынлы мунчаласын таска атып бәрде. – Уйнап кына чеметү шушындый була димени?! Кем ул?

– Бер кыз инде шунда...

Айгөлнең битараф кына авыз эченнән әвәләп чыгарган бу сүзләре әнисен тагын да ярсытыбрак җибәрде:

– Кем ул кыз?!

– Ярар инде, әни, була торган хәл ул безнең арада.

– Шулай умырып-умырып чеметешәсезмени?

– Юк инде...

– Кем икәнен әйт! – дип кызды әнисе. – Әгәр әйтмәсәң, директорыгызга барам, әйттермичә калмыйм. Моны чын явыз гына эшли ала.

Айгөл әнисенең туктамаячагын аңлады. Тик Энҗенең исемен әйтергә курыкты. Әгәр әйтсә, әнисе мунчадан чыгу белән Энҗеләргә китәчәк, аның әниләре белән тавыш-гауга чыгарачак иде.

– Әйтәсеңме яхшы чакта, юкмы?!

Әнисе Исламның килүен көтеп ала, аны ярата, шулай булгач,  аның бу шуклыгын гафу итәр, дип чамалады Айгөл.

– Шаярышканда Ислам чеметкән иде.

– Әстәгъфирулла! – әнисенең сулышы кысылып туктап калды.

– Авыртмады да ул, – дигән булды Айгөл. – Болай гына күгәргән нишләптер...

– Әйтәм җирле яшереп маташтың. Болай гына, имеш...

Әнисе шуның белән тынды. Ул бу нәрсәне яңадан кабатламагач, Айгөлнең күңелендә кузгалган борчулары юкка чыкты.

Ләкин Нәфисәнең рәнҗеш тойгысы онытылмаган, киресенчә, күңеленең иң тирән чоңгылларына ук үтеп кергән иде. Ул Әмирнең яшь чагында үзе артыннан йөргәнен, әмма ниятенең әйбәт булмаганын исенә төшерде. Ире үлеп, тол калгач та, Әмир җай килгән саен Нәфисә белән очрашырга теләвен читләтеп-чатлатып кына сиздергәләп торды. Малае да атасыннан ерак китмәгәндер. Исламның якын итеп йөрүләре, Нәфисәнең дә, Айгөлнең дә җанына кереп сөйләшүләре тыштан гынадыр. Шулай булмаса, баланың ябык кына беләген шул кадәр умырып алыр идемени? Моны эшләү өчен бик мәрхәмәтсез булырга кирәк бит. Айгөлне исән-имин чакта, эш тирәнгә киткәнче, бу малайдан биздерүне Нәфисә ничегрәк эшләү планын корды. Әле алар бала-чага, мәхәббәт дигән нәрсәне белмиләр, шулай да кызының күкрәкләре ару булып түгәрәкләнгән, инде малайлар шуны күрмәскә сукыр түгел, борыннарына ис кермәс дип тә булмый. Әгәр алар чынлап яратышып китсәләр? О-о-о, ул чакта Айгөлдән колак кагасыңны көт тә тор. Ислам ул талантлары белән авылда кала торган түгел бит инде. Кыскасы, борыннарына ис кергәнче үгезне мөгезеннән алырга булды Нәфисә. Иң элгәре Ходайдан Исламның Айгөл юк чакта килүен сорады. Әгәр килсә, чеметүен әйтеп тормаска булды. Ул төп сәбәп түгел, төп сәбәп аның да канында әтисеннән килә торган әйбәт булмаган теләктә иде. Аны да кычкырып әйтергә ярамый, чөнки гаугасы бөтен авылга таралачак. Сәбәбен дә әйтмәскә, шартлатып араны өзәргә. Нәфисәнең соравын, рәхмәт кенә яусын үзенә, Ходай ишетте бугай, Ислам Айгөл өйдә юк чакта килеп керде. Аның:

– Хәерле кичләр, Нәфисә апа! Исән-сау гына ятасызмы? – дип сәлам бирүенә ул Исламга арты белән торган килеш боздай салкын бер сүз әйтте:

– Ару.

Үзе юк эшен бар итеп, өстәл янында мәшәләнгән булды.

– Айгөл өйдә юкмыни? – дигән соравына җавап бирмәде, ачулы кыяфәт белән аның каршына килде. Нәфисәнең исәнләшүеннән үк Ислам ниндидер күңелсезлек барын сизгән иде инде.

– Ислам, мин сиңа бер нәрсә әйтим әле. Безгә килеп борчылып йөрмә, үскәнем. Синең монда йөрүеңне өнәмәгән, ялгыш аңлаган кешеләр дә күп. – Бу сүзләрне Нәфисә үзе уйлап чыгарган иде. – Әти-әниләреңнең дә ихатада эшләре күптер... Алар да өнәмәс...

– Мин бит Айгөл янына эш эшләшер өчен дип йөрмим, Нәфисә апа.

– Сез яшьләрнең ни дип йөргәнен бер Ходай гына белә. Борчыма син безне. Айгөлгә дә шулай тынычрак булыр. Бу минем сиңа үтенечем генә түгел, таләбем!

Соңгы сүзләрен Нәфисә башын артка ташлап, каты итеп әйтте. Ислам ишетелер-ишетелмәс кенә тавыш белән:

– Ярый алайса... – дип, акрын гына ишеккә атлады.

Шушы сүзләрне әйткәч, җиңеләеп калырмын дип хыялланган Нәфисә бөтен гәүдәсенең авыраюын сизде. Тәрәзә турыннан Исламның капкага таба үтеп киткән шәүләсен салынып төшкән авыр күз кабаклары астыннан томанлы гына шәйләп калды...

***

Айгөл соңгы көннәрдә Исламның үзгәрүенә гаҗәпсенде. Ул аларга килми башлады. Айгөл аңа берни дә сиздермәде, җитешә алмыйдыр дип уйлады. Дәресләрдән соң әле репетиция, әле сәнгать мәктәбе, әле спорт түгәрәге – аның чыннан да вакыты тар. Шулай йөри торгач, Айгөл, түземе төкәнеп, аны берничә мәртәбә үзләренә чакырды, фәлән әйбер пешерәм, төгән әйбер пешерәм, дип тә карады. Тик Ислам кырыкмаса кырык сәбәп тапты, ярар, бушагач та барырмын, дип елмайды. Аның тавышы да, елмаюы да ясалма төсле күренде. Ахырда Айгөл Исламның аларга барырга теләмәвен аңлады. Көндез мәктәптән кайтканда, шаяра-шаяра сөйләшеп, Айгөлләргә кадәр кайта торган Ислам ярты юлдан ашыга-кабалана үзләренә таба борылды да китте. Кич репетициядән соң бергә кайтса да, алар турына җитәр-җитмәс «вакыт юк» дип кайтып китте. Репетициядән Әсгать белән өчәүләп кайтсалар, Айгөлне аның белән калдыру ягын карады. Гүя Ислам Айгөл белән янәшә булудан курка иде. Тора-бара Ислам урынын Әсгать биләде. Тышкы кырыслыгыннан, кискен сөйләшүеннән Айгөл аннан элек куркыбрак йөри иде. Ул үзе ягымлы гына малай икән. Әсгать Айгөлне бик күп шагыйрьләрнең шигырьләрен сөйләп шаккатырды. Тик Ислам Айгөлнең күз алдыннан гел китмәде. Аның тавышы, көлүләре ишегалдында эшләп йөргәндә дә, өйдә чакта да гел колагында яңгырап торды. Аңа Исламсыз кызык бетте. Мәктәптә, репетициядә очрашулар аның күңелен күтәрмәде, киресенчә, йөрәген генә сыкратты. Айгөлне хәтта төнлә йокысыннан уятып, бер сорау борчыды: «Нәрсә булды аңа? Ник килми ул?» Әсгать сәбәпче түгелме икән, дигән уй күңеленә керә башлауга, Айгөл ул уйны читкә куды. Бу чынбарлыктан ерак иде. Алайса ни соң? Күптән түгел район мәдәният йортында югары уку йортлары студентлары белән очрашу булган иде. Шуннан соң, «мин фәлән институтка барам, мин төгән җиргә укырга керәм», дип алдагы хыяллары белән уртаклашу модасы башланды. Модасын мода, әмма бу очрашу чыннан да тугызынчы, унынчы, унберенче сыйныфларның күңелләрендәге яшерен хыялларын дөрләтеп җибәрде. Исламның аларга килми башлавы да нәкъ шушы көннәргә туры килә ләбаса. Аның сәләтләре күп, кайсы юнәлештә китсә дә югары очачагы бәхәссез. Ул биеклеккә беркайчан да менә алмаячак Айгөл аңа нәрсәгә? Әнә янында чәчрәп торган Энҗеләр, Фәйрүзәләр, Сөмбелләр, Лилияләр, Ириналар бөтерелә. Башка сыйныф кызлары да Исламны үз урталарына алырга җай эзләп кенә йөриләр. Исламга аның бернинди үпкәсе дә юк. Һәркем үзенә уңайлыны сайларга хокуклы. Аның бит Айгөл алдында сүз биргәне дә, үз өстенә гомере буе тормышта алга сөйрәп алып барырмын, дигән бурычы да юк. Әгәр Исламга ачуы килсә, Айгөлгә, бәлкем, җиңелрәк булган булыр иде. Юк, ул аны ачулана алмады. Ул моңа кадәр күрсәткән ярдәмнәре, игътибары өчен аңа бик тә, бик тә рәхмәтле иде. Айгөлнең күңелен иң якын туганыннан аерылгандагы шикелле юксыну ачысы өттерде. Ул ачы бер генә минутка да йөрәген ычкындырмады. Айгөл рәхәтләнеп ашый алмады, йокысы качты, күзгә күренеп ябыкты. Юксыну ачысы кимсенү тойгысы белән кушылып, әнисе күрмәгәндә, мал-туар арасында абзарда эшләп йөргәндә, яшерен күз яшьләре коюга китерде. Айгөл үзен бу дөньядагы иң бәхетсез кеше итеп тойды. Ахырда ул сабырлыгын тәмам җуйды. Беркөн мәктәптән кайтканда, кайнар яшь тулган күзләре белән аңа карап:

– Ислам, ни булды? Ник безгә килмисең? – дип пышылдады.

Ислам аны бу кыяфәттә күреп, әллә нишләп китте, Айгөлнең йөрәк ачысы дулкын булып аның да җанын өттереп алды. Ул Айгөлнең күзләренә кыенсынып кына карап:

– Әниеңнән сора, – диде дә үзләренә таба китеп барды.

Айгөл кайту ягына атлады, тик әле генә Ислам әйткән сүзнең мәгънәсе һаман аның зиһененә барып җитә алмады. Ни аңлата ул? Димәк, аның мәгънәсен бары тик әнисе белә. Айгөл адымнарын кызулатты, өйгә ул инде сулышы кабып килеп керде. Әнисе чәй эчеп утыра иде. Айгөл сумкасын идәнгә шапылдатып атты да өс-башын чишенмәгән килеш әнисенең каршына килде һәм акырып сорады:

– Әни, нишләп Ислам безгә килми?!

Кызының бу кыяфәтен күргәч, ачыргаланулы бу сүзләрен ишеткәч, Нәфисә кулындагы чынаягын чак төшереп җибәрмәде. Авызына капкан ризыгын йотар-йотмас сикереп торды, әмма теле сүз әйтергә әйләнмәде. Айгөл елый башлады:

– Әни, ник дәшмисең?! Ислам синнән сорарга кушты...

Нәфисә үзен булдыра алганча кулга алып, сүз башлады:

– Кызым, иң элек чишен дә яныма утыр әле.

– Кызым, еларга түгел, шатланырга кирәк, – Нәфисә аның чәчләреннән сыпырды, кызын кочагына алды. – Исламның тыштан бер төрле, эчтән бөтенләй икенче төрле икәнен күрдек ич. Ябык кына тәнеңне сөягеннән умырып ала язган! Әз генә миһербаны булган кеше шушыны эшли аламы? Йә, уйлап кара үз башың белән!

Айгөл елавыннан туктап, уйга калган иде. Нәфисә «әйткәнемне аңлады», дип куанды һәм кызын ныграк инандыру өчен дәлилләрен көчәйтте:

– Ярый без аның кем икәнен вакытында белеп алдык. Аның әтисе дә хатын-кызларга җиңелрәк караштa иде. Шуңа күрә мин Исламга безгә килеп йөрмәскә куштым.

Әнисе тагынниләрдер сөйләде, әмма Айгөл икенче уйларга баткан иде. Бу хәлнең килеп чыгуында ул төп гаепле кеше үзе икәнне бөтен аяусызлыгы белән аңлады. Айгөлгә әнисен алдарга кирәк булмаган. Исламны бер гаепсезгә әнисе каршында әшәке зат итеп калдыручы ул – Айгөл! Хәзер инде чын дөресен әйтсә дә, әнисе ышанмаячак! Ничек төзәтергә соң бу хәлне? Барысы өчен дә үзем гаепле икәнмен, ахыргача шулай булып калырга тиешмен, дип уйлады Айгөл ныклы карарга килеп.

– Әни, мин сиңа әйтмәгән идем, монда төп гаеп миндә бит! – диде ул әнисенә түбәнчелек белән.

– Ничек синдә?! Ничек синдә?!

– Миндә! – дип алдашты Айгөл күзен дә йоммыйча. Чөнки бу кыен хәлдән чыгарса, шушы гөнаһсыз алдашуы гына чыгарачак, дигән ныклы карарга килгән иде ул – Мин Исламны үзем башлап чеметтем. Атна буе туктаусыз борып-борып алдым.

– Нишләп алай эшләдең?! Анда ни ачуың бар иде?! – дип шундук ышанганын күрсәтте әнисе.

– Үзем дә белмим. Аның миннән яхшы укуыннан көнләштем бугай. Кайчакта урамда-мазарда чеметкәндә, кычкырыплар җибәрә иде бичара. Ә ул мине нибары бер мәртәбә чеметте...

Айгөл инде үз ялганына үзе ышана ук башлады, ахрысы. Нәфисә аны

тыңлап-тыңлап утырды да, үзенең кыз чакларын исенә төшерде һәм авызын бияләй кадәр җәеп, башта көлеп җибәрде, аннары яшьлек елларын сагынып еларга тотынды, соңрак көлүе белән елавы бергә кушылды: икәүләшеп елап-көлеп туйгач, алар тынычланып калдылар. Салкын бозлы яңгыры белән килгән давыл үтеп киткәч, дөнья ничек тынычланса, аларның да җаннары бер-берсенә якынаеп, күңелләре җиңеләеп калган иде...

## Әйтер сүзләрем күп, әмма...

Тугызынчылар, унберенчеләр хәзер БДИ дип хәлдән тайдылар, укуларын онытып, репетиторга чабып, югары баллар җыю хыялы белән йөриләр, шул хыяллары белән йоклаганда да саташалар. Ислам иң элек Айгөл белән, аннары Энҗе, Ольга, Фәйрүзә белән биеде. Әллә игълан ителәчәген белеп, әллә болай гына Сөмбел Ислам янына килеп басуга, ак танец игълан иттеләр һәм ул Исламны биергә чакырды. Башта алар бер сүз дә дәшмәделәр, бер-берсенең күзләренә карашып кына алдылар. Сүзне Сөмбел башлады:

– Сине Дон Жуан дип йөртәләр икән дип ишеттем.

Ислам тавышсыз гына көлеп куйды:

– Ә сез кем, маркиза? Бөтенесе белән дә шаярасыз.

– Ә син бөтен кызларны да үбәсең. Балачагымда әнкәй минем өстән бикләде дә эшкә китте. Уйный алмадым. Хәзер шуны кайтарам.

– Фаил белән дәме?

Сөмбел башын артка ташлап көлеп куйды. Фаил белән Лилия нәкъ алар янында бии иде. Бераз ераккарак киткәч Сөмбел:

– Ул минем өчен... барыбер, – дип куйды. – Куам, китми, йөри бирә... Беркөн сорый: «Син берәр кешене яратасыңмы соң?» – ди.

Шунда танец бетте. Ислам аның кулын ычкындырмады:

Бу ел чыккан пароходлар
Бар да яшел түбәле.
Әйтер сүзләрем күп әле,
Әйтә алганым юк әле.

Әйдә тагын бергә чыгыйк әле.

Музыка яңгырауга, алар кабат биергә тотындылар.

– Син ни дип җавап бирдең соң?

– Бер яраткан кешем бар, – дидем.

– Кем дидең?

– Фаил дә шул сорауны бирде. Мин «Әйтмим», – дидем. «Мин аны беләм»,– диде ул. «Белгәч ник сорыйсың?» – дидем. «Үз авызыңнан ишетәсем килде», – ди. «Ишет алайса: шул син уйлаган кеше», – дидем.

– Алай икән, – дип куйды Ислам, елмаеп.

– Нигә теге кеше кем ул, дип сорамыйсың? – Сөмбелнең йөзе елмаюдан балкый иде.

– Кызыксынсам, дөрес аңламассың, дип куркам.

– Син шулай куркакмыни?

– Куян кебек калтырап торам, – Ислам көлә-көлә аның кулын кысып куйды.

Танцы бетте. Чыкканда:

– Безне ныклап бәйләүче нәрсә бар икән, дигән уй килде әле минем башыма, – диде Сөмбел.

– Бар. Балачагыбыз.

– Шул гынамы?

Ислам аны коридорның аргы башына алып китте.

– Аңардан да кадерлерәк нәрсәнең булуы мөмкин түгел. Мәңгелек. Үзе саф.

– Балачак... ул иртәнге җәйге томан кебек. Әз генә була да, кояш чыккач, эреп оча. Синең кебек...

– Нәрсә минем кебек?

– Онытгыңмыни? Үткән атнада телефонга СМС җибәрдем информатика дәресендә: «Шундый матур итеп елмайдың. Тагын бер генә елмай әле», дип.

– Әйе шул. Мин елмайдым. Укулар беткәч, стена газетасы чыгарасы идек, син югалдың. Айгөл белән кайтып киткәнегезне әйтте Энҗе.

– Айгөлнең проблемасы килеп чыккан иде.

– Кайсы төшеннән?

– Йөрәгеннән, билгеле.

– Хәл иттегезме проблемасын?

– Өлешчә хәл ителде. Мин килгәндә, стена газетасы редколлегиясе әгъзалары таралышкан иде...

– Алдашасың!

– Иң элек сине Әнәскә утырып киткән диделәр. Синең дә аның белән хәл итәсе проблемаларың булгандыр, дип уйладым.

– Уйланасың икән! – дип көлеп куйды Сөмбел.

– Уйлану гына түгел, күз алдына да китерәм.

– Нәрсәне?

– Кочаклыйдыр дип.

– Кочаклатты, ди!

– Үбәдер әле.

– Үптерде, ди!

– Алайса ник кенә йөри соң ул?

– Ә син ник йөрисең соң?

– Синең белән рәхәт булганга.


– Ул да шуңа күрә йөридер.

– Ә син үзең ни дип йөрисең?

– Мин йөрмим. Укыйм. Әни янына кайтам да икенче көнне тагын сезнең янга укырга киләм. Әнәс мине авырыксынмыйча машинасы белән ташып йөртә. Бүген дә ул мине көтеп тора әнә.

Сөмбелнең беркайчан да андый серле, матур итеп елмайганын күргәне юк иде Исламның. Бу елмаю бик озак аның күз алдыннан китмәде...

*(Дәвамы киләсе санда.)*



Марат
Кәбиров

# БАЗАРДА ҮЗ ХАКЫҢ БУЛМАГАНДА...

## Бер адым

Җиңүче булырга теләдем...
Тик җиңү юлларын белмәдем...
Юлларын белмәгән килеш тә
Мин җиңеп чыгарга теләдем.

Сез миннән көлдегез генәдер:
«Син әле... кем әле... йөзләрдер... меңгә бер...»
Җиңүләр меңгә бер булсыннар,
Тик мин бар...
Һәр шәхес – бердәнбер.

Һәр шәхес бердәнбер булса да,
Язмыш бар...
Язмышлар – кемнәндер...
Җиңүче булырга теләдем.
Кемнәрдер көлгәндер... көлгәндер.

Хыялны шәм итеп яндырдым...
Шәмнәрем кайвакыт сүнгәндер.
Сүнгәнен кемнәрдер күргәндер...
Көлгәндер.
Көлгәннәр меңнәрдер...

Ә хаклык сан белән үлчәнми...
Төркемнең йөзе юк, заты юк.
Мескеннәр –
Мәңгегә
Мескеннәр:
Мескеннең җиңүгә хакы юк.

---

Марат КӘБИРОВ (1970) – *шагыйрь, прозаик; «Онытма таңнарны», «Мәхәббәт яңгыры», «Китап» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

Мин дә шул мескенлек эченнән
Атладым җиңүгә бер адым.
Күрделәр...
Көлделәр...
Сөрделәр...
Җанымны телделәр – чыдадым.

Чыдадым – бу мескен төркемгә
Тимәс дип зыяным... (Файдам да?!.) –
Никадәр гайрәтле булсам да,
Ялгызым идем мин мәйданда.

Ялгызым...
Тик сиңа ташланган
Төркемнән дә зуррак явыз юк.
Ул төркем безнеке – мескеннәр...
Бердәнбер булу ул – ялгызлык...

Ләкин мин җиңәргә теләдем,
Җиңәргә... ялгызым булсам да.
Ялгыз җан – яу түгел.
Барыбер,
Бер эзсез югалмас җиһанда.

Җиһанда сакланыр шикелле
Безнең дә самими теләкләр.
Йөрәктән йөрәккә күчәр күк
Җиңүгә әйдәүче сурәтләр.

Өметем яшәтә.
Ә үзем...
Үзем мин җиңүче булмадым.
Шулай да
Мескенлек эченнән
Җиңүгә атладым бер адым.

## Бәя

Асыл яки
Алтын булу гына
Берни түгел әле...
Бу заманда
Алтын булуың да берни тормый,
Базарда үз хакың булмаганда.

Һәркем җирдә үз бәясен яулый –
Кем бәясе ничә алтынлык?!.
Ә бәяң юк икән, кадерең юк,
Бернигә дә, димәк, хакың юк.

Сатылалар: «Сатылмыйм!» – дип яшәп,
Бәяләре төшеп беткәннәр дә:

Сынган өметләрне ялгыйлар да.
Һәм үзләре сына көтмәгәндә.

Гаепләп тә һәм аклап та булмый.
Һәркемнең үз эше... Үз көчедер...
Сатылмасам, кем соң ярдәм итәр?
Ә сатылам икән, кем кичерер?

Гаепләп тә һәм аклап та булмый...
Һәм аңлап та булмый...
Бу заманда
Алтын булуың да берни тормый,
Базарда үз хакың булмаганда.

Тик шулай да
Кем бәяли икән
Иң-иң асыл затын заманнарның?..

Сатылмаганнарның бәясе – юк...
Бәясе юк(!) – сатылмаганнарның...

## Сәер мизгел

Әллә нинди сәер мизгел бу,
Аңлый торган мизгел түгел бу.
Сәер мизгел хуҗа дөньяга –
Әллә яңгыр, әллә кар ява.

Әллә көлә, әллә елый ул,
Әллә йоклый, әллә уяна...
Сәер мизгел хуҗа дөньяга –
Әллә яңгыр, әллә кар ява.

Әллә нинди сәер мизгел бу,
Аңлый торган мизгел түгел бу.
Әллә нинди халәт җанда да –
Әллә яңгыр, әллә кар ява.

Әллә көләм, әллә елыйм мин,
Әллә йоклыйм, әллә уянам...
Сәер мизгел хуҗа җанга да –
Әллә яңгыр, әллә кар ява.

## Бозлавык

*Гололёд на земле, гололёд...*
В.Высоцкий

Егыла урамда малайлар,
Абруйлы абзыйлар егыла.
Бозлавык үзенә суыра,
Карамый кечесе-зурына...

Аякта нык басып килгәндә,
«Мин мәңге егылмам!» – дигәндә,
Тая да егыла кешеләр.
Егылып мәңгегә имгәнә.

Кемнәрдер имгәнә бүген үк,
Кемнәрдер иртәгә имгәнер.
Егылмый калырга тырышып,
Шуышып яшиләр кемнәрдер.

Бозлавык бу җирдә, бозлавык...
Без дә бер егылмый узмадык.
Сау гына узарлык юл да юк,
Бозлавык бу дөнья, бозлавык.

* * *

...Кайларгадыр ташлап калдырулар
Җиңел дисеңмени үткәнне син?!

Хәтта гади генә шәһәрдән дә
Китәм диеп кенә китәлмисең.

Китәм диеп кенә китеп булмый.
Китәм, китәм диеп, еллар узды...

Китәм диеп узган елларымдай
Җырларым да бераз сызланулы.

Бәхет микән, бәхетсезлек микән
Яңа ярга аяк басуларым?..

Китүләр ул – кителүләргә тиң:
Үзем генә беләм ачыларын.

## Яралы яугир

Сызыла йөрәк маем,
Алга атлаган саен.
Алга атлаган саен
Урында калу кыен.

Чигенү мөмкин түгел.
Бер адым... Тик бер адым
Атларга иде тагын.

Йөрәгем – телем-телем...
Чигенү мөмкин түгел,
Чигенү – ярты үлем.

Аз гына чыда, җаным.
Бер адым... Ярты адым....
Бер адым...
Ярты адым...

## Өмет

Өметеңне өз дисең син...
Өзелде инде өмет.
Үземнең дә хәлләрем шул
Өзелгән өмет кебек.

Мәңгелек түгел өмет тә
Өзелә – түзми икән.
Өметләрең өзелсә дә
Сөюләр сүнми икән.

Сүнми икән, дөрли икән,
Тынгылык бирми икән.
Киртәләрне бар дип белми,
Тәртәгә керми икән.

Өметеңне өз, дисең син,
Өмет ул... Өзек бит ул...
Өзелә дә ялгана ул...
Шуңа да өмет бит ул.

## Соңгы озату

Мин юлларга китәм инде...
Юлларга китәм инде.
Син беләсең кайтмасымны,
Мин беләм көтәреңне.

Елмаеп кул болгап калдың,
Кузгалмый озак тордың...
Бу минем соңгы китүем,
Бу – соңгы озатуың.

Китеп бардым. Көтеп калдың.
Аралар ераkланды.
Еламадык. Араларда
Мәхәббәт елап калды.

Мин китәмен, син каласың,
Кемгә калырсың инде?!
Кемгә калсаң да, барыбер
Көлгә калырсың инде.

## Хәбәрләр юк

Хәбәрләр юк синең тарафлардан,
Синең тарафлардан җил исми.
Җил иссә дә, кайнар хисләреңне
Алып килми миңа килешли.

Әллә инде җилләр аяусызлар,
Әллә инде үзең сүрелдең?
Җилләр генә шундый аяусыздыр,
Сүрелүең дөрес түгелдер.

Хәбәрләр юк синең тарафлардан,
Хәлләреңне белми тилмерәм.
Язмышларың кайда йөртә икән,
Нинди уйлар белән, кем белән?

Йөрәк хәлен йөрәк сизә, диләр…
Шулай дигәннәре хак микән?
Синең дә шул ачы билгесезлек
Утларында янган чак микән?

Хәбәрләр юк синең тарафлардан.
Кайчан килер икән хәбәрең?..
…Хәлләреңне белү белән генә
Җиңеләер кебек хәлләрем.

## Тәрәзәмне кем кага

Тәрәзәмне җил кагамы?!
Тәрәзәмне кем кага?!.
Уянам да йоклый алмыйм,
Җил кагылып узса да.

Кайтыр кешем юк бит инде,
Тәрәз кага җил генә.
Тик кемнедер көтә күңел,
Кем өчендер өзелә.

Тәрәзәмне кемдер кага,
Төн бит инде – кем анда?!
Кайтыр кешем юк бит инде,
Җил дә тынган урамда...

Урамнарда җил дә юк бит,
Юк бит кайтыр ярым да.
Тәрәзәмне кемдер кага
Төннең урталарында...

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

Фирүзә
Җамалетдинова

# КОШЛАР ОЯ КОРГАН ҖИРДӘ...

РОМАН

Ул көннәр сулардай аккан... Ни гомерләр үткән инде...

Җиһангөл үзе укыткан мәктәбенә таба бара. Соңгы тапкыр... «Йа Раббым, көч бир, сабырлык бир!» – дип пышылдый тау җилләре көйдергән иреннәре.

Хәтере шигъри юлларны яңарткандай итә:

Үкенмәскә иде, үкенмәскә,
Үкенмәскә кирәк үткән эшкә...

Тәненең авырлыгын, сөякләренең картайганлыгын сизеп атлый ул. Үткән икән лә гомер, үткән!

Озак, бик озак барды сыман Җиһангөл. Әйтерсең, авыр йөк салып меңьяшәр тауларга үрмәли. Үз язмышыннан күпкә көчлерәк икәнен тоя ул бу мәлдә. Таулар гүя аны танымый карап тора. Ә бит мәктәп белән ике арадагы юлны ничек узганны сизми дә кала иде. Коштай очып кына үткәндәй тоела иде...

Менә ничек үзгәрә бит тормыш! Хәер, табигать үзе дә гел үзгәрештә түгелме? Челтерәп аккан шифалы чишмәләр, тозлы сулар, диңгез-океаннар бар. Һәммәсе үзе су гына, ә үзе хикмәт инде! Чишмәләр кушылса, зур суга әйләнә. Алар диңгез-океаннарга агып төшәләр дә тозлыга әвереләләр. Үзе камиллек, үзе могҗиза түгелме бу? Тик... Тик кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр дә, кешеләр үзләре дә күпкә катлаулырак шул. Океаннар океан, диңгезләр диңгез ярыннан чыкмаса да, кешеләр җир өстенә сыеша алмый... Ә бит игелек орлыкларын салмады түгел Җиһангөл, салды. Кечкенәдән салырга кирәк дип тырышты. Шулай да каян килеп чыкты соң әле бу явызлык?

Җил кояш баешы тарафыннан исә, мөгаен, яңгыр китерер. Хәерлегә булсын... Менә үргә дә күтәрелде. Адымнары салмак, үлчәп кенә атлаганын күрәләрдер. Күңеле дә бер дә үз урынында түгел сыман. Баш өстендә инде картаеп ныгыган өрек, чикләвек куакларының тыйнак шыбырдашканы ишетелә. Алар аны таныдылар мәллә соң? «Кая югалдың син, Җиһангөл? Синең нечкә билле, озын толымлы, багалмадай тулышып өлгергән чагыңны без әле онытмадык», диләрдер. Ничекләр чая кыз идең бит син, диләрдер. Һәрвакытта үз сүзеңне үзең әйттең. Давылга каршы чыгып басарлык көч йөртә идең ләса күкрәгеңдә, нигә шулай кинәт җебеп төштең әле, диләрдер. Хәер, ул моңа җавап бирә алмас та иде. Чит җирләр күзләремнең төсен алды, сагыну сагышы күз төпләремне җыерчыклар белән бизәде, дисенме? Аякларым да, гәүдәм дә хәлсезләнде, чөнки бу җиргә мин яшьлегемне бирдем, гомеремне

*Ахыры. Башы узган санда.*

бирдем, дисенме? Кеше өенә үз уставың белән керергә ярамый. Чит йортта күпме яшәсәң дә, нибары өйдәш булып кына каласың икән. Ни әйтсәң дә, торган җир туган җир була алмый икән ул, дисенме?..

Йә, нәрсәгә иреште соң Җиһангөл? Хәләл көче белән төзегән йорт-җирен үзбәкләрнең үзләренә үк калдырып китә. Ул өйдә аның хәләл хезмәт көченә бөртекләп җыйган әйберләре дә шактый. Аларны балаларның йөк авырайтып алып торасылары да килмәде. «Тәлинкә-кашык Казанда да бардыр», дип кенә җибәрделәр.

Нәрсәгә ирештеме? Әйе, кадер-хөрмәткә иреште. Менә аны саубуллашу мәҗлесенә чакырдылар. Ул белә: үзе хакында җылы сүзләр сөйләүчеләр күп булыр. Чөнки бу мәктәптә инде аның укучылары укыта. Әйе, барысы да диярлек. Рус теле укытучылары гына читтән килгән, диләр.

Үзбәкләрне үзе дә хөрмәт итте. Килгән көнне үк аңлады: үзбәк теле ят тел түгел икән. Һәр сүздән таныш мәгънә, таныш җылылык сирпелеп тора. Ризыкларына да тиз ияләште. Табигатенә дә. Хәтта башына кереп карамаган эшен дә ярата булып чыкты. Балаларсыз тормышны ул хәзер күз алдына да китерә алмас иде.

Кемдер аңа: «Синең бүген эшләгән яхшылыгың иртәгә онытылачак, әмма барыбер булдыра алганча игелек кылырга тырыш», – дигән иде. Әйе, булдыра алганча игелек кылырга тырышты. Балаларга йөрәген өзеп бирергә дә әзер иде. Аларның гыйлем аласы килә, укырга-язарга өйрәнәсе килә, аларга ярдәм кирәк иде. Ярдәм итте Җиһангөл. Үзенә шушылай ташланырлар дип уйлап та карамады ул. Юк, хәер, артыннан картлык дигән галәмәт куа килмәсә, әле дә ярдәм итәр иде. Өйгә киңәш сорап кагыла үтүчеләрне дә бер дә борып чыгарганы юк. Үзен олылаганнарын белеп яши иде сыман ул. Ничек болай килеп чыкты соң әле? Еллар буена ирешелгән биеклекләрең бер мизгелдә ком тавыдай ишелер дип кем уйлаган?! Һай, тотрыксыз икән лә бу дөнья дигәннәре...

Җиһангөл күзләрен җиргә кадап атлый торгач, күтәрелеп кинәт алга карады, газиз мәктәбен күрде. Әйе, әйе, барысы да бүгенгедәй күңелендә аның: бер генә вакыйганы да теге заманнардан казып аласы юк.

Бер тәрәзәсез, иске камыш йорт та юк шул инде. Ул килгән еллардагы тәрәзәсез мәктәпне сүтеп, балчык-ташларын таулар арасына ташыдылар. Зур тәрәзәле өр-яңасын салып куйдылар. Әле балчык стеналарны Җиһангөлләр кирпеч белән үзләре тышлашты. Укытучылар өчен берсе дә ят эш түгел иде. Алар эшләргә, бөтен күңел байлыгын, матурлыгын сала-сала эшләргә генә тиеш иде.

Шунда аның яшьлеге якты хыялына ашыга, уйлары игелеккә тарта, хисләре һаман туган җире белән тоташа иде. Мәктәпне сүткәч, өч төнне күз яшьләренә манчылып кичте Җиһангөл. Аның урынына шыбыр пыяладан торган бик күп тәрәзәле ике катлы ташпулат калкып чыкты. Әнә ул газиз бинаның ничәмә-ничә күзе аңа томырылып карап тора. Дөресрәге, аны төзүдә укытучылар үзләре дә булышты.

Димәк, балаларга бу белем учагы әле тагын да гасырлар буе хезмәт итәчәк. Димәк, юкка яшәлмәгән...

Үзбәк егете Бәкернең мәхәббәтен кире кагуын хуплап бетермәсәләр дә, яраттылар Җиһангөлне. «Ул үзе замана шалапае булса да, Бәкернең ата-бабалары эш белән яшәгән кешеләр. Иң олы агасы ил, Ватан өчен шәһит китте. Нәселе начар түгел аның», – диделәр. Сугыштан исән кайткан агалары татар кызларына өйләнде, ил-көнгә үрнәк гаилә кордылар, диделәр.

Көн саен бәхетле йөзләрне күрү, чыр-чу килеп чабышкан шаян-шук балалар аның гомерен шушы җирлеккә бәйләп куйды. Мәңгелеккә дип уйлаган иде. Туган җирне берни алыштыра алмаса да, ул бу ком чүлен туган җирен яраткандай яратты. Чит-ят җирдәге чит тавышларны, чит тынлыкны тыңларга өйрәнде. Тәмуг утыдай кояшта ныгыган һәр үсемлекнең, һәммә тереклекнең аһәңе башкача: алар күккә якынрак булырга тырышалар икән. Яшен тамырыдай тармаклы-тармаклы арыклар да, текә кыя-таулар да үзенчә серле икән. Югыйсә таулар күчә, диләр. Ә мондагылары күчүне исләренә дә кертеп карамыйлардыр сыман, елдан-ел ныгый баралардыр кебек тоелды.

Дөрес, килгән елларында чилләләргә чыдый алмыйча, чирләп яткан чаклары да булыштырды. Бер кеше тирләмәгәндә дә, өстеннән тир арыктай агадыр кебек иде. Юеш күлмәктән йөрергә кыенсына, шуңа сумкасына алмашка кием тыгарга гадәтләнде. Тора-бара тәмуг эссесе җәннәткә әверелде, башкалар шикелле үк җәй айларының үз рәхәтлеген тоя башлады.

Монда яшәргә, хәтта монда туфракка әйләнергә дип карар кылды. Балаларга да ата-ана каберен читтән, әллә кайлардан эзләп йөрисе булмас, дип фикерләде. Ни дисәң дә, алар шул туфракта яралган балалар ласа.

Үзбәкләр аны тандырда җәймә-күмәч, пылау пешерергә өйрәтте. Гаилә кыенлыкларын җиңәргә укытучылар булышты. Улына алты айлар чагында, зур тәнәфестә улын имезергә кайтып килер иде. Соңга калган вакытлары да булыштырды. Шунда башка дәрестән бушаган укытучылар ярдәм итте, алар дәресне башлый торырлар иде.

Менә ничек килеп чыкты бит...

Балалары да үзбәк телен өйрәнмәскә теләп карышмадылар, аларның үзләрен дә уздырып сөйләшәләр. Укый-яза да беләләр. Үзе ничек җиңел өйрәнсә, улы белән кызы да урам балалары белән уйный-уйный ук бөтенесен отып алдылар. Оныкларын әйткән дә юк. Төрки телләрнең, ни дисәң дә, тамыры бер инде... Шуңа бераз төшенсәң, сөйләшеп киткәнеңне сизми дә каласың.

Эшләде Җиһангөл. Тырыш булганы өчен аны башкаларга караганда, күбрәк хөрмәт иттеләр кебек. Юккамыни хәзер дә олысы-кечесе үзенең остазы, укытучысы дип атый. Аның укучылары атказанган фән эшлеклеләре, мөгаллимнәр, дәрәҗәле табиблар, исемле төзүчеләр булдылар. Хәер, кемнәр генә юк алар арасында! Киләләр. Рәхмәтләрен әйтә беләләр. Шул җитә аның үзенә. Нindидер исемнәр алсыннар дип түгел, кеше булсыннар дип тәрбияләде һәммәсен. Үзе дә караңгы кышлакта якты бер нур булып яшәвен белде. Әле дә йорт саен аның калуын, бөтенләйгә китмәвен телиләр.

– Шул сугыш чукмарлары сүзенә карап китәргә җыенасызмы? – диләр. – Ялгышлык бу, бер чик куярлар, бераз көтегез, – диләр.

Әйе, таныды Җиһангөл тәрәзәгә таш атучы Бәкерне. Таныды! Ул да өлкәнәйгән инде югыйсә. Чәчләренә чал төшкән. Үгезнекенә тартым юан муенын ярып:

– Беркемгә дә ташлама юк! – дигән сүзләре карлыга-карлыга чыкты ласа. Үч алу җае туры килгәнгә бик канәгать иде сыман...

Тик мәхәббәтне үч белән буйсындырып булмый шул.

Яшьлегенең бер көнендә кинодан кайтып килгәндә куып тотты аны Бәкер. Бер танышы очрап, йомышым бар дип, Сәгыйтьне читкәрәк алып киткән иде. Кыз тукталып, көтеп торырга яхшысынмады. Дөресрәге, горурлыгы моңа ирек куймады шикелле. Ул егетне көтә-көтә алга атлады. Ул арада шап-шоп атлый-йөгерә Бәкер аның белән тигезләште.

– Егетең шушы буламы әллә? – дип сорау бирде ул, тавышына мыскыллы аһәң салып.

– Әйе, Сәгыйть исемле, – дип җаваплады кыз.

– Ыһым, ыһым, – дип тамак кырып торды Бәкер бер мәлгә. Аннары: – Телисеңме, мин аның муенын борып сындырам... – дип, тешләрен шыкырдатты. – Теге чакта сине кышлакка китергәндә үк «бу кыз минеке булачак», дидем... Телисеңме... Муенын... Хәзер үк...

– Теләмим. Якын кешесенең муены сынуын беркем дә теләмидер. Ачу кемдә дә бар, аны йота белү кирәк. Китегез сез, үтенеп сорыйм...

– Каршы килмә, Җиһангөл...

– Бер күктә ике ай булмый...

Җиһангөлнең бу зат янәшәсеннән атлаганда, кан тамырларында кан туктап калгандай тоелды. Чигәләре шартлардай булып кысты. Нигәдер курка иде ул Бәкердән.

Ул арада аларны Сәгыйть куып җитте.

– Җиһангөл минем туганым була, – дип таныштырудан сүзне башламакчы иде Бәкер.

– Капка баганаларыгыз бертуганмы? – дип, рәхәтлек тоеп көлде Сәгыйть башын артка ташлап. Ул Бәкерне аерым сөйләшүгә читкәрәк чакырды.

Җиһангөл әкрен генә, вак-вак алдырып атлавын дәвам итте. Ниндидер кыргый тавышка артына борылып караса, ни күрсен – Сәгыйть белән Бәкер җирдә әүмәкләшә иде.

– Кычкырам! Кешеләрне чакырам хәзер! Милиция чакырам! – Җиһангөл еламсырап, егетләргә каты итеп эндәште. Таулар аңа кычкырып җавап бирде:

– Кыч-кыр...

Тауларга кайдадыр этәч, кош-корт тавышлары кушылып китте.

Үзе ачуына буылып, әкрен генә алга атлавын белде. Кайсыдыр гөпелдәп җиргә килеп төште. Кайдадыр ябалак ухылдап куйды, таулар ыңгырашкандай тоелды. Кемнәрдер тәрәзә пәрдәләрен ачып карадылар. Сөйләшкән тавышлар ишетелеп-ишетелеп китте. Тик яшьләр янына чыгучы, сугыш чукмарларын аерырга теләк белдерүче күренмәде.

Бераздан Сәгыйть Җиһангөлне куып тотты. Борыныннан кан ага, күз төбе кызарыпмы, күгәрепме чыккан, аның ярты бите караңгылыкта караеп күренә иде. Ай яктысы көндезгедәй якты тоелса да, эңгер-меңгер тәмам төшеп җиткән чакка тартымрак кич иде ул.

– Кыртлаган тавык кебек өскә оча, хәерсез. Бирермен мин аңа! Үзбәктә кыз беткән мәллә? Калым түләмичә генә кыз алмакчы...

– Йә, ярар, мә сөрт битеңне... – Җиһангөл кесәсеннән кульяулыгын чыгарып, егеткә сузды.

Беравык алар сөйләшми генә атладылар. Яп-якты ай аларга йөзе белән борылгандай тоела, яшьләрне сыендырган җиһанга иксез-чиксез нурлар тарата... һәм тугры сакчыдай ияреп, артларыннан кайта иде.

Ул арада аларны милиция машинасы куып җитте. Эчтә Бәкернең тонык шәүләсе чалымлана иде.

– Утырыгыз! – дип катгый боерды милиционер.

Сәгыйть машинага табан атлады.

– Мин дәме? – дип сорау бирде Җиһангөл, нишләргә белмичә.

– Сез дә. Сез – шаһит. Иң дөресен сез сөйләрсез, дип уйлыйм...

***

Нинди матур кич иде ул. Бөтен тарафтан алма, шәфталу исе аңкый. Чәчкәләрдән хуш ис бөркелә. Розалар кеше биеклек булып үскән, алар ай яктысында эре-эре чәчкәләрен көчкә күтәреп, күбәләкләр каршында гүзәллекләре белән масайгандай, горур елмаешып торалар. Табигатьнең һәр тереклеген назлап, йомшак кына җылы җил исә. Адашкан киектәй күк йөзендә мендәр кадәрле генә болыт йөзеп йөри. Карамы ул, әллә зәңгәрме – монысын чамалау һич мөмкин түгел.

Җиһангөл сизде: егет дулкынлана иде. Шактый сүзсез торганнан соң ул куен кесәсеннән бәрхет кап чыгарды:

– Өйләнергә уйладым, – диде елмаеп. – Әйдә, киеп карыйсыңмы?

– Кызык, безнең авылда беркем дә балдак белән өйләнешми. Кайдан таптың син боларны? – дип чыркылдап көлде кыз.

– Монда да бөтенесе түгел инде. Бик яратышканнар гынадыр. Ә кайдан алганны сорама. Махсус, көмешне коеп ясап бирделәр. Оста зәркәнчеләр бар ул безнең тирәдә.

Кыз кинәт көлүеннән туктап калды. Гомәрне күз алдына китерде. «Бер марҗага өйләнгән икән», – дип язган иде әнисе. Янә йөрәгенең кайсыдыр кылы өзелеп киткәндәй булды. Балдакларга күзләрен алмый карап торса да, кияргә ашыкмады.

– Йә, йә, киеп кара инде...

Егет кечкенәрәген кулына алып, кызның атсыз бармагына кидертеп тә куйды.

– Кара, чап-чак. Әллә соң миңа алдыңмы син аны? – Җиһангөл янә чыркылдап көлеп җибәрде.

– Сиңа, гөлкәем, чык миңа кияүгә. Язмыш безне менә шунда китереп очраштырган икән, без дә аңа каршы бармыйк инде...

– Абау, менә сиңа фәлсәфә...

– Минем әни шулай дияргә ярата. Философ түгел ул алай үзе. Татар кызына өйлән, ди. Нәселне әллә кемнәр белән бутый күрмә, ди. Үз өммәтемнең баласы минем дә балам булыр, ди.

– Ә әтиең нәрсә ди?

Җиһангөл монысын белә иде. Сораштыруы бары тик әтисен искә төшереп, егетнең гаиләсе хакында күбрәк беләсе килүдән иде.

– Әтием юк инде. Сугыштан кайтуга вафат булды, – диде егет, тирәннән уфтанып. – Бөтен тәне ярчыктан тора иде аның, әллә ничә кат контузия алган, Берлингача барып җиткән... Кулыннан гөл түгелә иде, ди әни. Мине дә эшкә әти өйрәтте. Кием, савыт-саба шкафларын икәүләп ясадык. Ут чыбыкларын алыштырырга әтидән соң күрше-күлән, таныш-белеш мине чакыра... Сәмәрканд базарында аны танымаган кеше юк, баш иеп күрешәләр иде. Бик күпләргә йортны әти төзеде. Мине дә ияртеп йөрде. – Сәгыйть кызга күз сирпеп, үзе башын чөя төшеп көлеп җибәрде:

– Йә, мактана беләмме?

– Ата мактанчык икәнсең лә, – дип, егетнең сүзен күтәреп алды Җиһангөл.

Кыз башын аска иде. Ник әйткәненә дә үкенде кебек. Нигәдер әтисен, күршеләре Сафа абзыйны күз алдына китерде. Сугыш адәм балаларының аң-зиһененә дә үтеп кергән: бик сирәкләргә кешелеклелек, күпчелеккә кешелексезлек сыйфатлары тагып җибәргән иде. Әтисе, әнә, чит-ят халык

белән бөтен өйне тутырып яшәде. Хәтта авылга кино килсә дә, кешеләр, киномеханикны: «Әнә теге йортка бар син, алар ашатырлар да, чәй дә эчертерләр», – дип, аларга юллап җибәрәләр иде. Хәер, киномеханик та бик мәрхәмәтле кеше: бала-чаганы бушлай кертә. Ике озын эскәмиягә беркетелгән киноаппаратны кем әйләндерә, киноны шул карамый калмый. Әлбәттә, телсез кино инде, сугыш турында. Дөресрәге, киномеханик үзе дә сугыштан кайткан кеше: бик җентекләп аңлатып бара. Бу кеше ил батыры, ди. Әнә ул сугышка керер алдыннан уйлана, ди... Әнә тәмәкесен көйрәтеп җибәрде, ди.

Ә Гомәрнең әтисе, аюдай олпат гәүдәле Сафа абзый, киресенчә, салып ала да ике япьле сәнәген күтәреп: «Кем качырса, шуны чәнчеп үтерәм», – дип, хатынын эзләп йөри. Бәләкәй буйлы, какча гәүдәле Рәфига апаны күзенә күрсәтми. Кайсы капкадан килеп керсә дә: «Теге таракан кая кереп качты икән, күрмәдегезме?» – дип, сорау биреп, йортны бер айкап чыга да ары юнәлә. Урамда эт тә калмый, ул тынычланганчы, кешеләр ишекләрен бикләп, өйдә шым гына утыралар. Бу хәлгә Җиһангөлнең бабасы гына ачыклык кертеп, үзалдына сөйләнеп ала:

– Менә нишләтте бит сугыш гөрнәдирдәй егетләрне, – ди. – Кул-аяк гариплегенә чыдый ул адәм баласы, күңел гариплеге яман... Әле бит ул балаларны да гарипләндерә...

Кырыс кеше шул Сафа абзый. Кырыслыгы белән Гомәргә дә акыл өйрәтмәде ул, һаман кирәксезгә шелтәләп, каккалап-суккалап торды. Шуңадырмы, улы ихтыярсыз егет булып үсте. Бара торган юлыннан кире борылып китү аңа берни дә тормый кебек...

–Ниләр уйлыйсың, матурым?

– Авыл исемә төште... Әтием... Сугышка безнең авыллар гына кергәндер кебек тоелган иде миңа. Баксаң, синең әтиең дә яраланып кайтып вафат булган икән...

– Өмет кайтарган инде аларны...

Шунда кызның әтисе сөйләгән бер хикәят кылт итеп исенә төште:

«Бүлмәдәге үле тынлык эчендә дүрт шәм яна икән. Беренче шәм әйткән: «Мин – тынычлык булам. Әмма минем януымны теләүчеләр дә, аны бәяләүчеләр дә юк. Мин сүнәм!» – дигән. Һәм сүнгән.

«Мин – ышаныч! – дигән икенче шәм. – Ләкин үземнең кешеләргә кирәклегемне тоймыйм, шуңа мин сүнәм...» Һәм сүнгән.

Өченче шәм: «Мин – мәхәббәт! – дип, аваз салган. – Әмма минем тирә-юньне яктыртырлык көчем калмады. Кешеләр мине кабул итмиләр. Хәтта иң якыннарын да яратмыйлар», – дигән һәм Мәхәббәт шәме дә сүнеп киткән.

Шулчак бүлмәгә бер бала йөгереп кергән. Һәм бу өч шәмнән ник сүнүләрен сораган. Сәбәбен белгәч, ул дүртенче шәмнең тавышын ишеткән: «Курыкма, мин янам бит! Минем ялкыннан сүнгән шәмнәр барысы да кабыначак! Алар янә җир өстендәге бар караңгылыкны яктыртыр. Чөнки мин – Өмет!»

Бу сүзләрне тыңлап торган баланың күзләре очкынланган. Ул өмет шәмен кулына алып, өч шәмне дә кабызып җибәргән...

– Кызык, чынлап та шулай бит, бөтенесе сүнеп беткәндә дә, өметләре исән калган... Без дә шул өмет белән яшәдек бит... Яшибез...

– Әйе, өмет белән, – диде кыз. Беразга башларын иеп, сүзсез атладылар. Җиһангөл күзләрен күтәреп, күкләргә төбәлде.

Кыз кинәт болытларга караган көенчә сөенеп кычкырып җибәрде:

– Киек казлар! Кара, һавада өчпочмак ясаганнар!

Киек казлар тезелешеп үткәнне күрде исә, Җиһангөлнең бәгыре телгәләнә, аларга ияреп туган ягына юл аласы килә. Ләкин канатлары юк шул. Хыялы гына канатлы. Шуңа да эче поша: үзбәк җире – сагынган саен кайта торган җир түгел. Ярый әле, сагынганда, күңеле тулы җыр була. Кыз үзе дә сизмәстән:

«Китә казлар, китә казлар», – дип, җыр башлады да туктап калып, аны эчтән генә җырлап бетерде. Кинәт күңеле тулды.

Ә егет аның күңелендәгесен тоймады да кебек. Ул:

– Гел бертөрле оча инде алар. Һәр кош күршесенең канаты биргән һава агымына ышанып бара. Шулай алар көчләрен саклыйлар икән. Югыйсә, ерак юлларга ничек чыга алсыннар соң? – дип, белгәнен сөйләде.

– Сиңа кем әйтте боларны?

– Китаптан укыдым.

– Кызык.

– Монысы әллә ни кызык түгел әле. Кызык китаплар бар миндә, укырбыз бергәләп.

– Кайчан?

– Өйләнешкәч... Чык миңа кияүгә, Җиһангөл! Әнием дә бик әйбәт минем. Килешсәгез, бәлки, бергә яшәрбез.

– Димәк, «А» пунктыннан «В» пунктына килеп җиттем. Татарстан белән Үзбәкстанны тоташтыра ала, димәк, бу нокталар? – дип көлде кыз.

– Мәхәббәтне, йөрәкне йөрәккә тоташтыра. Мин яратам сине, Җиһангөл, нигә дәшмисең?

Егет кызның юлына каршы төшеп күзләренә карады да аны билләреннән кочып күтәреп алды.

– Җә, оялтма инде, – диде кыз, комачтай кызарып.

Очар кошларның канат җилпүен ул тетрәнеп күзәтә, алар артыннан тартылып-талпынып куя, тик шул ук вакытта сөю галиҗәнаплары аны үзенә буйсындыра иде. Теләр-теләмәс кенә:

– Мин дә... – дип, башын аска иде ул.

Ахырдан үкенеп тә куйды: дөрес эшләдеме болай әйтеп? Әле бит мәхәббәтме бу, әллә күз төшү генәме – аңларлык вакыт та үтмәде. Алайса, Гомәр ник һаман истән чыкмый? Аһ, юк, ул өйләнгән ләбаса... Ул балачак дусты, күрше... Кыз Гомәр белән эскәмиядә утырганда кунар җай эзләп, икесе янында да бөтерелгән умарта кортын исенә төшерде. Маэмай әллә кайда кадәрле куа-куа артыннан йөгерде. Без-без итте дә очып китте умарта корты. Мәхәббәтләре дә шулайрак булды түгелме соң?..

Шул мәлдә аның күз алдында ак яллы ап-ак атның йөгәнен учларына кысып тотып, үзе киртәгә кунаклаган соры киндер кепкалы, шакмаклы ситсы күлмәкле шук малай җанлангандай булды. Һай, ничек ярата иде аны атлар! Ерак офыкларга карап чапкан җирдән туктап, янына килерләр иде малкайлар. Үзен дә җирнең чын хуҗасы, диярсең. Ике кадакка эләгеп торган гарбил тактадан сугылган киртә суырылып төшеп, бөтен тынычлыгын җимерер төсле тоелса да, һичкайчан бернинди афәт тә якын килми иде аңа. Әлеге серле мизгелне фотога гына төшереп алыр иде мөмкинлеге булса. Шундый әкияти мәлне ничек үз итмәсен инде йөрәк? Тик мәхәббәтме соң ул? Мәхәббәт шундый буламы? Хәер, икесе өчен дә ул мәхәббәт сер булып калды, авылда да алар хакында беркем бер сүз дә сөйләмәде. Үз-үзенә сораулар бирә-бирә кыз җаныннан чып-чын җавапны табарга тели иде.

Нигәдер Бәкерне дә исенә төшерде. Үч алмасмы? Теге чакта аңардан:

– Бу егетләрнең кайсын сайлый йөрәгең? Ач сереңне безгә дә, чибәркәй. Болай озак дәвам итә алмый, барыбер берсенә «әйе», икенчесенә «юк» дип әйтергә туры киләчәк, – дип, маңгаена төшеп торган чәчләрен уң якка авыштырып тараган, олпат гәүдәле милиция лейтенанты серле елмаеп сорады аннан.

Кызның бит алмалары утка чолганды.

– Без Сәгыйть белән кайтып бара идек... – дип, сүз башлауга:

– Әһә, барысы да аңлашылды болай булгач, – дип, каш астыннан гына сөзеп карады погонлы зат. Шуннан Җиһангөлне тәмәке исе ыслаган тынчу, кысан бүлмәдән чыгарып җибәрделәр. Өч ир заты егетләрчә сөйләшергә теләгәннәрдер, мөгаен, дип уйлады ул.

Бераз баргач, Җиһангөл артына борылып карады.

Башын ия төшеп, чиядәй кызарынып, кызу адымнар белән атлый-йөгерә килгән егетне күреп:

– Ә Бәкер кая? – дип, Сәгыйтьнең күзләренә төбәлеп сорады кыз. Аннан өстәде: – Бигрәк зур бавырлы булып чыкты ул, үзенә күрә генә түгел.

– Аны алып калдылар. Унбиш тәүлеккә... – дип җавап бирде егет бик борчулы кыяфәттә.

– Ни өчен?

– Җәмәгать урынында тәртип бозган өчен.

– Үч алмасмы соң, Сәгыйть? Үчле егеткә охшаган ул.

Егет бераз уйланып торды. Аннан:

– Алмас. Яраткан күңелдә ялган булмый. Тик ул минем өлешемә кермәкче. Бәкер иренен ялап калды бит барыбер, – дип, җиңеллек аша әйтеп куйды.

– Көлмә кешедән...

– Көлеп әйтүем түгел, кеше сынлы кеше булса икән, йөри шунда үзбәк халкын хур итеп... – диде егет һәм өстәде:

– Минем дус егет эшли анда. Кичкә үк чыгар, борчылма...

– Андый киребеткән затлар һәр халыкта бар, – диде Җиһангөл, үзбәкләрне яклый биреп.

– Хыялый гашыйклар диген... Гашыйк булган өчен аны гаепләргә дә ярамыйдыр инде анысы... Гөл чәнечкесез, мәхәббәт көнчелексез булмас, ди минем әни. Болай дип тә әйтә: «Гыйшык – төтенсез ут, ачкычсыз йозак, дәвасыз авыру, савытсыз эчемлек, йөксез авырлык, туктау урыны билгесез сәфәр ул», – ди.

Кыз дәшмәде. Шулай да егетнең «борчылма» дигән сүзе Җиһангөлнең йөрәгенә уктай кадалды. Бәкергә җен ачуы чыкты. Шундый кадерле кичне бозмаса, ни булыр иде инде, җә?!

***

Сәгыйтькә торган саен күбрәк гашыйк булды кыз. Көннәрдән бер көнне егет күрше авылга Татарстаннан бер төркем артистларның концерт белән килүләре хәбәрен ишетеп кайтты.

– Мотоцикл белән барачакбыз, кадерлем, – дип, алдан белгертеп тә куйды.

Җиһангөл, кыен хәлгә генә калдырмаса ярар иде дип, бераз куркыбрак торса да, киресенчә, бу сәфәр егеткә ихтирам хисләре генә уятты. Егет мотоциклны ике мөгезеннән эләктергәч тә, кызга йомшак кына эндәште:

– Өчпочмаклы утыргыч астында ике ягында пружина бар, аннан тота күрмә, кулың кысылыр, «сидение» кырыена тотын, – диде.

Ул көнне кояштан бөтен дөньяга яп-якты эссе нур тарала иде. Тик кызга эсселек кояштан түгел, күз карашларыннан агыла, егетнең сүзләреннән ургыла кебек тоелды. Аның бәхете ташыганы күренеп тора иде.

Кыз җиңел сулап куйды. «Билдән коч, әйдә», – дип әйтер инде дип, коты очкан иде. Ничекләр утырып барасы инде моңа дип, ике бите ут янды, бигрәк тә кешеләрдән оялды. Менә ничек җиңел хәл ителде мәсьәлә.

Күпме гомерләр үтсә дә, күпме сулар акса да, бу җылы май кичен оныта алмады ул. Оныгы еш кына егетләрнең мутлыгыннан зарлана. Хәер, ул үзе дә җебеп тора торганнардан түгел... Ир-ат та тәрбияле иде шул без яшь чакта дип уйлый Җиһангөл. Ни гайрәтле Бәкер дә тәрбиясез түгел иде...

Хәтерендә: җәйнең җиләс кичке һавасына ирек, иркен сулыш теләгәндәй, тәрәзәләрен киң ачып куйды Җиһангөл. Йокламаса йокламас икән бу бала! Нәни кызчыгын йоклата алмыйча интегеп бетте тәмам. Гомерендә исенә төшермәгән бишек җырлары хәтерендә яңарды. Әле берсен, әле икенчесен көйләде.

Әлли-бәлли итәр бу,
Үсеп, буйга җитәр бу.
Үсеп буйга җиткәчтен
Галим булып китәр бу...

«Ничекләр матур икән бит безнең халыкның көйләре! Гади генә дигәннәре дә әллә нинди бетмәс мәгънә сыйдырган», – дип уйлады.

«Җиһангөл җырлый!» – дип тынып калды Бәкер тәрәзә артында. «Ничек матур җырлый икән әй-лә! Әгәр дә минем хатыным булса, ул, бәлки, үзбәк җырларын өйрәнер иде. Әнә бит, абыйларымның хатыннары өйрәнде...»

Сәгыйтьнең эштә икәнлеген белсә дә, тәрәзәгә чиртмәде, өйгә килеп кермәде Бәкер. Тыңлап торды да үз юлына юнәлде. Җиһангөлнең ялгыш кына тәрәзәдән тышка күзе төште. Күрде ул Бәкерне. Башын аска иеп, салмак адымнар белән үз дөньясына таба китеп бара иде...

Җиһангөл янә бишек янына килде. Җырны дәвам итте:

Йокла, йокла, күз нурым,
Йом күзеңне, матурым...

***

Дәрескә килеп утырган балаларның су күрмәгән куллары, чебиләгән тәпиләре Җиһангөлне битараф калдырмады. Иртән мәктәпкә җыенганда, сумкасына бер кисәк исле сабын тыкты. Балаларга дәрес башында ук:

– Дәресне яхшылап үзләштерсәгез, без бергәләп арык янына төшәрбез, – дип өметләндереп куйды. Күреп тора: балалар аның белән җир читенә дә барырга риза. Хәер, бөтенесе дә бала түгел инде, бер үк сыйныфта үзе белән бер яшьтәге укучылары да бар аның.

Арык буйларына әстерхан чикләвеге, сырганак, тут куак-агачлары хуҗа булып алган. Таулардан төшкән су юлын һәр йорт үзенә борып керткән. Кирәк чакта ул юлны ачып, су кирәкмәгәндә ябып куялар. Күп гаиләләр арык кырыйлап, помидор утыртып чыккан. Су ничек кенә салкын тоелмасын, соңгы помидоргача үз җирендә кызара икән. Хәер, көндез җылына инде ул җылынуын. Җимеш-яшелчәләр барчасы җыеп бетермәслек уңыш бирә икән монда.

Җиһангөл кайчакта үзе дә чарасыз кала: предметларны, җисемнәрне

тотып, рәсемен күрсәтеп тә аңлатып була. Ә менә таң ату, кояш баю кебек төшенчәләрне ничек төшендерергә? Кыенга туры килде аңа. Күпме сүзлек актарды. Китаплар укыды. Дөресрәге, үзбәкчәне дә, урыс теленә дә балалар белән бергә өйрәнде.

Укучылары дәресне йотылып тыңлады ул көнне. Аннан бергәләп су янына киттеләр. Битләрен-кулларын гына түгел, иске галошларын да арык суында юа-юа рәхәт чиктеләр. Утракларын суга төшереп югалттылар.

– Апа, солиш төшеп китте, алып бирегезче, – дип, Җиһангөлдән ярдәм сорадылар.

– Нәрсә соң ул? – дип, елмаю катыш аптырап сорады укытучы. Кайсыларыдыр утракны кәлүш төбеннән суырып алып, аның күз каршысына ук китереп куйдылар да «менә ул», диделәр.

Җиһангөл табып кына түгел, утракларын юып та бирде. Кояш астындагы кайнар комда алар шытырдап кибеп тә китте. Арык суында сабын эреп беткәндәй булды, аның каравы икенче көнне укытучы каршына чип-чиста балалар тезелешеп утырды. Үзбәкләр чабатаның ни икәнен белмиләр, дәрескә яланаяк килүчеләре дә шактый иде баштарак. Җиһангөл аларга үзенең искергән галошларын бирә бара. Тегеләре өзелеп аяктан төшеп калганчы кияләр иде. Мамык кырларында тетелеп кенә бетә иде аяк киемнәре. Арыш капчыкларын билгә бәйләп, мамык җыя-җыя, шуны көне буе кыр буйлап өстерәп йөреп кара син! И, шуклыклары да җитәрлек иде инде. Мамык арасына сузылып ятып, «Мең дә бер кичә»дән әкиятләр сөйләшеп мутланганнары да булды. Ачылмаган мамык капларын бер-берсенә бәрешеп уйный башласалар, Җиһангөл хәйләне шунда ук сизеп ала, теге хәйләкәрләрне өннәреннән тиз чыгара торган иде.

– Синекеләр өч килограмм да җыймаган ласа! – дип, Җиһангөлгә аптырап карады мәктәп директоры. – «Позор!» тактасына язарга боларны. Кара тактага! Күрәсезме, апаларыгыз ничек эшли. Йөзәр килограмм җыйганнар! Их сезне! Ишетәсеңме мине, Бәхтияр?

Бәхтияр өчен Җиһангөл дә кызарды ул чакта. Бәкер дә башын иеп, Җиһангөл апасына карамаска тырышып басып торды. Яраткан укытучысын шушылай хур иттеме инде ул ил-көн алдында? Оят иде аңа, оят иде.

Әлбәттә, балалар белә: урта сыйныфларны олылар эшли торган яхшы кырларга якын да китермиләр. Алар җыйган мамык өченче сортка китә. Барыбер дә бу сыек кырлардан да, тырышканда, ким дигәндә, утыз килолап җыеп булыр иде дә бит...

***

Җиһангөлне балалар торган саен күбрәк яратты. Укытучының аларның өйләренә барасы килә, тик һаман кыюлыгы җитеп бетми, бераз гына эчке курку да тотып тора иде. Чөнки фатир хуҗасы: «Монда бөтен ир-атлар да кесәләрендә пычак йөртә, зинһар, балам, ипләп кенә сөйләш», дип кисәтеп кенә тора. Шуңа кыз мәктәпкә җиткәнче: «Ходаем, үзең сакла», – дип, көненә әллә ничә кабатлый.

Шулай да мәктәп директорының хатыны аны тагын өйләренә алып кайтты. «Синең аркада мәктәп районда беренче урынга чыгып бара, без сине бик хөрмәт итәбез», – диде ул. Үзбәк җирендә мәдрәсәләрдә гыйлем туплаган татар зыялыларын – Курсави, Мәрҗани, Утыз Имәниләр хакында сөйләп алды Җиһангөл.

– Мин бу хакта беләм, – дип кушылды директор хатыны. – Үзем дә «Үзбәкстан географиясе»н татар кешесе Җиһанша Бәхтияров язган дәреслектән укытам... Татарларны хөрмәт итәбез без... Сине дә...

Җиһангөл инде чынлап та мәгълүматлы укытучы, белемгә омтылышы ягыннан башкалардан аерылып тора иде. Укытучылар әзерләү мәктәбен дә уңышлы тәмамлады. Читтән торып, югары уку йортына керергә җыенган чагы менә. Шул хакта да сөйләшеп алдылар. Аннан алар икәүләп бакчага чыгып, бәрәңге казыдылар. Бармакбаш кадәрле генә бәрәңгеләрне хуҗабикә юып, кабыгын да әрчемичә ашка салып җибәрде. Җиһангөл сизде: бәрәңге болар өчен ят ризык, ахрысы... Аның каравы, кызны алар тел йотарлык пылау белән сыйладылар. Үзбәкләрнең бөтен тормышы ишегалдында. Тышта аш пешерәләр, үзләренчә камышны балчык белән сылап, ашханә оештырып куйганнар. Тандыр-учаклары янып тора...

Хатын Җиһангөлне үзбәкчә «холвайтар», безнеңчә әлбә ясарга өйрәтте. Онны атланмайда кыздырасы да, шикәрле су, чикләвек салып куертасы икән.

Тагын Җиһангөлне аларның ике яшьләр тирәсендәге кызлары гаҗәпкә калдырды: ул һаман шытыр-шытыр итеп, сукмактагы кирпеч ватыкларын кимерде. «Ашказаны нишли инде бу баланың?» дип уйлады Җиһангөл һәм хуҗадан керосин сорап алды. Аны бала тирәсендәге кирпеч ватыкларына сибеп чыкты. Бала карап торды-торды да бер юеш кирпечне алып авызына капмакчы булды. Теленә керосин тәме ягылды. Ул нәни авызларын бөрә-бөрә төкерде-төкерде дә ачы кычкырып елап җибәрде. Шуннан башкача сукмактагы кирпечләргә күз дә салып карамады. Хуҗа хатын аңа берәр атнадан соң монысы өчен дә рәхмәт әйтте. «Бакча тулы җимеш бит, өз дә аша гына, ә ул кирпеч кимерә, хәерсез», дип уфтанып та алды. Аннан:

– Хәер, мин үзем дә бу балага авырлы чакта кухня почмагындагы штукатурканы кимереп бетерә язган идем, ә энием мине күтәргәндә, шырпы яндырып күкерт исе иснәп утырган. Шуңа микән, теләсә нинди исне тиз тоям мин, балам да шулайрак, Ходайның хикмәте, – дип өстәде.

– Җаны теләгән – елан ите ашаган, – дип кушылды Җиһангөл.

– Елан ите зыянсыздыр әле ул, баксаң. Кытайлар ашый, ди бит аны. Ә кирпеч ашаучыларны бер дә белмим мин...

Икәүләп көлешеп алдылар.

– Ул да хатын-кыз затыннан ич, – дип сүзне йомгаклады Җиһангөл.

***

Җиһангөл, мәктәпкә барып җиткәнче, чибәрлегенә сокланып: «Сөбханалла» дип калучылар янышнан тыныч кына үтеп китә башлады. Үз матурлыгына үзе дә ышана. Артыннан гүя кояш ияреп бара, артыннан гүя таулар ияреп бара – аңа шулай тоела иде. Күңеле тулы җыр иде аның. Күңеле исә чит-ят бу җирдә шушы җырны аңлаучы, үзен яклаучы эзли иде.

Гаилә дигән үз дәүләтеңне төзеп, тыныч кына яшәргә кирәктер, дигән фикергә килгән иде инде ул. Аннан, Сәгыйть – ни дисәң дә, үзебезнең кеше. Аерым йорт җиткерәм, дип тора. Ихаталары да иркен. Тагын биш өй салсаң да сизелмәячәк. Ә туган илгә кайтып нишләр соң? Китәселәр китеп беткән бит инде...

Туйны туган-тумача белән генә үткәрергә җыенсалар да, үзбәкләрдә бу мөмкин хәл түгел икән. Йортка чатыр корырга туры килде. Көннәрдән бер көнне алар өчен урамнар буйлап чапкыннар үтте:

– Тыңлагыз, тыңлагыз, ишетмәдем, димәгез! Сәгыйть белән Гөлҗиһан туйга җыя, килми калмагыз!

Туйны йортка зур чатыр корып, табынны җиләк-җимеш, яшелчә белән тутырып, зур казаннарда пылау пешереп, бөтен шартын китереп уздырдылар. Табынга кеше саен кашык куйганны үзбәкләр, таҗиклар аңлап та бетермәде бугай. Арада:

– Дөгене без барыбер бармак очларына элеп кабабыз, – диючеләр дә булды.

Кияү белән кәләшнең янәшә утыруына да бик гаҗәпләнеп карадылар. «Туйда килен чаршау артында бары тик елавын белергә тиеш», – диделәр. Ә монда Җиһангөл май кояшы сыман елмая да елмая...

Сәгыйтенең дә урыны – ир-атлар өстәлендә булса, яхшырак, имеш... Татарча туйда башкачарак икәнен һич аңлый алмадылар кебек.

Зур-зур табаклар белән кем армут, кем шәфталу, кем йөзем күтәреп килде. Һәр җимешнең йөзе алсу, җылы кояш нурын сеңдергән, шифалы дымнан татлы тәм алган иде. Җиһангөл шунда туган нигезендәге янгынны исенә төшерде. Онын-ярмасын шулай табаклап ташыды бит аларга авылдашлары... Мәрхәмәт, мәрхәмәт кешеләрне кеше итеп яшәтә җир өстендә.

Кем үзбәк тә, кем татар икәнне белерлек тә түгел иде бугай. Өстәлләр сыгылырлык нигъмәтләр янына җимеш суларын мулдан тезделәр. Җиһангөлне иң гаҗәпләндергәне шул булды: исерткеч эчемлекләр хакында хәтта сүз кузгатып карауучы да күренмәде. Аек тормыш аңа бәхет китерергә тиеш иде. Хәер, китермәдемени? Исән-сау балалар тудырды. Еш кына: «Бала сөю бәхете бирде бит миңа Илаһым. Күтәргәнмен. Имезгәнмен. Бакчага, аннан мәктәпкә илткәнмен. Шулай язган икән – монда нишлисе? Әти-әниле, пар канатлы булып үстеләр...» – дип куана. Гөрнадирдай улына, гүзәлләрнең гүзәле кызына карап туярлык түгел, инде оныклары буй җитеп килә. Алар да Сәгыйть белән Җиһангөлнең нәсел дәвамнары ласа.

***

Бәхтияр татар җиренә килгәнче, юл өстендәге китапханәгә керде. Укытучы апасыннан ишетеп, Тукай дигән шагыйрьне исендә калдырган иде. Җиһангөл апасы сөйләвенчә, егерменче гасыр башынача үзбәк илендә бер генә типография дә булмаган. Беренче типографияләр Казаннан китерелгән. Аларда татар белгечләре эшләгән. Гомумән, китапларның күпчелеге Казаннан, зур юллар үтеп, монда үз укучысына ирешкән. Ул укытучының әлеге шагыйрьнең китапларын мәктәп китапханәсенә дә, бистә китапханәсенә дә бүләк итеп алып килгәнен хәтерли. Баштарак башка телләрне камил белмәгәнгә, Җиһангөл укучылары белән татар телендә сөйләште, шуңа балалар чит сүзләрне бик тиз отып алдылар, аның нечкәлекләренә тиз төшенделәр. Бала-чаганың хәтере яхшы, һәммәсе исләрендә кала иде. Хәер, үзбәкчәгә дә укытучыны балалар өйрәтте. Ә урысчаны барысы бергәләп өйрәнделәр.

Бәхтиярга китапханәче дә китапларны тиз табып бирде. Бер генә бөек затларын да белмичә барып төшү ихтирам итмәү кебек тоелыр дип, аларны кат-кат күздән кичереп чыкты ул. Берсен күңеленә охшаганга язып та алды:

Валлаһи, и валлаһи, и валлаһи!
Бәхете барлар кырда җәйли, валлаһи!
Ак күмәч белән ашарлык саф һава;
Җир яшел, кошлар да сайрый, валлаһи....

Китапханәче кыз: «Иртүк бер агай кергән. Татар кешесе булып чыкты. Минем Такташның «Алсу»ын яңадан укыйсым килә, табып бирегез әле шуны, ди. Табалмадым инде», – дип куйды.

Бәхтияр бу шигырьне язып алганда ни сәбәпледер, беренче укытучысын – Җиһангөл апасын исенә төшерде. Башыннан, мөгаен, нәкъ шушы китапны Татарстаннан ул алып килеп тапшыргандыр, дигән уй йөгереп үтте. Китапханә фондын туплауда яшь укытучы шактый эш башкарды ласа. Тирә-як авыл-шәһәрләргә чыгып, үзе китаплар җыеп йөрде. Инде азмы-күпме фонд булды, инде укучылар кирәк иде. Ул китапханә оешты дип, халык күбрәк йөргән җирләргә, мәхәллә советы бинасы каршындагы белдерүләр тактасына афишалар ябыштырды. Бер тапкыр бу эшне Бәхтиярга да кушты. Малай ябыштырганда интегеп бетте: бәрәңге җилеме йә бик тиз кибеп китә, йә берекми җанына тиде. Халык, бигрәк тә балалар, әкренләп китапханәгә юнәлде. Монда белемгә ишекләр ачык, күңелләр дә ачык иде... Әнә шул чакта танышты Бәхтияр кабат Тукай дигән шагыйрь белән.

Кеше күңеленә, кеше рухына хезмәт итә шул бу китапханә дигәне, дип уйлап алды Бәхтияр. Ә бит кешеләрнең рухи дөньясы, гореф-гадәтләре, әхлагы шушы китапларда.

Бәхтияр ул чактагы күңелле мизгелләрне күңелендә тергезә-тергезә, бүгенге халәтенә кайтты, үз-үзенә: «Димәк, язмыш бу!» – дип, катгый итеп әйтеп куйды.

– Димәк, язмыш бу! – дип кушылды Мәхәббәт, сумаладай кара чәчләрен караңгы зәңгәр яулыгы астына этә-этә.

Алар күзенә иң башта ишелгән терлек фермалары, язгы ташу юып киткән күпер, күптән ябылган мәктәп, ишегенә йозак салынган, тәрәзәләре кыелып төшкән, әмма элмә тактасы торып калган кибет чалынды.

Күктә челтәрле ак болытлар йөзә, көньяк кояшыннан һич калышмаска тырышып, көләч кояш бәллүрдәй якты нур коя иде. Язның җәйгә авышкан чагы. Шуңа да һәр үләннең төсе җетеләнеп күренә, якты яшеллек җанга бертөрле тынычлык иңдерә иде.

– Җиргә орлык төшеп, буразна сызылгач кына, җиһанга ямь керә. Җир сулыш ала. Җир сулый! Аның сулышы рәхәтлеген тою бөтен кешегә дә тәтеми, – диде Шамил күңел күтәренкелеге белән. – Сез дә авыл балалары бит. Сез моны тоярсыз...

Бәхтияр шуңа пошынды: авылда нибары биш-алты тәрәзәдә ут яна. Ә тормыш иткәндә, ил картларының зирәк сүзе дә, ак әбиләрнең төпле киңәше дә кирәк. Элек өмәләр бар иде. Йорт салганда, бүрәнәнең авыр башына гаярь егетләр барып ябышыр иде. Беткән авылның гомере! Беткән!

– Беләсезме, нигә беткән бу авыл? – дип, сораулы карашын үзбәкләргә төбәде Шамил. – Бердәнбер мулланы теге кара елларда Себергә куганнар моннан. Кулларын каерып, богау салганнар һәм каршында Коръәнне утка ташлаганнар. Бу затларга рәхмәт укый алмас иде бит инде ул...

Өр-яңа мәчет салып куярга кирәк монда... Авыл халкын да бергә җыячак ул.

– Сез Азат белән үз авылыгызга төзегәнсез бит.

– Төзүен төзедек тә... Авылдан чыккан байлар аз түгел анысы, алар да булышты. Тик йөрергә кешесе әзрәк. Мәчет эченә карга тутырып булмый бит, туганкаем... Дөрес, бәйрәмнәргә кайта халык. Алай да ярый. Бәлки, тора-бара үзгәрер.

– Азан әйтүче бармы соң? – дип сорады Бәхтияр.

– Юк иде. Сугыш ветераны яши аргы якта. Әйттем: «Абзый, авылда

башка кеше юк, азан әйтергә өйрәнәсең», – дидем. «Кемнән өйрәним соң мин аны?» – ди. Күрше авылда мәзин бар мәйтәм, ул барысына да төшендерер. Алып бардым. Бер кат та азан әйтми калганы юк. Дөрес, баштарак тавышы калтыранды. Сулышы да җитми кебек тоелды. Ләкин үзебезчә мәкамне тыңлап туярлык түгел… Намазны да бик тиз өйрәнде.

Мәхәббәт үз уена чумган иде.

– Рәнҗеш төшә шул, – дип, тирән көрсенде ул. – Безгә килешер микән соң мондый туфрак

– Нинди туфрак?

– Каһәрле туфрак? Карап торсаң, зур яу үткәндәй авыл өстеннән...

– Бу авыл халкының яртысы Себергә сөрелгән, яшәп калганнарының күпчелеге игенчеләр... Тик сезнең монда бер бөртек гаебегез дә юк. Аллаһ җәзаны һәркемгә гамәленә карап бирә, диләр, үзләренә әйләнеп төшкән әнә... Шул гына...

Ир үз сүзләреннән үзе курыккандай, як-ягына күз йөгертеп алды, аннан авыр сулады. Бер-берсенең күзләренә карамаска тырышып, беркавым сүзсез тордылар. Шул мәлдә Шамил сүзне икенче юнәлешкә борып җибәрде

– Дөрес, уңдырышлылыгы ягыннан бездәге җирләрне сездәгеләр белән чагыштырып булмый инде, ләкин тырышканда барыбер нәрсәдер үстерергә мөмкин.

– Бераз игътибар бирсәләр, әлбәттә, үстерер идек, – дип куйды Мәхәббәт, ниндидер бик тирәндәге өметен кузгатып. – Үзбәк дип карамасалар...

Шамил көлеп җибәрде.

– Хәзер дөньялары буталып бетте инде... Уникенче гасырда Мәскәүгә нигез салучы Долгорукий инглиз саналган, аңарда бераз грек, бераз кыпчак, бераз швед каны да бар, диләр. Үзе дә кыпчак ханы һәм грек императоры кызларына өйләнгән... Ә барыбер дә иң ышанычлысы – үз көчегез инде, комачауламасалар, рәхмәт, диярсез... – дип куйды аннары, көлүеннән кинәт туктап. – Бездә халык гомер-гомергә үз көченә ышанган, көче җитми башлагач, ташлап качкан аннары. Чөнки иртәгәсе көнгә дә бик шикләнеп карый хәзер кеше. Гаепләп тә булмый: башы Себер киткән бабаларын уйламаска тиешме ул? Тарих тәгәрмәче гел әйләнеп тора, диләр бит.

– Әйе шул, һәркем авыл тарихының бер кыйпылчыгы. Ул кыйпылчыклар таралган, юкка чыккан, күрәбез. Димәк, бездән өр-яңа тарих башланачак, – дип ышанычлы итеп әйтте Бәхтияр.

– Бәлки... – дип ышаныр-ышанмас кына җөпләде Шамил. Аннан сүзен дәвам итте:

– Мин үзем дә аулаграк, ташландык бер авылны сайладым. Гөл итәм, менә күрерсез, дидем. Кунакка кайтып йөрүдән туктатам мин сезне, көннәрдән бер көнне бөтенегез авылга яшәргә кайтачак әле, дидем.

– Ышандылармы соң? – дип, йомшак кына сорады Бәхтияр.

Кошлар сайравын ишетеп, өчесе дә тынып калдылар. Җилләр дә тынып калгандай булды.

– Бәхтияр, күрәсеңме, өй каршындагы куак башына кошлар оя корган... – Мәхәббәт очкынлы карашларын агач-куакларга күчерде.

Бәхтияр белән Шамил дә башларын күтәреп, биеклеккә төбәлде.

– Кошлар оя корган җир... – дип, күтәренке тавыш белән әйтеп куйды Бәхтияр.

– Димәк, без кошлар оя корган җирдә... – дип кушылды Шамил.

***

Табын янында Җиһангөлгә кушылып, Бәхтияр белән Мәхәббәт гел җир хакында сөйләштеләр. Өсләренә тау баскандай, авырлыктан аларның уйлары да, сүзләре дә таркалып-таркалып китә, ниндидер курку күңелләрен яулар шикелле тоела. Моны Шамил дә сизде. Өйдәге һава торышын бераз җиңеләйтү өченме, кайсыдыр газетада күзенә чалынган бер мәзәкне сөйләп, бераз кәефләрен күтәрергә тырышты.

– Ике ир-ат капка төбендә домино уйнап утыра, ди. Шулвакыт хатыны йөгереп чыга да иренә кычкыра башлый.

– Күрегезче бу оятсызны! Сыерлар ач, ә ул домино суга!

Ире:

– Каян беләсең син аларның ач икәнлекләрен? – дип сорый.

– Ишетмисеңмени, бөтен авылны урыныннан кубарырлык итеп кычкыралар бит.

– Син дә алардан кимен куймыйсың, ләкин бу бит әле син ач дигән сүз түгел...

Җиһангөл улының җорлыгына кызыгып та куя. Менә бердәм көлешеп алдылар. Аннан янә моңсулык урнашты. Мәзәк кенә бу авыр халәттән бөтенләйгә тартып чыгара алмады, чөнки алда җитдидән-җитди сынаулар тора иде.

Әйе, татар иленә килгәндә күңелләрендә курку бар иде. Әгәр дә, үзегез безнекеләрне куып җибәрдегез бит, дисәләр... Әй, булды инде ул чакта хәлләр... Үзбәкләр, хәтта кыргызлар белән ике арага салынган күперне дә сүтеп ташлады. Туганнар аерылды: бер ишләре Кара елгасының бер ягында, икенчеләре икенче ягында калды. Ярый, елга батып үлмәле түгел. Аның күз алдында онытыла язган картина пәйда булды: яшь кенә кыргыз егете үзбәк картын җилкәсенә утырткан да елганы кичеп бара... Телевизордан күрсәттеләр ләса... «Каян килә кешеләргә мондый тар күңеллелек», дип уйлаган иде Бәхтияр ул чакта. Инде ышанды: татарлар тар күңелле түгел икән. Үзгәреш монда да сизелә: урамнарны, кибетләрне «Джойта», «Косио», «Антарес», «Икеа» кебек аңлаешсыз исемнәр чуарлаган. Үзбәкләрдә болай түгел әле... Ташкентның үзендә дә чиста үзбәкчә урамнар җитәрлек. «Янги хаят» урамын берәү дә үзгәртми, «Яңа тормыш» булып кала бирә. «Әллә соң татарлар үз исемнәрен дә, үз телләрен дә яратып бетермиләрме?» дип уйлап куйган чаклары да булыштыра аның...

Җиһангөлнең Шамилне тыңлаганда, күз алдыннан ерак-еpактагы балачагы йөгереп үткәндәй булды. Бер тапкыр әнисе белән йомырка сатарга баргач, алар караңгыга калдылар. Урман авызына якынлашканда, нәрсәдер ялт-йолт килә, шомлы кара тамгалар игътибарны җәлеп итә иде.

– Нәрсә бу? – дип аптырап сорады ул.

– Бүреләргә охшаган, кызым, – диде әнисе. – Ярый әле шырпы тыккан идем кесәмә...

Җиһангөлнең аяклары калтырый башлады. Әнисеннән бер адым да калышмаска тырышып, янынннан йөгереп барды.

– Курыкма, алар безгә тимәсләр...

Әнисе шул мәлдә «Аятелкөрси»не укый-укый башыннан яулыгын тартып алды да бер почмагына ут төртте. Яулык дөрләп яна башлады. Шул мәлдә бик кызык хәл булды: бүреләр, бер-бер артлы тезелешеп, урман эченә кереп киттеләр. Бераздан еракта-еракта аларның улаган тавышлары гына ишетелде.

– Тагын каршыга чыксалар, нишләрбез инде? – диде кыз еламсырап, калтырануыннан туктый алмыйча.

– Чыкмаслар, кызым. Үзе яраткан бәндәләрне Аллаһы саклый ул.

Юл буена бик уяу, шомлы төннең бөтен тибрәнешен тоеп кайтсалар да, бүреләр күренмәде.

Менә шушы балачак төне үзбәк җиреннән чыгып китәсе төнне төшендә янә кабатланды. Җиһангөл үз-үзенә урын табалмады. Язмышына буйсынып, төп йортым да шушы булыр, дип ышанып яшәгән никадәрле гомере әрәмме? Кем бутый бу дөньяларны? Югыйсә алтмышынчы елларда ук урыс теллеләргә каршы чыгышлар хакында сөйләштереп алгалыйлар иде. Үзбәкләрнең һич кенә дә урыслашасы килмәде. Совет чорының басымы басым ясаучыларның үз башына әйләнеп төште. Ул бары кире реакция бирде. Җиһангөл укыткан мәктәптә дә йөз үзбәк, бер урыс телле кеше утыра икән, җыелышны бары тик урысча гына үткәрергә кушалар иде. Хәер, Җиһангөлне алар урыс теллегә кертмәделәр дә. Үзләренеке итеп санадылар.

Ә бер тапкыр ул районга табибка күренергә барды. Урысчалап исәнләшкән икән. Табиб аңа башын да калкытмады. Ә икенче бүлмәдә үзбәкчә сөйләшүен ошаттылар. Игътибар белән тыңладылар. Даруларын да язып кулына тоттырдылар. Нинди генә эш төшеп, кая гына барсаң да, үзбәк телен белү кирәк иде шул.

Туган якларына кайткан саен Җиһангөлнең юлы Казан аша үтте. Китап кибетләренә кагылган саен сумкасы китап белән тулды. Белемне эзләп табып алырга, аны бөтен тирәнлеге белән укучыларына җиткерергә тырышты. Шуңа авыр күтәрүдән дә, юлларның урау һәм озынлыгыннан да курыкмады. Авырлыксыз җиңеллек килмәс, диләр, ул моңа ышана иде.

Тел өйрәнүдә җиңеп чыкмаслык кыенлыкларга очрамады ул. Бергә яшәү, тел-лөгать алмашу ике халыкны да баетты гына түгелме? Алып килгән китапларын ул укучыларына тәрҗемә итеп укыды. Кызыксынып тыңладылар. Эш сөючән, кунакчыл, ипи-тозлы халык үзбәкләр. Татарлар кебек үк.

Инде менә Җиһангөл дә – сәясәт корбаны. Каберләр тегендә-монда чәчелде. Туган җир дигән төшенчәнең дә инде әһәмияте югалды. Әхмәт энесенә: «Әнине монда китермәгез, үзегез карагыз», – дип әйтә алмады шул... Ахырдан адаштырган язмышына рәнҗеде. Бу туфракны каһәрләргә дип, авызын ачканда тыелып калды, Аллаһыдан гафу сорады, яман уйларыннан тәүбә итте. Хәзер ул шушы сабырлыгы өчен сөенеп бетә алмый. Җир өстенә аңардан каһәр чәчелеп калмады, сабырлык сибелеп калды.

– Башлап сабырлык чәчсәгез, җир ул барысын да кичерә, – диде тыныч кына. Бу – әнисенең сүзләре иде. Их, никадәрле алтын киңәшләрен, алтын мәгънә салынган сүзләрен колак яныннан гына үткәреп җибәргән ул аның... Ана сүзләре – яшәү күзләре булган икән лә...

***

Җиһангөлне телефонга чакырттылар. Биш минутлык сөйләшү дип язылган иде телеграммада. Коты алынды тәмам. Әллә соң, Ходаем, әни белән бер-бер хәл бармы, дип курыкты. Телефонның теге башындагы тавыш йөрәгенә тынычлык өстәде.

– Әнине сиңа китерсәк, ничек булыр икән, апа? Тәнемә җылы үтми, ди. Ни әйтсәң дә, көньяк кояшы башкачарак карый бит ул. Бер очтан шунда балаларга да күз-колак булыр. Үзең эштә ләбаса.

– Китерегез, энем, – диде Җиһангөл. – Әнине күпсенмәм, карармын. Булдыра алганча инде...

Әнисен сагынган иде Җиһангөл. Менә ул аның үз янында булачак. Еллар буена тупланган сагыну ачысы таралыр да китәр, Алла боерса. Анага булган бурычын оныткан кешедәй яшәп яту аңа болай да уңайсыз, шуңа каршылыклы хисләр эчендә калгалаган чаклары да юк түгел иде.

Сөйләшүдән соң берәр атналап вакыт үтте микән, Әхмәт энесе әнисенең төенчекләрен күтәреп килеп тә төште. Әнисе белән энесе янында басып торган Алмазны күреп, Җиһангөл аптырап китте.

– Абау, Алмаз түгелме соң бу? Ничек киләсе иттең, улым? – Ул аны яратып кочып ук алды.

– Аны да сиңа китердем, – диде энесе. – Гөлфизә апа әнидән аерма, әни кайда булса, ул да шунда яшәсен, диде.

Җиһангөл бераз сүзсез торганнан соң:

– Шулай инде, гарип кошның оясы һәркайда, – дип, күзен аска төшерде.

Гомере буена да аңламады Гөлфизә апасы: баласы язмышына ана салганны, ана тәрбиясен беркем дә алыштыра алмый җир йөзендә. Дәү әниләр, әби-апалар ничек кенә шәфкатьле, мәрхәмәтле булмасыннар, балага ана назын бер генә кеше дә бирә алмый. Ничек шулай балаңны үзеңә якын китермичә, бер читтән карап торырга буладыр?

Җиһангөл гаҗәпләнеп сорап куйды:

– Ничәнче сыйныфта соң әле син, Алмаз? Уку елы да төгәлләнмәгәндер бит әле.

Егет өчен Әхмәт энесе җавап биреп өлгерде:

– Унынчыда. Менә белешмәләре. Монда берәр мәктәпкә урнаштырырсың инде, апа. Тагын берничә ай укыйсы калган дигәндәй... Имтиханнарны кайда бирсә дә, барыбер ич... Аннары үзе карар. Дөньяда эш бетмәгән...

Ни дисен инде Җиһангөл? Апасы кеше көе белән яшәргә яратмый шул. Үзенчә яши бирә. Димәк, аңа хәзерге вакытта шулай җайлы. Улының китеп торуы кирәк.

Аның күз алдында җәяүле буран йөгергән юллар, зәмһәрир кыш, артсыз чана, кара юртак бия терелгәндәй булды. Үткәннәрдән бер мизгел өскәрәк калкып чыкты.

Алмазга ничә айлап булды икән ул чакта? Күп булса, өч-дүрт айлыктыр. Ерак әбиләренә – күрше авылга барырга җыендылар алар. Нарасыйны зур юрганга төрделәр. Алмазны кочып утырган апасы янына Җиһангөл сыенды.

Ат көзгедәй чиста юлдан юыртып китте. Чана артыннан кар бөртекләрен ияртеп, җил йөгерде. Әллә көне шундый идеме: кай якка барсаң да, җил каршы. Кыз уңга, аннан сулга борылып карады: кай якка борылса да, җил сулыш юлын томалады, күзләрен ачыттырды, бит очларын чеметте.

Шулай карангалап бара торгач, апасы кочагындагы нәни төргәккә күзе төште. Ни күрсен – апасы юрганны җилгә каршы ук борып, баланың йөзен тутырып ачып куйган... Бала да озак чыдый алмады: башын як-якка боргалап чырыйлап елап җибәрде. Җиһангөл бермәлгә өнсез калды. Аннан исенә килеп:

– Әнигә әйтәм мин сине кайткач, яп Алмазның битен! – дип сулкылдады. – Үтерәсең бит, апа...

Яшь әни бер сүз дә дәшмәде.

Җиһангөл белә: апасы бу мәлдә – җаны тартмаган ирдән аерылган хатын, Алмаз исә – беркемгә кирәксез ятим иде.

Шуннан соң Алмаз чынлап та бик каты чирләде. Кыз хәлне әнисенә сөйләп бирде. Әлбәттә, апасына яхшы ук эләкте.

– Һәр бала үз ризыгы белән туа, син шуны да белмисеңмени? Бездән оялмасаң да, Раббыдан куркыр идең, башыңда миең булса, – дип орышты.

Гөлфизә апасы тәрәзә каршына басып мышык-мышык яшь сыкты. Бу яшьләр энҗеләрдәй коелса да, Җиһангөл аларга нигәдер бер дә ышанмады. «Нишләп күралмый икән соң ул үз баласын?» дип уйлады, тик уен кычкырып әйтмәде.

– Ирен яратмасын да, ди… Бала бит – бәгырь җимеше, аны яратмаска мөмкинме? – дип, әрнү катыш сызланды Әсмабикә.

Әсмабикә сабыйның тәнен каз мае белән уды. Мәтрүшкәле, бөрлегәнле чәй эчерде. Аннан иске-моски чүпрәкләргә төреп, җылы мич башына менгереп салды. Ни хикмәт: бала иртәнгә кадәрле йоклады. Әллә җылы тансыклаган, әллә тән кызуының кинәт сүрелеп китүе изрәткән, ул уянырга уйлап та карамады. Җиһангөл дә бала тирәсеннән китмәде. Төнлә уянып, җылы битләреннән тотып-тотып карады да кире урынына барып ятты. Әтисе белән әнисе иртән биләүсәне ачып җибәрсәләр, баланың бөтен тәне ясмык-ясмык кабарып чыккан иде.

– Үтердем баланы! – дип ачыргаланып кычкырды Әсмабикә. Әтисе, ничәнче көнен иртә таңнан пимасын киеп, озын туныннан тышта йөренеп торды. Күңеле нидер сизенә иде, күрәсең. Аннан кызының башсызлыгын да, каты күңелле булуын да белә иде ул. Корбангали тиз-тиз киенеп, авылның ат духтырына йөгерде. Тегесе шунда ук иярә килде. Ибрайның: «Кеше белән терлек чире арасында әлләни аерма юк», – дип сөйләнә-сөйләнә ишектән кергәнен ишетүгә, кыз мич артына ук посты. Арттан гына башын сузып караганда, әле Ибрай бүреге белән бергә салынган кәләпүшен тиз-тиз башына каплап маташа иде. Кунактан янә бер чир эләктерә кайтканнар икән: духтыр куйган диагноз «корчаңгы» дип атала иде. Анысын да тиз дәваладылар. Малай чынлап та яшәү арбасына чытырдап ябышкан иде...

Хәер, моның сәбәбен дә белә кебек Җиһангөл: Вафа җизнәсе апасын урлап качкан кичтә аннан да ныграк кайгырган кеше Мостафа гына булгандыр. Ул шул мизгелдә әтисе янына килеп җитте:

– Корбангали агай, әтием бул, зинһар, биреп тор айгырыңны, Гөлфизәне куып тотып алып кайтыйм. Рөхсәт ит, зинһар! Синең ризалыктан башка үзбаш эшли алмыйм мин моны. Әйт, «Ярар» диген...

Күкрәгенә Гөлфизәнең фоторәсемен кыса-кыса күз яше белән елады Мостафа. «Унҗидесе дә тулмаган бит әле аның», дип тәкрарлады.

Корбангали бик озак кына сүзсез торганнан соң:

–Язмыштан узмыш юк инде, Мостафа. Димәк, сиңа язмаган... Карчыга авызыннан төшеп калган кош кебек булыр ул аннары... Әйдә, сабыр итик, – диде дә сүзне өзеп куйды.

Корбангали ул елны атлар карый иде. Айгырларның ниндие генә юк иде аңарда. Шул айгырлар белән апасы килен булып төшкән авылга Җиһангөл кунакка йөри башлады. Кунакка димәсәң, хәтере калыр, дөресрәге, Гөлфизә апасы аны күбрәк үзенә булышырга чакыра иде. Әбекәе белән бардылар бер тапкыр. Менә анда савыт-сабаны юып та карады соң Җиһангөл. Чөнки йортта әни кеше авыру гына да түгел, гарип, ул мендәргә сөяп утыртып куйсалар гына, бераз утырып тора ала, киленгә каенананы, тагын биш каенешен, каенатасын, ирен тәрбия итү белән бергә, йорттагы терлек-туарны да карарга, колхоз эшенә

дә өлгерергә кирәк иде. Килеп төшкәч тә апасы аны имән бармагы белән генә чакырып, сандык артын күрсәтте. «Мин килгәндә дә шунда яталар иде болар, ничә кат алып юдым инде», диде. Камырга каткан кырыклап агач кашыкны җыеп алгач, изрәтә-изрәтә тәкате корыды кызның. Стена тулы кандала, таракан кыймылдый.

– Салам алып керегез дә тазга салып яндырыгыз. Төтенгә озак чыдамый алар. Аннары ачып җиллəтербез, – диде әбекәе аптыраулы кыяфәттә.

– Анасыз йорт менә шундый була, кызым. Хатын-кызга Аллаһ саулык бирсен! И, йөрәгем әрнеде, балакаем, апаң өчен. Бәхете булмады микәнни инде шулай итеп? Кодагый өчен дә борчылдым. Күпме еллар авыру бит.

Җиһангөлнең чынлап та мондый йортны беренче күрүе иде. Кыз аңлады: өйнең дә, илнең дә тоткасы – хатын-кыз икән... Апасы бу йөкне тартырмы соң? Мәхәббәттән көч алганда, җиңеп тә булыр иде, бәлки. Тик җизнәсе бит аны сөйгән егетеннән аерып, урлап качты... Инде хәзер эчеп йөри... Бер тапкыр килеп керде: аягында көчкә басып тора. Урамда буран. Зур капканы ачып, әтисе атны тугарып, абзарга кертеп япты.

– Ходай бу зәхмәттән тикмәгә генә тыймаган, кешелек дөньясы шуны аңламый яшәвен дәвам итә, – дип үртәлде үзе. – Аракы сүзне озайта, гомерне кыскарта торган нәрсә ул...

Колхоз эшенә чыга алмыйча ике көн ятты кияве. Аннан гел сәбәп уйлап таба башлады: йә бармагын кыскан, йә аягын авырттырган. Табиблары да ышана бит...

Шулай да алардан өй ялт итеп калды, бүлмәгә тәмле кысыр аш исе таралды. Йомырка белән ярма салып кына пешерсәләр дә, ашап туйгысыз тоелды. Апасының күңеле тулды хәтта.

Акчарлакка тиң иде шул апасы. Басып түгел, йөзеп кенә йөрер иде бит. Шул акчарлакка тиң ап-ак алъяпкычына була урлагандыр әле аны җизнәсе. Әнисе еш кына апасы эшкә киткәндә, Гөлфизә ни киеп китте, кызым, дип сорап куяр иде.

– Теге син теккән ап-ак киндер алъяпкычын, әни, – ди Җиһангөл. – Үзе чиккәнен...

– Аһ, чәчрәп киткере! Бар, барып алыштырып кайт. Кеше күзе харап итәр үзен. Кирәксә-кирәкмәсә, кем шулай йөри, диген.

Ә бер тапкыр икесенә дә әтиләре пардан ак яулыклар алып кайтты. Әбекәйләре шуларны бәйләтеп, аларны Биләр тавына алып барды. Ватаннарын саклап шәһит киткән унике кызның фаҗигале язмышы хакында сөйләде. Кызлар күмелгән ул тау әле дә мәгърур, түбәсен күкләргә терәп тора бирә. «Кызлар тавы» дип атала икән. Башларына тиярдәй булып агылган болытлар аның әле дә күз алдыннан китми. Ул тау битләрен нарат чәере исе баскан иде. Шунда бик киң елга күрделәр алар. Өстендә акчарлаклар оча иде.

– Теләк тели-тели барыгыз, бу безнең өчен бик изге җирләр, – диде карчык. Шунда алар икесе дә Аллаһыдан акчарлакларга ризык сорадылар бугай. Ниндидер таш билгеләр бар иде аннан. Аның тирәсендә дә акчарлаклар оча иде. Шунда алар яулыкларын салып, култык астына яшерделәр, акчарлаклар алып китә күрмәсен, янәсе...

Гөлфизә апасы да акчарлакка тиң иде дә соң, менә кайда килеп эләккән бит... Җитмәсә, җизнәсе аларга кагылганда, гел кызмача була. Монысы әтисенә аеруча ошамый. Кояшка каршы йортның капка төбендә ап-ак күлмәк киеп утырган, үз вакытында бу дөньяның бик күп сугыш-яулары аша үткән картны борын асты кипмәс борын ачы суга ябышкан киявенең бу гадәте тирәннән

калкынып борчый. Җитмәсә, араларында мәхәббәт тә юк, дип уйлыйдыр... Ә тормыш сынауларын мәхәббәтсез ничек җиңмәк кирәк?

Әйе, җиңә алмадылар шул ул сынауларны. Юллары аерылды. Алмазны сабый чагыннан ятим иттеләр.

Җиһангөл апасының Алмазны ни өчен шулай яратмавын да чамалый кебек, бала – суеп каплаган әтисе чөнки... Сөймәгән, күңеле тартмаган җан иясен күргәндәй буладыр ул... Үзен көчек баласы урынына куеп урлавын кичерә алмыйдыр.

Инде шул бала егет булып җитешкән. Инде янә беркемгә дә кирәге юкмы? Җиһангөлгә Алмаз энекәше бик кызганыч булып тоелды. Әлбәттә, сыйдырыр ул аны. Бер казанга салган аштан өлеш чыкмасмы? Бер башлаган икмәк җитмәсме? Җитәр. Үз балалары әзрәк тешләп кабар... Шушы нарасыйны елый-елый ачы буранлы зәмһәрир кыштан йолып алды түгелме?! Мәктәпләр монда да бар, ул аны иртәгә үк мәктәпкә урнаштырыр. Әйдә, берәр эшкә ярар әле шунда, көрәк бетмәсә, тизәк бетмәс, диләрме? Урамда трай тибеп йөрмәстән, спорт түгәрәгенә дә яздырыр.

Ул үзбәкләрдә дә баланың бик кадерле зат булуына кат-кат инанды. Ләкин өлкәннәрне бала үзе дә яшьли хөрмәт итәргә өйрәнә. Алар әти-әнигә «сез» дип зурлап дәшәләр. «Әнием, сезнең хәлегез ничек?» ягъни мәсәлән. Ата-ана балага да шулай дәшә түгелме? Ул бу хакта бер укытучыдан сорап та карады. Тегесе:

– Бала да туу белән шәхес ич. Син дип дәшү бездә нарасыйларны түбәнсетү санала, – дип җавап бирде.

– Кит аннан, бездә чит кешегә генә шулай эндәшәләр, – дип куйды Җиһангөл. – Монда да үзебезчә хаклык бар: димәк, иң кадерле, иң якын зат ул бала.

Болай гына да түгел, әти кеше хатынына һәрчак бер баласының исемен кушып дәшә икән. «Кабилнең әнисе, син ни дигән идең әле баягынак?» ягъни мәсәлән. Икенче юлы ул башка баласының исемен атый шулай. Әнисе дә: «Ашым пеште, Кабилнең әтисе, әйдә, алып кер балаларны», – ди. Баштарак мондый сөйләшүләр Җиһангөлгә чит-ят тоелган иде дә, хәзер күнекте инде. Хуплый да кебек. Чөнки бала әти-әнисе авызыннан үз исемен ишеткәч тә сагаеп кала. Аларда җаваплылык хисе тәрбияләнә, имеш. Аннан әти-әнисенең үзен ничек яратуын, алар өчен бик кирәк булуын да тоеп тора, ди. Барыбер дә бу гадәтләр үзбәкләрнең үзләренә күбрәк бата кебек, Җиһангөлнең исә балаларын бары тик үзебезчә генә тәрбиялисе килә.

Барыбер дә еш кына:

– Менә ни өчен картлар йортлары да, балалар йортлары да юк икән боларда, – дип уйлый. Хөрмәтне хөрмәт кенә тәрбияли ала шул. Хәер, аларның шәһәрендә бер балалар йорты бар, диләр, тик бер генә үзбәк баласы да тәрбияләнми, аны Рәсәйдән күчеп килүчеләр тутыра икән. Үзбәкләрдә тәртип башкача, бала яшьтән ятим калса, ягъни әти-әнисе үлеп китсә, аны туганнары тәрбиягә ала. Туганнары булмаса, күршесе ала. Аларда: «Балалы йорт – базар, баласыз йорт – мазар» дип кенә җибәрәләр. «Мазар»ы зират дигән сүз була инде.

Менә Алмаз да – ятим бала, Җиһангөл дә исән-сау туганының баласын күпсенмәде бит. Анасы аңардан котылу җаен гына турылый, дөресрәге, үзен күбрәк ярата. Ә үзен яраткан затка ялгызлык кулайрак. Эшләве дә яшәве дә үз хаҗәте өчен.

Җиһангөл үзен әле әнисе урынына, әле Алмаз урынына куеп карый: аларның һәр икесенең дә хәле җиңел түгеллекне аңлый. Туган җирдән, якыннарыннан аерылудан туган сагыш мөлдерәп тулган күңелләрен чайпалдырмаска тырыша.

Алмазның әтисе дә вафат инде хәзер.

Сәгыйте дә гаиләдә берьюлы ике тамак артуга бер дә каршы килмәде.

– Әйдә, сыярбыз әле, савабы безгә булыр, – дип кенә куйды. Савап өчен монда бөтен эшне эшләргә әзер шул кешеләр. Менә шундый киң күңеллелекне күрү мәхәббәтне дә арттыра шикелле. Әллә хөрмәтне генә микән? Хәер, ничек булса да гаиләне нығытучы гамәл инде. Гомер бит ул комга сеңгән су кебек, кай таба таралып киткәнен дә сизмисең. Моны өлкәннәр авызыннан гел ишетеп тора. Үзең өчен дә, кеше өчен дә файдасыз гомер – үтә аянычлысы. Җир өстендә ни бер яхшылыгың калмаса, кешеләр ни дияр?

Аннан, Җиһангөл белә: дөньядагы һәр нәрсә Аллаһы Тәгаләдән. Нинди авырлык килсә дә, бу – Аның сынавы. Нәрсәгәдер ирешәсең икән, аңа Үзе бер сәбәп китереп чыгара. Кеше исә, үзем ирештем, дип уйлый. Менә бу һөнәрне сайлармын дип уйлаган идеме ул? Аллаһ кушуы буенча, шул өлкәгә кереп киткән икән – димәк, бу инде гомерлек. Яисә монда килергә җыендымы кайчан да булса? Ә бит юллар гүя үзе китерде. Хатынның уйларын бүлеп, урам яктан тавыш ишетелде:

– Җиһангөл апа, сезне мәхәлләдә көтәләр.

Ул дертләп китте. Ни булды икән?.. Әллә Алмаз берәр этлек эшләргә өлгердеме? «Йа Аллам! Ярдәмеңнән ташлама!» – дия-дия мәхәллә советы урнашкан бинага йөгерде.

– Энекәшең безне санга сукмый, исәнләшми узып китә, нинди оятсызлык! – дип, аһ-ваһ килде аксакаллар аны күрүгә.

– Сез безне гафу итегез, зинһар, бездә гадәт шундый бит: белмәгән кеше белән исәнләшмиләр...

Үзегездә үзегезчә яшәрсез, тик бездә безнеңчә булсын, дигән мәгънәне төшендереп кайтардылар Җиһангөлгә. Артыннан берсе:

– Ризыкларыбызны яратасыз, үзебезне дә, гореф-гадәтләребезне дә өнәмисез, – дип кычкырып калды.

Бу сүзләрдә хаклык та юк түгел иде. Мәктәптә җирле халыкка урыс теллеләрнең карашын күреп тора ул. Җиһангөл килгән елларда алар азчылык иде әле. Аннан, елдан-ел ишәя бардылар. Хәер, ул үзе дә болай ярамаганны бик яхшы белә, энекәшенә төшендерергә генә башына килмәгән. Хәер, алдагы көннәрдә генә Степаннарга сеңелләренең кызы килгән. Хуҗаны да чакыртканнар ди. Шортыдан урамда йөргән теге кыз бала. Степанга:

– Бу кызыңа әйт инде, урамда трусыдан йөрмәсен, безнең рөхсәтебез юк, – дигәннәр, имеш...

«Гаеп үзебездә... нишлисең...» дип фикер йөртте Җиһангөл.

Алмаз... Үз баласы булса, Җиһангөл үзе аны каеш белән ярыр иде дә... Ул сабый да үз холкы белән яратылган шул. Кызыксынучан. Нечкә күңелле. Авыр сүзне бер дә күтәрми, кызлар кебек күз яшен тәгәрәтергә генә тора. Монысын Җиһангөл ятимлектән дип уйлый. Әтисе юк инде, әнисе дә канат астына алырга җыенмый. Ярый, әбисе үзеннән калдырмый, әби тәрбиясе – бик мәрхәмәтле тәрбия ул. Карчыкның үзенең дә оныгын җәлләүдән күзеннән һич яше кипми әнә.

Малайның да торган саен әбисенә ышанычы арта бара, аның карты ясаган агач караватта азга гына борылып яткан арада да сыңар кулын артка сузып, үз тәненнән аермавын, тигез, кайнар сулышын тоеп тынычланганда да, ятимлеген исенә төшереп өзгәләнүен бала сиземе белән сиземли, ятимлек бәхетсезлеген җиңелрәк кичерергә ярдәм итә иде.

Карты үлгәч тә оныгын ач-ялангач итмәде. Яз җитсә, какы, кыргый суган, юа, балтырган җыйды, җәй җитсә, Алмазны ияртеп, урманга җиләккә менеп китте. Урманда атлаган саен вак ботакларның шартлап сынганы ишетелә. Малай шушы тавышны яратты. Күбрәк ботак-чатаклы җиргә юлыкса, тыпыр-тыпыр сикеренә башлар иде. Җиләклеккә, аланга чыкканчы арып-талып бетәләр иде. Юл уңаенда яшен камчылаган чакка да юлыктылар. Элек «витамин» дигән сүзне белгән кеше юк иде, карчык та балага файда булсын, буй тартсын, дип сөйләште.

Күрше карчыклары: «Әнисенә озат», дисәләр дә, «Юк инде, таудан таш артамы?» дип кенә куйды.

Кибетләрдә кабым ризык юк иде шул ул елларда. Хәзер генә ул әнә, сыгылып торган киштәле кибет каршында кешеләр ачтан үлә. Сәләтләрен эшкә җигәр мөмкинлек таба алмыймы алар? Әллә аракы аркасында хәерчелеккә чыгып, бәхетсезлеккә дучар булалармы? Җиһангөл бу хакта еш уйлана. Үзләре кайтып урнашкан шәһәр яны бистәсендә дә кыйшайган йортлар аз түгел... Каргалган йортка кара кура үсәр, ди иде әтисе. Шул кадәрле җирләргә кемнәрнең каргышы яуды икән соң? Мондыйлары рәттән тезелеп тормаса да, Җиһангөлнең эчен пошыра иде.

Әнә Шамиле никадәрле эш урыны булдырды бит халыкка. Ат суялар, казылык ясыйлар. Шәһәр халкы сыпырып алып бетерә. Авызда эри, диләр. Хәрам юкны сизә халык. Бәхтияр да кызыга. Бераз хәлләнгәч, мин дә казылык цехы ачармын, дип сөйләшештерә. Тик менә кәефне кыручылар табылып кына тора...

***

Елкылдап торган чит ил машинасын күреп имәнеп китте Бәхтияр. Вәкарь белән генә кабинадан чыгып, ачкыч бәйләмен бармагында әйләндерә-әйләндерә өенә табан атлаган берәүне тәрәзәдән күреп, үзе каршы чыкты.

Тегесе исәнләшеп тә тормастан:

– Безнең авылда чит кешеләр юк иде әлегәчә. Сез монда кайдан килеп чыктыгыз? – дип, төртмәле сорау ташлады.

– Үзбәкстан якларыннан... Сезнең халык та бездә әз түгел.

– Барыбыз да бертуганнардай идек без монда. Бер-беребезне беләбез. Кунакка йөрешәбез дигәндәй... Бәйрәмнәребез бар иде. Гает, Сабантуй... Каз өмәләре...

– Иде... Хәзер кеше юк бит инде. Киткәнсез. Ә мин бер тәрәзәдә булса да, утны саклыйм.

Ир йомшарды. Бик озакка сүзсез калды. Аннан:

– Саклагыз. Сүндерә күрмәгез сез аны, – диде дә юл читендәге машинасына табан атлады.

Бәхтияр да машинасына утырып, Җиһангөл апасына юнәлде.

***

– Бәйрәмнәребез бар иде, диме? Чынлап та бар иде бит алар. Авыл барында бәйрәмнәр дә яши. Сездә дә шулай ич ул, Бәхтияр, – дип җөпләп куйды Җиһангөл.

Бәхтияр белән сөйләшү Җиһангөлнең хәтерен янә үзбәк иленә тоташтырды.

Сәгыйте белән Нәүруз бәйрәменә бардылар икәүләп. Бу – Яңа ел башлану дигән сүз. Алар килгәндә, халык умарта күчедәй гөжләп тора иде. Йөзләр шат,

күңелләр күтәренке, кешеләрнең һәммәсендә бәйрәм рухы иде. Урамда казан асып, халисә пешерделәр.

– Халисә дигәне ни аңлата икән соң? – дип сорап куйды Җиһангөл иреннән.

– Саф дигән сүз ул, ягъни саф күңелдән әзерләнгән ризык.

Бистә байлары казан янына куй итен китерә торды. Хатын-кызлар аны вак-вак кисәкләргә бүлгәләде. Аннары зур казанга салып, төне буе кайнаттылар. Әкрен генә, леп-леп кенә кайнап утырды ул. Иртәнге якта гына туралган кишер, суган, вакланган бодай салып җибәрделәр. Урам тулы хуш ис, бөтен кешедә бәйрәм рухы иде. Иртәнге намазга азан тавышы яңгырады. Намаздан туры ук кешеләр халисә казаны янына җыелды. Ашка килми калу боларда тәкәбберлек билгесе санала икән. Дин буенча бу гамәл гафу ителми. Олылар өстәл артында бәйрәмчә сөйләшеп утырган арада бала-чага савыт тотып йөгереп килә-китә торды. Халисәне салдырып алуга, алар, җил тизлеге белән күздән югала бардылар. Мәхәллә хуҗаларының шулай бөтен эшне тиз оештыруына таң калды Җиһангөл. Үз туйларын уздырганда да, мәхәллә ярдәм итте ләбаса. Мәхәлләдән вәкилләр беркөнне:

– Пәдәр ашына Сәгыйть әкәгә чакыру китердем! Белми калмагыз, ишетмәдек димәгез! – дип урам буйлап хәбәр таратып йөрделәр.

Бөтен мәхәллә ир-аты кыз чыгасы йортка ашка килә икән монда. Бу – инсафлы кызны абруйлы итеп озатуны белдерү билгесе. Хуҗа, ягъни әти кеше яки берәр ир туганы пылау әзерли. Йортка зур өстәлләр сузганнар. Төчегә пешкән ризыкны бик яраталар икән, табыннарга ни генә куелмаган. Өстәлдәге печенье-прәннекләрнең һәммәсен төче камырдан пешергәннәр. Җимеш суы белән чәй – шулай ук табын күрке икән. Бу – «Пәдәр ашы» (Ата ашы) дип атала.

Иренең бик атлыгып тормаганын чамалаган Җиһангөл:

– Чакырган җиргә барырга кирәк. Читтән килгән башы белән безне хөрмәт итми дип, мине гаепләрләр тагын, – дип, мәҗбүриләп кузгатты. Аһ, никләр кузгатты ул аны! Шунда Бәкер дә буласын белсәме?! Тегесе дә явызларча кыланды: Җиһангөлгә карашы туп-туры төшәрлек итеп каршы яктагы эскәмиягә җайлашты.

Җиһангөлдән бигрәк Сәгыйть нишләргә белмәде:

– Сиңа карап утырыр өчен килгән ул, – дип көнләшеп, җилтерәтеп хатынын алып кайтып та китте. Югыйсә үзбәкләр бит татарларны беркайчан да аермыйлар. Үзләре кайда – Җиһангөлләр дә шунда. Башка татарлар да. «Нинди мул табыннан алып чыгып китте бит, җүнсез. Санламаган кебек», дип пошынды Җиһангөлнең танышлары.

Сугыш чорындагы ачлык әлеге табында, өстәл күтәргесез муллыкта үзәкләрен өзеп исенә төште Җиһангөлнең. Черек бәрәңге эзләп, туфрак актарып йөргән чаклары бар иде бит...

Шулай бер тапкыр бәрәңге җыйганда, кызлар аңа:

– Һай, өлгерсең лә... Бу чибәрлекләрең белән кемнәрне куандырырсың икән? – дип, бик сокланып карадылар. Күз тидеме, кайтып җиткәнче ботына чуан чыкты.

– Әни, бер йомырка пешереп бир әле, өстенә куйыйк, бик сызлый бит, – дип үтенде кыз шунда.

– Ничек бирим, балакаем, дәүләткә түлисе бар бит, – диде әнисе.

Аһ, ул ачлык! Җелекләренә төште лә ул ачлык! Ярый, әнисе тырыш булды: бәрәңгенең яшь сабакларын кисеп, аш пешерер иде, бахыр. Үлән коткарды инде җәйләрен.

– Сугыш беткәчтен, балакайларым, һәрберегезгә бер йомырка, бер ипи пешереп бирермен, – дия иде. Болай буласына гомердә ышанмас иде Җиһангөл. Килде бит ул көннәр! Сугыш һәм ачлык кешеләрне бер валчык икмәкне дә исраф итмәскә өйрәтте.

Еллар үтә торды. Һәр үткән ел яңа сулыш, яңа рух, яңа куанычлар алып килде. Балалары мәктәптә укыган елларда туган ягына кайткач та исе китте Җиһангөлнең: тышкы ягыннан ук чәере агып торган юан бүрәнәләрдән тазаның йортлар калкып чыккан, халык икенче өй кебек үк ап-ак келәтләр җиткереп куйган. Келәт тулы ризык. Онның тарттырганының да, тарттырмаганының да өскәкләре аерым. Әтисе көйләп калдырган туку станогы әле дә намуслы хезмәттә. Иданнәрдә үзләре тукыган паласлар... И шатланды да соң ул чакта туган җирендәге муллыкка... Җир өстендәге барча байлык Аллаһы нигъмәте булса да, кешеләр моңа лаек икәнлекләрен тир түгеп, эш белән исбат итәргә тиеш шул...

Әнә, монда да табын тулы йомырка. Йомырка гынамы соң? Тик муллык арткан саен кешеләрдә җан тынычлыгы кими бара никтер. Ни дип көнләшергә инде? Һаман: «Яратмыйсың син мине, сизеп торам», – диюен белә. Тагын ничек була инде ул ярату? Ярый, Гомәр хакында хәбәрдар түгел. Гомәрме? Хәер, ул яшьлек офыгындагы якты рәшә генә. Ерак-еракларга төбәлгәндә, җан нидер эзләгәндә генә, хәтер яктысында уйнаклап ала.

***

Яратмаган кеше белән бер түбә астында яшәп буламы? Юк, мөмкин түгелдер бу хәл. Яратадыр Җиһангөл Сәгыйтен. Хатын-кызның күңеле алкын, баш өстендәге кояшка караганда, ерактагы рәшәләрне яхшырак күрүчән мәллә соң? Шуларга күбрәк ышанучанмы әллә? Юк, юк, кая барса да, өен сагынды, мәктәптән тизрәк өенә ашыкты ул.

– Ярый әле сине очраттым, югыйсә мәңге буйдак булып калачак идем, – дигән иде бит аңа Сәгыйте.

– Ник? Үзбәк илендә кызлар беткәнме әллә? – дип сорады Җиһангөл.

– Кызлар күп лә ул, тик берсе дә минем язмышым түгел сыман... Мин сине гомерем буена саклармын, – диде дә егет, кызны беренче тапкыр кочып алды.

– Кит, кеше күрсә, оят... – дип читкә тартылды кыз. Һай, ничекләр оялган иде ул чакта! Искән җилләрдән, томырылып карап торган айдан, салмак шыбырдашкан куаклардан оялган иде...

Ярату иде бу, чын мәхәббәт иде... Менә кайларга килеп тапты ул чын мәхәббәтен...

– Тормышта иң мөһиме шул: үзеңне яраткан ярны сайлап алырга кирәк, кызым, – диде аңа әнисе. – Хатын-кыз ияләшә торган зат ул. Мин әтиеңне кияүгә чыкканчы бер генә күрдем. Иңне иңгә куеп, нинди бәхетле тормыш юлы кичтек...

– Ә Гөлфизә апа? Ул ияләшә алмады бит... – дип, әнисенә текәлде Җиһангөл.

– Аның холкы башкарак, кызым... Ордым-бәрдем генә яшәп булмый алай. Дөньяда тору өчен дөньяның үзеннән дә сабак алу кирәк. Аннары, бәхет кошы кунганда беленми, очып киткәндә беленә, диләрме? Аерылып кына, бәхеткә тиенә алганы юк бит әле аның да.

Бу сөйләшүне Җиһангөл әнисенең киңәшедәй кабул итте. «Ә бит әни мең хаклы», дип уйлап куйды ул, яңа йортка кирәсе түшәк-ястыкны какканда.

Ир-егетне, өйләнгәч, йорт төзеп, башка чыгару үзбәктә генә түгел. Туган

ягында да шулай итәләр иде. Бу инде йортка баш булу, ягъни үзеңә-үзең хуҗа булып яшәү дигән сүз. Җиһангөлгә нәзберек гөл кебек кенә яшәргә язса, бәлки, аның мәхәббәте дә башкачарак күренер иде. Ә монда йорт саласы. Бу яклардагы балчыкның үзлелегенә хәйраннар калырлык. Ком-ташлы өске катламыннан арындыргач, аста бер дигән чимал ята. Җиһангөлләр дә үз мәйданнарындагы җирне файдаланырга уйлаштылар. Кирпеч суга торгач, нигез астында тирән подвал барлыкка килде. Ә кирпече... Аны вату һич мөмкин түгел, сөяк тә сөяк, кирпечләр дә – сөяк иде.

Тагын шунысы да бар: мондый өйләрдә җәен эсселек бер дә сизелми, кышын алар җылыны да яхшы тота икән. Табигать бу тирәләрдә аеруча үзенчәлекле: чилләдә урамга баш тыкмалы түгел – эссе, ә төннәрен Памир тауларыннан салкын төшә иде. Ел әйләнәсенә тау башларында ап-ак кар ята, кичләрен кофта-яулыксыз тышка чыгам, димә. Соры таулар тезмәсе бик күп байлыкны яшереп саклый: иксез-чиксез алтын казылмалары турында да сөйләп кенә торалар. Хәер, монысы Җиһангөлне һич тә кызыксындырмый иде.

Каенаналарының бусагасыннан беренче кат атлап кергәндә, аңа башын шактый ияргә туры килгән иде.

– Бигрәк җайсыз, башсыз калырга да мөмкинсең монда, – дигән иде ул бу галәмәтнең мәгънәсенә төшенмичә генә. Баксаң: һәр нәрсәнең хикмәте бар. Үзбәкләрнең бөтенесендә шулай икән. Башны ию – Илаһка да, өйгә дә, илгә дә, йорттагыларга да хөрмәт билгесе, дип аңлаттылар аңа.

Өйләренең эче дә акшарланган: бәрелеп китсәң дә, буяла, хәер, монда һәрберсендә шундый хәл иде. Ә Җиһангөл бер тапкыр авылдан Ташкент шәһәре аша килде. Шунда кәгазь обойлар сатып яталар иде. Гади генә соры кәгазьгә бизәкләп, караңгырак төстәге ромбиклар төшерелгән иде. Һич уйлап тормады: күтәрде дә кайтты. Ябыштыргач өй ялт итте. Бөтен урам обойланган өйне карарга җыелды. Бусага аша кем үтсә дә, аларга хәерле гомер теләделәр. Каенанасы улы белән килененең эшчәнлегенә куанып бетә алмады. Йорт төзелеп беткәнче ашарга да үзе пешерде, балаларны да үз канаты астына алды, чөнки улы белән килене икесе дә хөкүмәт эшендә эшли, үзләренә вакытлары бик аз кала иде...

Ә бит җиңеп чыктылар! Түбәне өмә белән яптылар аннары. Без дә кеше рәтенә кердек бит дип куаныштылар. Өй эченә шкафларны бизәкләр уя-уя Сәгыйть үзе ясады. Әнисе Җиһангөл алдында:

– Атасына охшаган ул, кулыннан гөл тама, – дип үсендереп торды.

Кышлак берничә ел эчендә зур бистәгә әверелде. Шәһәрдән дә ерак түгел, шунлыктан яңа йортлар һаман ишәя барды. Илленче-алтмышынчы елларда бу якларга паспортсызлар агылды гына. Күпчелек халык төзелештә, шәһәрдә кондукторлар, поездларда контролёр, вагон вожатыйлары булып эшли башлады. Бистәдән шәһәргә автобуслар сәгать саен йөреп торды, шуңа калага күченеп яшәү ихтыяҗы калмады да шикелле. Җитмәсә, 1966 елдагы җир тетрәүдән соң, Ташкентны яңадан төзергә кирәк булды. Халык тагын монда агылды.

Бистәдә дә һәр яңа гаилә үзенә оя корды: балчыктан йорт җиткезде.

Бернинди заман җил-давыллары да вата алмаслык йорт Җиһангөл белән Сәгыйтьнең мәхәббәтенә һәйкәл булып, үзбәк җирендә торып калды...

***

Җиһангөл Бәхтияр белән Мәхәббәтне вакытлыча пропискага кертте. Аннан Рәсәйдә вакытлыча яшәү өчен рөхсәт юлладылар. Авылда йорт сатып алдылар. Һәм Шамил ярдәме белән ике гектар җирнең вакытлыча хуҗалары булып

куйдылар. Янәшәдәге елгага мотор батырып, су суырткыч әтмәлләделәр. Кыяр-помидор, кабак-ташкабак, суган, кишер, кәбестә утырттылар.

Һәр үсенте бу мәрхәмәтле җиргә хуҗа кайтканны тойгандай, нәкъ экияттәгечә, ай үсәсен көн үсте. Бу хәл тирә-күрше авылларга барып ишетелде. Кызыл борынлы, комач чырайлы әзмәвердәй ир затлары аларга эш сорап килә башлады. Тик Бәхтиярны шунысы борчыды: алар бүген бер чәкүшкәлек акча эшләсәләр, иртәгә бөтенләйгә югалалар иде. Ләкин бит эш көтми, уңыш җыюның үз вакыты бар. Моңа икәүдән-икәү генә өлгереп бетә торган түгел иде. Ике-өч атна үткәч, тагын пәйда булганнары да юк түгел.

Мәхәббәт аларны кызгана, иренә акчалата бирмәскә куша, хуш исле пылау белән тамакларын туйдырып җибәрмәкче була. Тик тегеләрнең ризыкта бер генә гамьнәре дә юк, һаман акча таләп итәләр иде. Хәер, үзбәкләргә дә яхшы ук керде ул зәхмәт. Наркотиклар дигәне тагын. Аларның да исерекбашлары илдән чыгып китмидер. Читкә юл сабучылар алар, гадәттә, эшчән һәм тәртипле була...

– Бәхтиярың бәләкәйдән тәртипле иде, – дип, хатынның күңел кылларына кагылып ала Җиһангөл.

– Әлхәмдүлилләһ, – дип кенә куя хатын.

«Әлхәмдүлиллаһ» дип яшәгән кешедә өмет барлыгын белә ул. Аллаһ биргән нигъмәтләргә риза булу – ул инде үзе үк тулы бәхет дигән сүз. Мәхәббәтне көн-айларның тиз узуы хәйранга калдыра.

– Монда җәйләр кыскамы соң, әллә гомер шулай тиз үтәме? – дип сорый.

– Бу хакта уйларга әле син яшьсең, илледән соң оча ул гомер, иллегә кадәр бераз йөреп тора әле, – дип җаваплый Җиһангөл.

«Ә без өлгерербезме?» дип, үз-үзенә сорау куя хатын.

«Без дә шулай өлгерербезме, дип яшәдек, менә ничек килеп чыкты бит. Йорт салырга тырыштык. Балалар үстердек. Укучылар тәрбияләдем. Димәк, өлгергәнмен...» дип, эчтән генә фикер йөртә. Югалтулары күбрәкме, табышларымы, монысын ул хәзер генә әйтә дә алмас кебек. Юк, юк, табышларыдыр... Иң зур табышы аның – туган җиренә әйләнеп кайтуыдыр, бәлки...

Шамиле дә әнә Бәхтиярга:

– Үз эшеңне булдыру – үзеңчә яшәү инде ул. «Үземчә яши алмадым, дип үкенергә калмасын, – дип әйтеп алды.

– Үзең теләгәнчә яшәү авыр шулай да. Райондагылар бер дә «әйе», «ярар» дигән сүзләрне белми, ничә барсаң да «Карарбыз...» дип кенә калалар. «Ничә морҗадан төтен чыга? Авылның хәле ничек?» дип, бер кеше дә сорамый, – диде Бәхтияр бик пошынулы кыяфәттә. – Аннан, монда табигате дә бит... Җәй бер дә юк. Үзбәкстанда туфрак ничек уңдырышлы: җиргә таяк төртсәң дә, күкрәп үсеп китә. Ун төп помидор утыртсаң, күршегә өләшеп тә бетерә торган түгел.

– Авырлыксыз җиңеллек килми шул... Рәхәтнең хакы кыйммәт монда... – дип елмайды Шамил. – Тавык та тырнап туена, нишлисең...

Хәер, Бәхтияр белә: уйламаганда-көтмәгәндә аларга бәхет елмайды. Җиһангөл апасы белән очраштылар. Ә бит якташлары сөйләвеннән белә: подвалларда кунып йөргән, тамак ялына көне-төне вагон-вагон йөк бушаткан чаклары да аз булмаган...

Ә монда... Авырлыкларны күмәкләп хәл ителгән җирдә ничек эшләп булмасын икән?

«Ләкин кеше яши бит, һәркайсы нидер үстерергә тырыша, эшләгән кешенең

эше дә, ашы да була», дип, эчтән генә уйлады Җиһангөл дә. Аның улын да, киявен дә җирдән аерасы килмәде. Шамиленә: «Кияү балакайны үзеңнән калдырма», – дип, бер генә әйтте. Азат кияве дә тыңлады. Икесе дә уңдылар әнә. Помидор-кыяр теплицалары гына да ни тора! Май башларында ук халыкка помидор-кыяр сата башлыйлар ласа! Дөрес, Шамиленең хатыны Сылу да, ике уллары да – булышчы. Кызы Назлы белән оныгы Әлфинә дә көчләреннән килгәнчә ярдәм итәргә тырышалар.

Эшнең җаена тиз төштеләр. «Күз курка, кул эшли», дип кенә җибәрәләр хәзер. Элек помидор дигәннәре кызармый да иде әле. Аны киез итек эченә тутырып, мич башына куялар, бушатып караган саен берәр саргылт йөзлесе күренсә, шул бик җиткән инде. Шатлыкның иге-чиге булмый. Ул үзбәк җиренә килгәч кенә, помидорның күпьеллык үсемлек икәнлеген белде. Каенанасы бер яхшырак сортлы төпне гөл савытына утыртып, киләсе яз өчен саклый торган иде. Озын үсентенең ботакларын сындыргалап, суга утырта да эше бетте кодагый. Орлык чәчеп, чыкканын көтеп азапланасы да юк. Тамыр җибәргәч туфракка гына төртәсе кала..

Ә беркөнне кунакка килгәч, Мәхәббәтнең бүлмәгә бикләнеп үксеп-үксеп елаганын ишетте Җиһангөл. Йөрәге шомланып куйды. Бөтенесе дә җайланып беткәч кенә, нинди корт чаккан инде бу баланы дип аптырады. Хатынның үксегәне аермачык ишетелә, җаны тулы әрнү икәнлеген ишек артында торып та тоярлык иде.

– Йә, ни булды? Кем кыерсытты? – дип, ишекне шакыды ул.

– Сагынды-ы-ы-м... – дип сузды Мәхәббәт. – Өйгә кайтасым килә. Үзбәкстанга. Балаларым, әти-әнием янына. Бәхтияр да сагына. Бер сәбәпсез ач бүре кебек йөри башлый, шуннан сизәм.

Ишекне ачты да елавыннан туктап, Җиһангөлнең күзләренә карап сорау бирде:

– Ә сез сагына идегезме, апа, бездә яшәгәндә?

Җиһангөл куырылып куйды, йөрәге үз урынына кайткандай булды. Сагынудан икән лә бу күз яшьләре. Үтәр... Күнегер дә...

– Кеше туган җирен сагынырга тиеш, Мәхәббәт. Шушы сагыну хисе сиңа монда яшәү көче өстәячәк, күрерсең....

Бу хәлләрнең авырлыгын үзе кичерсә дә, ул инде хәзер аларга җиңелчәрәк карый шикелле. Кеше кайгысы еракта, үзеңнеке йөрәктә шул. Ул чакта аның сагынуларын кем генә аңлады икән? Туган якка кайтасы айларында тәмам канатлар үскәндәй тоела иде. Уйлары канатлана, күңеле канатлана, хисләре канатлана... Китсә дә, кайтса да, җанында гел бер күренеш пәйда була: юл читендә кершәндәй ап-ак яулык чите белән битен каплап, сагыш тулы күзләрен олы юлга текәп, әнисе басып тора. Айлар тора... Еллар тора...

Ул карашны Җиһангөл кайчак ап-ак буран эченнән, кайчак сап-сары яфракларны аралый-аралый, кайчак каштан чәчәкләрен коеп искән язгы җилдән, кайчак җәйге кояш нурында иркәләнеп очкан тузганаклар арасыннан тотып ала. Җиһангөл аларда акланмаган өметләрен, җирсү сагышының тирәнлеген, гомернең алдаучан мизгелләрен күргәндәй була. Әнисенең дә заманында тулган ай күк тоелган йөзен елдан-ел тирәнрәк ермачлаган җыерчыклары азына баргандай тоела. Аны моңсулык... чиксез моңсулык били....

Туган якларны урап килгән атналарда күңел чит җирнең җылысын тоймый башлый сыман. Җитмәсә, әнисе дә кайлардандыр табыштырып, кызының

юл биштәренә Рәшит Ваһапов, Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова җырлары язылган пластинкаларны тыгып җибәрә.

Менә ул бу юлысы да мәктәптәге зур радионың шушы җырларны әйләндереп тыңлау өчен көйләнгән өске өлешенә Җиһангөл күз алмасы кебек саклап кына, җайлап кына кагылды. Елый-елый күзләре кызарып бетте. Бөтенесен ташлап, бөтен дөньясын калдырып, өр-яңадан яши башларга да әзер иде ул мәлләрдә. Тик туган ягында башлансын иде яңа тормышы...

Җиһангөлнең күз алдыннан коры сөякле саксауллар, әстерхан чикләвеге куаклары, биек-биек гөләпләр шуышып узды. Бар табигать ят иде аңа ул чакта. Бөтен кеше чит иде. Аннары әкренләп һәммәсе «үз»гә әйләнделәр.

– Сез сагына идегезме, Җиһангөл апа?

– Сагына идем, Мәхәббәт, сагыну-сагыш беркемгә дә сары май түгел. Еш кайта торган җир дә түгел бит. Шуңа гел балачагымны, авылда үткән елларымны уйлап яшәргә тырыштым. Күңелле уйлар теләсә нинди авырлыктан коткара. Син дә шулай ит... – дип киңәш бирде ул. – Узганның көле тузган, дисәләр дә, монда да мин кыен килсә, Үзбәкстандагы бәхетле чакларымны искә төшерәм. Тик бер үкенечем дә юк, улым – җирнең хуҗасы. Мин шуны теләгән идем. Кызым – татар теле укытучысы. Монысы минем иң зур хыялым иде. Бәхтиярларга дәрес биргәндә, урысча сөйләсәм, урысча телем көрмәкләнә, үзбәкчәгә күчсәм, үзбәкчә үк килеп чыкмый. И-и, кызыга идем үзбәк балаларына үзбәк теле укыткан Зөлфиягә. Ходай Тәгалә минем уй-хыялларымны язып барган икән бит... Мин теләгәнчә булды барысы да. Нәкъ минем язмышны кабатлады кызым. Телне яхшы белмим бит, урыс мәктәбендә укыдым, дип карышып та караган. «Татар кешесенең рус мәктәбендә башлангычларга татар теле укытырлык та гыйлеме булмагач, ни әйтерсең...» – дип, директор оятлы иткән үзен. Аннан өстәгән: «Бер дә борчылмагыз, курсларга укырга җибәрербез без сезне», – дигән. Менә шулай Гөлиям үз юлымнан китте. Укытучы һөнәренең кыены күп булса да, уңай яклары да аз түгел. Ике айлап җәйге ялы гына да ни тора! Мин әле дә үзбәк җирендәге балаларга белем биргән елларымны бик сагынып яшим.

– Безнең кышлакта да бик сагынып сөйлиләр сезне, апа. Бу җиргә килен булып төшкән кеше генә булсам да, Сезнең хакта мин дә бик күп яхшы сүзләр ишеттем, – дип, Мәхәббәт янә яшьле күзләрен кулъяулыгы белән сөртеп алды.

– Туктале, Мәхәббәт, алай бик сагынгач, илеңә кайтып килсәң, ни булыр икән соң? Йортыңны үзем алып калырмын.

Мәхәббәтнең шушы тәкъдимне ишетәсе килгән иде, ул Җиһангөлне кочып ук алды. Йортта кеше каласы булгач, Бәхтияры да тиз ризалашты.

– Алма кебек хатыныңны ялгызын юлга чыгарып җибәрергә курыкмыйсыңмы? – дип, кылларын да тартып карады.

– И-и, көнләшә белми лә ул, апа, – дип, кет-кет көлде Мәхәббәт.

***

– Минем синдәй чибәрне киноларда да күргәнем юк, кадерлем, – дип сокланып карап торган Сәгыйте туйдан соң ничекләр кинәт кенә үзгәрде соң? Көнчелек дигән яман чир аны эчтән ашый, хатын исә моны күреп торганга үртәлә иде. Көнләшмәслекме соң? Аның урамнан үткәнен тәрәзәдән карап калучылар әз мәллә? Күзсез кеше генә моны күрмәс. Бу хәлләр ирнең аңын томалый, күзләренең төсен тоныкландыра, сүзләренең тәмен ала иде. Болай гына да түгел, Сәгыйте аның үзен яратуына, йөрәк хисләренең бер дулкында тирбәнешен тоймаганга үртәлә.

Җиһангөл дә моны битараф кына күзәтә алмый. Аның күңелендә, кайчандыр күршеләренә кунакка кайткач, чит җирләргә ымсындырып чакырып китергән Шакирәгә карата рәнҗеш утлары кабына, җанын көйдерә иде.

– Тәүбә, тәүбә, кичер, Илаһым, аның ни гаебе бар? Мин үзем килдем ләса, – ди ул, гаебен танырга теләгәндәй. Әйе, үзе дә гаепле шул. Көнләшү чиреннән газапланган ирен ярсыткан чаклары да булгалады. Тәрбияли, имеш. Чирне тәрбияләп булмаганны, бары тик дәваларга гына мөмкин икәнлеген ул яшьлек белән аңлап та җиткерә алмагандыр. Урам як бакча янында үсеп утырган алмагачны төбе-тамыры белән актарып атасы килә аның хәзер дә. Ә ул үсә дә үсә. Яз саен бөреләнә, яфрак яра, чәчәк ата, җимеш бирә. Ә мәхәббәтләре җимеш бирмәдеме? Кешечә яшисе генә инде.

Ул чакта соңга калып кайтырга күнеккән ирен ник котырындырганын үзе дә аңламады Җиһангөл. Шул мәлдә яшьлек чаялыгы калкып чыктымы, Сәгыйтен акылга утыртырга теләдеме, әллә сабырлыгы сындымы – табигатенә хас булмаган адым ясады. Хатынының матур күлмәген киеп, иннекнең җетесен сөртеп, хушбуйның затлысын сибеп, караңгы төндә кая чыгып киткәнен белергә теләп бәргәләнде ир. Югыйсә ерак китмәде: алмагач артына гына посты. Ә Сәгыйть кулындагы балтасын болгый-болгый әле уңга, әле сулга йөренде дә туп-турыга китеп барды. Алмагач ягына күз дә ташламады хәтта. Хатын шул минутта ук өйгә керде, ике бала да изрәп, татлы йокыга талган иде.

Икенче көнне иртүк каенанасы килеп керде. Алар биек таш коймалар белән уратып алынган бер ихатада өч-дүрт буын бергә яшиләр. Җимеш агачлары астында дастарханнары да уртак. Яшел чәй, лагман, манты, сумса – барысының да яраткан ризыгы. Сер яшерәм, димә, һәммәсен сизеп-белеп торалар.

Ана айнып бетмәгән улын көчкә уятып, гаиләсенең тынычлыгын алып, газапта яшәтүенә рәнҗүен әйтте.

– Җир өстенә сыймасаң, сыярлык итә ул Аллаһ. Һәркемгә тигез итеп, ике метрны шуңа бүлеп куйган әнә. Шунда бөтенесе дә сыясын белеп, гыйбрәт алсыннар өчен... – дип сүкте. – Йә, әйт, нигә эшкә бармадың? Жалу белән миңа килгәннәр эшеңнән.

– Мине беренче июнь көнне 15 сәгатьтә эштән азат итүегезне сорыйм дип, гариза язып кайткан. 3-4 ай акча алмаганга эче поша. Теге дөньяда да директор итсәләр, җир астын бетерәчәк ул, дип, хуҗаларын сүгә, – дип куйды хатын йомшак кына.

Ир ыңгырашты. Башларын тотты. Әнисенә күтәрелеп карамыйча гына:

– Әйе шул, җир астына ничек сыярлар икән дип кайгырам. Үлеп торасы да юк аларга... Ә мин... әни... шундый реакция бирә торган химик элемент инде, үзең беләсең... Эшләп яраса, ат ярар иде. Һаман кыйнап торалар бичараны шуның өчен. Чыбыркысын да ничәдән үреп эшлиләр бит әле... Очына кыллар куя-куя... Ә хуҗалар үзләре идарә итә торган илгә тамчы да ышанмыйлар. Безнең җитәкче каядыр чит илгә үк чыгып качкан әнә, – дип сөйләнде.

– Үз гаебен үзе таныган кешедән дә бәхетлерәк зат юк ул. Ә хуҗаларыгыз танымый... Монысы куркыныч. Тик юкка борчыласың, улым, замана узып китә торган нәрсә. Җил кебек. Тагын бер кат әйтәм: юкка гына бөтен кешегә дә ике метр билгеләп куелмаган. Күпме телисез, күпме кирәк, шуның кадәр алыгыз, димәгән бит... Бер аңларлар алар да. Күрерсең: бөтенесе дә үзгәрер. Акчаны да вакытында бирә башларлар.

Сәгыйть әнисенең гыйбрәтле сүзләреннән айнып киткәндәй булды. Аптыраулы карашын идәнгә төбәп:

– Акча гына түгел шул, әни. Күз карасыдай саклап тоткан станогымны башка бер яшь малайга бирделәр. Ике көндә башына җитте, имансыз нәрсә... Хуҗадан бит монысы да... – Ир әрнүен сиздереп иңрәде.

– Шуны бел, улым: кешене ашаткан хуҗалар була, аларның үзенә дә җитә, кешегә дә җитә. Ашатмаганнарының кешегә дә юк, үзенә дә җитми.

– Алар китап укымаганмыни, әни. Рух кая? Кадалмыйлар да...

– Властьта рух булса, алар бу хәлгә төшми, балам. Тарихтан да гыйбрәт алмыйлар ичмасам. Македонскиймы әле бөтен дөньяны яулаучы? Үлгәндә, ике буш учын күрсәтеп күмәргә кушкан, бичара. Бөтен дөньяны яулагач та, буш китәсе шул җир өстеннән... Хуҗалар барысы да шулай: бөтенесенең дә Македонский буласы килә, ә гыйбрәт ала белмиләр... Тынычлан әйдә. Йотасы булса, диңгезне акула йотар иде. Авызы нинди зур! Тик йотар көч бирелмәгән. Юкка борчылма син, балам. Барысы да үз урынына утырыр бер. Дөньялыкта яхшы кебек тоелса да, бакыйлык өчен кешеләрнең кылган гөнаһлары да, мал-мөлкәтләре дә, дәүләте дә зыянга гына. Кеше хакы бигрәк тә куркыныч... Шуңа ачуланма син аларны. Сәясәт үзгәрде ләбаса, хәзер яман затлар күп итеп урласын өчен, яхшыларга бик күп эшләргә кирәк, диләр... Аннары бел: беркайчан да кешегә яманлык теләмә. Яманлык теләсәң, үзеңә дә яманлык кайтачак. Без күрмәгән юллары бар аның. Шунысын да онытма: яхшылык яхшылык белән килә, акча белән түгел. Ә гаиләне, тигез мәхәббәтне сакларга кирәк аны...

Сәгыйтьнең җанында әллә чарасызлыктан, әллә эшкә бәйле уйларыннан арынырга теләүдән, үзе дә аңламастан, көнчелек шаукымы кузгалды:

– Тигез мәхәббәт юк безнең арада, әни. Киленең яратмый мине. Яратмыйча яшәде ул, сизеп торам, – дип, авызын сыңар кулы белән ышыклап пышылдады.

– Ни сөйлисең, син, улым? Җиһангөлгә тагын нинди гаеп тагарга җыенасың? Өйдә тәртип булса, мәхәббәт килә ул. Тәртипсез йортта нинди мәхәббәт калсын? Рәнҗетмә киленемне. Ул бит кеше баласы, синең моңа хакың юк. Ызба күрке – хатын булса, йорт күрке – ир, акылыңа кил, улым, балаларыгыз хакына, – дип чыгып китәргә җыенганда, юлыннан кире борылды ана.

Җиһангөл аптырап китте. Әллә соң Бәкер белән сөйләшеп торганын җиткерүче булганмы? Отыры көнләшүенең сәбәбе шушымы? Ә бит Бәкер көтмәгәндә очрады. Җиһангөлнең мәктәптән кайтып килеше иде. Сумкасы тулы тикшерәсе дәфтәрләр. Контроль эш яздырган иде балаларга. Авыр иде сумкасы, шуңа ул бер якка авыша төшеп атлагандай тоелды үз-үзенә.

– Ник Сәгыйтең алып кайтышмый боларны, бичәкәй? – ярым мыскыллы тонда сорау бирде ул.

– Ул эштә бит әле, – диде хатын, үзенә эндәшкән ир-атка күтәрелеп карамыйча да.

– Димәк, бәхетле яшим, дисең инде...

Җиһангөл дертләп куйды. Узгынчы шундый сорау бирәме? Ул чит кешегә борылып карады... һәм бөтен тәнен салкын алды. Аңа мөлдерәп, нәфрәт тулы ике кара күз төбәлгән иде. «Бәкер... Янә мине эзләп килдеңме, Бәкер?» Тагын дошманлыкмы күңелеңдә? Дошманны куй дип уйлама, бүре дип уйла, диләрме? Чып-чын бүредер син, әй...

– Бәхетле... Биргәненә шөкер итә белү кирәк. Улыбыз, кызыбыз үсеп килә.

– Анысы, минекеләр алтау. Әмма оныта алмыйм мин сине, татар кызы. Һаман теге аклы күлмәгеңне киеп, төшемә керәсең дә бөтен дөньямны чуалтасың... Сез, татар кызлары, бик талантлы затлар бит. Күпме халыкларның

мәдәниятен, әдәбиятын бар иткәнсез, диләр. Татар кызлары бөтен халыкларга да күренекле әдипләр, рәссамнар тудырып биргән, ди безнең мәгариф идарәсе башлыгы. Канчура агайны хәтерлисеңдер әле син... Бәлки, бездән дә әллә кемнәр туар иде...

– Әллә ниләр сөйләмәгез инде, Бәкер... Кеше булсыннар... Минем яшәү максатым шушы. Үзбәк балаларын да, үз балаларымны да бердәй яратып, шулай тәрбияләдем.

Юллары аерылгач та, Җиһангөл озак уйланып барды. Егетнең үзе янында ничек бәхете ташыганын күргән кеше бит ул.

Инде мәхәббәтнең нәфрәткә әверелгәнен дә күрергә насыйп булды менә...

***

Җиһангөл әллә нишләп Гөлфизә апасын исенә төшерде. Мәхәббәтсез яшәү кешенең күңелен катыра. Таш белән бер итә икән лә. Кайдадыр Себер якларында, җиде ят арасында берүзе яшәп ята әнә. Бу хәлгә кем чыдый алыр иде? Әнисе дә: «Куылмыйча Себер китте, бала», – дип, аның өчен хәсрәтләнә. Йөрәккә бәхетсез баланың әрнүе дә күбрәк, ди. Яратып кына яшәргә ярый җир өстендә. Яратып кына... Мәхәббәт юклыктан никадәрле язмышлар ватыла. Сөю җитмәү миһербансызлыкка юл ача. Монысы балалар җанына кагыла... Аңа Алмазның моңсу карашы чагылып киткәндәй тоелды, аның нарасый тавышын ишеткәндәй булды.

Гөлфизә апасы каяндыр табыштырып, улына бер кап төсле карандашлар һәм дәфтәр җибәргән иде. Шуларны алдына туздырып салгач, малай апасына бик җитди сорау бирде:

– Апа, әйт әле, дөнья нинди төстә?

– Төрле төстә, – дип җаваплады Җиһангөл. – Кояш менә мондый, сары.

– Ә чеби?

– Чеби дә – сары. Тавык – ап-ак. Күк – зәңгәр. Җир – кара...

Малай карандашларга карап, бераз уйланып торгач үзе дә:

– Дөнья төрле төстә икән... – дип куйды.

***

Җиһангөлнең уйлары каядыр бик еракка киткәнен чамалапмы, Бәкер сүзсез генә аның янәшәсеннән атлады. Аннары кинәт исенә төшкәндәй, ашыгып:

– Әйт, теге чакта Сәгыйтеңне тукмаган өчен гаеплисеңме мине? – дип сорады.

– Гаепләмим, ул вакыйгалар онытылды лабаса инде, әллә кайда, бик-бик еракта калдылар. Таулар артында кебек: инде теләсәң дә, күреп булмыйдыр...

Каенанасы Җиһангөл янына килеп:

– Әллә соң, килен, акча алып кайтмаганга битәрлисеңме син аны? Тауның башын болыт кисәр, ирнең башын «юк» кисәр, – дип куюы Җиһангөлне кинәт айнытып җибәрде. Карчык ашыга-ашыга ишеккә юнәлде.

Бусагага баскач тагын бер гыйбрәтле җөмлә әйтте:

– Ир аркасы – кала аркасы, белеп тор, килен, – диде.

Җиһангөл исә каенанасын озатканда:

– Әнкәй, гафу ит инде син безне, нишлисең, елгалар да тыныч яшәми, дулкыннары гел тынгысызлап, борчып тора, – дип акланырга тырышты.

Нишлисең, хакыйкатьне баш өстенә күтәреп булмый шул. Бәлки, чынбарлыкта ул киленен генә гаеплидер.

– Дөньялар болганырга тора бугай, – дип пошына-пошына өенә юнәлде каенанасы. Бусага аша чыккач та:

– Син минем сүзләрне авырга алма, килен. Сәгыйтеңнең кызып китә торган холкын кичерә күр, – дип, Җиһангөлгә таба борылды.

– Кичерәм, әнкәй... Бөтен кеше бертөрле булмый инде, нишлисең. Дөньяның да төрле көннәре бар бит: бер ямансу, бер моңсу дигәндәй. – Шулай сөйләнә-сөйләнә каенанасын җөпләде Җиһангөл.

– Шулай, әле җилле, әле тыныч... Бер уйланып алыр өчен бөтенесе дә кирәктер. Кешенең тормышны җәннәт ясавы да, тәмуг ясавы да үзеннән. Берсен күрми торып, икенчесенең кадерен белеп булмый.

– Бәлки, кирәктер дә... – дип кабатлады Җиһангөл.

Сәгыйть үзенә бик кадерле ике хатын-кыз затының сөйләшүен ишетеп торды. Аңа үзен бу хәлдән йолып алырга әнисенең дә зирәклеге җитмәде күк тоелды. Башыннан ук юрганын ябып куйды. Йоклаганга салышып бик озак ятты ул.

***

Сәгыйтьнең гаиләгә акча алып кайтмаганына ярты елдан артты, оятсыз оешма хуҗаларына чиксез нәфрәте шулай вакыт-вакыт өендә ташып чыга башлады. Тик моны әнисенә ничек аңлатсын соң ул? Ярый, хатыны аңлый да кебек. Татар булган өчен шулай кимсетәләр микән дип уйлаган чаклары да бар. Алай дисәң, бригадаларының яртысы – үзбәкләр. Алар да шулай ук акча күрми. Бала-чагалары да Сәгыйтьнекеннән күбрәк. Тешләрен кыса-кыса түзәләр ләса.

Аннан, ничектер, заводлары янә аякка баскандай булды. Яхшы гына эшләп тә киттеләр кебек. Өйдә дә тынычлык урнашты. Ул арада балалар мәктәпне, институтны тәмамлады. Башлы-күзле булдылар.

Ләкин еллар үткәч, күңелсез хәлләр тагын да тирәнәебрәк кабатланды. Сәгыйтьнең тагын еллап хезмәт хакы алганы юк, шушы хәл моннан берничә ел элек булган хәлләрне яңартырга, шул ук сүзләрне сөйләргә мәҗбүр итә иде. Җиһангөл дә инде олыгаю ягына авышкан, оныкларының әбием дип эндәшүен бик табигый кабул итә, ул чынлап та тәмам әби булып өлгергән иде.

Үзгәртеп корулар башланыр алдыннан ил дә үзгәрде: завод-фабрикалар зыянга эшли башлады. Дөресен әйткәндә, базар мөнәсәбәтләре иске калыпларны, кирәген дә, кирәкмәгәнен дә җимерде. Халык аптырашта калды: икмәк сатып алсалар, ул иртән торганчы күгәреп чыкты. Конфет-прәннек авызга алгысызга әверелде. Хокуклар чикләнде, коррупция чәчәк ата, дип сөйләште халык. Икейөзлелек, исереклек, наркомания, спекуляция һәм башка күренешләрнең күбәюе күзгә ташлана, диделәр. Боларның сәбәпчесен табарга кирәк иде. Әлбәттә, һәммәсенә үткәннәр гаепле. Тарих һәрчак гаеплеләрне эзләүдән һәм гаеплеләрдән генә тора шул...

Сәгыйте тагын шешәдән юаныч таба башлагач, Җиһангөл бер карарга килде: «Әни белән Алмазны алам да туган ягыма кайтып китәм! Илдә чыпчык үлмәс әле... Балалар инде үз көннәрен үзе күрә, минем ярдәмгә мохтаҗ түгелләр...» Бу хакта әнисенә дә әйтеп карады ул.

– Безне кайтарсаң ярый, кызым. Авылда кеше бетмәгән. Аннары теге каштаным да, имәннәр, наратлар да юанайгандыр инде. Әхмәтем салмаган яңа өйне, бәлки, Алмазым салыр, – дип, үзенең асыл хыялларын ялгап китте Әсмабикә. – Ә син сабыр ит. Кияү начар кеше түгел. Гаделсезлекне генә күтәрә алмый ул, балакай... Илдә тәртип урнашкач, барысы да үзгәрер...

Баланың бармагы авыртыр, ананың йөрәге авыртыр, ди бит. Ул тынгысыз

айларда карчыкның болай да какча гәүдәсе бөршәеп калды, күз төпләре зәңгәрләнде.

Кияве дә башта тузына, айныгач, гафу үтенү гадәтен алды. Әсмабикә аңа аналарча әйтеп куйды:

– Гафу үтенгәнче, ызгышмау яхшырак, бала, – диде.

Чынлап та, Җиһангөл сабыр итте, ул бу йортта бала тәрбияләүче дә, табиб та, пешекче дә, тегүче дә, җыештыручы да, финанс министры да, тагын әллә кемнәр иде. Хуҗалыкчыл хатын булды. Ир хакын хаклады, бала хакы, диде. Чөнки белә Сәгыйтен: җәмгыятькә булган үче шулай актарылып килеп чыга аның. Дөньяны үзгәртә алмаганга пошына, бахыр. Иренең үзен яратканын да белә. Бер тапкыр үз урамындагы ир-егетләр белән каядыр бик еракка балыкка барды Сәгыйте. Кайткач и мактаныштылар да соң: «Минем балык зуррак та, минем балык әйбәтрәк, имеш.» Кул яссуы берничә балык тотып кайтсалар да, алар үзара: «И-и, күрсәң, бүрәнә-бүрәнә балыклар сикерешә анда», дип сөйләштеләр. Шунда Сәгыйте артык сүз куертмыйча гына:

– Ә минем хатын әйбәт, – дип куйды. Сагынып кайткан иде ул Җиһангөлен. Күңеле булды Җиһангөлнең дә. «Акыллы атын, җүләр хатынын мактар», дисәләр дә, чынында алай түгел инде ул...

Җиһангөл каенанасы сөйләгәннәрне бер дә исеннән чыгармый. И-и, ул каенанасының туган як табигатен тасвирлаулары! Әкият тыңлагандай тыңлады аларны Җиһангөл баштарак. «Бер тапкыр, шулай... – дип башлый ул сүзен. – Каен полосасы буйлап барабыз. Наратлыкка килеп чыктык. Түбәләре белән күккә, әллә ак болытка микән кадалганнар. Агач төбенә карасак, чукыр нидер чүпли. Үзе кояш төсендә. Үзе тавыш биргәндәй итә. Безне күрмәгәндәй кылана. Шул кошның матурлыгына карап утыра торгач, себерке кисәргә килгәнебезне дә онытып кайтып киткәнбез... Кайта торгач, бер чокырга төшкәнебезне дә сизмәдек. Инде бу чокырдан ни карап тора, дисәк – нарат башы төбәлгән икән безгә...» Менә шулай тасвирлап бирергә ярата ул.

Тик туган җиренең һәр мизгелен җанында җанландырып яши, дип тормаганнар шул, сыер тоткан өчен илдән куганнар аларны. Күршеләренә һаман рәхмәт укый каенанасы. Килеп әйткән бит, бахыр. «Иртәгә сезне Себергә озатачаклар, бүген үк качыгыз», дигән. Төн уртасында чыгып киткәннәр. «Себер» дигән сүздән котлары очкан. Ул чакта ике бала белән үзбәк җиренә килеп төпләнгәннәр. Бу гамәлләренең дөрес булуына куанмаган көннәре юк менә. Нахакка авылдан куылуны кичерә алмасалар да, балаларын туган телдән аермаганнар. Өйдә туган телдә генә сөйләшкәннәр. Нишлисең, Рәсәй гомер-гомергә шулай яшәгән: үз халкының да, үз иленең дә мал-мөлкәтен һич кызганусыз тар-мар иткән...

Әмма монда да көн юк: хатынны бер төндә басмачлар алып чыгып киткән. Күрше хатыннары белән бөтенесе бергә елый-елый ялынганнар:

– Сез дә мөселман, без дә мөселман, җибәрегез безне! – дип сораганнар. «Кызыл»лар килеп кенә коткарды, дия иде ул. «Кызыллар» арасында татар егетләре дә күп булган. Хәмит исемлесе аларга килештереп тә йөргән әле. Тик бәхеткә омтылган гомере фаҗигагә очраган: бер иртәдә аны аклар чәнчеп үтергән. Хәер, күн тужурка кигән, наган аскан кырыс чырайлы затлар турында көне буе да сөйләп тора ала ул.

Каенанасын тыңлаганда Җиһангөлнең күңеленә шом төшә, шуңа кайда барса да, якты-күздә өйгә кайтып калырга ашыга.

– Кадимилекне яклаучылар күпчелек иде ул елларда. Укытучы

кызларыбызны да таш атып, пычаклар белән куып йөрүчеләр дә, хәтта чәнчеп үтергән очраклар да булды. Алар мәңгелек йортларын шушы туфракта таптылар, – дип сөйли Сәрбинур. Ул кызларның ять-яшь гомерләренең әрәм булуы Җиһангөлнең дә йөрәген өзә. Әтисе белән әнисе күз алдыннан китми. Җиһангөл монда килеп урнашкач та, Әсмабикә карчыкның хаттагы беренче җөмләсе: «Кызым, балам, синең күңелең кайсы далада?» – дип башланыр иде. Аһ, белсә иде әнисе аның баштарак ничекләр башы авыртканын. Ташбай карт балга әстерхан чикләвеге болгатып бирде. Шуны көн дә иртә-кич берәр бал кашыгы ашарга кушты. Ярдәме тиде бит, рәхмәт яугыры. Үзем үзбәк җирендә, күңелем Татарстанда яши бит минем, дип өзгәләнде.

Төркестанда совет хакимиятен корал көче белән читтән килеп урнаштыруны хәзер инде татарлар үзләре дә хупламый, тарихи ялгыш булуын таныйлар. Моны танулары үзбәкләрнең күңелен йомшартса да, тирәндәрәк, төпкелдәрәк кер калган шул инде барыбер...

Бу хәрәкәттә мәҗбүри катнаштыруларын, большевикларның матур ялганнарына ышанырга өндәүләрен, күпләрнең әлеге канлы көрәштә корбан булуын искә алгаласалар да, бу вакыйгаларның ике халыкның дуслыгына шактый зыян салуын да яшермиләр.

Җиһангөл дә әлеге тарихны өйрәнде, тик нишләсен? Татбригада турында сөйли башласалар, ике бите уттай яна. Үзе бөтен җанын биреп, үзбәк халкына хезмәт итә, алар җирендә яшәвен һәрдаим тоеп тора. Кешеләрнең үз җирендә үзе теләгәнчә яшәргә хокукы, хакы барлыгын да, күкләр катыннан әманәт итеп биргән телдә сөйләшергә тиешлекләренә дә төшенә. Мондый мәкерле тарихның башка кабатланмаслык ераклыкта калачагын дә сизенә. Белем күтәрү курсларына баргач, аларга «үзбәк» сүзенең мәгънәсен аңлатканнар иде. Француз галимнәре бу хакта язып та чыкканнар икән. «Үз» һәм «Бәк» – икесе дә төрки сүз. «Үзенең хуҗасы» «үзенә үзе бәк, әмир» кебек мәгънәләргә ия икән ул. Алтын Урда чорында Үзбәк хан идарә иткәндә, иске үзбәк теле дәүләт теле булган икән. X гасырда, 920-921 елларда Идел Болгарстаны ханы Алмыш Бохара һәм Багдадта илчелек оештырган. Анда илче итеп, Болгар бәге Абдуллах ибн Баштуны җибәргәннәр. Тынычлыкта, татулыкта яшәргә омтылыш гомер-гомергә дәвамлы нигез эзләгән югыйсә... Тик нишлисең...

***

– Татарларны, урысларны куып җибәргәч, барысы да үз урынына утырыр дип көткәннәр иде дә... киресенчә килеп чыкты, – диде Бәхтияр әрнүле тонда.

– Намуслы, хәерле гамәлләре белән халык теленә кергән затлар башына төште бит күсәкнең йомры, юан башы...

– Шулайрак булды шул, апа. Мәртәбәле затлар бик тиз таралды. Барлык тармакларда да белгечләр җитмәве үзен тиз сиздерде. Мәктәпләр укытучысыз, вузлар галимсез, хастаханәләр табибсыз калды. Булды инде анда хәлләр... мамык кырлары чәчелмәгәч, без – гади халыкның да кирәге бетте. Эшсезлек китте. Нинди данлы ефәк җитештерү, келәм туку фабрикалары эшли иде бит. Бөтенесе ябылды. Заводларның бик азы гына калды. Хәзер инде халык тагын Рәсәйне гаепли. Ни өчен гаепле, монысын белүче юк. Тик ярдәмне нигәдер һаман Рәсәйдән көтәләр. Дөресен әйтегез әле, Җиһангөл апа, сез безгә рәнҗедегезме?

– Үткән эшкә салават, калганына бәрәкәт, киләчәгенә хәрәкәт, диләрме? Ул

чакта, бәлки, бераз рәнҗелгәндер дә... ләкин каргыш чәчмәдем. Нишлисең, үткәннәрне үзгәртеп булмый...

Аннан, һәр халыкның үзен сакларга теләве табигый хәл бит, Бәхтияр. Беркем дә милләтенең бетүен теләми. Әйдә, шул чактагы тирә-күршеләребезне генә карыйк әле: ачлык-хәерчелектән качып килгән урыслар Иван белән Алексей үзләренчә яшәмәдеме? Бәби туен да, поминкаларын да үзләренчә үткәрделәр. Үзбәкчәне өйрәнергә теләмәүләре дә үзләренекен җуясы килмәүдәндер, бәлки.

Туган иленнән куылган кырым татары Сәхабетдинне ал. Атасы тегермән төзегән уллары белән бергәләп. Батраклар төнлә килеп ут төрткәннәр. Дөрләп янган тегермәне. Әмма янгын чыгуда хуҗаның үзен гаепләгәннәр. Имеш, ул колхозга бирергә теләми. Имеш, ул – контр. Күзгә төртсәң, күренмәс караңгы төндә улларын ияртеп, авылдан чыгып качкан ата белән ана. Сәхабетдин аларның олысы иде.

Бу якка эвакуацияләнгән яһүд Георгийның чынаяк асты кадәрле түбәтәен салган чагын күргәнең булдымы?

– Без аңа үзбәк түбәтәен бүләк иткән идек, кимәде, – дип кеткелдәп куйды Бәхтияр.

Җиһангөл сөйләвен белде:

– Колхозлашу чорында авылдан сөрелгән башкорт Хисмәтулла да татар, үзбәк белән башкортча гына сөйләште. Без дә балаларга туган телне оныттырмаска, күңелләрендә ата-бабалары туган җирнең җылысын сакларга тырыштык. Барыбыз да сезнеңчә дә кыланып, үзебезчә яшәдек. Югыйсә бу балаларны монда алып кайта алыр идемме? Ә үзбәкнең Пәдәр ашларына үзбәк җирендә торганга, сезне хөрмәт иткәнгә бардык. Димәк, совет кешесе дигән идея миф кына булган. Аллаһы Тәгалә шулай кирәк дип тапса, баштан ук халыкларның бөтенесен дә совет кешесе итеп яратыр иде бит... Ил башларына рәнҗесәң генә инде: һаман бер үк тырмага басалар...

– Үзбәкләр дә гаепле түгелдер, чарасызлыктан шулай килеп чыкты инде, апа, кемнәрдер власть бүлде, кемнәрдер илдә ни барганын аңламый да калды, – диде Бәхтияр, аеруча уңайсызлык тоеп.

Җиһангөл дә кемнедер гаепләргә җыенмый иде. Аның якты йөзенә җыерчыклар булып уелган гомер мизгелләре яхшы уйлар гына уйлата иде.

– Үзбәкләргә хәзер рәхмәт укыйм. Балаларым урнашкан. Оныкларым үзләрен монда тугандай хис итәләр. Дөрес, баштарак оныгым: «Минем җир өстендә виртуаль дусларым гына калды. Бөтенесеннән сез аердыгыз», – дип, гаеп ташлабрак сөйләшсә дә, хәзер язмышы белән килеште. Яңа дуслар да тапты кебек... Инде менә безнең арттан үзегез дә килеп җиттегез... Менә ничек матур итеп, бер табын артында сөйләшеп утырабыз. Сугышмыйбыз да. Сугышырга теләгебез дә юк. Алла сакласын, берүк. Илләребез аерым булса да, безгә барыбер бергәләп яшисе бит...

– Гади халыкка кая да бергәләп яшисе шул... Заманалар ничек болганса да... – дип, чәчен артка сыпыра-сыпыра җөпләде Бәхтияр. – Ләкин бит урыс телле халыкның үзләрендә иде төп гаеп. Бер тапкыр Ташкентта автобуста без – үзбәк малайлары дутарда уйнап барабыз. Бер төркем урыс телләләр килеп керде. Яшьләр инде. Якадан эләктереп, безне тышкы якка ташладылар. «Чуркалар!» дип кычкыралар үзләре. Икенче сортлы халык итеп карадылар бит алар безгә, апа. Шул көн үзләренә килде аннары.

– Тормыш шулай корылган: бөтенесе үзеңә әйләнеп кайта шул... – дип җөпләде Җиһангөл.

– Минем апам шәһәрдә үзбәк телен укытты. Уку түгел тыңларга да теләмиләр дип, мәктәптән елап кайтыр иде. Безнең киемнәрдән, телебездән көлделәр... Алар – бөек тел вәкилләре, имеш... Монысы да сәясәт булгандыр инде. Уртак совет халкын шулай күз алдына китергәннәрдер... – Бу мәлдә битләре, бөтен тәне ничек кызышканны Бәхтияр үзе генә белде. Җан әрнүе пәйда булды. Нишлисең, сәясәт дигәннәре һәрчак гади затлар кулы белән башкарыла... Алар һич тә кемнәрнедер илдән куучылар түгел, үзләре дә сәясәт корбаннары гына иде бит... Аңлый микән моны Җиһангөл апа, дип уйлый ир.

– Монда килер алдыннан, Ташкентта, 1870 нче елда ук оешкан татар мәхәлләсендә кунакта булдым мин, апа. Аларның күпчелеге беркая да китмәгән. Үз җайлары белән матур гына яшәп яталар бездә. Милли-дини бәйрәмнәрдә концертларда да күрештердем татар ансамбльләре чыгышын. «Якташ», «Ләйсән», «Мирас» исемлеләре әле һаман да халык янында икән. Чыгышларын үзбәкләр дә бик ярата.

– И-и, шулаймы? – дип, сөенү катыш сорап куйды Җиһангөл. – Гел шулай булсын иде инде берүк. Бер-беребездән дошман эзләү бер дә яхшы нәрсә түгел. Тынычлыкта яшәсеннәр. Менә бит, сугышмыйча да була. Бер өстәл артында ничек рәхәт итеп сөйләшеп утырабыз. Һаман бер-беребезгә ничек ярдәм итешү хакында уйлашабыз. Ләкин кайбер шайтани затларны тынычлык ярсыта: кулда – бомба, тирә-юньдә сугыш булсын алар өчен. Дөньяны җайлап алып бару турында уйлап та карамыйлар… Тормыш яме – татулыкта. Бер-береңне хөрмәт итүдә.

Ә бит Җиһангөлләр китәр алдыннан үзбәкләрдә дә аерымлану сәясәте каты барды. Үзбәк телен белмәсәң, сине кешегә дә чутламыйлар, ул бердәнбер дәүләт теле, үзбәк яшьләре Төркестан хәрби округында гына хәрби хезмәткә калдырылды, җитәкчелек эшләренә җирле халык вәкилләрен генә алдылар... Башкаларны ачыктан-ачык кудылар. «Үзбәкстан үзбәкләр өчен генә!», «Урыслар – Рязаньга, татарлар – Казанга!» дигән лозунглар урамнардагы диварларда эленеп тора башлады... Һәм болар бер дә юкка гына түгел иде...

Әйе, ачуы елга гына түгел, диңгез булып ташыды ул чакта Җиһангөлнең. Юк, юк, тел өйрәнүнең бер кыенлыгын да күрмәде. Берничә ай эчендә яхшы ук сукалады.

Ни дисәң дә, төрки телләр – тугандаш телләр. Сүзләребез бер тамырдан. Динебез дә уртак. Гореф-гадәтләр дә алай ук ят түгел.

***

Китәргә җыенган чорлар күңеленә юшкын булып утырды аның. Бигрәк тә контейнерлар җибәргән чорда. Инде шәһәрдә төрәсен төреп, тапшырып кына кайтасы урынга, алар ничә тапкыр ватык әрҗәләр янында басып калдылар. Үзбәккә дә, татарга да охшамаган бер зат ящикны тибеп сындыргач та вакланган такталарына кадәр таптап изде. Салып алганлыгы шактый ук сизелсә дә, нигәдер ул эш урынында һәм аңа сүз әйтүче күренми иде. Үзе һаман:

– Килмешәкләр! – дип кабатлады. – Ник безнекен алып китәсез, килмешәкләр... Сез безнең халыкны тәртипсезлеккә өйрәтүче! Яланбаш хәзер бөтенесе дә. Озын ыштаннарны да салдылар. Кыска итәктән йөриләр, зина кылалар, хатын-кызы да тәмәке төтәтә... Аракы эчә... – ул сүзен йомгаклап бетермәде, кулын селкеп: – Ярар анысы, – дип куйды да арырак атлап китте.

– Без шушы илгә җибәрәсе әйберләрнең барысын да хәләл көчебезне куеп эшләгән акчага сатып алдык, сезнекенә тияргә җыенмыйбыз, – дип караса да,

Җиһангөлне дә, хәтта кызы Назлыны да беркем ишетмәде. «Кешеләр кешегә явызлык кылып, өсләренә ничаклы гөнаһ алалар бит. Шул явызлык балаларына, оныкларына әйләнеп кайта аннары. Чөнки Аллаһы Тәгалә Җир шарының үзен дә әйләнә торган итеп яраткан», – дип уйлады Җиһангөл.

– Әйтегез, бездән сезгә ни кирәк? – дип сорады ул, ир-егетләрнең күзенә туры карап.

Тегеләре дә турыдан җавап бирде:

– Тәмәке, «җылыткыч». Шәраб булса да ярый...

Китүчеләрдән белешеп, машинага әрҗәсе белән куйган иде кызы аларны. Бер пакетка туйганчы ашарлык колбаса да, каклаган куй ите дә салды. Монысын гомер буена бергә, бер мәктәптә укыткан Сәрвәр китерде.

– Китәсегезне ишеткәч, телдән яздым, Җиһангөл апа. Сезгә кемдер, китегез, дип әйтергә җөрьәт итә икән, өстенә бик зур гөнаһ ала... Аңлагыз, безгә сезсез бик кыен булачак, – диде.

– Җыендык шул инде... – дип җавап бирде Җиһангөл.

Менә Сәрвәрнең ит ризыкларына урын чыкты.

– Әйдәгез минем белән, үзегез алып керерсез, – диде ул әзмәверләрнең берсенә. Өч литрлы банкаларда тозлы кыяр белән помидор да авыз суларын китереп тора, аларын үзе тотты.

Борылып караса, әзмәвер әрҗәне җиргә куйган да пакеттагы колбасаны зур-зур кабып, авызына олактыра.

– Аю урынына умыра, – дип, үзалдына елмайды Җиһангөл.

Шул арада Шамил Бәхтиярны табып алып килде. Бергәләп, яңа әрҗәләргә салып, стенканы да, диван-урындыкларны да, кием-салымны да озата алдылар. Әйбер юк чак иде бит. Татар җирендә бигрәк тә кытлык дип сөйлиләр. Бу елларның шаукымы кагылмаган берәр почмак калды микән Совет илендә? Боларын алу, йортны да шалкан бәясенә сатып калдыргач, хет тегендә тормыш башлап җибәрергә җайлырак булсын, дигән нияттән иде. Әнә шулай контейнерларны озата алмыйча, әллә ничә көннәр йөрделәр алар. Бу җирдә үзләренә эт саны да калмаганны янә бер кат тойдылар.

Әлбәттә, сүзләрендә хаклык та юк түгел кебек. «Үзебезнең Алмаз балакай нишләп куйды... Аллаһы үзе дә хупламагандыр, кешеләр дә авыз тутырып, гайбәт сөйләүдән тайчанмадылыр ул чакта. Әнисе белән Алмазны китерүче Әхмәт энесе малайның велосипедын да алып килгән иде. Беренче көнне үк ул аны эләктереп, урамга чыкты, тыкрыкларны, арык буйларын әйләнеп килде. Шунда чибәрләрдән чибәр бер кызны күрде.

– Теләсәң, велосипедыма утыртып әйләндерәм мин сине, – диде ул, аның зур, чем-кара күзләренә төбәлеп.

– Әлбәттә, телим, – дип җавап бирде кыз.

Алмаз аны велосипедына утыртып, урам әйләнде. Кыз төшеп калгач та, егет күздән югалганчы, керфекләре талганчы карап торды. Ә кичен Җиһангөлне мәхәлләгә чакырттылар.

– Туганыңны тый, ир хатынын аздыра ул, – диделәр. Хатын ушсыз калды.

– Кемне? – дип сорады.

– Зәйтүнәне.

– Ире кая карый соң аның?

– Командировкада. Белсә, башын кисәчәк ул малайның.

– Ярар, сөйләшермен, – диюдән башка чарасы юк иде Җиһангөлнең.

Җитмәсә, бот буе бер үсмер малай:

– Без велосипедта да йөри белмәгәндә, Алмаз кызлар белән йөри, – дип, авызын ерып калды.

Кайткач та сөйләшә алмады Җиһангөл Алмаз белән. Мәхәббәт иләслеге аның йөзенә чыккан иде. «Әйтәм аны соңгы арада ни кушсаң да карусыз эшли, ярдәм итәргә атлыгып тора», дип уйлап куйды ул. Җиһангөл тойды: ятим баланың дөньяда яшисе килеп яшәгән мәле иде... Сүз арасында гына:

– Син Зәйтүнәнең ир хатыны икәнен беләсеңме? – дип, басым ясап сорады.

– Беләм, бүген генә әйтте. Аны ирексезләп биргәннәр аңа, – диде Алмаз, башын иеп.

Берара сүзсез торгач, ул:

– Ире кайтса, тукмап ташлар үзеңне, аяк-кулыңны сындырыр дип куркам, – дип борчылуын белдерде.

– Зәйтүнә бит үзе дә минем велосипедыма утырып йөрергә тели, – дип куйды егет, сабый балаларча фикерләп. Үзе Җиһангөл апасына ачу тулы күзләре белән карады. Гадәттә, әнкәсе хакында сүз чыкканда, шулай караучан ул. Болай да Җиһангөл Алмазның җанында әнкәсенә нәфрәт, ачу кайнаганын тойгандай була. Ул да адәм баласы бит, аның да әнкәсенең йөз яктысы астында рәхәт чигеп иркәләнәсе, иркенәеп яшисе киләдер. Иң матур әни минеке, дип уйлыйсы киләдер. Хәер, шулай уйлаган чаклары бар иде аның да. Яшьтәшләре алдында горурланасы килгән чаклары бар иде... Тик язмышы аны һаман читкә каера, һаман араларын ераклаштыра.

Шулай да Җиһангөл Алмазның гайре табигый ат яратканын белә иде. Шул хакта ул Сәгыйтенә әйтеп карады.

– Әсмабикә әнидән сораш әле, бәлки, аның хәзер кызыксынулары да, шөгыле дә башкададыр. Кирәк икән, бүген үк алып кайтам. Теге очтагы Әхмәдулла агайларда ишәк тә, ат та бар, – дип, хатынының күңеленә тынычлык салды ир.

Карчык исә:

– И-и, балалар, ат күрде исә үзе ат сыман баскан урынында бии башлый бу бала... Үтәме соң? Үтәме соң?! – дип бөтен йөрәге белән хуплавын белдерде.

Кичен инде ак маңгайлы җирән кашка йортта басып тора иде.

– Намуслы кеше дә соң бу Әхмәдулла агай, хакын да тиешенчә алмады, әйдә, рәхәтләнсен балалар, – дип сөйләнде ир. Әлбәттә, ул үз улын – Шамилне дә күздә тота иде. Ләкин Шамилгә атка караганда, тимер-томыр арасында кайнашу рәхәтрәк тоелды сыман. Шулай да вакыт-вакыт ул да ат янында әвәрә килде. Ир егет ир егет инде, ни дисәң дә!

Ат Алмазны аеруча яратты. Аның шыпырт кына, аяк очларына гына басып, янына килгәнне дә сизә: пошкырына-пошкырына бер урында таптана башлый иде. Кайчакта кешнәп тә җибәрә. Чөнки малай күчтәнәчсез йөрми: табакка солы сала да башта ат алдына куя. Тегесе дә, бигрәк тә, учыннан ялманырга ярата. Сыйланып туйгач, Алмаз аның башыннан сыйпый, ялларын тарый, койрыгын тигәнәктән чистарта.

Алмаз белән Шамил генә түгел, бөтен урам малайларының юанычына әверелде юрга. Сәгыйть үзе дә ара-тирә эше төшкәндә, күрше авылларга атта гына җилдерер иде. Тик Алмазның атка мәхәббәте сүрәнрәк булып чыкты...

Берничә айдан соң Зәйтүнәсе белән кайларга качкандыр Алмаз, тиз генә белә дә алмадылар. Алар туган илгә күченгән чорга туры килде шул ул вакыйгалар.

Ә җирән кашканы Шамиле белән Җиһангөл Зәйтүнәнең әти-әнисенә тапшырып калдырдылар.

– Шушы йортка кайтачаклар барыбер. Рәнҗемик инде без аларга. Мәхәббәт дигән нәрсәне Аллаһы Тәгалә үзе иңдергәч, үзе ярлыкар да. Ә без – кешеләр мәхәббәт алдында көчсез, күрәсең... Яшьлекне тиз адаштыра шул ул, – дип, тынычлык сакларга тырышып урам як капканы япты Җиһангөл.

Урам буйлап атлаганда, җил кузгалган иде. Җил аның уйларын чуалтты кебек. Кофта төймәләрен эләктермәдем мәллә соң дип, уң кул бармаклары белән генә капшанып һәммәсен барлап чыкты. «Эләктерелгән югыйсә, кайлардан кереп, бөтен тәнгә үтә соң әле моның салкыны?» дип гаҗәпләнде. Күзе каршыдагы тауларга төште. Алар чал түбәләрен күккә терәп горурлык аша Җиһангөлне күзәтәләрдер сыман тоелды. «Бу тауларның да түбәләре юкка чалармагандыр, дип уйлады Җиһангөл һәм ян-яклап ишелеп чыккан чәчләрен ак яулыгы астына этте. Соңгы елларда аның да башына кырау төшкәндәй, чал-аклык ныклап торып урнашты шул.

Җиһангөл бөтен тирә-якка, беренче күргәндәй, җентекләп карый-карый алга атлады. Тас-тагаракларда, арыктан ишегалларына борып керткән күлләвекләрдә су өсләре җыерчыкланып-җыерчыкланып тора. Ачы җил гомер күрмәгәнне кылана. Көннәр тотрыксыз шул бу иртә язда. Ай-һай, тотрыксыз...

Ничек кенә йөгәнләргә тырышмасын, аның уйлары һаман Алмаз ягына авышты.

– Сәгыйть абыеңа әйтәм, чыбыркы белән ярыр үзеңне, – дип куркытып та алмакчы иде дә, Алмаз аның ни әйтергә теләгәнен аңлап җиткермәде, балаларча гаҗәпләнеп тутырып карап торды.

Янә дә бер кат сүз шул ноктага төелде.

– Менә, бу хәлне Сәгыйть абыеңа үзең аңлатып бирерсең, – дип куйды Җиһангөл. Бу әлбәттә Алмазны хәвефтән сакларга теләве, һич югы куркытырга маташуы иде.

– Нәрсәсен аңлатыйм инде... – диде дә борылып, үз бүлмәсенә кереп китте.

Сәгыйте дә: «Борын асты да кибеп бетмәгән малайга нинди мәхәббәт тагын?» дип кырысрак кагылырга җыенган иде дә, әллә үз яшьлеген, әллә Алмазның ятимлеген уйлап, әллә Җиһангөлнең кызгану тулы карашларын күреп, кинәт йомшады. Кулын нык кына селтәде дә йортка юнәлде.

Ничәнче төн инде Җиһангөлне йокы алмый. Ничәнче төн инде Алмаз Зәйтүнәсен көтеп, арык буенда качып торган мәлдә караңгы күкләрне нурга төреп, мөлдерәп тулган ай чыга. Ничәнче төн инде аның җемелдек күзләренә текәлеп ята Җиһангөл. Ничәнче төн инде...

Бүген яңгыр явачак, күкләр иртәдән үк караңгыланып тора дип, бер генә фаразламады ул, ничектер берсе дә тормышка ашмады. Язгы җил капка келәсе күтәрелүгә, нindидер могҗиза белән барча болытларны куып таратты. Төн дә мизгел эчендә үзгәрде. «Мәхәббәт төне шундый буладыр шул инде», дип, килешүле уйлар уйлады:

– Адашып кала инде балакай. Яхшыга булырмы, ямангамы?

Югыйсә баштарак кат-кат әйтте Җиһангөл: үткән гомерне кайтарып алып булмый аны, диде. Ялгышлар да гомер юлың буйлап сөйрәлеп, үз артыңнан бара. Башыңны ташка бәрә-бәрә япа-ялгызлыкта канлы яшь сыгарга туры килмәсен аннары, диде. Зәйтүнә – ни дисәң дә, кеше хатыны. Кешенекенә тияргә ярамый. Кешенекен алу – хәрам, диде. Бу сәер халәтенә ачык күзләр белән карарга теләмәде, балакай. Сүзләрнең һәммәсен колак яныннан гына үткәреп җибәрде. Апасының вәгазен тыңлаганда да, йөзеннән яктылык китмәде: аның бөтен вөҗүде бәхетле хыяллар, мәхәббәт бәхетенә тулышкан иде.

Шунысына беркемгә дә сиздермичә, эчтән генә куана да: Зәйтүнәгә мәхәббәте Алмаздан ай чирен юып алгандай итте. Һай, ничекләр интектерде Әсмабикәне оныгына ябышкан бу галәмәт. Тыныч төннәрен сагынып, күпме еллары үтте... Алмаз балакай үзе дә, уянып, төнге өрәкләргә ияреп йөрми, сабый бала сыман изрәп йоклый башлады... Бу хәлне башына төшкәннәр генә аңлар...

Күрче, кай арада аның янына Зәйтүнәсе үзе килеп җиткән, алар янә велосипедны әләктереп, урамга чыкканнар иде.

– Ирең кайтмадымы әле? – дип сорады Җиһангөл, яшь хатынны оялтырга теләп.

Зәйтүнә күтәрелеп карамыйча гына, юк дигәнне белгертеп, баш селкеде. Йөзенә рәнҗеш билгеләре бәреп чыкты. Күз тирәләре тартышып куйды. Искә дә төшерергә теләми иде шикелле Зәйтүнә ирен...

Җиһангөлгә дә кыен булып китте. Күрше-тирә аны да гаепли әнә. Урыс иленнән күченеп киләләр дә безнең әхлакны бозалар дип, йөзенә бәреп әйткәннәре дә булды. Илне зина туздыра, диләр. Тик әхлак җәмгыятькә бәйле икәнне берсе дә белми булыр. Һәр җирдә бер совет власте: тәртипләр дә, әхлак та бердәй тигезләшкән иде...

– Әйдә, тот руленнән, үзең генә йөреп кара, – дип, Зәйтүнәгә ымлады Алмаз, үзенә уйнарга иш тапкан нарасыйларча очынып.

Зәйтүнә куана-куана рульдән әләктерсә дә, аның авырлыгын чамалапмы:

– Юк, минем синең белән йөрисем килә дип, наз тулы карашлары белән егетнең күзләренә төбәлде.

Бу назлы карашлар каршында Җиһангөл көчсез иде. Ул янә бер кат шуны аңлады.

Бер дә үзеннән калдырасы килми иде дә бит Алмазны. Туган җиргә үз баласы сыймас идеме? Бу җирләр аңа мәхәббәт дигән олы хис бүләк итсә дә, кеше туган җирен хәтереннән юып ала алмый шул. Нишлисең менә?.. Мәхәббәт көчлерәк булып чыкты. Мәхәббәт адаштырды...

***

– Пыскып торган яңгырлар печән җирләренә бик килеште быел, – дип уйлап кына бетерде Бәхтияр, тау битендә чалгысын кайрап утырганда. Бу җирләргә чапкыч техника белән кереп булмаганга, әрәм калмасын дип, ул чалгысын эшкә җикте менә. Мондый да шау җиләкле печәнлекне тагын кайлардан тапмак кирәк? Ул белә: җиләкле-чәчәкле хуш исле печән малның сөтен куерта, татлы тәм кертә. Каймакка әвереләдерә тәмам. Яңгыры гына түгел, вакытында түгелеп төшкән кояш нурлары чабылган печәннең җелегенә үтә. Кыштырдап тора, копкоры була. Монысын да киптерер дә өскәрәк менгереп, пресслау машинасына тапшырыр. Аннары үз биләмәсенә алып кайтыр.

Үз биләмәсенә... Әйе, үзенекенә. Бер урамга булса да, җан кертте ләса Бәхтияр. Багана башларына лампочкалар куйды: бөтен урам шәһәрдәге кебек гөлт итеп тора. Ни дисәң дә, көтү чыкмаган авылда көтү чыга. Электр-көтүче әтмәлләргә дә исәбе юк түгел. Кемнеңдер саклап-күзәтеп торуы да кирәк булмаячак. Имеш, терлек токка бер бәрелеп китсә, бүтән ул якка табан борылып та карамый. Сөйләшүләре дөрескә чыкса, үзе бер табыш инде...

Ул үзе чапкан яшь печән арасына сузылып ятты.

– Җәннәт! Менә кайда икән ул дөньялыкның җәннәте! – дип сөйләнәсөйләнә учлап алып, печәнне күз каршысына китерде. Томрап торган кып-

кызыл җиләкләрне чүпләп-чүпләп капты. Борын тишекләрен киереп-киереп җиләкле һава сулады.

Чү! Каян килә мондый ят авазлар? Хәер, ул җәй буена бер кат та ут янмаган якты тәрәзәләрне күреп, кичтән бик аптыраган иде. «Ник кайтканнар? Ничек кайтырга булды икән соң халык?» дип, Мәхәббәте белән дә аптырашып сөйләшеп алганнар иде.

Шулчак чиләкләрнең бер-берсенә бәрелеп чыңлаганы, тимер шалтыраганы, кешеләрнең ачулы аһәң салып сөйләшкәннәре ишетелгәндәй тоелды. Бәхтияр печән арасыннан көчкә кузгалып торып утырды. Йокымсырап та китә язган икән. Чиләкле төркем аңа якынлашып килә иде.

– Сез хуҗа булдыгызмы инде безнең җирләребезгә? – дип, күзенә туры карап сорау бирде сылу гәүдәсенә спорт киеме килешле яткан, джинсы кепка кигән яшь хатын.

– Хуҗа булдым дип... Авыл буш бит. Кыш буена берүзем кар көрәттем. Бер кайтып күренүче дә булмады... – дип сөйләнде Бәхтияр.

Хатын чиләген җиргә ташлап, ике кулын ике бөеренә куеп ук сөйләшүгә күчте:

– Менә кайттык. Тик сез безнең ел да авылдашларны бергә җыя торган җиләклегебезне чабып ташлагансыз... Ә беләсезме, бу тау бите безнең өчен бик тә кадерле икәнен?

Аңа икенчесе кушылды:

– Җиләк җыяр өчен генә кайтмыйбыз бит без монда...

Төрле яклап, һәркем үз сүзен әйтеп калырга тырышты:

– Бу – безнең туган җиребез. Кендек каныбыз тамган җир, аңлыйсызмы шуны?

– Аланыбызга берәүнең дә кул сузарга хакы юк!

– Ул безнең өчен изге урын...

Бәхтиярнең куркудан аяк буыннары йомшагандай тоелды. Ул көч-хәл белән торып басты. Башы үзеннән-үзе аска иелде.

– Аңламаган идем. Хәзер генә аңладым... Гафу итегез сез мине! Кичерә күрегез! – диде ул, телен көчкә әйләндереп. – Ярамый дип, миңа беркем дә бер сүз дә әйтмәде бит.

– Килмешәк күз карашыннан билгеле, – дип куйды юка иренле яшь ханым. Иң авыры, күтәреп булмастае шушы сүздер, мөгаен. «Мин монда авылны аякка бастырам» дип, көнне төнгә ялгап эшләп ятам, ә болар ни диләр... Мәгънәсез булса да булыр икән бу адәм заты. Баксаң, мәгънәсезлек тә түгелдер әле.

Кайткач та, ул тәрәзәләрдә янган утларга карап, озак утырды. Димәк, йокы алмый боларны да, дип уйлады. «Менә сиңа беткән авыл! Моңарчы ул төбе-тамыры белән корыган җир», дип яшәде. Алай ук түгел икән бит. Тамырлар исән икән әле. Исән тамырларның бер тернәкләнеп китү ихтималы да бар. Югыйсә аңа көтүне беренче кат табунга куган көнне шәһәрдән кайткан бер зат бәйләнеп маташты.

– Соңгы кат күрим, көтүеңне бүтән безнең капка төбеннән йөртәсе булма! – диде.

– Ник? – дип гаҗәпләнеп сорады Бәхтияр. – Күктән юл салмадым бит әлегә. – Ул шаяртуга бормакчы булып елмайды.

– Ник, имеш... Капка төбен б...ка батырып бетерәсең ләса. Яхшылап әйткәнне аңламасаң, башкача да төшендерә алабыз без... Машинаны күрәсеңме минем? Шакшыга батып керсенме үз йортына?

Аптырап карады Бәхтияр аңа. Ул чакта «Бераз шөрепләре җитешми торган затлар монда да бардыр инде», дип кенә уйлады. Һәм кисәтү хакында шул ук көнне онытты да.

Ә монысы... җитди. Шаярырга ярамый. Бәхтияр өчен ул нибары печәнлек кенә булса да, монда туып, монда үскәннәр өчен якты тау итәге – чынлап та изге җир иде. Авылның гореф-гадәтләренә төшенми, кадерле-изге урыннарын барламый торып, монда яшәп булмаячак икән, дип фикерләде. Үзен боларны белмәүдә гаепле санады.

– Авылның димәк хәтере исән әле. Җиләкле аланнары да исән булырга тиеш аның. Исән булырга тиеш... Димәк, туган-үскән җирләрен онытмыйлар. Онытмагач, бер кайтырлар... – Ир шулай уйлады. Чалгысын иңенә салып өенә кайтып барганда да, аны уйлар саташтырып, чыгырыннан чыгарды. «Үзләре туган җир, диләр, үзләре Сабантуйда бер, җиләк чорында бер күренеп алалар да, шуның белән бетте... Ник болай икән бу кешеләр?» дип үртәлде.

Өйгә кайтып, Җиһангөл апасына бөтенесен түгеп салмакчы иде дә, Мәхәббәтенең аяк киемен күргәч, һәммәсе онытылды. Ишек ачылуга хатын үзе дә йөгереп чыкты.

– Бу юлы бер дә киләсем килмәде, син монда булганга гына, үземне мәҗбүриләп юлга чыктым, – диде Мәхәббәт, авыр сулап. Ирнең башы түбән иелде. Мәхәббәтеннән исә үзбәк җирендә өлгергән шәфталу исе килә иде...

Бергәләп сөйләшә-сөйләшә, чәй эчтеләр. Ирнең йөзе моңсуланганын хатын да сизенде.

– Син башка төрле бүген, Бәхтияр, – дип куйды.

– Мәхәббәт, тыңла әле син мине, – диде Бәхтияр. – Шамил дөрес әйтә. Җаең булган саен бу авылның мәчете өчен нигез казый башла, ди. Синең янга көрәк тотып кем дә булса килми калмас, ди. Бер көрәк, бер көрәк – шуннан җыела ул, ди. Авылдашлар күңеленә менә шулай, гадел хезмәтең белән генә юл салып була, ди.

– Әллә кайчан әйткәнне нигә әле искә төшердең, син, Бәхтияр?

Ир дәшмәде.

– Ярар, мәчет урынын билгеләргә бергәләп барырбыз, авыл картларын да чакырырга кирәк булыр... – дип нәтиҗә ясап куйды аннары.

Мәхәббәт сизде: ир моннан беркая да китәргә уйламый, киләчәккә башкачарак карап яшәргә җыена иде.

***

Җире барны җир тартыр, җир тартмаса, ил тартыр, дип фикер йөртсә дә, Җиһангөл гаиләсенә кайтып урнашу җиңелгә туры килмәде. «Сугыштан качканыгыз күренеп тора», дисәләр дә, бер җыенып, бөтенләйгә дип чыгып киткәннәрне туган җирдә дә көтеп торучы юк иде.

Шунысы куандыра: бөтен илдә таркалу, үзгәртеп кору барганда, ыгы-зыгылы, коточкыч авыр бер чорда татар илендә тотрыклы тынычлык хөкем сөрә. Илбашына, аның гамәлләренә халык ихлас ышана. Аңа таяныч булып күкрәген куярга әзер тора. Бу хакта Җиһангөл ишетә, хатларда да шулай язалар иде. Шуңа ул туган ягын күңелендә бәһаләп бетермәслек хәзинә итеп тота. Үзен, нәселен саклап калачак җепләрне барлый...

Әлбәттә, башта туган авылларына кайтып төштеләр. Авыр чемоданнарын күтәреп, сукмаксыз, чирәм баскан авыл урамы буйлап барганда, якындагы урманда кәккүк кычкыра иде.

– Кәк-күк... кәк-күк...

«Йа Раббым, көч бир, сабырлык бир!» – дип, тавышлы урман ягына төбәлде Җиһангөл.

Ул кулларын йөктән арындырып, аяк астындагы яшел үлән кыякларына күзен текәп, сагыну сагышында өртелгән кәккүк тавышын тын алмый тыңлады. Туган җирдә ишетелгән һәр аваз аның җанына якын, күңеленә табигый рәхәтлек бирә иде. Бик озак газапланып тормады кәккүк. Авылга шулай аз гомер санадымы, берәрсе үлем түшәгендә ята идеме – белмәссең... Кадакланган тәрәзәләргә карый-карый атласа да, Җиһангөл әле моны яманга юрамады. Әйтерсең, хәзер генә тоемлады: туган җирнең кояшы да бүтән икән бит. Гомере буена туган җир кирәк икән кешегә!

Кинәт гәүдәләре тураеп, йөзләре мөлаемланып китте. Әйтерсең, кайту аның гомерлек хыялы булган. Әйтерсең, ул хыялына якынлашып бара...

Ни дисәң дә, шактый өлкәнәйсәләр дә, монда чыбык очы туганнары яши иде әле. Шуңа да шатланды Җиһангөл. Тамырларың юк икән – синең өчен авылда зират һәм каберләр генә кала шул...

Хәер, контейнерларны да шушы туганнары адресына җибәрделәр. Тик берәр стансада буталып ятадырмы, әллә башка адрес белән киткәнме, белгән юк, кайдалыгын кат-кат юллап йөрергә туры килмәгәе. Җиһангөл аларның тәмам өметен өзеп, кул селтәгәч, җиде-сигез айдан соң гына килеп төшәчәген әле башына да китерми иде...

Туганнары аларны якты чырай белән каршылады. Күмер салып, самавыр кабызып җибәрделәр. Табада коймак чыжлады.

– Авылда, мәсәлән, былтыр ничә бала туды? – дип сорыйсы итте Җиһангөл чынаягындагы чәйгә өрә-өрә.

– Берәү дә юк, – дип җавап бирделәр аңа.

Шунда гүя яшен аның йөрәге аша сызылып үтте, шунда гына ул туган авылының киләчәге юклыгына ышанды. Аһ, бу ышанычны югалтуы! Ничекләр авыр ул...

Җиһангөл тәрәзәдән үрелеп, үзе үскән нигез ягына төбәлде. Әйтерсең, аны анда кемдер көтә иде. Әнисе, дияр идең... Барыбер дә әнисенең сүзләре колак яныннан үткәндәй тоелды. Телефоннан сөйләшкәндә:

– Редискалар өлгерде, кызым, сузар гына идем, буем җитми, – дип өзгәләнер иде.

Җиһангөл дә күңелен күтәрергә теләп:

– И әни, мин дә кетер-кетер кетердәтеп җибәрер идем дә соң, – дип җаваплар иде.

Инде әллә ниләр үскән нигезнең эзе дә юк. Икенче тапкыр янган ул. Беренче янгында да бөтен нәрсә көлгә әйләнгән, бердәнбер Коръән китабына гына ут-ялкын якын да килмәгән иде. Аллаһының кодрәтенә-могҗизасына шунда бөтен күңеле белән ышанды әнисе... Сорыйсы әйберен Раббысыннан гына сорады. Нигезем саклансын, дип сорамаган, күрәсең... Балалар үзләренчә көн итсеннәр, дигәндер. Әнисенең васыяте иде бит Аллаһы кушканча яшәү. Беркемне дә рәнҗетмәскә, үзеңне рәнҗетсәләр дә, каргамаска кушты. Каргыш ике яклы, әйләнеп үзеңә төшәргә дә мөмкин, диде.

Үзбәк якларыннан кайткан авылдашларының күпчелеге Түбән Кама ГЭСын төзүгә керешкәннәр, ди әнә. Каманың агышын үзгәртеп, инде субайлар кагып бетергәннәр, диләр. Алар Амударья, Сырдәрьяларда ГЭСлар төзегән кешеләр, шуңа илгә бик вакытлы кайтып төшкәннәр, имеш...

Тик туганнарның, авылдашларның фикере аваздаш: монда көндез чыра

яндырып эзләсәң дә, эш табыласы түгел, ди. Авылда исерек буйдак егетләр дә әби-чәби генә җан асрый. Ир затлары пенсия акчасына ялланып, кемгә утын ярып, кемгә су китереп, чәкүшкәлек акча эшли. Алар арасында да конкуренция зур, имеш.

Туган авылында эш юклыкны ишетү Җиһангөл өчен көтелмәгән борчулы яңалык иде. Элек чабаталы чакта да авылдагы эшне тавык чүпләп бетермәслек, кешеләр көн арасына кергән төнгә дә хәтта үпкә саклыйлар сыман тоела иде. Беләгендәге мускул-сеңерләре өзелгәнче эшләде ләса ул да! Туган җирендә бер шөгыльсез яшәүне Җиһангөл һич тә күз алдына китерә алмады. Бу хәлләрдән аның йөрәге киселә, хуҗалар чыгып киткән арада балалары белән дә киңәшләшеп карады.

– Вакытлыча гына, үз нигезебездә йорт җиткезгәнче берәр өй алып, суган-кишер үстереп тапшырыр идең – шәһәр бик ерак, юл чыгымнарын да капламаячак, – диде улы.

– Миңа укытырга авылыңда мәктәп тә юк бит, әни, – диде кызы.

– Нигә монда ябыштыгыз соң әле, бу хәтта минем әти-әниемнең дә туган җире түгел, карт әбием дә монда җирләнмәгән, – диде Әлфинә оныгы.

– Бу балаларны авыл белми, барыбер чит итәрләр, килмешәкләр дип карарлар, йорт җиткерү җиңел эш түгел, куйган хезмәтегез юкка чыгар, – диде авылдашлары.

– Бу томрап пешкән җимешләрдән көч-гайрәт туплаган яшь колынчакны караңгы авылда бикләп тота алырсызмы икән соң? – дип, Әлфинәгә ымлады күрше карчыгы.

– Зур түрәләр башкалада утыра, ә монда безгә көн-төн йөгереп йөрсәк тә, бер күз салган кеше дә булмас. Сезне гүпчим бар дип тә белмәсләр... – дип зарланган сыман әйтеп алды сул як күршеләре.

Җиһангөл үзенчә бер ачыш ясагандай булды: «Балаларым белән күршеләрем арасында, димәк, упкын барлыкка килгән. Ике як та бер-берсен таныргга теләми». Ул үз уйларыннан телсез калды. Эчтән генә: «Димәк, җепнең очын үзем яхшы ук чуалтканмын икән...» дип уйлады. Әллә нәрсә булды аңа: әйтерсең, көче җитмәстәй авыр йөк күтәреп бара. Иңнәре кинәт салынып төшкәндәй тоелды. Авылдашлары, туганнары да башка кешеләр. Фикерләүләре, яшәү рәвешләре башка. Әнә бит ничек сөйләшәләр: «Басу-кырлар агуга манчылды, инде бер киткән кошлар да кайтмый безгә», – диләр, колхоз рәисен дә «алабута министры» дип кенә йөртәләр. Тары ярмасына да талон керткәннәр ди. Сабан тургайларын бер генә кешенең дә күргәне юк, күлләр-чишмәләр кибеп беткән икән... Гел начарны гына күрергә өйрәнгәннәрме әллә?

Имеш, зур шәһәрләрдә читтән кайткан ватандашларга булышлык күрсәтү комитетлары оешкан, ярдәм күрсәтергә әзерләр, ди. Газеталарда аларның эшчәнлеге хакында язып кына торалар, әле күптән түгел журналистларны чакырып, зур конференция дә уздырганнар, ди... Хәтта бездәге милли оешма җитәкчеләре үзбәкләрнең милли «Берлек» оешмасына да барганнар:

– Ни өчен мөселман кардәшләрегезне өнәмисез? – дигәннәр. Совет власте урнаштыру чорында татар бригадасының Үзбәкстандагы хәрәкәтен кичерә алмыйлар икән һаман да. Аннан, татарлар үзбәк җирендә дә урысларның үзләрен дә уздырып урыслашып баралар, имеш. Аларны эзәрлекләүче юк, әмма бу хәлләргә ризасызлык белдерми булмый, дип әйткәннәр, ди. Боларны Җиһангөл тегендә ишетмәгән дә иде, мондагы хәбәрдарлыкка шаккатты. Туган җирләрендә кызыксынып торалар, димәк, аларны онытып бетермәгәннәр әле.

Ярдәм итүләре икеле, үзбәк илендә яшәп яткан 800 мең татарны республика һичничек сыйдыра алмас, дип уйлады Җиһангөл.

Кыйшайган йортлар, такта кадакланган тәрәзәләр, алабута, кычыткан, шайтан таягы астында калган бу авыл Җиһангөл өчен шомлы да, җан әрнеткеч газиз дә иде. Ярый, авыл халкы кәҗә асрый, ипи-сөтсез яшәмиләр икән. Карчыкларның да күпчелеге кыш чыгарга балалары янына шәһәргә күченә, калганнары елга буендагы талларны кисеп, кышлыкка утын әзерлиләр, ди. Авылда кибет тә ябылган: юл өзелмәсә, он, шикәр, шырпы ише көндәлек кирәк-яракны сәүдәгәрләр китергәли. Элеккеге партком секретаре мулла булып алган, ди.

– Клубка җыеп, «Коръәннең уңай якларын тормышка ашыру» турында сөйли башлауга мин чыгып киттем, изге китапка ревизия ясамакчылар хәтта, – дип, рәнҗеш катыш әйтеп куйды бер туган тиешлесе.

Авылдашларыннан ишеткән һәр җөмләдән йөрәге куырылып киткәндәй тоела Җиһангөлнең. «Ай-һай, авыр кайтып җиткәч, туган җирне югалтуы, – дип уйлап куя ул. – Әткәм йорты – югалган туган нигезем минем».

Укытучысы – Ульяна Ивановна да Вәсиле белән шушы авылда хәерле гомер кичереп, бакыйлыкка күчкәннәр. Балалары читтә, ди. Йортның тәрәзәләренә такта кадаклап киткәннәр.

Гомәр дә Себердә укып, хәрби хезмәткә күчкәч, туган авылына кайтып тормаган. Хәрби кешегә, хөкүмәт кешесенә әверелгән. Ике кызы да инде мәрхүм марҗа әниләре фамилиясендә, безнең милләт кешеләре түгел, ди. Бу хәбәр Җиһангөлнең бәгырен җәрәхәтләде. Димәк, аның нәсел җепләре өзелгән инде. Шунысы үкенечле түгел: Җиһангөл әле, ни дисәң дә, шул җепләрне саклый алды... Тукта! Нишләп тагын Гомәрне искә төшерде соң әле ул? Җиһангөл үз уйларына бирелеп, диванда оеп утырган бер мәлдә күршеләре Мөнирә килеп керде. Ул кулына ап-ак сөлгегә урап тоткан әйберен өстәлгә куеп ача башлады.

– Туган нигезегездән истәлек-хатирә китердем сезгә, – диде. Һәм сөлгене як-якка ачып җибәрде.

– Коръән! Әллә янгыннан исән чыккан Коръәнме бу? – дип гаҗәпләнеп сорады Җиһангөл.

– Шул Коръән. Ходайның могҗизасы. Бөтен авыл белән шаккаттык инде ул чакта. Мин аны сез кайтканчы саклап торачакмын дип, үземә алдым. Әсмабикә әби намаз карчыгы иде бит. Җүнле кеше иде, мәрхүмә.

– Әлхәмдүлиллаһ, мин дә намазда. Балачакта әбием белән бабама сәхәргә ризык әзерләгән бала ич мин. Әбием әйтә торган иде: «Син, кызым, йомырканы юганчы да юасың, югач та юасың. Итнең һәр җепселен юмасаң да булыр иде инде», ди иде, мәрхүмәкәем. – Җиһангөл Изге Китапны калтыранган куллары белән кат-кат сыйпады. Күзләренә яшьләр төелде. – Балаларым да намазга басарга әзер. Догаларны беләләр...

Җиһангөл шактый таушалган Коръәнне кулына алып, беренче битен ачып җибәрде. Аннан иске заемнар килеп төште. Җиһангөл елмаеп куйды. Күңелендә узган чорларның:

Биек тауның артыннан
Кояш чыга кызарып.
Совет илен ныгытырбыз,
Яңа заем чыгарып.

Заем, заем,
Без заемнар алабыз.
Заем алып, ил баетып,
Коммунага барабыз,

– дигән җыры яңарды.

«Ил баемады...» – дип фикерләде Җиһангөл.

– Тотып ат! Кая качып калган!

Аннан сүзне кирәкле юнәлешкә борып:

– И-и, әлхәмдүлиллаһ, хәерле балалар үстергәнсез, димәк... Ярый бу истәлекне үз өстемә алганмын... – дип өстәде.

– Бу истәлек-хатирә генә түгел, Мөнирәкәем, бу – хәзинә. Рәхмәт яусын сиңа моның өчен, – диде ул, тетрәнүле сүзләрен тел очында әвәләп.

Җиһангөл монда кайтканнан бирле төшендә туган йортының чормасында актарынганын күрә. Иске китапларны ачып-ачып укып карый, иске самоварның җиз корсагын куллары белән ышкып, тузаннан чистарта, әнисенең туку станогын почмаккарак этеп куя, аның һәр нәрсәсен барлап чыга. Туган йортның чормасы да кадерле, анда да нәсел, ил тарихы сыенган, дип уйлый Җиһангөл. Уянгач та ни укыганын, җиз самоварның, станокның кай җире ким-китеклеген һич исенә төшерә алмыйча исәңгерәп ята. Ул белә: бу нечкә җепләр аны һаман туган җиренә бәйләргә тели. Мондагы һәр җеп җанга тоташкан шул, аны берничек тә өзү мөмкин түгел. Авылны әле әнә шушы тырышлыклары, чырышлыклары аркасында әҗәлне якын җибәрми торган карчыклар саклап-тотып тора. Рәхмәт аларга.

Ул авыр уйларга бирелеп, туган нигезенә табан атлады. Күңелен нindидер чир баскандай тоелды. Бу фани дөньяны уйлап, авыруга сабышырга ярамый да соң?!. Нindидер күзгә күренмәс җепләр аны нәкъ менә бүген шул тарафларга тарта иде.

Җиһангөлләрнең йорты янгыннан соң сүтелгән-чистартылган, бары тик шәһәрдәге паркны хәтерләтеп, юан-юан нарат, чыршылар гына үсеп утыра һәм колач җитмәстәй юан каштан шәмдәлләрдәге шәмнәрдәй чәчкәләрен биек күкләргә каратып, яфракларын салмак кына җилдә тибрәтә-тибрәтә аңа ниләрдер сөйләмәкче була... Юка гына чыбык иде бит кайчандыр ул да... Хәер, Җиһангөл үзе дә яшь каштан чыбыгы сыман иде ләса. Аның күз алдыннан сугышлар кичеп кайткан әтисе, күпне күргән ялтыравык тимер көрәге, агач утыртасы чокыр, кылҗайган чиләктәге мөлдерәмә су күз алдына килде. Хәтта шул каштан төбеннән ак маңгайлы маэмае сикереп чыгар сыман тоелды...

– Үткән икән лә гомерләр! – дип куйды ул үзалдына. – Шушы каштан булмаса, ничекләр чит тоелыр иде бу өйсез нигез. Ә ул агач кына көенчә дә шушы туфракның җылысын, матурлыгын саклап калган. Өметне барыбер сүндерми әнә: ап-ак чәчкәләре күкләргә төбәлгән... Энесе Әхмәтне көтәдер, бәлки... Бәлки, Алмазныдыр... Әхмәт башка юл сайлады шул инде. Күптән шәһәр кешесе булды. Авылдан кеше качып бетеп барган бер чорда аны гаепләргә дә кирәкмидер... Язмышы шулдыр авылның... Аларныкы гына буш түгел бит. Ятим нигезләр буа буарлык...

– Җиһангөл!

Абау! Яшьлеге эндәште түгелме аңа? – Ул борылып карарга да куркып, баскан урынында кымшанмыйча торды.

– Исәнме, Җиһангөл! Синең мондалыкны ишеттем дә кайттым менә... –

Ир-ат тавышы аны баскан урынына кадаклангандай итте. Йөрәге тугарылган аттай кая очканын белми, кайнар кан тамырларына сыешмый башлады.

– Исәнме, Гомәр! – диде ул, борылып карамыйча гына. Эчтән генә «Кайтмасаң яхшырак буласы иде бит. Гомер азагында нигә миңа мондый җитди сынау?» дип уйлады.

Гомәр Җиһангөлнең каршысына килеп басты.

– Нигезегез исән, Җиһангөл... – диде ул. – Беркем кулына да күчмәгән, диюем...

Гомәрнең әйтергә теләгәне шул иде: «Әйдә, Җиһангөл, шушында йорт җиткерик тә бергәләп яшәп китик. Син дә ялгыз, мин дә ялгыз. Ялгыз гомер кичүе ничекләр кыен бит...» Ул эшләпәсен пеләше күренмәслек итеп батырып киде. Җиһангөл ян-яктагы чал чәчләрен ак яулыгы астынарак этте.

– Нигезебез исән... Алмаз энекәшем кайтырга тора, – дип горур тавыш белән әйтеп куйды Җиһангөл. Аннан өстәде:

– Менә бит, язмыш безне дә очраштыру әмәлен тапты...

«Мин сиңа йөрәк сүземне әйтергә кайттым, Җиһангөл. Мәхәббәтем сүзен әйтергә кайттым. Син белмисең минем ничекләр сагынып яшәүләремне! Марҗага өйләнгәнсең бит әле, дисеңдер... Алар чая, әйтә торган сүзне үзләре ярып әйтә шул. Ымнар аша аңлаша белмиләр дә. Беркая да китә алмыйсың...»

Ир башын аска иде. Иреннәрен кан оерлык итеп тешләде. Башында тоташтан хәрәкәтләнгән сүзләр ирен очларына кысылып калгандай булды.

– Бу каштанны хәтерлим әле: чыбык кына иде бит, бахыр. Инде юан агачка әверелгән. Ап-ак чәчәккә төренгән.

Җөмләсенең калган өлешен ул эчтән үз-үзенә генә әйтте: «Безнең мәхәббәт агачы бу, Җиһангөл. Ап-ак булып утыра һаман да. Чәчкәләрен күрәсеңме, ничек күккә төбәлгәннәр! Ә күкләрдә чиста дөнья. Анда болытлар да бер-берсе белән аңлашып яшиләр... Без аңлаша алмадык шул. Җирдән аерылып булмадымы?..»

– Безнең кебек үк чал чәчле агач инде ул да, – дип, басым ясап әйтте Җиһангөл һәм Гомәрнең күзләренә карады. Күз яшьләрен голт-голт йотканын тоемлады. Үзенең дә керфек очларына садә яшь эленде.

Әллә кайдан кинәт искән җил каштанның чәчкәләрен койды. Аклык битләренә, аяк асларына сибелеп-сибелеп төште.

«Бәлки уйларсың, Җиһангөл. Мин бит синең өчен кайттым... Ә теге чактамы? Әйе, Миңниса артыннан сине көнләштерер өчен генә бардым. Аның капкадан кереп киткәнен бүрәнәләр өстенә утырып карап калдым. Ул үзе мине күрмәде дә кебек. Очлы күзләр күргән... Сиңа җиткергәннәр. Йөрәк сүземне әйтә алмадым шул, Җиһангөл, беркайчан да әйтә алмадым...» – Гомәр боларны күз нурлары аша җиткерде шикелле.

«Күрче, көз җиткәч, кеше кышка әзерләнә... Ә бу һаман да яз эзли... Хәер, берчак булган иде ул шулай: синоптик кичтән минус егерме дип хәбәр итте. Мамык шәлемә уранып, ишектән башымны тыксам – түбәләрдән тып-тып тамчы тама...»

«Соң инде...» – дип җаваплады Җиһангөлнең моңсу карашы. – «Соң инде, Гомәр...»

***

Икенче көнне үк Җиһангөл гаиләсе белән ерак шәһәргә, кала тирәсендәге авылларга эш караштырырга чыгып китте. Дөресрәге, ул үзе эш кешесе түгел инде, ә менә балалары киңәш-табыш өчен әниләреннән дә кулайрак берәүне дә күзалламыйлар.

Шәһәрдән тиз гайрәтләре чикте: ватандашларга ярдәм итү комитетын эзләп тормаска булдылар. «Яшисең килсә, башкаларга таянма, үзеңә ышан», – ди иде әнисе. Шуңа тагын бер кат инанды Җиһангөл. Җитмәсә, кайда гына кагылсалар да, кайтучылар күп, дигән җөмләне әйтеп калырга тырышалар. Берьюлы ун-унбиш гаилә бергә кайтучылар да шактый, ди.

Эзли торгач, шул мәгълүм булды: кала тирәсендә яңа байларның күкрәп күтәрелгән бистәләре ышыгында калган борынгы авыллар әле бетеп бетмәгән. Элеккеге иске мәктәп бинасы, медпункт эше корылмалары да сүтелмәгән. Әле алар һаман кулланылышта. Шушы бистәләрнең үз халкы шәһәрдә эшли, шуңа авылда укытучылар, ашханә хезмәткәрләре, мич ягучылар җитешми икән.

Яңа бистәләр яңача тормыш белән яшәргә җыена, әмма иске мохит белән һичничек кушыла алмыйча азапланулары бераз күңелне шомландыра сыман тоела. Күпчелек берсен-берсе белмичә, биек коймалар артында көн итсә дә, иске мохиттәгеләр кемнең ничек сулаганын тоеп тора. Авылның болай яңарыш алуын бераүләр хуплый, икенчеләре борынгыдан килгән гореф-гадәтләрнең, «авыл» дигән бөек төшенчәнең җимерелүенә көенә.

Арада Җиһангөлләргә дә ил өстенә төшкән авырлыклардан качып, рәхәт тормыш эзләп читкә китүчеләр, инде монда тормышлар көйләнгәч, янә кеше өлешенә керергә торучылар яки килмешәкләр диебрәк караучылар очрый иде. Чыннан да, шәһәр тирәсендәге авылларга, чикләр ябылганчы дип, тиз арада җыенып, ун-унбишләп гаилә бергә кайтып төшүчеләр дә булган, диләр.

Шәһәр янындагы бер мәктәпкә укытучы тапмаганга, вакытлыча торырга дип, ишелә язган түбәсез бaрактан урын бирделәр шулай да. Җиһангөл кызының да үз юлыннан китүенә беренче мәртәбә шунда куанды кебек. Туган авылында да мәктәпләрне берләштергәннәр, тирә-юньдә тагын иллеләп укытучы эшсез калган, ди, әнә. Инде авылга оптимальләштерү дигән афәт үтеп керергә тора, ди. Димәк, болай булгач, урамда калмаслар, барысына да әлегә газиз башлар сыярлык урын иде бу. Хәер, болай гына да түгел, ташландык барак каршында шәмдәлләрдәге шәмнәр кебек ап-ак чәчкәләрен зәңгәр күкләргә чөяргә теләгәндәй каштан агачы утыра... һәм ул Җиһангөлгә туган авылын, газиз нигезне, әтисе утырткан бакчаны искә төшереп тора иде... Ул каштанга якын килеп, аның кубырчыкланып беткән калын кайрыларыннан сыйпады. Тәне буйлап әллә нинди җылы дулкын йөгереп узгандай тоелды.

– Каштан күккә төбәлгән. Каштан һаман күккә төбәлгән ләса... – дип пышылдады. Каштан янәшәсендәге агач-куакларга кошлар оя корган, алар ашыга-ашыга җим ташый иде.

Әйтерсең, бу юан агачның бөтен яшәеше Җиһангөлнең үзенә тоташкан. Әйтерсең, ул аның хыял-өметләре, газиз халкының үзе күрергә теләгән чагылышы иде.

– Кошлар оя корган җирдә калыйк без, балалар, башка беркая да бармыйбыз. Эзләдек. Таптык менә, – диде Җиһангөл. Бу мәлдә Сәгыйте аның күз алдыннан китмәде. Ризалашыр иде микән ул шушы җирләрдә яшәргә? Аһ, ничек еракта бит үзе. Адәм баласын туфрак баса, туфрак араны салкынайта, дисәләр дә, ирен югалткан көннән ул аны чын-чынлап яратуын аңлады. Нинди генә эшкә тотынса да «Ул ни әйтер?» дигән сорау каршысына килеп, баш ия. Вакытлар үткәч ерагаер, дип өметләнсә дә, янәшәсендә иренең җылысын тоя, күз карашларының үткенлегеннән исәнгерәп кала иде.

Ә Гомәр яшьлектәге бер яктылык, серле рәшә генә булган икән лә...

Улы белән кызы:

– Барагы бик иске бит, әни, сүтүе дә мәшәкатьле булыр, – дип, бер генә әйтеп карадылар да башка җавап ишетмәгәч, тындылар.

Эшне нидән башларга дип, озак баш ватып маташмадылар, ни бар акчаны җыйнаштырып babакның түбәсен ябып куйдылар, мич чыгардылар. Шунысы кыенга туры килде: халык өмә дигән матур йоланы онытккан. Ни эш башласаң да, үз көчеңә генә таянырга кирәк булды. Хәер, шәһәр тирәсендәге авыллар өр-яңа баштан укмашып кына килә, аларның иске тарихы җуелган, яңасы әле язылмаган. Бу яңа тарихны Җиһангөл аңлый да, хуплый да алмый. Әмма яшәеш ноктасының шушында төпләнергә теләвен яхшы чамалый. Әйдә, кошлар оя корган җирдә тормыш булмый калмас әле, ди. Тирә-күршедә дә әнә балта-пычкы тавышы тынмый.

Аларга да балта-пычкыны бирәү дә кызганмады.

Кайтып урнашкан чорлар исенә төшсә, ул вакыт-вакыт олигархларның кая куярга белмәгән миллиардлары хакында да уйлап куйгалый. Белә: халык та болар хакында ишеткән-укыган саен телне шәбрәк шартлатырга өйрәнеп бетте инде. Нишләтәсең, кешегә бирүчеләр алар түгел. Гади халык кына ул бүлешә белә, бары – бергә, югы – уртак, дип яши. Авыр булды шул тернәкләнеп китүләре... Туган-тумачалары да ярдәм кулын сузды: бурычка акча биреп торучылары да бар. Мохтаҗ кешегә әҗәткә акча биреп тору сәдакага караганда да саваплырак, диләр. Монда әле бу хакта онытмаганнар шикелле. Аннан Аллаһы үзе ярдәм итте. Улының, киявенең бизнеска керешеп китүе дә уңышлы гына килеп чыкты. Тора-бара яңа йортлар җиткерде. Инде иман качкан авылны торгызмакчы булып ята, җыйнак кына булса да, мәчет салды әнә. Авыл картларын бер үзәккә туплап куйды. Алар таякка таянып булса да, барырга тырышалар. Ил-көнгә иман сорыйлардыр...

– Мин әнигә охшаган, таш астыннан да чыгам. Үз көчемә таяна беләм. Күрәсез: көнем муеннан тирес эчендә үтә. Кулдан көрәк-сәнәк төшми. Балалар хакына болар. Сиңа да җиңел булмаячак, – дигән иде ул Бәхтиярга да.

Хәзер авылга юл салдыру мәшәкате белән йөри. Халыкның күзе аңа төбәлгән: «Син булдырасың!» – дип кенә җибәрәләр. Баштарак, кысанрак чакта: «Һәрберсе минем өлешкә керергә тырыша», – дип, ачуы килсә дә, хәзер ярый әле бу эшне башкарырга кирәк дип, чаң сугып торучы авылдашларым бар, дип куана. Юл газабы – гүр газабы, барысы да беләләр: һәммәсенең балалары, нәсел-нәсәбе авылга тоташкан. Ә Шамилнең авыл халкы алдында гына түгел, районда да дәрәҗәсе бар. Шәһәрдә дә таныйлар. Дәрәҗә булса да, гадилек – канда. Кешеләрне ярдәменнән ташламый. Әйтерсең, авылның тәртиптә торуы өчен ул җаваплы.

Эш белән яшәгән гаиләдә үсте шул ул. Җиһангөл үзе дә, ире дә гомумхалык язмышы өчен борчылдылар, гомерләрен илгә хезмәт итүгә багышладылар. Улының да балачактан каешларына кадәр елкылдап торыр иде.

– Кем чистартып бирә соң моны болай сиңа? – дип сорап куярлар иде бабасының кордашлары.

– Әти! – дип горурланып җаваплар иде улы, бөдрә чәчләрен артка тарый-тарый. – Итек кунычы белән чистарта ул аны.

Яхшы укыды. Сәхнәгә килеп чыга: киноартист дип белерсең. Шаян шигырьләрне кешенең рухын күтәрерлек итеп сөйли иде. Шуңа балачактан яратты аны бистәдәге халык та.

– Улың кара күзле булсын! – Җиһангөлнең күз алдыннан ишәккә атланган үзбәк карты, Бәхтиярның бабасы үтеп китте. «Юк, – диде ул үз-үзенә, – улым болгар-кыпчак нәселеннән. Минем дәвамым ул. Күзләре берничек тә кара була

алмас аның. Күк төсле яп-якты, зәп-зәңгәрләр! Безнең җирлеккә, һай, ничек килешеп тора. Беркем дә: «Күзләрегез ясалма мәллә?» дип сорамас. Монда аның күзләре дә, үзе дә чит түгел. Тамырлары барыбер шушында тоташкан. Улы белән чиксез горурлана Җиһангөл. Аңа караган саен үз җирендә басып торуына инана.

– Ярый чит-ят җирдә адашып калмадык, улым, – ди. – Илдә чыпчык үлми барыбер дә. Ә сезне мин гомерем буена киләчәккә өметем итеп күрдем. Улы юкның урыны юк, кызы юкның кадере юк, дип белми әйтмиләр икән шул.

Оныгы Әлфинәнең генә бераз тормыштан гайрәте чиккәндәй тоелды. Кайткан мәлдә дусларын телдән төшермәде. Алар янында миңа рәхәт иде, сез генә аердыгыз, диде. Күрше егете Хәлбайны сагынды. Аның күченеп китәр алдыннан танкта йөртүен «Һай, кызык булды да соң!» дип, һаман искә төшереп торды. Алкын яшьлеккә бәйле якты хатирәләр аңарда җирсү хисләре уята, шуңа да бабасының бабалары яшәп, бакыйлыкка күчкән бу якларга җаны берегеп китә алмый иде әле. «Менә ничек була икән ул Ватанны югалту», – дип, Җиһангөл аеруча пошынды. Үзенең авылдан чыгып киткән мәлен исенә төшерде. Өметләре зур, хыяллары ничек якты иде бит! Гомерне болай тиз генә узар да ирешелгәннәрнең бөтенесе шулай тиз арада челпәрәмә килер дип кем уйлаган?

Оныгы үзен яратканны яхшы белә Җиһангөл. Күршегә генә кереп китсә дә, артыннан:

– Әбекәем, озак торма, тиз кайт! – дип кала.

Әлфинә кайтуга тегүчелеккә укырга кереп, кулына таныклык алса да, бу һөнәр дә аңа куаныч китермәде. Үз эшемне ачам дип талпынып карады. Италиядән тукымалар кайтартты. Тукымалары искиткеч яхшы иде. Тик кием кисү остасын табу һич мөмкин хәл түгел, ә тегүченең язмышын – бизнесының алга китешен оста кисүче генә тәэмин итә икән. Шулай да ул әбисеннән, әти-әнисеннән аерылу хакында башына да китерми, җәфалана-җәфалана булса да, үзен бу яклардагы тормышка күнектерергә тырыша иде. Җиһангөл күрә: эштән кайтканда, кара мыеклы чибәр генә бер егет аны машинасы белән дә китерештерә... Җаен туры китереп сораштырып караган иде дә, оныгы елмаюы белән генә җавап бирде. Әйдә, хәерлегә булсын!

***

Инде менә Бәхтияр гаиләсенә дә танышлык аша җиңеллек килде. Дөрес, үзләре дә тырышлар. Бәхтияр да, Мәхәббәт тә, ни дисәң дә, мамык кырында үскән балалар. Мамык җыю ярышларында чыныккан затлар. Көненә 150-200әр килограмм мамык җыюның ни икәнен бик яхшы белә Җиһангөл. Аның күз алдыннан иксез-чиксез ап-ак болытлардай мамык кырлары чагылып үтте. Кичтән кырны аклыктан арындырып кайтып китәрләр иде бахырлар. Иртән килсәләр... тагын ап-ак. Эскерт-эскерт өелгән мамыкны ничекләр ташып бетергәннәрдер? Мамык җыйганда кигән алъяпкычын истәлеккә монда да алып кайтты. Шактый искергән булса да, алъяпкыч аңа коры, кояшлы үзбәк көзләрен исенә төшереп тора. Һай, матур булган ла ул көзләр! Бөтен Рәсәйне, башка бик күп илләрне тәэмин иттеләр бит алар шушы чимал белән. Мәктәп укучылары гына булсалар да, һәркемнең үз нормасы билгеләнгән иде. Хәзер инде анда да кырлар мәйданы ягыннан бик кимегән, диләр, әнә.

– И апа, мамык җыйганда, чәйне эчеп тә карый идек соң! – Хәтерлисезме, безгә аны кытайлардан кергән дип сөйли идегез. Россиядә 1640 елда гына ни икәнен белгәннәр, Монголиядән урыс патшасына Алтынхан бүләк итеп җибәргән, дигәнегез әле дә истә.

И бәхәсләштек тә соң ул чакта: «Чәй ул үзбәкләрнеке, күрәсезме, бездә чәйханәләр күпме, имеш. Ни икәнен дә белмәгән халык шулчаклы чәйханә тотамы? Ә сез, татар халкы да ефәк юлы буйлап, Кытайга чәйгә йөргән, хәзер инде аның кайсы халыкныкы булуы һич әһәмиятле түгел, ди идегез».

Әле минем әбигә кан басымы белән авыргач, бер бал кашыгы чәйне җылы чәйнеккә салып, кайнар су коярга һәм шуны чәйнегендә үк суытып эчәргә кушкан идегез. Хәзер әни шулай итә.

– Берәр җирдән укыган булганмындыр инде. Менә бит нинди ул укытучы авызыннан чыккан сүз, – дип гаҗәпләнеп куйды Җиһангөл.

Ул кызына карап тора да хәзерге укытучылар дөньясына кызыгып та куя: алларында компьютер. Нинди мәгълүмат кирәк, бөтенесе шунда. Аптырый да: кызының алдында һаман кәгазь-каләм, һаман план төзүдән бушамый. Һәр яңалыктан хәбәрдар булу сорала бит укытучыдан. Һөнәри осталык дигән нәрсә ул бер көндә үзеннән-үзе барлыкка килә торган нәрсә түгел, гомерең буена тырышасы. Тик кәгазь боткасыннан нишләп һаман да арына алмый икән соң бу мәктәп? Монысына ул беркайчан да җавап таба алмады.

Җиһангөл урыныннан кузгалып, кухня ягына юнәлде. Әлфинә оныгының эштән кайтыр вакыты җитеп килә, чәй куеп җибәрәсе булыр. Кыздырган бәрәңге ярата, бераз майда йөздереп, кетердәп торырлык, кызгылт төс кертеп алсаң да яхшы. Эшне тиз тотарга ярата Җиһангөл. Табада май чыжлады. Газ миче өстендә чәйнек сызгырды.

– Абау! – дип йөрәгенә ябышты ул кинәт, тәрәзә каршысына килеп туктаган машинаны күреп. – Кем белән бу кыз? Әллә көпә-көндез егетен алып кайтамы? Белмәссең... Оят качкан шул замана яшьләрендә.

Җиһангөл уйларын төгәлләп бетергәнче, кыз белән егет машинадан сикереп төшеп, бер-берсен кочып алдылар. Иреннәре иренгә беректе...

– Нишлиләр болар?! Кешедән оялмыйча... Абау, җаным!.. – Җиһангөл йөзен яулык очы белән каплады. – Көпә-көндез гөнаһка батыралар, хәерсезләр, – дип сөйләнде.

Ул арада машина капка төбендә тузан болыты калдырып китеп тә барды. Әлфинә канатлы коштай өйгә юнәлде.

– Әбекәем!

Җиһангөл дәшмәде.

– Әбекәем, мин кайттым. Ник сөйләшмисең син, ә?

– Сөйләшерлегемне калдырмадың, кызым. Көн үзәгендә егетләр белән үбешеп торасың лабаса. Кешедән оят. Бөтен урам гыйбрәт итеп сөйләр инде...

– Яратам ич мин Риназны, әбекәем. Ул да мине ярата.

– Ярату шундый буламы?.. И-и бала, бала... Мине рәнҗетәсең килмәсә, башка мондый хәлне минем күземә күрсәтмә, ярармы?

– Ярар соң... Ә ярату гаепме?

Кыз күзләрен түгәрәкләндереп әбисенә төбәлде. Аның мәхәббәт тулы йөрәге һич кенә дә әбисенең тар күңелле бу гамәлен аңлый алмый тилмерде.

– Ә син бабайны болай яратмадыңмы? – дип сорап куйды ул.

– Чын сөю ул иреннәрдә түгел, йөрәктә була, – дип җаваплады Җиһангөл, авыр сулап. – Ә йөрәкне бөтен кеше дә күрергә тиеш түгел аны...

Ул яулыгын төзәтештереп бәйләде. Күлмәк итәкләрен кагыштырып җибәрде. Аннан:

– Әйдә, бәрәңге кыздырдым, кызым. Син яратканча итеп. Чәй дә кайнады... – диде, тавышын йомшата төшеп.

***

– Кышын-язын теплицаны җылытырга утын кайлардан алырбыз икән,– дип борчылып торганда, Бәхтиярларга базарда сатучы бер үзбәк танышлары кагыла үтте.

– Базар тулы агач әрҗә, зуррак машина белән килсәң дә була, – диде ул, сүз иярә сүз чыгып сөйләшеп киткәч. – Үзем төяшеп җибәрермен...

Бәхтияр шаккатты: базарның үз законнары икән, анда чүпне алып китүченең үзенә акча түлиләр, ди, хәтта. Хәер, ул моның белән кызыксынмады да. Шамил аңа:

– Эшнең тәртибенә төшенеп, аны бер эзгә салып, хезмәт тәмен тоя башлагач кына матди кызыксыну туа башларга мөмкин, – дигән иде бит. Шулай да ул төшенде инде: акча бакчада үсми шул...

Иң мөһиме: үсентеләрне саклап булачак, дип куанды ир. Ни дисәң дә, узган яз кыенгарак туры килде. Барыбер дә кеше бәрәңге утырткан чорда аларның кыярлары өлгергән иде инде. Шунда ул үзләрендәге таяк төртеп куйсаң да, агач үсеп чыгасына ышандырган газиз туфракны кат-кат күз алдына китерде. Бакчаларны арык суы белән генә сугарырлар иде. Бер көнне уң як күршесе суны буып, үзенә табан кертсә, икенче көнне икенчесе дигәндәй... Су да җитә, уңыш та мул иде шул... Хәер, суга монда да кытлык калмады анысы. Тик гербицидлар сипмәгәч, чүбе күп. Ә басуны гел утап тормасаң, башны кашырга гына калмагае... Тырышмый кая барасың? Аларның бәрәңгесен, суганын аеруча ярата халык. Каралмый, череми, диләр. Хәзер инде район-шәһәр шифаханәләре, завод ашханәләре – аларның даими клиентлары. Көз җитте исә мәктәп ашханәләре дә кушыла. Ни дисәң дә, монда агусыз, нурланыш кулланмыйча үстергән ризыкның кадерен белүчеләр арта бара. Әнә бит, радиодан алтмыш процент ризык чит илдән керә, күбесе бөтенләй ашарга яраксыз, диләр. ГМО, нурланыш кулланган ризыклар, имеш... Чөнки Бәхтияр белән Мәхәббәт монда поездда килгәндә дә аптыраудан һушсыз калып тордылар: никадәрле җирләр буш ята. «Нигә болар чәчелми дә, сөрелми дә икән соң?» дип, бер-берсенә сорау тулы карашларын төбәделәр. Икесе дә җавабын белми иде, әлбәттә. Хәер, үзләре дә чәчәрбез дә урырбыз дип башларына да китермәделәр. Мамык кырларыннан туйган иде инде алар болай да... Ә баксаң, яңа җирдә чәчүе дә үстерүе дә башкача икән. Аннан эшне үзең ачып, үзеңчә эшләү аларны рухландыра, киләчәккә өметләр дә уята иде.

Монда килгәч кенә белделәр: Россиядә буш җирләр утыз-кырык миллион гектар, диме? Коточкыч бит бу, диештеләр. Кешеләр үзләре үстереп ашасын иде һич югында. Авылда да бәрәңге бакчалары буш ята әнә, балалары шәһәрләшкәнгә шулайдыр инде. Кытайлар үстереп җибәргәнне көтә халык... Югыйсә мондый кара туфракны бер генә кеше дә исраф итмәс иде. Ир белән хатын шулай уйлады.

Үзләреннән сатып алучылар бер дә өзелеп тормады.

Ни дисәң дә, һәммәсен крестьян-фермер хуҗалыклары җитештерә хәзер. Дөрес, райондагылар мондый хуҗалык оештыру өчен дүрт-биш битлек документлар үрнәген чыгарып күрсәткәч, Бәхтияр егылып китә язган иде.

– Кая карама – «птичка» куеп утыручылар, ник болай кеше башы катыралар икән, – дип гаҗәпләнде.

Шамил:

– Бергә-бергә башкарып чыгарбыз, борчылма, – дигәч, тынычлана төште. Ярдәм итүче барында куркасы түгел икән шул...

– Менә мондагы карчыклардан сорашып кара, сезнең заманда ничегрәк иде, дип. Тасвирлап бирерләр алар үткәндәге тормышны. Иткә салым, йонга салым, йомыркага салым... Ә бит яшәргә тырышканнар барыбер. Сыер асраганнар, сарык тотканнар, йорт тулы тавык кытаклап йөргән. Ә бүген бернинди салым да юк, авылда сыер түгел, тавык та юк. Әни әйтә җыры да бар иде әле аның ди. Ничек әле? Менә болай:

Колхоз сорый бер күкәй,
Хуҗам сорый бер күкәй.
Ике күкәй сала алмыйм,
Асылынам мин, түтәй...

Хәзер бит инде тавыкларга да хөррият. Колхоз бетте, хуҗаларга да күкәй әллә бар, әллә юк. Дөрес, базарга күчеп бара дөнья. Монысы да җиңел хәл түгел. Табиблар дөньяда авырулар барын онытып, базарга чыгып утырды. Укытучылар дәфтәр-китап саласы сумкаларын чүпрәк-чапрак белән тутырды. Йотты аларны базар. Эздән чыгарды. Җир кешеләре дә җирне хәзер төкерек төшәр урын итеп кенә күзаллый... Ә бит кешене һаман да җир ашата. Югыйсә эшләргә иренмәскә генә кирәк. Гөрләтеп яшәп була бүген авылда ялкаулыкны муенга атландырмасаң, – дип, өмет чаткыларын күпләп салды Шамил. – Без кайткан чорларда җиңел булмады: 90 елларда ил җитәкчелеге авылны бөтен мәшәкатьләре белән бергә үз иркенә ташлады. Халык эшли, продукция җитештерә, ә бер тиен дә акча ала алмый. Колхозлар тәмам бөлгенлеккә төште. Инвесторлар шул чорда керде авылга. Курыкмыйча эшкә алындылар. Ләкин халык һәммә нәрсәгә ышанычын югалткан иде инде. Эшләмәскә өйрәнеп өлгергән иде. Юк кына эшкә дә кеше табалмыйча җәфаланып беттеләр.

Бәхтияр белән Мәхәббәт гадел хезмәттән курыксалар, шулчаклы чакрымнар үтеп, нидер эзләп йөрмәсләр дә иде.

– Монда кадәр килергә иренмәгәнне, эшләргә генә иренмәбез, – диде Бәхтияр. – Нишлисең, кеше бәхетен читтән эзләүчән шул...

– Әйе шул. Ир-ат бигрәк тә. Хатынны булса да, күрше авылдан ала инде ул түлке, – дип шаяртты Шамил.

– Чынлап шулай, – дип, башын артка ташлап көлде Бәхтияр. – Минем Мәхәббәт тә – күрше авыл кызы. Башта мин аны читтән эзләп таптым. Аннан икәүләп бәхет эзләп, читкә чыгып киттек... Алай зарланмыйбыз үзе.

– Бәхет эзләгән затларга зарлану һич килешми, – дип, сүз уңае гына әйтеп җибәрде Шамил.

Шулай да бер дә авырлыксыз ни бар? Узган җәйләрнең берсе коры килде. Туфрак шыкраеп кипте. Җирдә аждаһа авызыдай куркыныч ярыклар хасил булды. Коеларда су калмады. Күл дә саекты. Менә шунда Бәхтияр сугару системасы кирәклегенә төшенде. Әлбәттә, барысына да акча кирәк, әмма Шамилнең бер кат та аларның ихтыяҗына бармак аша гына караганы юк...

Яздан ук үз көчләре белән буаны буып куйдылар. Күлне, коены

чистарттылар. Тирән итеп скважина казыттылар. Кыскасы, эше җиңелдән булмаса да, суга кытлык дияргә калдырмадылар.

Авылда көтү чыкмый. Сыер мөгрәми, сарык-бәрәннәр тавышы ишетелми. Ара-тирә казлар каңгылдашканы, үрдәкләр бакылдашканы гына колакка чалынгалый. «Авыл терлек-тарусыз яши аламы? Балалары кайда бу карт-карчыкларның?» дип гаҗәпләнә Бәхтияр.

Үзләренә менә эш башлаучыларга бирелә торган грант та ярап куйды. Берничә абзар төзеделәр. Авылда:

– Өйләре ишелергә тора, анысын яңартмыйлар, терлекнекен карыйлар, – дип сөйләштерсәләр дә, һич исләре китми. Үзләре корган планны бозарга бер дә исәпләре юк.

Мал асрауның да җаена төштеләр. Ике йөз баш казлары үсеп килә. Ике йөз егермеләп бәбкә алганнар иде дә, баштарак нindидер зәхмәт тиеп, егермеләбе кырылды. Өч савым сыерлары да сөтле булды, кышлау таналары да дүрт башка җитте. Ашату ягын да вакытында кайгырталар. Печәнлек җирләрдә печәнне чәчеп, чабып, пресслап-бастырыклап куя торган техника да алдылар. Ул яктан эш җиңеләйде.

Бәхтияр тәрәзә аша капка алдында солы чемләгән шома, тыгыз тәнле таза атына күз төшереп алды. Яткан җирдә күшәгән таналары карашына чалынды. Йортта әнә тавыгы-күркәсе йөгереп йөри. Алары да аз түгел икән.

Якташлары авылга кечкенә генә сату ларёгы куярга тәкъдим ясады. Карбыз-кавын, җиләк-җимеш белән үзебез үк тәэмин итәчәкбез, диләр. Бәхтияр монысына да ризалашты. «Ничә авылга бер ларёк кую начар булмас иде ул», – дип, Мәхәббәт тә килешүен сиздерде. Мәхәббәтнең әтисе бу якларда шәһәр базарында гомере буе җимеш саткан. Гаиләсен туклыкта, муллыкта яшәткән. Картлыгында үз кояшы астына күченсә дә, кызы гаиләсенең бу тарафларга юл тотуын хуплаган. Оныкларының татар иле белән таныша торуына да бер дә каршы килми.

Быелгы җәйдә Бәхтияр белән Мәхәббәтнең уллары Малик та әтисе янында тракторда йөрергә өйрәнде. Үзбәкстандагы уку йортына кергәч, әти-әнисенә булышырга килде ул беренче тапкыр. Инде өченче курста менә.

Кечкенәләрен Бәхтиярның әниләре җибәрми тора: бер башлаган җирдә бетерсен, авылыгызда мәктәп юк, дисез. Әлегә кузгатмагыз, җәйгә алып китәрсез, ди. Дөрес, балалар җәй буена үзләре белән булалар. Озаткан чакларында җаннары өзгәләнә, әлбәттә. Бу хакта еш кына Җиһангөл апасына да сөйли ул.

– Бала «бал» сүзеннән алынгандыр инде ул, бу кадәр үк татлы булмас иде, – ди.

– Анасы – умарта корты инде, димәк, – дип, кетер-кетер көлә Җиһангөл.

– Әйе, балның ничек җыелганын умарта корты гына беләдер...

Тик нишлисең, тормыш кануннары һәркемне җиңә шул. Менә шулай бер каршылык, бер уңыш аша көннәр арты көннәр үтә торды.

Бәхтияр белән Мәхәббәт тормышка бераз хыялыйрак карыйлар. Һаман телевизордан өстәгеләрнең кайларда йөрүе белән кызыксыналар. Алга киткән илләргә барып чыксалар, аларның тәҗрибәсен өйрәнәләрдер дип, ихластан куаналар. Чөнки аларда фермерлар бары тик табышка гына эшли, диләр. Моны хәтта закон үзе яклый икән. Бер литр сөтне 20 тәңкәгә сатып утырмыйлардыр шул алар... Бушка эшләгән авыл үзеннән-үзе бетәргә мәҗбүрдер. Бу илдә көн саен берничә авыл бетә дип укыды газетадан беркөнне Бәхтияр. Шулайдыр... Һич ялган юктыр... Эшләргә кеше табып булмавы да галәмәт инде, баксаң...

Беркөнне аларга бер төркем мәктәп балалары килеп керде. Үзләре шаярышалар, үзләре шаркылдашып көлешәләр. Баскан урыннарында биеп торалар. Көчләрен кая куярга белмәгәнлекләре холык-фигыльләреннән күренеп тора. Бәхтияр яшьлекнең гамьсезлегенә, җиңеллегенә сокланып карады.

– Абый сездә эш бар, диделәр...

– Ә өегездә юкмы? – дип сорады Бәхтияр да, башын җүләргә салып.

– Безнең йортта тавык кына кытаклап йөри...

– Бездә тавыгы да юк...

Бераз акча эшләп алырга теләкләре барлыгын тиз сизенде ир. Бәхтиярдан бигрәк Мәхәббәт куанды. Болар исерекләр түгел инде, чакырсаң, иртәгә дә килергә мөмкиннәр, дип уйлады. Тик арада авыл советы рәисенең кызы да булган икән, әнисе кара тавыш кубарды. Мин бердәнберемне сезгә кол итәр өчен үстермәдем, аны эшкә ялларга ни хакыгыз бар, дип бәйләнде.

– Үзләре эш сорап килделәр ләса, – дип караса да, ирне суд залында гаепле калдырдылар. Бер чит хатын аларны якларга тырышып та карады.

– Ул баланың әнисе дежур көнендә идән юуучы кызга булышып, урындыкларны парта өстенә күтәреп куйганы өчен дә укытучыны судка бирде, һаман-һаман яман затларны тыңлаудан туктагыз инде, – диде.

Зур штрафлар түләргә мәҗбүр булды Бәхтияр.

Әйе, ул белә: авылда да, тирә-юньдә дә аларга кеше хезмәтеннән файдаланучылар, шуның аша тормышларын көйле генә алып баручылар итебрәк карauчылар да юк түгел. Яратмыйча карыйлар. Шул ук вакытта исерек ирләрен оялтырга теләп:

– Үзебезнекеләр эчеп ята, әллә кайлардан читтән килгәннәр кайда җимеш сата, кайда җир хуҗасы булып ала, кайда кафелар ача, – дип кычкырып сөйләшкәннәренә дә юлыкканы бар. Андый чакта сүзсез кала Бәхтияр. Эчтән генә: «Кеше өлешенә кермим, кеше хакына калганым юк», дип уйлый. Ә бит ул яхшы белә, ватандашларына җирле халыкка караганда, күпкә азрак түлиләр. Янына зарланып килүчеләр дә булды. Бер якташы: «Каладай йорт торгызып бирдек, хакын тиешенчә дә түләмәде. Бай, имеш, үзе. Ничек кеше хакыннан курыкмыйлардыр?» – дип әрнеп сөйләде. Әле монда шулай. Мәскәүдән бөтенләй бер тиенсез кайтып китүчеләре дә бар, диләр. Югыйсә үзара, башкаланы да, башка шәһәрләрне дә безнекеләр гөлт иттереп тора дип горурланып сөйләшештерәләр. Ни барына шөкер итә беләләр.

Ә бу җирләрдә бизнес бик әкрен үсә, диләр. Дөрес анысы. Бәхтиярга да Шамил ныклы иңен куймаса, бернигә дә ирешә алмас иде кебек тоела. Югыйсә ул бер эшне дә качып эшләргә җыенмый. Артыгын алдынгылыкка чыгарга да җыенмый. Урталыкта барса, гаиләсенең тамагын туйдырып, муллыкта яшәтә алса, шул җитә. Моның өчен күпме бюрократик киртәләрне үтәсе булды. Субсидияләр турында мәгълүмат таба алмыйча аптырады. Районда да аны бик салкын каршыладылар.

– Сез әле бизнеска керә дә башламаган, даими пропискагыз да юк, – дип, һаман кире бору ягын карадылар.

– Ләкин мин эшләргә телим, – диде Бәхтияр.

– Без әле сездә уңышлы проектны тормышка ашырырлык потенциал күрмибез, – дип җавап бирде аңа үз гомеренә бер мәртәбә дә көрәк тотып карамаган кыз бала.

– Минем хезмәтем кешеләрне ризыклы итү генә түгел, үзем яшәгән җирнең дәрәҗәсен үстерү дә, илнең икътисади көчен арттыру да. Эш мәйданнарын

киңәйтсәм, авыл кешеләренә эш урыннары да булачак, – дип карады. Шулай әйтергә аны Шамил үзе өйрәтеп җибәргән иде.

Дәүләт ярдәме нидән гыйбарәт икәнне тәки белмичә кайтып китте Бәхтияр. Мәхәббәтенә:

– Шамилдән башка юл уңасы түгел икән минем, – дип, бер генә җөмлә әйтте.

Бер-ике көн күңелсезләнеп, иңнәрен салындырып йөрде дә янә дәртләнебрәк эшкәябышты. Авырлык күрмәгән, рәхәтне белми диләрме әле?

Дөрес, эшләргә теләүче ир-егетләр сирәк, ә бала-чага кирлә торды. Уйлана-уйлана Бәхтияр да җаен тапты, эти-әниләреннән рөхсәт язуы алып килүләрен сорады. Әнә шулай күрше авылның укучы балалары эштән курыкмаска, тормыш итәргә өйрәнеп, тирән кесә төпләренә бераз акча да салып куйдылар. Аннан үзбәк, таҗик дуслары агыла башлады. Хәзер инде аларда торып эшкә урнашканнары гына да өч дистәдән артыктыр. Үзләре дә эшне җиңеләйтә төштеләр кебек. Уңышны базарга илтеп, ватандашларына тапшырырга йөк машиналары да бар, җир сөрергә яңа трактор алып җибәрделәр. Орлыкларның яхшы сортлыларын юнәттеләр, үзбәк якларындагыларын да сынап карарга алындылар. Хәтта бер бөртек чүп-үләнне дә әрәм итү юк, үсемлек төбенә бөтенесе дә сеңеп кенә китә дә мул уңышка әверелә иде. Авылдашларының көлне урамдагы багана төбенә түккәннәрен күреп, Мәхәббәт һушсыз кала язды.

– Ул бик яхшы ашлама бит, ник бакчагызга сипмисез соң? – дип сорады.

– Элек көл җыючылар бар иде, хәзер кирәге калмады шул, – дип җавап бирде тимер чиләгенең төбен кага-кага ак яулыклы әбекәй, аның ашлама икәнлеген һич тә аңларга теләмичә.

Үзләренә киләчәк ничектер өметле кебек тоела хәзер.

– Җиһангөл апаның аягы җиңел булды, – дип куйды Мәхәббәт беркөнне. Чынлап та, һәркем үзенә эшләсә генә, хезмәтен нәтиҗәле итә аладыр. Эшенә күрә ашы, хезмәтенә күрә күмәче... Уртак малны аны эт тә ашамый, дидеме әле Җиһангөл апа? Башта ук такта белән бәйләнмәгез, тимер коймалар тотыгыз, диде. Күп эштә акыллы киңәше кирәк булды безгә. – Кунакка чакырасы иде аны ничек тә. Яхшы киңәш – ярты бәхет, диләр. Аның хәерле киңәше аркасында без монда бит...

– Үзем барып алырмын. Пылау пешерергә яхшы дөгең бармы соң?

– Бар, – дип елмайды хатын. – Дөгене генә үстерә алмыйбыз, калганы барысы да үзебезнеке... Бәрәкәтле дә соң бу татар җире...

– Сиңа бер яңалыгым да бар, Мәхәббәт. Голландиягә китәбез тиздән Шамил белән.

Мәхәббәтнең күзләре зурайды.

– Нишләп йөрисез анда? – дип гаҗәпләнеп сорады ул.

– Яхшы нәселле сыерларны үзебез шунда барып сайлаячакбыз, диде Шамил. Эзләмичә энә дә табылмый, матурым... Аннан безнең әни: «Йөргән йөрәкле булыр», дияргә ярата. Әле бит яшисе бар безнең... Авылны яшәтәсе бар...

Бәхтиярның бөтен вөҗүде киләчәк яктылыгы белән тулгангамы, күңеле күтәренке иде.

Ир елмая-елмая машинасы янына юнәлде. Урамда вак кына яңгыр сибәли, чөгендер-кишер яфраклары дымланып ялтырыйлар, помидорлар әле кып-кызыл, әле ямь-яшел уңышларын күрсәтергә теләгәндәй иелмичә дә утыра бирәләр, кашкарыйлар, бәрхет гөлләре исә мул бакчага карап куангандай, төрле төсләрдә уйнаклап нур тарата...

***

– Җиһангөл апа! – дигән тавышка күзләрен ачып җибәрде ул. Кемдер тәрәзәгә шакыдымы соң? Әллә таш тидеме? Йокларга дип тә ятмаган иде, Әсмабикә карчыктан калган челтәрләп эшләнгән кашагаларны, карават япмаларын Алмазга бирергә дип әзерләп йөри торгач, бераз хәл җыярга гына яткан җирдән оеп кителгән менәтерәк. Төш күрергә дә өлгергән хәтта. Кояш эссесе җанны көйдерерлек җете бер көн имеш. Үзбәкстанда яшәп яталар имеш. Урам тулы халык арыш басуыдай чайкала. Кычкырышалар мәллә соң? Сүзләрен бер дә аңламый нигәдер. «Казанга...» диләрме?

– Җиһангөл апа!

Торып утыргач та таныш авазларга игътибарын юнәлтә алмыйча, ул, як-ягына каранды. Үз илендә, үз өендә икән бит! Шушы халәтеннән бөтен вөҗүде куаныч белән тулды. Барча газаплар да шулай тиз генә куанычка әверелсен иде ул! Чыдар иде һәммәсенә.

Тавыш янә кабатланды:

– Җиһангөл апа! Мин бу – Бәхтияр.

Күкләр аяз, кичә генә кызы юган үтә күренмәле тәрәзәләрдән кояш нурлары ургылып керә, өй эче җылы яктылык белән тулган иде. «Күңелгә генә түгел, сызлап торган буыннарга да рәхәт шул кояш җылысы», дип уйлап куйды Җиһангөл. Аннан тәрәзә аша Бәхтиярны күреп:

– Хәзер... тукта... һай, ишегем ачык лабаса, кер әйдә! – дип өйалды ягына таба атлады. Шунда күз алдында дүрт шәм шәүләсе уйнап алгандай тоелды. Абау! Төштә күргән икән лә ул аларны! Үзеннән-үзе күңел түрендә җанына якын җыр яңарды: «Шәмдәлләрдә генә утлар яна...» дип, эчтән генә көйләде ул, шулай ук һәркемгә мәгълүм хикәят исенә төште:

«Бүлмәдәге үле тынлык эчендә дүрт шәм яна икән. Беренче шәм әйткән: «Мин – тынычлык булам. Әмма минем януымны теләүчеләр дә, аны бәяләүчеләр дә юк. Мин сүнәм!» дигән. Һәм сүнгән.

«Мин – ышаныч!» – дигән икенче шәм. – Ләкин үземнең кешеләргә кирәклегемне тоймыйм, шуңа мин сүнәм... Һәм анысы да сүнгән.


Өченче шәм: «Мин – мәхәббәт!» – дип аваз салган. Әмма тирә-юньне яктыртырлык көчем калмады инде. Кешеләр мине кабул итмиләр. Хәтта иң якыннарым да яратмыйлар, – дигән дә Мәхәббәт шәме дә сүнеп киткән.

Шулчак бүлмәгә бер бала йөгереп кергән. Бу өч шәмнән дә ник сүнүләрен сораган. Сәбәбен белгәч, ул дүртенче шәмнең тавышын ишеткән: «Курыкма, мин янам бит! Минем ялкыннан сүнгән шәмнәр барысы да кабыначак! Алар янә җир өстендәге тоташ караңгылыкны яктыртыр. Чөнки мин – Өмет!»

– Чөнки мин Өмет! – дип кабатлады Җиһангөл ишеккә табан атлаганда. Аннан:

– Туган җирдә өмет дигәне дә яктырак, ышанычлырак икән шул... – дип өстәде. Башы иелгәнне сизмәде дә Җиһангөл. Иреннәре:

– Рәхмәт сиңа, Ватаным! – дип пышылдады. Күрче, ярата белә икән бит ул һаман да! Аллаһыны яраткан моңарчы да... Мәңгелек сөю шул икән... Ташлама, Раббым... Ярлыка...



Әнвәр
Шәрипов

# ТӘПИ БАСКАН ҖИРЕМ ЧИРӘМ ИДЕ...

## Печән исе

Җәй айлары.
Шәһәр урамында
Күкрәп үсте үлән газонда.
Чабып ташладылар беренче кат,
Җыймадылар...
Чапкан көе калды ул шунда...

Узып бара идем урам буйлап,
Җәйге иртә белән кинәнеп,
Борын ярып, печән исе керде,
Сулышларым китте киңәеп.

Иснәдем дә яңа печән исен,
Әллә нишләп шушы урында,
Җыр язасым килде минем кинәт,
Яңа чапкан печән турында.

Җәйге эссе көндә, абый белән
Чапкан идек болын печәнен.
Алып каба идем
Арасыннан
Җир җиләген, кызарып пешкәнен...

Алып кайткан идек ул  печәнне,
Ат арбасын төяп тутырып,
Күпереп торган, әле кипмәгән дә
Печән өсләренә утырып.

---

Әнвәр ШӘРИПОВ (1941) – *галим, шагыйрь; «Тукта, мизгел!», «Кем идең син?» һ.б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*

Күр әле син:
Һәр үләне аның
Кояш нуры белән тулышкан...
Нинди сихәт бирә шушы печән
Без сулаган иркен сулышка...

Һәркөн иртән шәһәр буйлап йөрим,
Үткәннәрне баштан кичереп.
Комсызланып печән исе исним,
Балачакны искә төшереп...

## Без язмышны үзебез язабыз...

Һәрбер яшәлгән көн – атылган йолдыз;
Һәр йолдыздан сызылып эз кала.
Һәрбер яшәлгән көн кешеләрнең
Язмыш дәфтәренә эз сала.

Язмыш алдан язылып куела, диләр,
Бәхәсләшмим, бәлки, шулайдыр.
Әмма һәр гамәлне, һәр адымны,
Кайсы якка атлауны без хәтта
Үзебез бит сайлап алабыз.
Һәм язмышны үзебез язабыз.

## Таш күңел

Ташлар чолгап алган тормышымны:
Торган йортым – бетон-панельдән.
Баскан җирем – асфальт,
Урамнар – таш –
Аермасы шушы авылдан...

Тәпи баскан җирем чирәм иде,
Тирә-ягым – яшел басулар...
Кырга чыксам, тургай моңы иде, –
Ул моңнарда күпме ярсу бар!..

Тургай моңы, басу киңлекләре
Балачактан тулган күңелгә.
Шуңа да мин сәерсенеп карыйм
Шәһәрдәге бетон-панельгә.

Шәһәр тормышына күнеккәнбез,
Кабул иттек инде без аны.
Ташлар арасында яшибез шул,
Әллә шуңа микән
Таш күңелләр басты дөньяны.

Ташлар, дибез, ташны җансыз, дибез,
Гел тискәре бәя бирәбез...
Ә үзебез җылы чыксын өчен,
Мунча ташына сулар сибәбез...

Ташлар да бит безгә кирәк кайчак,
Җиһан буйлап Илаһ тараткан...
Һава, туфрак һәм су белән бергә
Ташларны да сөеп яралткан.

Кыя ташы, әнә, нинди горур,
Аңа басып җырлый башларбыз...
Ташлар безгә ныклык өчен кирәк, –
Нигез корып булмый ташларсыз...

Һәрчак матурлыклар, моң-җыр белән
Тулы була безнең күңелләр...
Ташлар кирәк, алар булсын,
Әмма
Таш күңелләр кирәк түгелләр.

## Казан урамнары тулы моң...

Казанымны күпме афәтләрдән
Ходай үзе генә саклады.
Бүген дә әле ишетелә кебек
Әби-бабаларның аһлары.

Казан урамнары тулы сагыш,
Казан урамнары тулы моң.

Халкым минем моңлы халык булды,
Җырны юлдаш итте, җырлады.
Дөньядагы күпме халыкларны
Әсир итте татар моңнары.

Казан урамнары тулы сагыш,
Казан урамнары тулы моң.

Тәүге сөюемне югалтуым
Йөрәгемне минем яндырды.
Шул ялкыннар Казан урамында
Мәңге сүнмәс сагыш калдырды.

Казан урамнары тулы сагыш,
Казан урамнары тулы моң...

*«Илең турында уйла» әдәби конкурсы*



Айзирәк
Гәрәева-Акчура

# ГАҖИЗЛЕК

хикәя

*Икенче Бөтендөнья сугышында Төркия бер тарафка басмыйча нейтральлек-битарафлык саклауга ирешкән ил, бары сугыш тәмамланганда гына кушыла. Әмма дөньяны күз яшьләренә батырган афәт Төркия үзәгендә урнашкан татар авылы Солтаниягә кадәр килеп җитә. Бу елларда иртәгесе көнгә дип саклаган азык-төлек запаслары җыеп алына, авыл кешеләре күбрәк кипкән йөзем белән көн кичерә. 1950-60 елларда шул авылда туган җирләреннән меңнәрчә чакрым ераклыкта аерылып калган татар солдатлары да яши. Арадан берсен Агай дип йөртәләр...*

***

Шәрифә үзе бәйләгән йон оекбашларны, башмакларны Искешәһәр базарына алып чыгып сата. Ара-тирә поезд белән Биләҗек шәһәре базарына да барып кайта. Бабалары – татар мөһаҗирләре нигез салган туган авылы Солтаниядән чыгып киткәннән соң, бу һөнәре ни дисәң дә, дөнья көтәргә ярап куйды. 1900 елларда суык мәмләкәттән күченгән мөһаҗир кызы бит ул, әнисе аны кечкенәдән бәйләргә өйрәтте. Алар җирләшкән урын Төркиянең кыш күренми торган диңгез буе түгел, нәкъ туган якларындагы кебек кышларын суыта, кар шактый ята. Әле авылда чагында кичтән көрәкләрне өйгә кертеп калдыралар, чөнки төне буе кар явып, буранлап тәбәнәк ишекләрне күмә. Шуңа да ишекләр эчкә таба ачылмалы итеп ясалган, карны гына казып чыгарга кала.

Искешәһәр кышы үзенә бер төрле, җилле, дымлы, карлы... Гомумән, шәһәр өйләре суык. Матди ягы ныгракларда чуеннан ясалган соба – мич булса, фәкыйрьләрдә калайдан гына ул. Калай соба өй һавасын хәтәр җылыткан кебек тоела, әмма күмер янып бетүгә суына. Ул арада идән дә җылынырга өлгерми. Күмер сатып алып, собага шуны ягыш. Ә аны алырга акча җиткерергә кирәк.

---

Айзирәк ГӘРӘЕВА-АКЧУРА (1978) *– язучы, журналист; «Тешле кояш» китабы авторы. Төркиядә яши.*

һич югы «тәзәк» кала, ягъни тиресне киптереп ясалган ягулык чимал инде ул. Кыскасы, собаң – чуенмы, калаймы, якканың – күмерме, тизәкме, барыбер кышны җылы оекбашсыз чыгам, димә.

Тарихи Биләҗек – Искешәһәрдән сиксән чакрым ераклыктагы кечерәк, таулар эчендә урнашкан шәһәр. Биләҗеккә беренче аяк басканда, таш мәчетләрнең биек манараларын җимерек хәлдә күреп, Шәрифәнең коты алынган иде. Кайчандыр азан яңгыраган, ае балкып торган борынгы манаралар яртылаш кына калган. Боларны махсус шулай тоталар, төзәтеп куймыйлар икән, Беренче Бөтендөнья сугышының гыйбрәтле хатирәсе итеп саклыйлар. Ярым җимерек корылмаларның «азанлы теле» киселгән, алай да хәтерне әйбәт яңарталар. Манараларны җимерүчеләр греклар булганны да оныттырмыйлар.

Шәрифә базарга йөрүчеләр белән тегесе-монысы турында гәпләшеп, Биләҗек халкын белеп өлгерде, дияргә була. Оекбашларын бик яратып алалар. Төенчеге һәрчак бушап кайта. Алман сугышы беткәнгә 4-5 еллар булгандыр, беркөнне базарда колагына татарча сүзләр ишетелде. Янында вакыт уздырып йөргән берничә карчык бар иде, тел белән дөнья йөген бушатып торганда, бер мәлгә сүзсез калды. Искешәһәрдә булса, болай аптырамас иде. Анда татар мөһаҗирләренең дәвамчылары шактый яши. Ә Биләҗеккә ничә килеп, татарны очратканы юк әле. Шәрифә теге карчыкларны онытты, алар аша үрелеп, берничә адым читтә нидер караган, сайлаган дүрт ир-атны күзләде. Үзара шундый матур итеп татарча сөйләшәләр! Берсе өлкәнрәк күренә, яше кырыклар тирәсендә бардыр. Ә калганнары... Өсләрендәге киемнәре бик шәптән түгел, таушалган, үзләре нык кына йончыган, ябыклар... Алай да карт түгел болар! Әллә кырым татарларымы?! Юк ла, сөйләшүләре, үз-үзләрен тотышлары, йөзләре, торыш-килбәтләре Казан татарларыныкы бит! Базарда сата торгач, кемнең кем икәнен төс-кыяфәтеннән үк аера башлаган Шәрифә шулай бер караш ташлауга үз бәясен чыгарырга кереште. Ай Аллаһым, ник эндәшми тора соң? Татарлар бит! Китеп баралар мәгәр, тизрәк кычкыр, туктат, кайлардан килгәннәр, сора!

– Исәннәрмесез! Килегез монда!

Гөҗләп торган базарда ишетми китүләре бар дип курыкты, каты гына итеп татарча кычкырды. Аның тавышына дүрт ир генә түгел, тирә-яктагылар барысы берьюлы борылды. Хатын татарларга туры карап, кулын болгап чакырды.

– Сезгә әйтәм, сезгә! Килегез монда! Шәрифә бәйләгән җылы оекбашларны башка беркемдә тапмассыз.

Тегеләр бер-берсенә аптырап карашып алгач, хатын янына килде. Арадан иң яшь күренгәне шаккатуын яшереп тормастан:

– Апа, син каян татарча беләсең? – дип эндәште.

– Татар булгач, татарча белмәскә?!

– Чынмы, апа?

– Каян килеп чыктыгыз? Биләҗеккә, дим, кайдан килдегез? Кайсы як татарлары сез?

Ирләр көтелмәгән очрашудан хатынның бер-бер артлы яудырган сорауларына җавап бирә алмый тордылар. Ун ел элек туган якларыннан аерылган, сугыш яралары белән бергә сагыну, җирсү хисен татыган, чит илләр туфрагын таптап йончыган элеккеге гаскәриләр әз тәэсирләнмәде бу минутларда. Үзләрен тыныч тотарга тырышсалар да, каушап-югалып калдылар. Шәрифә исә ватаннан килгәннәрне очратуына, рәхәтләнеп татарча сөйләшә алуына шатланып, сорауларын тезде дә тезде...

– Мәмләкәтегез кайдан? Кемнәрдән сез? Нишләп йөрисез?

Арада иң өлкән күренгәне бөтен соравына бер җөмлә белән җавап бирде:

– Апа, без алман әсирләре.

– Ә-ә-ә...

– Туган якларга кайта алмадык. Төркиягә сыендык. Башта Истанбулга китерделәр, ватандашлык алганчы берникадәр вакыт Тузла күчмән мосафирханәсендә яшәдек. Аннары безгә Биләҗектә яшәргә рөхсәт бирделәр.

– Алай икән...

– Чит илләрдә эш йөрткән бер милләттәшебез – завод хуҗасы, Алманиядән Төркиягә килергә булышты. Ул коткарды дияргә була. Истанбулдагы татарлар да тырышты...

– Апа, ә син монда яшисеңме? – яшь әсир өлкән иптәшен бүлде.

– Биләҗектә түгел, Искешәһәрдә. Безнең татар авылы ерак түгел бит моннан.

Әлегә кадәр бер сүз эндәшмәгән тәбәнәк буйлы, сирәк чәче астыннан маңгае буйлап колак турысына кадәр сузылган яра эзе шәйләнгән әсир балаларча куанып кычкырып җибәрде:

– Кит инде! Татарлар яши торган авылмы?

Дүртенчесе – кулындагы таягына кулы белән генә түгел, ярты гәүдәсе белән таянганга күрә, бер тарафка авышып торганы да телгә килде:

– Булмас!

Хатын аларның авыл турында ишетүгә шатланганнарын күргәч:

– Әйдәгез, авылга кайтабыз. Биләҗектә болай ялгызбаш йөрмәгез, – дип, чын-чынлап кодалый башлады.

Өчесе ризалык биреп өлгерде, бары тик башкаларга караганда бераз хәллерәк һәм күзгә күренеп торган бер гариплеге булмаган өлкән әсир авыр сулап куйды. Хәер, игътибар белән рәк карасаң, бер күзе ак төшкәндәй тонык күренә. Ул иптәшләренә артык дулкынланмаска ялынгандай:

– Егетләр, тынычланыгыз, беләсез бит, безгә Биләҗектә генә яшәргә рөхсәт ителде, – диде.

Шәрифә аларның әле берсенә, әле икенчесенә карады. Юату сүзләрен эзләде, ни дияргә белмәде. Аннары һәркайсының кулына берәр-берәр җылы оекбаш тоттырды.

– Атыгыз ни, сорамадым да...

Әсирләрнең иң өлкән күренгәне үзен Ваһап дип таныштырды. Иң яше – Җаппар, авыл барлыгын белеп аеруча сөенгән таяклысы Камил һәм ярасын капларга теләпме, чәчен шактый үстергәне Закир икән. Тагын бер иптәшләре барлыгын әйттеләр, ул өй саклап калган. Үзе юкның күзе юк дигәндәй, аның исемен атап тормадылар. Шәрифә насыйп булса, күрешербез-танышырбыз дип, артык төпченмәде. Төенчегеннән соңгы оекбашны төрекчә:

– Аркадашыгызга, – дип сузды. – Өй саклап калганга.

Шәрифә чит илдә ялгыз башлары яшәргә мәҗбүр калган бу Аллаһ бәндәләре өчен бик тә борчылды. Биләҗектә калган мосафирханәләренең адресын сорап, кайда яшәгәннәрен ачыклады. Аерылышыр алдыннан әсирләр күңеленә әллә кайчан юкка чыккан өмет хисен уятырлык сүзләр әйтте:

– Авылга кайтып, башлык белән сөйләшеп карыйм. Бәлки, ул бер юлын табар... Аның сүзе үтә. Сезне берәр ничек Биләҗектән авылга кайтарыр. Барып чыкмаса, бәлки, Искешәһәргә урнашырга ярдәм итәр. Анда татарлар күп яши. Бер-берсен беләләр, йөрешәләр... Үзебезнекеләр янында яшәсәгез әйбәтрәк. Дөрес, алдагысын бер Ходай белә...

Шәрифә китеп барды. Әсир солдатларның кулларындагы туган якларындагы төсле тип-тигез итеп, җан җылысы кушып бәйләнгән йомшак оекбашлар гына чынбарлыкны раслап тора. Югыйсә, ниһаять, теңкәләрен корыткан сугышка, әсирлеккә бәйле куркыныч саташулардан арынып, бик зарыгып көтелгән бер матур, тәмле төш күргәннәренә куанудан узмаслар иде. Әле генә чит тавышлар, чит халыклар белән гөж килгән базар уртасында татар апаеның сүзсез юаткан ягымлы, җылы карашын күргәннәренә ышанмаслар иде.

Камил таягын култыгына кыстырып, җылы оекбашны кулына киде һәм йөзенә терәде. Калын, җылы бүләк Татарстанда калган хатынын, ике баласын хәтерләтте һәм аларны сагыну, юксыну хисе йөрәген учлап кысты. Күз яшьләре кулындагы оекбашларга сеңде. Ваһап аның җилкәсеннән кагып куйды. Нидер әйтергә тамак төбенә утырган төерен йота алмады, күз алдына янып торган мич яктысында акрын гына көйли-көйли йон эрләп утырган хәләле килде. Җаппарның авызы колагында иде, йон исе килеп торган оекбашның әле берсен, әле икенчесен иснәп карагач:

– Абзардагы сарыклар искә төште, – дип, яшь аралаш көлде.

Ни еларга, ни көләргә белмәгән Закир:

– Ходай бу миһербанлы хатынны юлыбызга чыгарган икән, бу юкка түгел. Күңелем ничә елдан соң тәүге тапкыр яхшылык киләсен сизә... Алла боерса, әйбәткә бу, егетләр... Җанга бер рәхәт керде. Ирекккә чыгып, менә шулай, татар апасы белән сөйләшеп торыр көнне күрермен димәгән идем. Ходай насыйп итте, – диде.

Һәркайсының ялгыз, сынык күңелен татар хатыны бәйләгән җылы оекбаш юатты.

***

Ун-унбиш көн узмагандыр, Биләҗеккә татар әсирләре янына авылдан бер кеше килеп җитте. Шәрифә аның хакында мохтар, мохтар дип сөйләгәч, башта исеме шулай дип уйлаганнар иде. Авыл җитәкчесенә мохтар, диләр икән. Бу колхоз рәисе кебек кеше булып чыга, димәк. Ваһап туган якларындагы «Ленин», «Совет юлы», «Очкын», «Кызыл таң» колхозларын искә төшерде. Колхоз рәиссез яши алмас, чөнки уртак малга бер хуҗа, сакчы, колхозчыларны эшләтүче, эш көннәрен санаучы кирәк бит. Ә монда теге заманнардагы тәртип. Большевиклар килгәнчегә кадәрге кебек. Һәркемнең үз җире, һәркемнең үз хуҗалыгы булгач, бу мохтарның нигә кирәге бар икән?! Шәрифә аңлатты, авыл мәсьәләләрен хәл итүче, шуларны хәл итәр өчен илчә (район) башлыгына йөреп, авыл кешеләре гозерләрен җитәкчеләргә аңлатучы, юлларны, суларны карап торучы, диде.

Мохтар 50 яшьләр тирәсендәге, уртача буйлы, туры карашлы, җитди йөзле татар булып чыкты. Ул үзен Барый, дип таныштырды. Әсирләрнең барысыннан да өлкәнрәк иде, шуңа күрә аңа Барый абзый дип эндәштеләр.

Барый Биләҗек һәм Искешәһәр җитәкчеләренә хат язып, әсирләр өчен җаваплылыкны үз өстенә алды. Шул сәбәпле Биләҗектән Искешәһәргә һәм Солтания авылына күчү рөхсәте бирелде. Авыл башлыгы яңа танышларын, сез минем мосафирларым дип, үз өенә сыендырды, кадер-хөрмәт күрсәтте. Хуҗалыгында аларга яшәп торыр өчен бер бүлмә аерды.

Мосафирлар килгән, дигән хәбәр авылга тиз таралды. Ахшамга картлар чәйгә җыелды. Хәл-әхвәл белешү, танышу китте. Чәй арты чәй эчелде, күбрәк картлар сөйләште. Әти-әниләренең кайлардан, ничек килгәннәрен искә

төшерделәр. Кунакларның гаскәриләр икәнен белеп алгач, сугыш темасына күчтеләр.

– Авылга нигез салынганга 60 еллап, күп тә, аз да түгел, бер кеше гомере инде. Болай гомер тарлаларда үтә. Тарла дигәнем, кыр. Тик илләр үзара тыныша алмаганда, авыллар тыныч кала алырмы?! Тарла кайгысы калырмы?

– Юк, – дип, сүз алды җыйнак кына сакаллы, чандыр гәүдәле бер карт.

– Хак, хак... – дип җөпләде башкалар.

– Юк шул. Һәр сугыш авылга үз эзен салып килә. Менә этиләр туган җирләреннән мең газап белән аерылган, Төркиягә кадәр килеп җиткән. Бер белмәгән, күрмәгән туфракка таянып тормыш кора гына башлаганнар, басулар эшкәртеп, яшәргә генә керешкәннәр, 1914 елны Беренче Бөтендөнья сугышы башлана...[1] Безнең Солтания авылыннан да киттеләр ул сугышка. Батыр йөрәкле дистәләгән шәһитебез бар. Гәрчә яңа килгән мөһаҗирләргә хәрби хезмәт мәҗбүри куелмаган ул вакытта.

Беренче кич шулай картлар хатирәсе белән сизелми узды.

Икенче көнне ахшам чәе янә җәйге алачыкка әзерләнде, өстәлгә ханымнар пешергән кош теле, пәрәмәч кебек татар ризыклары тезелде, кунакларны сыйлау ниятеннән яңа бал куелды. Күрше-күлән җыелды. Кабат элеккеләрне искә төшерделәр...

Кичәге карт салмак кына янә тарихи хәлләрне барлады.

– Кем җиңә – канун шуның кулында дигәндәй, җиңүчеләр Төркиянең җирләрен бүлешә. Бу чорда грек хәрбиләре төрек авылларын басып, туздырып, Төркиянең Урта диңгез ярларын ала. Аннары үзәктә урнашкан Искешәһәр, Бурса шәһәрләренә кадәр юл тота. Грекларның төрек авылларына зур зыян салуы турындагы куркыныч хәбәр Солтаниягә үзләреннән элек килеп җитә. Шуңа күрә ул чактагы авыл җитәкчесе грекларны авылдан берәр чакрым читтә каршы ала.

Картны мохтар бүлде:

– Ул бит Россиядә университетта югары белем алган, француз телен яхшы белгән, диләр.

– Туры әйтәсең, чит тел белгәнгә күрә греклар белән килешү төзи алгандыр да. Авыл эченә бер генә грек гаскәрие дә керми.

Инде таралышабыз дип торганда, арадан берсе янә этисе сөйләгәннәрне исенә төшерде.

– Дөрестерме, шундый бер хикәят тә телдән телгә күчеп йөри. Греклар туктап торган урында безнекеләрдән кемдер бер мылтык табып алган. Тегеләр онытып калдырган дип, артларыннан йөгергән. Шуннан мылтыкны башлыкларына тапшырган. Ә ул: «Кемнең мылтыгы?» – дип, гаскәриләреннән сораган. Берсе алга чыгып та баскан, аны атып та үтергән.

Әлеге хатирә барсын сискәндерде. Кемдер әле генә кабахәтлектә гаепләнгән грек солдатын кызганып куярга өлгерде. Кемдер башлыкларының кансызлыгына гаҗәпләнде... Баягы карт салмак кына сүзне йомгаклады:

– Алар юлларында очраган авылларны нык мәсхәрә иткәннәр. Җәлладлык кылган – җәллад кулыннан үлгән.

[1] Ул заманда Алмания ягында саналган Төркиягә – Госманлы империясенә берьюлы берничә җирдә сугыш алып барырга туры килә. 1915 елның 19 февраленнән башлап, 1916 елның 9 гыйнварына кадәр Ататөрек җитәкчелегендә барган Чанаккале сугышы төрекләрнең батырлыгын данлаган көрәш буларак тарихка керә. Истанбулны алырга һәм Босфор Бугазы аша Кара диңгезгә чыгып, Россия патшасына революционерларга каршы көрәшергә ярдәм итәргә теләгән Антанта – Итилаф (Россия, Бөекбритания һәм Франция хәрби-сәяси берлеге) илләренә каршы сугыш тугыз айдан артык дәвам итә. Төркия тарафыннан ике йөз меңгә якын солдат шәһит китә.

Өченче көнне җыелышкач та, авыл халкы тарих сәхифәләрен яңартты. Болар сөйләнгәндә, мохтар беркемне бүлми тыныч кына утырды. Әгәр мосафирлар кире Татарстанга кайта алмаса, аларга шушы җирдә яшәргә кирәк булачак. Ә җирлек тарихын белмичә анда ничек яшисең?! Сөйләсеннәр әйдә, аңлатсыннар, рәхмәт үзләренә.

Әсирләр һичбер сүзгә катышмый. Уйларында ни? Телләре сөйләмәгәч, ничек беләсең?! Кеше күңелендәгене белүнең башка юлын бирмәгән Ходай... Бары тел аша. Мохтар сынап кына, кунакларына күз ташлады. Акылын бер сәер сизенү кисеп узды. Болар бит гәүдәләре белән генә биредә утыра, үзләре әллә кайда. Күз карашларында ниндидер бушлык... Мохтар аларның бу халәтеннән куркып китте. Тизрәк чәй тәкъдим итте. Шул рәвешле кунакларын хәзерге чынбарлыкка кайтарды. Картның сүзе инде тәгәлләнеп килә иде:

– Күпме кан коюлардан соң бәйсезлек сугышында инглизләрне җиңә Төркия. Шуннан соң озак та үтми кем төрекләр ягында калган, кем каршы якка чыккан дип тикшерү, эзләнү эшләре башлана... Менә шул чакта авыл башлыгын яратмаган бәндәләр, аның греклар белән килешү төзүе хакында тикшерүчеләргә барып әйтмәсеннәрме?! Гаҗәп бит ул безнең халык... Мәхкәмә эшләрендә ул үзен яклап чыга һәм аклана. Хаким греклар белән килешү төзүне авылны коткару максатыннан ясалган адым буларак таный һәм аны хыянәттә гаепләми. Авыл башлыгы хөкүмәт тарафыннан акланып, авылга кайта. Әмма авылдашларының мондый адымын кичерә алмый. Нигезен ташлап, башка урынга күченә. Авылдан ерак түгел җирдә, елга башына тегермән сала. Хәзергә кадәр бөтен тирә-як әлеге тегермәннән файда күреп яши. Сугыш вакытындагы хыянәт башка, тыныч тормышта бөтенләй башка...

Ниһаять, кич утыруларның тәэсире сизелде. Әсирләр көндезләрен ишегалдында, басуга барганда, үзләрен иркенрәк тота башлады. Беркөн иртән торгач, Ваһап йорт хуҗасы янына килеп:

– Барый абый, рәхмәт сиңа... Без болай булыр дип, күз алдына да китермәдек. Авыл кешеләре бик үзгә, башка төрлерәк, димме. Әйбәт кешеләр, кызык сөйлиләр. Без аларны тыңлап, үзебезнең туган якларга кайткандай утырабыз. Безнең әле аңга килеп җитә алган юк. Хәтта җөмлә төзеп әйтергә йөрәк җитми. Килгәнебезгә ничә көн, әле рәхмәт тә әйтә алган юк. Гаеп итмә, сезгә мәшәкать булдык...

Башкалар да берәм-берәм рәхмәт әйтте. Әмма алар һаман кабырчыкка яшеренгән әкәм-төкәмнәр кебек. Әле һаман ниндидер явызлык, начарлык, котылгысыз авырлык пәрдәсе эчендә иделәр. Кайчак онытылып китеп ишегалдында уйнап йөргән бала-чагалар белән шаярып алулары, җиң сызганып, басуда эшләүләре, малларны караулары, кайчак тынсыз калып, тыныч дөньяны тыңлаулары – янәдән тормыш тәмен тоя башлауларына бер ишарә иде. Тик барыбер хәтерләреннән сугышта һәм сугыштан соң күргәннәрен сөртеп ташлау мөмкин хәл түгел. Берара тынычланган кебек тоелсалар да, яралы тәннәре газапларны яңарта. Мохтар мосафирларын сиздерми генә күзәтте. Закир ялгызы калганда, күбрәк Ходай белән сөйләшә. Ходаем, дип ялвара, аңардан ниләрдер сорый. Шуннан юаныч тапкандай тынычланып китә. Камил исә булдыра алганча елмаерга тырыша, ә ялгызы калса, тавыш-тынсыз гына елый. Андый чакта гел бер сүзне кабатлый «Бәгырькәйләрем, кичерегез, кайта алмыйм. Бәгырькәйләрем, мин исән калдым... Бәгырькәйләрем...» Ваһап белән Җаппарның үз-үзләрен тотышлары

бераз охшаш. Икесе дә тәкъдирләренә буйсынган, хәзер шушы тормышта яшәргә кирәклеген кабул итмеш кебек. Ә менә бишенчеләре, теге чакта өй саклап калганы, озын буйлы, йөз-кыяфәткә барысына караганда чибәррәк әсирне әлегә аңлап җиткермәле түгел. Ике кулы, ике аягы да үз урынында, зарар күрмәгән кебек. Ваһап танышкач та, нидер кисәтергә теләгәндәй, аның шактый дәрәҗәле хәрби икәнен, бик күп җәфалар кичергәнен, алманнар тарафыннан каты кыйналганын берничә сүз белән генә әйтеп куйды. Төннәрен күзгә күренеп тормаган яралары сызлыймы, бик каты ыңгыраша иде ул. Еш кына йокысызлыктан ишегалдында караңгылыкка төбәлеп утыра. Бүтәннәре дә күп сөйләшми, бу исә көне буена ике-өч сүз тутырып әйтмәс. Ул бары тик башкаларның яшерен кайгылы хәтере, хәсрәте кебек: барлыкка бар, әмма юклыгы барлыгыннан ныграк сизелә.

Берара кыр эшләре күбәеп китте, иркенләп ахшамларда чәйләп утырулар киселде.

50 нче елларда авыл тирәсендә буш торган җирләр күп иде, ә илгә икмәк җитешми. Хөкүмәт менә шул вазгыятьне үзгәртү максатыннан эшкәртелмәгән җирләрне басу итәр өчен сугыштан соң Төркиягә сыенганганнарга бүлеп бирә башлады. Бу хакта Барый шәһәргә баргач ишетеп кайтты. Әгәр дә шушы канунны файдалансалар, бу татар әсирләре җирле булачак дип уйланды. Җирле кеше ач калмас. Һәм шул мәсьәләне хәл итәргә тотынды...

Ә аннары авыл хуҗасы кинәттән генә гаиләсе белән шәһәргә күченергә карар итте. Мосафирлары аның артыннан калмады.

Шәһәр тормышы яңа кыенлыклар тудырды, тормыш алып барырга иң беренче нәүбәттә эш табу мөһим иде. Әмма алай җиңел генә эшкә урнашып китәрмен, димә. Кайда да белем алганлыкка кәгазь сорыйлар. Шуннан Җаппар кыскача, үзләренең кем булуын, кайларда укыганнарын, нинди һөнәр үзләштергәннәрен, нинди вазифалар башкара алуларын аңлатып, Искешәһәрнең мәгариф эшләренә җаваплы кешесенә атап хат язды. Көн күрерлек бер эшкә бик тә ихтыяҗлы икәнлекләрен әйтте. «Безгә имтихан үткәрегез, гыйлемебез барлыкны расларбыз. Хат өстеннән хәлебезне аңларсыз», – дип тәмамлады. Мәгариф башлыгы аларның хәлен аңлады, хөкүмәткә язган хатны почта аша җибәргәндә ябыштырыла торган «пул», ягъни махсус марка ябыштырылмаган иде. Димәк, хәлләре «пул» ала алмаслык мөшкел.

Бишенче әсирне күзләре тонып, үз-үзен белештермәс дәрәҗәгә төшкәнгә күрә, заводта озак тотмадылар. Ябык, каты тавышлы, тынчу завод бинасында эшләргә яшьтән тузган нерв күзәнәкләре чыдамады. Бер ара Искешәһәр үзәгендә урнашкан кибетләргә йөкче булып ялланды, кул арбасы белән әйбер ташыды, бушатты, төяде... Авыр эш, әмма барыбер үз иркендәрәк бит, урамда, һавада йөреш. Тагын берничә татар әсире белән шул эшендә танышты. Искешәһәргә башка татар әсирләре дә тегеннән-моннан күченгән иде. Аралаша торгач, бүтән шәһәрләргә җирләшкәннәр турында да хәбәрләштеләр.

Күп вакыт узмады, бишенче әсир яңа танышлары белән кабат авылга юл тотты. Башкалар авылда яшәүче татар гаиләләренең мәрхәмәтенә вакытлыча кинәнеп, күбрәк шәһәр тирәсендә тормыш корганда, ул Солтаниядә калды. Мохтар сатып киткән йортның яңа хуҗаларына сыенды, элек аерылган бүлмәгә урнашты. Хуҗаларга каралты-кура, йорт эшләрендә булышты. Шулай итеп, Солтаниядә авыл Агае барлыкка килде...

***

...Баядан бирле телефон чыбыгында ялгыз кош утыра. Үзе күгәрченнән бераз гына зуррак, кәкре томшыгын аксыл-җирән түшенә батырган, куе соры, кара тимгелләр сибелгән канатларын нык кына җыйган. Канат очы берәр карыш озынлыктагы койрыгына кадәр төшкән. Сәгатьләр буе кымшанмый, ара-тирә генә муенын боргалап куя. Көяз күренә, беркемдә эше юк кебек. Әмма бу тышкы бер алдавыч күренеш кенә. Түгәрәк, янып торган кара күзләре урамдагы һәр хәрәкәтне күзәтә. Көндезге аучылардан саналган лачыннар нәселен дәвам итүче, кыргыйның[2] һәр мизгеле уяу.

Татар мөһаҗирләре нигез салган Солтания авылын үз итүе юкка түгел. Тирә-юнен басу-кырлар уратып алган, сарык көтүләре йөргән, сыер, ат кебек эре мал, күркә, каз, тавык ише кош-корт асралган җирдә тормыш бара. Тереклек тереклекне тартыр дигәндәй, кыргыйга азык булырлык тычканнар, кыр йомраннары да шактый ияләшкән бу тирәгә.

...Моңа кадәр селкенми дә утырган ялгыз кыргый томшыгын күтәрә төшеп, муенын борды.

Авыл башыннан, бераз читтәрәк Икенче Бөтендөнья сугышы вакытында болгар мөһаҗирләре өчен аерым тәбәнәк итеп кенә балчык кирпечтән өйләр салынган иде. Кыргый шул тирәне күзәтте.

Сугыш беткәнгә 7-8 ел, әлеге алачыкларга вакытлыча сыенган болгарларның китүенә шактый вакыт узды инде, берсе дә авылда торып калмады.

Соңгы вакытта менә шул ташландык өйләрнең берсенә җан керде төсле. Әлегә кадәр бу тирәгә әллә ни аяк басмаган авыл кешеләре берәм-берәм дә, бергәләп тә шул өйне урап китә торган булдылар. Баштарак бик йөрделәр, аннары туктадылар. Җанлану күзгә күренеп кимеде, монда бары бер җан калды.

Үзенә-үзе гел татарча сөйләшеп йөргән Агайдан беркемгә зыян тимәде, шулай үз дөньясында гомер итте. Авылда аның хакында сугышта бик зур кеше – дәрәҗәле хәрби булган дигән сүзләр ишетелде. Булыр, булыр, бик белемле, укыган кеше икәне сизелә, дип килештеләр. Яраланып, әсирлеккә төшкәч, бик каты кыйналган дигән сүзләр таралды. Берара пилот икән дигән сүз дә чыкты, чынлыкта беркем дә төгәл генә Агайның кем икәнлеген белми иде. Хәтта чын исемен дә. Авылныкылар исемен белмәгәнгә күрә, баштарак аңар Агай дип эндәшәләр иде, шул исем булып телгә керде.

Капка ачылды. Яше утыз тирәсендәге ир төп-төз атлап, урамга чыкты. Үрә катып туктады. Аннары үзенә-үзе русча әмер бирде: «Налево!» Сулга кырт борылып басты. Янә әмере яңгырады: «Шагом марш!» Күкрәген киереп, ияген югары күтәреп, туп-туры алга атлады. Урамның икенче башына барып җиткәч, янә үзенә-үзе әмер бирде, туктады һәм иң кырыйдагы өйгә карап үрә катты. Өйнең урам якка караган кечкенә тәрәзәсеннән олыгаеп барган бер бабайның тавышы ишетелде:

– Агай, килдеңме, хәзер чыгарам...

Күп тә узмады, капка ачылды. Бабай сөйләнә-сөйләнә сөлге капланган куштабагын гаскәригә сузды.

– Ризык булсын. Коеңны казып бетердеңме әле? Мине генә түгел, беркемне дә ярдәм итәргә кертмисең икән. Югыйсә теге көнне кызган идем. Кем инде ялгыз башы кое казысын?!

[2] Кыргый – гади торымтай (лат. falco tinnunculus), лачынсыманнар ыругына керүче, Үзәк Европада карчыгадан соң иң таралган ерткыч кош.

Агай аны әллә ишетте, әллә юк, табакны кулына тоткан килеш янә гаскәриләрчә кырт борылды.

– Монда сиңа җиңел генә казыла торган мамык кебек туфрак юк. Комлы таш! Суына барып җиткәнче күпме төшәрсең, ярдәмгә килгәннәрне кума, дим. Агай, тыңла мине...

– Направо! Шагом марш!

Агай килгән юлы буйлап атлап китте. Бабай аны:

– Айт-два, айт-два, шагым марыш... Бөтен сүзең шулмы?! Болай итеп йөрсәң, сугыш синнән һич чыкмас, – дип кызганып та, сүгеп тә озатты.

Төркиянең тоташ балчык өйләрдән торган тып-тыныч татар авылы буйлап совет хәрбие бара. Урамның ике ягына тезелгән өйләрнең бакчаларында безнең якларга ят йөзем, армут, инжир агачлары үскән кебек, бу урамга совет гаскәрие дә шулкадәр чит. Әнә ул үзенә-үзе әмер бирә. Үзен-үзе туктата яки алга җибәрә. Аның гаскәри боерыгы бик шәп яңгырый, әмма беркемгә аңлашылмый. Тавышын ишетеп алганнар ишегалдыннан, тәрәзәдән үрелеп, артыннан карап кала һәм иплән кенә язмышка көрсенә. И балакай, кемнәрнең газизедер инде син?! Нинди язмышлар сине бирегә китереп ташлагандыр?! Безнең мөһаҗирлек юлын таптарга ниләр этәргән?! Туган җиреңдә якыннарың көтәдер бит!

Ул авылдагы беркем белән сөйләшми диярлек. Хатыннар соравына бөтенләй җавап бирми. Баштарак әле, ни дисәң дә, кеше арасында ешрак була иде. «Бик дөрес кеше» дигән аты чыкты. Бөтен эшен җиренә җиткереп үти, беркемгә зыяны юк. Әлбәттә, аз сөйләшкәне өчен гаепләп утырмадылар, үз иттеләр. Якын тормый, кешечә аралашмый дип тә ачуланмадылар. Шул юыныргa яратмавы белән генә килешмәделәр. Йорт хуҗалары аның теш-тырнагы белән каршы килүенә карамастан, кулларын бәйләп, сакалын кырды, мунчага алып кереп юды. Чәч-сакаллары үсеп, пычранып беткәндә, куркынычка әйләнә иде, ә югач, бик тә ягымлы, килеш-килбәте хәтта сокланырлык яшь ир кыяфәтенә кайта. Берникадәр вакыттан соң Агай авыл башында ялгыз торган өйләрнең берсенә ияләште. Шәһәргә китеп-китеп эшләп кайтты. Авылда бары тик берничә кешедән ипи алды, шулардан ук өенә урын-җир өчен капчыклап, салам ташыды. Бөтен аралашканы шул, ихтыяҗына күрә...

Көннәрдән бер көнне Агайның ялгыз башына кое казый башлавы телдән-телгә күчеп сөйләнде. Читтән күзәтеп торган кешеләрне гаҗәпкә калдырып, башта кулына ике тимерчыбык алган. Шуларны бөкләп тоткан да ишегалды, бакча буйлап озак кына йөргән. Ул адым атлаган саен, кулындагы тимерчыбыклар төрле тарафларга борыла икән. Шуннан тимерчыбык башлары бер-берсе белән «кавышкан» урында тукталган, шунда көрәген кадап куйган, имештер. Берничә көннән күрделәр, шул урында кое казый башлады. Балчыкка батып беткән яшь ирне кызганып, сәерлекләренә гаҗәпләнеп сөйләделәр. Янына бармадылар түгел, бардылар... Әмма Агай ачуланып куды гына.

Каты җир чокып тирләп пешкән, арыган Агай көрәген бер читкә ыргытты. Койма аркылы гына үрелеп, урам тарафына күз ташлап алды. Койма күләгәсен чамалап, җиргә утырды. Бөтен тәненнән тир акты, ә ябык тәне дер-дер калтырады, сөякләренә кадәр өшеде.

Көрәкләр күтәреп килгәннәр, бездә өмә ясау гадәте бар, диләр... Имештер казышабыз, диләр... Әйе, казышырлар, күмеп китмәкчеләр...

...Чокыр тулып өелә башлагач, бозылган мәетләр өстенә акбур сибәрләр. Көн дә лагерь янында чокыр казып, шуларга мәет ташып, хәлдән таялар.

Үзләре дә ярым мәет, хәлсез, ач. Бүгенме, иртәгәме аларны да чокырга ташлаячаклар.

Бер гаскәри мәет ташыганда хәлсезләнеп егыла башлады. Янындагысы булышырга теләп, терсәгеннән тоткан иде, фашистларның җен ачуы чыкты. Шунда бүкән өстенә салып ярдылар гына. Күм-күк булып катканчы... Аннары өстенә салкын су сиптеләр. Бер мизгелгә аңына килде кебек, әмма озакка түгел, катып калды. Лагерьдагы үлекләр белән бергә аны чокырга ташлаттырдылар. Теге ачлыктан хәлсезләнеп егылган, аяк астында аунаган гаскәри исә әле аңына килеп-килеп китә иде. Аяклары белән типкәләп алгач, аны да мәет чокырына илтергә кушып акырдылар. Аны күтәреп барган ике әсир бер-берсенә карашып куйды. Үлмәгән түгелме, шешенгән күз кабагы селкенде кебек. Чыгар-чыкмас тавыш белән «Әни... Әни...» – дип кабатлады, ыңгырашты... Күтәреп барганнарның берсе Агай иде, ул «әни» сүзен ишетеп алды, акрынайды. Ничек ташламак кирәк?! Читтән күзәтеп торган сакчы аркасыннан автоматы белән шулай төртте, авыртудан умыртка сөяге ярылгандай тоелды, тешен кысып атлады. Яныннан барган башка бер әсир: «Үлде ул, үлде. Төне буе «әни» дип саташты... Миннән ерак ятмый иде... Аның әллә ничә ярасы бар эчендә, үлекләп бетте. Син үзең егылма...» – диде. Болай да котырган эт кебек ябышырга гына торган сакчы аларга янә бер акырды. Сөйләшергә ярамый иде...

Бабай ярдәм итәргә киткәннәрнең кире борылып кайтып барганнарын күргәч, хатынына ашарга әзерләтте. Аш, бер савыт су күтәреп, үзе китте. Җир казу җиңел эш түгел, карыны ачтыр, тамагы кипкәндер. Ризыктан баш тартмас, дип төшенде. Капкасын ачты, ишегалды уртасында казый башланган коега күз ташлады, шул тирәдә көрәк аунап ята. Ә Агай күренми... Ачык ишек янынарак барып эндәште:

– Агай, эш барамы? Бик эссе...

Койма күләгәсендә утырган Агайны башта абайламады. Ашын кая куярга белми тирә-ягына каранганда күреп алды һәм имәнеп китте.

– Әстәгъфирулла... Ник эндәшмисең?

Агай аны танымады төсле. Шулай акаеп карады, бабай ни дияргә белми артына чигенде. Алай да үзен кулга алды, бернигә игътибар итми, кырыс тавыш белән сөйләнде:

– Ашап ал, дим, хәл кереп китәр... Җәһәннәм эченә төшкән кебек карап торма миңа. Нигә ярдәмгә килгәннәрне эшләтмәдең?! Бая күрдем, кайтып баралар иде. Әллә алар эшләре беткәнгә сиңа килгән, дип уйлыйсыңмы? Көне-төне тарлауларында яталар, вакыт табып килгәнгә рәхмәт әйт...

Ризыкларны төреп алып килгән сөлгене чирәмгә җәйде. Шунда ипи сыныгын, аш табагын куйды. Су савытын Агайга сузды.

– Су да китердем. Кибеккәнсеңдер...

Агай йотлыгып су эчте. Күз алдыннан куркыныч, җирәнгеч хәлләр акрынлап югалды, киеренкелектән каткан тәне язылды кебек. Аңы ачылып китте. Бабай казыла башлаган коены карап килде. Йөзенә соклану, гаҗәпләнү чыкты чыгуын, әмма теле белән күңелендәгесен җәеп салмады. Алай да кырыс тавышы бераз йомшарган иде.

– Хәтәр казыгансың. Тәмам, казы, казы. Тирәнгә төшкәч нишләрсең, курик... Су чыгармы тиз генә, юкмы... Барыбер ярдәм кирәк булыр... Кое казу бик хәвефле эш, сак бул. Кирәге чыгар, менә бау, чиләк китердем...

***

Авыл тирәсендәге аланнарда эсселектән үләннәр кара көйде, шайтан таяклары гына чәчәк атты.

Кыргый белән Агай өчен кояш кыздырамы, юкмы – барыбер иде, берсе аудан туктамады, икенчесе кое казуын дәвам итте.

Кыргый тимер чыбыкта ничек селкенмичә утырса, кайчак күк йөзендә дә шулай хәрәкәтсез калыр иде. Дөресрәге җил уңаена очар, ә җирдән караганда тик торган кебек күренер. Шул мизгелдә ул үткен күзләре белән корбанын күзәтер. Җирдә кыштыр-мыштыр килеп йөгерешкән тычканнарның берсен сайлар... Бер мизгелдә ук кебек атылыр һәм күз ачып йомганчы аны тырнаклары белән эләктереп алыр. Никадәр җитез кош! Никадәр акыллы! Әмма кайчак онытылып, бөтен игътибарын корбанына юнәлткән мәлдә, тагын да биектәрәк очкан, тагын да ерткычрак кошлар аның үзен күзли! Хәтта күпкә көчсезрәк каргаларга кадәр «йомшак чагын» күреп алуга ташланырга тора! Их кыргый, исәр җилләргә ышанма, канатларыңны җәеп онытылма. Җил бер көн бер тарафтан, икенче көн башка яктан исәр. Ә син ауга чыккан мәлдә үзең корбан китәрсең! Үзең таланырсың!

Агай ташландык өйләр тирәсеннән уртача зурлыктагы ташлар ташыды. Коены казып төшкән саен, шуларны чокыр эченә дивар итеп тезде. Чираттагы мәртәбә аяклары белән ташларга баса-баса менде. Җирдә аунап яткан бер такта кисәген алып, янә юк булды. Шул такта кисәге белән үлчи-үлчи коены туры казырга тырыша иде.

Башта балчыкны өскә көрәге белән атты, тирәнәя башлагач, капчыкка тутырып чыгарды. Чокыр өстенә ике якка бүрәнә казып утыртты, алар арасына тимер беркетте. Биш-алты метр тирәнгә төшәрлек бауның бер очын шул тимергә бәйләп әйләндерде. Бау балчыклы капчыкны тартып чыгарырга да, үзенә төшеп-менеп йөрергә дә ярдәмче булды.

Ниһаять, кое төбе суланды! Капчык урынына чиләк бәйләп төшерде, шуңар сулы балчыкны тутырды. Аннары үзе үреп төшкән диварның чыгып торган ташларына баса-баса өскә үрмәләде. Сулы балчыклы авыр чиләген кое төбеннән тартып алгач, хәлсезләнеп, коры җиргә чүгәләде. Чиләгендәге балчыклы суга кулларын терсәгенә кадәр батырды. Кире алды, тагын батырды. Шатланып сөйләнде.

...Су чыкты! Әнисе, кара, күрәсеңме, безнең бакчада су бар! Синең дә җилкәләреңне көянтә ашамас... Мунча ягам, дисәң, су ишегалдында гына... Менә күрерсең, күршеләр безгә суга йөри башлар әле. Авыл очына барып тормаслар, безгә керерләр. Керсеннәр, әйеме, бер кое суы барыбызга җитәр...

Аннары кызу-кызу кабат төште, кабат сулы балчык чыгарды. Тирләп пеште, пычранып бетте. Ул эшләгән арада сизми калган, аш китергәннәр. Тәрәзә төбенә берничә телем икмәк белән бергә шулпа салынган табак куеп киткәннәр. Караңгыланып килгәндә, ишегалдында аркасы белән коймага терәлеп утырган килеш ашады да җәйге җылы төн кочагында, йолдызлар астында сөйләнә-сөйләнә изрәде.

...Җаным, күрдеңме, коебызның суы ничек тәмле, ә?! Тәмле шул... Сез минем кайтканны көтегез, яме. Карагыз аны, кое суын эчеп бетермәгез. Эчеп бетермәсәгез... Куян күчтәнәче алып кайтырмын. Соң, оныттың дамы әллә? Җир җиләген әйтәм! Теге, печәнлектән куян биреп кайтарган иде бит. Бәбиебезне көткәндә, җиләк дип, авыз суын корыттың бит... Әнисе, кулыма алсаммы? Уянырмы? Уяныр шул, тимим. Йокласын сабый. Күрешергә насыйп итсә иде... Елама, кайтырмын. Куян күчтәнәче алып кайтырмын...

Сукыр кошка оясын Аллаһ ясар, диләрме әле, Агайга да мөмкинлекләренә күрә тормыш корырга ярдәм итте. Кое казыгач исә, бакчасына яшелчәләр утыртып, җиләк-җимеш агачлары үстереп мәш килде. Агайның тиз арада су чыгарлык кое казуына исе киткән авыл кешеләре, аны үзләренә кое казырга чакыра башлады. Аларга да ул башта ике тимер чыбык тотып килде. Җир астыннан аккан су магниты тәэсирендә әлеге тимерчыбыкларның хәрәкәткә килүен, әлбәттә, аңлатып тормады. Бик аз сөйләшә иде бит ул. Сөйләшкәндә дә, күбрәк үз-үзе белән генә, дигәндәй.

Дөрес, кайчак ап-аермачык итеп, йөрәккә үтәрлек итеп әйтеп куя. Андый вакытта аның күз карашы ягымлы, үзе кырт-мырт ишарәләр ясамый, тыныч була. Беркөнне авылга икенче мәртәбә кайткач сыенган гаиләгә ипигә килде. Һәм, ни гаҗәп, тиз генә кайтып китәргә ашыкмады. Үзе калган бүлмәдә ятып торды, аннары ишегалдына чыгып утырды. Аңардагы үзгәрешкә хуҗа кызлары игътибар итте. Әмма эндәшмәделәр, читтән генә күзәттеләр. Чыр-чу килгән бала-чагага карап утырган Агайга беркем якын килмәде. Хуҗаның олы кызы кечкенәсе белән кунакка килгән чак иде. Күкрәк сабыен күтәреп чыкты да Агайдан ерак түгел, агач күләгәсе төшкән урынга җәйге алачыкка килеп утырды. Агайның ягымлы карашы аңар төбәлде. Айт-двага басып йөргән гаскәри кыяфәте каядыр юкка чыкты, аның урынына тормышы балкып торган, якыннарының яратуын тоеп яшәгән, нечкә күңелле бер яшь ир барлыкка килде.

– Минеке бишектә калды.

Баласы белән мәшгуль ана аның ни әйткәнен аңлашмый калды.

– Агай, миңа дәштеңме?

– Минем балам... Бишектә йоклап калды, – дип кабатлады Агай. Аннары ничектер уңайсызланып китте кебек. Янә бер кат: «Минеке бишектә калды», – диде дә авыз эченнән нидер сөйләнеп, ишегалдыннан чыгып китте. Өйдән чыккан Миңҗамал кызына дәште:

– Кызым, Агай күренмәдеме?

– Әле китте.

– И, житешмәдем алайса... Иртәгә дә кил, димәкче идем. Базарга барып киләсе идек. Каралты-курага күз колак бул, дисәң, урыныннан да кымшанмый саклый. Бик дөрес кеше ул...

– Әни, беләсеңме ни диде?

– Ни?

– Балам бишектә калды, диде.

– И Аллам, Үзең ярдәмеңнән ташлама... Сөйләшми бит, ничек чыдый торгандыр, эченә җыеп йөртә. Айт-дывасы – русча да мыгырдаганда – гел татарча. Әмма ничекләр аңлап җиткерәсең?

– Әни, бу юлы ап-ачык сөйләште. Мин әллә ялгыш ишетәмме дип торам. Күрсәң, әни, күз карашлары шундый нәүмиз, үзе ялгыз, чарасыз, елап җибәрә яздым... Аннары... Әллә нишләде шунда, күзләрен челт-челт йомды, иңсәсен җыерды. Мин тагын сорау биргәнче чыгып китте.

– И кызым, аның хаста тәне генә безнең арада йөри. Зиһене, уе кайда, кем белсен...

***

Тора-бара Агайның сәерлекләре күзгә күренеп арта башлады. Өеннән ерак китмичә яланга чыгып, ташлар белән сугышлы уйнавын ни әйтергә, ни чара күрергә белмичә, читтән генә карап йөрде авыл халкы. Ташларны тезеп куя

да әмер бирә, кайберләрен очкыч итеп очырта, кайберләрен танк итеп йөртә, шартлата, чәчә-җыя... Өлкәннәр «мескенкәем» диеп кызганып китсәләр, бала-чага тагын да ныграк үрти башлады.

Яланның бер тарафында Агай сугышлы уйнаса, икенче яктарак авыл малай-шалайлары йомран ояларына су сала, шулардан чыгып йөгергән йомраннарны тота. Котлары чыккан йомраннарның койрыкларына шалтыравык бәйләп мәш киләләр. Малайларданмы, шалтор-шолтыр килгән тавыштанмы башларын кая алып качарга белмәгән соры йомгаклар әрле-бирле тәгәри. Бала-чагага кызык, рәхәтләнеп шулар артыннан йөгерә! Мондый вакытта кыргый, гадәттә, биектән оча, йә ара-тирә һавада эленеп торып, мәхшәрне өстән берничә минут күзәтә дә таулар ягына очып, күздән югала.

Йомраннар качышып беткәч, малайлар өйләренә таба юл алды. Ташлар белән «сугышлы» уйнап яткан Агайны күрүгә яңа кызык тапкандай: «Агай! Озын агай! Здравый агай! Тиле Агай!» – дип кычкырып үртәргә керештеләр. Үзләре бик якын килергә курка. Чөнки таш ата башлавы бар. Бу юлы исә җиргә йөзтүбән капланып ятты да үксепме-үкси Агай.

Ул арада урам башыннан түгәрәк кенә гәүдәле бер хатын килгәне күренде. Култык астына сөлгегә урап, нидер кыстырган. Җитез-җитез атлый. Юл уңаенда читтә яткан чыбыкны алды, бәбкәләрен ияртеп йөргән казларны, үзенекеләр булса кирәк, тыкрыктан яланга таба куып алып китте. Шуннан яланда Агайны үртәгән балаларны күрүгә казларын онытты, кулындагы таягын болгый-болгый кычкырды:

– Әй, үртәмәгез! Үртәмәгез! Улым, кил! Кил тизрәк, дим!

Авылга таба юл тоткан балалардан бер малай аерылып калды.

Хатын култык астына кыстырган сөлгесен сүтте, малайга түгәрәк күмәч тоттырды:

– Мә, Агайның карыны ачтыр. Илтеп бир әле.

Төче камырга тәгәрмәч төсле түгәрәк итеп пешерелгән күмәчне агай клиндер дип, бик яратып ашый.

– Әни... Аңа якын барырга куркам.

– Әле генә бит үрти идегез!

– Без бит ерактан гына...

Чын дөресен әйткәндә, Агай янына барырга теләмәве куркудан түгел. Әле берничә көн элек әнисе яңа пешергән ипинең бер өлешен кисеп, Агайга илтергә кушты. Малай ишегалдына керергә теләмичә бер ташка ипине куеп китәргә уйлады, янәсе, капка каккан тавышка үзе чыгып алыр. Әмма кагарга җитешмәде. Агай, көтеп кенә торган диярсең, үзе атылып чыкты. Бик кәефсез күренде. Йокламаганга охшаган. Кашлары җыерылган, карашы шөбһәле. Малай тизрәк кулындагы ипине сузды. Һәм үз күзләренә үзе ышанмады. Ир ипине җиргә ташлап аягы белән изде. Бәләкәйдән өлкәннәрнең ипине зурлаганын, валчыгын койган өчен дә орышканнарын белеп үскән бала бит ул! Агайның бу кыланмышын күреп, нишләргә белмәде. Артка чигенде. Авылны яңгыратып кычкырасы килде. Тукта! Нишлисең син?! Ипине мәсхәрәләмә! Ходай сугар!

Агай башта аягы белән ипине изде. Шикләнеп кенә бер малайга, бер җирдә яткан ипигә карады. Аннары җиргә чүгәләде, тапталган, балчыкланган ипине учына җыеп алды. Һәм малайга борылып та карамыйча ишегалдына кереп китте. Малай ябык капка каршында авызын ачып басып калды. Башка беркайчан бу адәмгә ипи китермәячәк!

– Улым, бар, бар. Карыны ачтыр. Аның бит ипи пешереп ашатучысы юк. Улым, сиңа берни булмас. Моңа кадәр беркемгә зыян салганы юк. Гөнаһсыз җан ул.

– Безгә таш атты!

– Тиле дип кычкырсалар, кем дә атар, улым. Акыллы да атар! Бар, курыкма. Мин сине моннан карап торам.

Малай күмәчне тотып, теләр-теләмәс кенә урыныннан кузгалды.

Җиргә капланып яткан Агайдан берәр метр чамасы ераккарак клиндерне куйды да кире әнисе янына чапты. Малай әйләнеп килгәндә, әнисе Агайга төбәлгән дә йомшак тавыш белән сөйләнеп тора иде.

– Агай, бәпкәм. Син ярата торган... Ал, ал... Аша, бәпкәм...

Үзе белән бер чама яшьтәге, кырыкка җитеп килгән иргә шулай балага эндәшкәндәй бәпкәм дию дөрес тә түгелдер инде, әмма ни дисен, күргәннәре – кичергәннәре берничә таулыктыр, әмма зиһене үзе уйнаган ташларның иң кечкенәсенә тиң калган. Чыкмаган җаны гына бар. Алырмы күмәчне?! Клиндер дип сөенерме? Әллә хәрбиләр төсле әмер биреп, кычкыра-кычкыра төп-төз атлап китеп барырмы?!

Бераз казларны куган итеп, читтән генә күзәтеп тордылар.

Агай башын күтәрде, урыныннан торды, өстен кагыштырды һәм күзе клиндергә төште. Кырыс йөзе яктырып китте, яшьле күзләрендә сөенеч күренде. Клиндер! Иң яратканы шул – төче күмәч! Яланнан клиндерне тәгәрәтә-тәгәрәтә өенә таба чапты.

Хатын яулык очы белән генә күзенә тулган яшен сөртте. Аннары казларын малаена карарга кушты да кайтып китте.

...Язгы яңгырлы көндә Агайны өендә үлгән килеш таптылар. Буш өй эче салкын, коры җиргә салам җәелгән. Шул саламда газап эчендә бакыйлыкка күчкән иде ул. Тән һәм җан газабы сөйкемле йөзенә тирән җыерчыклар булып сызылган. Киемнәре ертык. Чәчләре үскән, сакал баскан, күптән юынмаган. Бәлки, ашамагандыр да... Урамда йөргәне күренми башлагач, өенә кергәннәр иде, шундый аяныч күренешкә тап булдылар. Авыл картлары аны мөселман йоласы белән бар шартын китереп җирләргә әзерләде. Юарга алып баргач, янә гаҗәпкә калдылар, Агай учыннан җиргә вак кызыл ташлар коелды.

Телефон чыбыгында кыргый утыра. Үзе тыныч, күзләре уяу. Мизарлыкка килгәннәрне күзәтә. Агай авыл халкы өчен шул ялгыз кошка тиң иде.

Җеназага кеше күп җыелды, дога кылынды. Кызыл ташларны яңа казылган кабер тирәсенә сиптеләр.

Кем син, Агай?! Ватаныңны сакларга дип, чит-ят җирләргә чыгып киткән һәм төрле тарафларда: кырларда, юлларда, чит туфракларда ятып калган миллионлаган кызыл гаскәриләрнең бары берсе. Әә бәлки, аларның авыр хәсрәте, югалтулары, күргән газапларыдыр?.. Йөзләрчә кат үлем белән йөзгә йөз очрашудан, күңел һәм тән әрнүләреннән, сагыштан тилергән җаннарыдыр...

Рухың меңәрләгән чакрымнарны кичеп, туган җиреңә әйләнеп кайткандыр, кулыңда бит кире каккысыз ишарә – «куян күчтәнәче». Әә туган ягыңда – анысы кайдадыр – син, мөгаен, хәбәрсез югалганнар рәтендә, бәлки инде, күптән мәрхүмнәр исемлегендәдер. Бишектә йоклап калган нарасыең инде күптәннән ятимлек кочагына таба тәпи киткәндер...

Сугыш хакында кем ни сөйләсә дә, кан һәм күз яшьләреннән торыр. Һәр солдат язмышында сугышның үзгә бер аянычы ачылыр.

...Озак вакыт узмады, авылдан кыргый китте. Ара-тирә телгә алдылар аны.

– Кыргыйны күргәнең бармы? Кыргый кошын әйтәм.

– Кошмы?

– Әйе, шундый кош бар иде. Элеккеләр кыргый дип әйтәләр иде.

– Нинди кош соң ул?

– Ялгызы тимерчыбыкта бер тавыш-тын чыгармый утыра торган иде. Сайрамый торган кош ул...

– Юк, күргән юк шул...

***

Биләҗек аша килгән әсирләрнең акрынлап тормышлары бер эзгә салынды кебек. Мөһаҗир татарларының кызларына өйләнүләре дә ярдәм итте. Иң яшьләре Җаппар үзенә ярны Искешәһәрдә тапты, Истанбулга китеп, сәүдәгәрлек юлына керде. Җирсү хисенә дәва табарга тырышыпмы, гел татарлар белән аралашты, татарлыкны саклады. Закир да Истанбулда яшәде, баштарак татар кешесе җитәкләгән заводта эшләде. Соңрак сәүдәгәрлек эшен корды, әллә ни баемаса да, тормыш көтәрлек мая туплады. Яше барган саен дингә ныграк тартылды. Ваһап җир эшеннән ерак китәргә теләмәде, ахры, бер кечкенә шәһәргә төпләнде. Яңа гаиләсе белән шунда көн күрде.

Камилнең икенче хатыны бала тапмады. Ул Россиянең Оренбург төбәгендә калган балаларын көннән-көн ныграк юксынды. Түземлеге төкәнде. 60 нчы еллар башында ничек итсә итте, икенче хатынынннан бәхиллек алып, беренче гаиләсе янына кайтырга карар кылды. Поезд белән Болгариягә, Болгариядән Мәскәү аша туган җиренә юл тотарга ниятләде. Бу адымга тәвәккәлләп, башкаларга да туган якка кайтырга бер өмет хисе бирде төсле.

Вокзалда хушлашу вакыты җитте. Алда билгесезлек һәм туган җир көтә! Бәгырь кисәкләрен кочагына алып кысар мизгел көтә! Бик каты дулкынланган, күз яшьләрен көчкә тыеп торган Камилне Җаппар башка озата килүчеләрдән бер читкәрәк алып китте.

Утны-суны бергә кичкән дусты белән болай сөйләшүнең сәбәбе бар. Чит илдә көн күрмешләре көйле генә барган кебек тоелса да, әледән-әле тынгысызланырга берәр сәбәп чыгып тора иде.

Берничә ел элек аларга үзе кебек үк әсирлек юлын үткән, Анкарада яшәп яткан бер татар килгән иде. Ул бүлмәдә ялгызы гына калганны көтеп утырган икән. Җаппар балконга чыккан арада, хатыны аш бүлмәсенә киткән җиреннән кире борылып, алгы якка керә. Һәм тегенең шкаф тартмаларын ача-ача нидер эзләгәнен күреп хәйран кала. Сиздерми генә кире чигенеп чыга да ишек кырыеннан күзәтеп тора. Кунак өстәлдәге кәгазьләргә дә күз сала, өстәл тартмасын ачып актара. Ашыгып, нидер эзли, тикшерә... Җаппарның балконнан кергәнен күреп, берни булмагандай урынына барып утыра.

Бу хәлне хатыны кунак киткәч кенә сөйли. Башка әлеге кеше белән аралашмаска, өйләренә китермәскә тырышалар. Һәр татарга чын күңеленнән ышанган, туганы кебек күргән Җаппарның күңелендә шул көннән соң шик уяна инде. Бераз саграк булу кирәк икән дигән нәтиҗәгә килде, әмма теге адәмнең гамәленә бер аңлатма таба алмады ул. Бәлки, урлашырга акча эзләгәндер, дип акларга теләде. Әмма, белүенчә, ул хәерчелек чигендә калган адәм түгел иде...

Камилне читкәрәк алып киткәч, гозерен пышылдап диярлек әйтте:

– Камил, тыңла әле. Минем дә бер кайтып киләсе килә. Син андагы вазгыятьне кайткач күрерсең, хат язып күндер. Бәлки, килеп җитәр.

– Әлбәттә, язармын, дускай!

– Хатыңны ачык яза аласыңмы, юкмы – билгесез. Гаиләң белән фотога төш, шуны юлла. Әгәр вазгыять яхшы булса – фотога аяк басып төш. Бераз начаррак икән, утырып төш. Тагын да начар булса, чүгәләп утыр. Шуннан синең хәлне дә, вазгыятьне дә аңларбыз.

Атналар, айлар узды. Дүрт күзләп көтелгән хат килде. Җаппар кабалана-кабалана хатны ачты, эчендәге фото идәнгә очып төште. Кулындагы хатны онытып, тизрәк шуңа бакты һәм хәлсезләнеп кәнәфигә утырды. Тын калды.

...Тирә-ягында җил катырак иссә авып китәргә торган, шыр сөяккә калган, өрәкләрне хәтерләткән әсирләр үзара сөйләшә. Туган илләренә кайтачаклар, газизләре белән очрашачаклар! Чит илләрдә күргәннәре үткәндә калыр! Ничә еллар дәвамында кара кайгыга батып, өмет баглап хәбәр көткән әни-әтиләре, хатыннары, балалары кочакларына сарылып елар. Күбесенең вагонга менәрлек тә көчләре юк, бары тик җәһәннәмнән котылу, сугыш бетү, кайту турындагы җылы, шатлыклы хис аякта тота. Хәер, барысы да яхшылык кына көтми, ышану хисе күзләрендә чагылмый, ниндидер бер сиземләү, пошыну бар. Сугыш елларында күргәннәре бу хисләрне бөтенләйгә җуеп ташлаган кебек. Аңа карамастан, адәм баласын өмет йөртә, күрәчәгенә дә өмет китерә. Җаппар шулай, төрле телләрдә сөйләшкән әсирләрнең ыгы-зыгысыннан пышылдап әйтелгән берничә җөмләне аңлап алды. «Исән каласың килсә, вагонга менмә, кач...»

17 яшьтә авылдан аерылды, бөтен күргәне сугыш һәм әсирлек, яра һәм үлем. Аңа бит әле 20 яшь кенә! Үләсе килми...

Хатынының күрше бүлмәдән: «Хат кемнән?» – дип эндәшкәне ишетелде. Шул тавыш янә чынбарлыкка кайтарды. Үзен тизрәк кулга алды. Янына килеп баскан сөеклесенә хатны сузды:

– Камилдән. Гаиләсе белән кавышкан.

Хатыны идәндәге фотоны күрде, шуны ашыгып кулына алды. Җаппар тәрәзә тарафына карап, калтыранган куллары белән күз яшен сөртте.

– Җаным, балалары үзенә охшаган, әйеме? Үсеп беткәннәр инде! Бик бәхетлеләр!

Чыннан да фотода күп еллардан соң яңадан кавышкан гаилә бик бәхетле күренә, гаилә башлыгының йөзендә елмаю чагыла иде.

Берничә көннән соң Җаппар хатны Закирга күрсәтте. Иптәше сәлам хатын укып чыккач:

– Фото салырга тиеш дигән идең. Фотосы бармы? – дип кызыксынды.

Җаппар иптәше төпченмәсә күрсәтеп тормаска ниятләгән иде. Гүргә кадәр сузылачак хыял кырыклыгын яшәтәсе килмәде. Әмма үзе сорагач, юк, диярргә теле әйләнмәде. Башка бүлмәдән фотоны алып чыкты.

– Әйе, җибәрде. Мә, үзең кара...

Фотода Камил иң алга – җиргә сузылып яткан иде. Димәк, туган илгә кайту һаман да әле үлемгә тиң...



Рәзинә
Мөхияр

# КАБАТЛАНА ТАРИХ...

## Утлар-сулар кичеп

*«Туган җирне сайламыйлар
Ул – синеке...»*

Әти-әни, туган җирне, туган телне
Сайламыйлар: Аллаһыдан бирелгән ул.
Йөрәкләргә сеңгән сүзләр алышынмый,
Алышынмый, күңелләргә үрелгән ул.
Әти-әни, туган җирем, туган телем –
Аллаһыдан бирелгән зур бүләкләрем.

Туган туфрак, урман-суы, яланнары...
Иң беренче сулыш алган һавам бит ул.
Яланаяк тәпи баскан туфрак-җирем,
Ни булса да, йөрәгемдә ярам бит ул.
Әти-әни, туган җирем, туган телем –
Аллаһыдан бирелгән зур бүләкләрем.

Чәнчеп алган усал, кырыс кычытканым,
Алабутам, әрсез булсын, җанда бит ул.
Купшы үлән, гүзәл чәчәк кирәк түгел,
Җанга якын ромашкалар монда бит ул.
Әти-әни, туган җирем, туган телем –
Аллаһыдан бирелгән зур бүләкләрем.

Туган җирем, туган телем, һәм милләтем,
Туган халкым, йөрәгемдә ут-ялкын ул.
Ата-бабам каны тамган җиребезгә
Береккәнмен җаным белән, үз халкым ул.
Әти-әни, туган җирем, туган телем –
Аллаһыдан бирелгән зур бүләкләрем.

---

Рәзинә МӨХИЯР (1956) *– галимә, шагыйрә; С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты. «Нәрсә булды миңа?», «Асылыма кайтам», «Күңел тәрәзәләрем» һ.б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*

Данлы, шанлы тарихы бар халкыбызның,
Утлар-сулар кичкән милләт, чыныккан ул.
Каксалар да, суксалар да, торып басар,
Җил-давылдан исән калыр – корычтан ул!
Әти-әни, туган җирем, туган телем –
Аллаһыдан бирелгән зур бүләкләрем.

## Янам...

Агыйделкәй ага, һай, алкын,
Суларыңда йөзәм, бик салкын.
Йөрәгемдә яна ут-ялкын,
Синең өчен янам, әй халкым!

## Димәк...

Кояш көлеп, җиргә караса,
Карның чәчен җилләр тараса,
Кошлар матур итеп сайраса,
Сыерчыклар оя сайласа,
Гөрләвекләр кинәт абынса,
Юллар энҗе-элпә ябынса,
Очкын чәчкән күзләр ут янса,
Күңел бәхет-шатлыктан тулса,
Йөрәк изге эшкә омтылса...

Димәк, җиргә тагын яз килгән,
Кырыс кыш та инде җиңелгән,
Җиңелүдән башы иелгән,
Бөтен җиһан моңа сөенгән,
Җылылыкка Галәм тиенгән,
Кызлар яз күк купшы киенгән,
Барсы күркәм, гүзәл күренгән.
Язбикәбез көлемсерәгән,
Нурларына дөнья төренгән.

## «Каргышлы» еллар

Әй тарихның канлы язмышлары...
Кемнәрнеңдер хата-ялгышлары.
Кычытканы, әче әремнәре,
Яраларның сызлап әрнүләре.

Тарихларда «каргышлы» еллар бар,
Капламасын аларны салкын кар.
Кайтавазы ничә буын аша
Йөрәкләрдән ташкын булып таша.

Кабатлана тарих, уяу булыйк,
Халкыбызның үткәнен без барлыйк!
Ни булса да, бердәм була белик,
Вакытында чараларын күрик!

Бер шырпыдан ялкын чорнап ала,
Чорнап ала, барысын көл калдыра.
Илне, телне, кардәшлекне саклыйк,
Кеше булып яшәүне без аклыйк!

## Буран улый

Буран улый...
Нигә дулый?!
Нәрсә даулый?!
...Авыр сулый...
Каурый-каурый

Карлар бурый.
Урый-урый,
Юлчы юрый:
Нидер сорый...
...Буран улый...

## Әй...

Әй... вакытның агышлары...
Күңелемнең сагышлары...
Уй-фикернең табышлары...
Тәкъдирләре... язмышлары...
Язмышларның ялгышлары...
Кемнәрнеңдер каргышлары...
Дөнья бабай каешлары...
И кояшның баешлары...

## Күз яшьләре – энҗе бөртек

Борчу-кайгыларым да юк,
Тула да куя күңел.
Күңелне йөгәнләп булмый,
Әйдә, түгелсәң, түгел!

Тынычланып та калырсың,
Тып-тыныч елга сымак.
Тумыштан ук булгансың бит
Нечкә күңелле елак.

Күз яшьләре – энҗе бөртек,
Җанны-тәнне ул пакьли.
Битарафлык, катылыктан
Йөрәгемне ул саклый.

## Менәр кыям

Бөеклеккә дәгъва итмим –
Аллаһ бөек.
Түбәнгә дә тәгәрәмим –
Танылыйм дип,
Лаек булсам, булмасам да,
Дан алыйм дип.

Һәр кешегә фарыз-тиеш
Гамәл үтим.

Әз булса да, яктылыкка
Өлеш кертим.
Тузан бөртегедәй эзем
Салып китим.

«Динем!» – димен, «телем"!» – димен,
Янам, көям.
Мәңгелектә алар алда
Менәр кыям.
Динем, телем сулышын мин
Җанда тоям.

## Үземчәлек

Үземчәлек – үзенчәлек
Күптән мине сыйфатлый.
Үземчә үзенчәлекне,
Үзенчә үземчәлекне
Шигырь  юлы исбатлый.

## Сары чәчәк

Сары чәчәк бүләк итте миңа онык,
Күбәләкләр уйнагандыр аңа кунып.

Ул үзе дә сары чәчле, нәкъ тузганак,
Килгән миңа Сары чәчәк булып кунак.

Тузганак та, оныгым да – сары кояш,
Онытылды сагыш... җанда бары кояш.

## Гомер буе шундый булдым

Авыр сүзләр җанга яра,
Җанга яра, җанны яра.
Гомер буе шундый булдым,
Үзгәрергә юк бер чара.

Авыр  сүздән күңел китек,
Күңел китек, ни хәл итим?
Гомер буе шундый булдым,
Мәңгелеккә шулай китим.

Авыр сүздән йөрәк ярсый,
Йөрәк ярсый ташып-ташып.
Гомер буе шундый булдым,
Чистарынам күккә ашып.
Авыр сүзләр әйтмә ашыгып.



Айгиз
Баймөхәммәтов

# УРЫН

хикәя

Зәбир утны сүндереп, эш бүлмәсеннән чыгыйм дигәндә генә, телефон шалтырады. Ир дерт итеп куйды.

– Кайтырга вакыт җитсә, эшем ияләре табылып тора, – дип, үзалдына сөйләнде дә, утны яңадан кабызып, телефонга үрелде.

– Әйе, тыңлыйм!

– Хәерле кич! – Чыбыкның икенче очында оешма сәркатибенең ягымлы тавышы ишетелде. – Зәбир агай, сезне Флорид Әгъзамович үзенә чакыра. Хәзер үк.

– Әллә берәр мөһим эш килеп чыктымы? – Зәбир кызыксынуын яшерә алмый сорап куйды. Әмма теге кыз ишетмәде бугай, бәйләнеш өзелде.

Зәбирнең йөрәге котырып тибә башлады. Ни булды? Кайтыр алдыннан шеф нигә чакырта икән? Соңгы арада тәртип бозмады шикелле. Шушы бетмәс сораулар аның башын чүкеде.

Зәбир монда бер елга якын эшли. Коллективта иң яшь белгеч. Шуңа да бүлектә аңа гел бәйләнергә генә торалар. Олырак хезмәткәрләр дә оперативка саен сөйләгән сүзләрен яшьләргә акыл өйрәтү белән тәмамлап куя. Ул үгет-нәсихәтләр һаман да Зәбирнең колагында чыңлаган кебек:

– Без дә яшь булдык, әмма эшкә карата җаваплы идек...

– Куй инде, хәзерге буын акча турында гына уйлап тик йөри.

Бигрәк инде! Шул тиклем фәлсәфәче булып кыланалар. Әйтерсең, үзләре эшкә килгәндә, күпне белеп, рәхмәткә генә тир түгеп йөргәннәр диярсең. Ә яшьләрнең берәр житешсезлеген күрсәләр, ябырылырга гына торалар.

Флорид Әгъзамович ни өчен чакыртты икән? Соңгы арада нәрсәне дөрес эшләмәве, нинди хата җибәрүе хакында исенә төшерергә тырышты Зәбир.

Әй, каһәр суккыры! Шуны да онытып торсын әле! Кичә эштән ярты сәгатькә алдан сыпырткан иде бит. Моны күрше бүлектән Гәрәй генә күрде. Ә аның күзенә чалындыңмы – бетте! Гәрәй алдында артык хәбәр сөйләргә ярамый дип, юкка әйтмиләр икән. Кичен ишетеп калса, таң атуга эштә барысы да белә.

– Дустым, артыгын эшләп куярмын дип куркасыңмы? – дигән иде көлемсерәп.

Зәбир аны-моны уйлап тормыйча, җаваплады да куйды:

---

Айгиз БАЙМӨХӘММӘТОВ (1988) – *язучы, журналист; Шәехзадә Бабич исемендәге Башкортстан Дәүләт республика яшьләр премиясе лауреаты. Башкорт, татар, рус, казакъ, кыргыз телләрендә чыккан «Калдырма, әнкәй!», «Урам балалары», «Кызык бу тормыш...» кебек китаплар авторы. Уфада яши.*

– Агай, минеке бит день за полтора!

Болай дип әйтергә аның хакы бар иде. Әнә, айлык норманы үтәү кәгазен карасыннар. Зәбир гел арттырып эшли. Ә Гәрәйгә бу сүзләр җитә калды. Шаркылдап көлеп, үз бүлмәсенә кереп китте.

Эшкә урнашкач та, Зәбир шул бә\ндәне өнәмәде. Җүнләп сөйләшә дә белми бит. Һәр сүзендә мыскыл, төрттереп алу, авырткан урыннан чеметү. Ни әйтәсең – эче тулы этлек. Бер рәтле эше юк. Иртәдән кичкә тиклем гайбәт сатудан бушамый. Кайчан карама, Гәрәй йә бухгалтериядә чәй эчә, йә келәт мөдире тирәсендә урала. Тик күмәк җыелышта үзгәрә дә куя. Шул тиклем матур итеп телмәр тота, әйтерсең лә, былбыл сайрый. Теле телгә йокмый чукынчыкның. Имеш, эш нәтиҗәлерәк булсын өчен яңадан-яңа алымнар уйлап табарга кирәк. Ә бездә күпләр үз эшенә өстән генә карый, фәлән дә төгән. Үзенең ни өчен айлык норманы даими үти алмавына да җавабы әзер:

– Мин сан артыннан кумыйм, товарның сыйфатлы булуын хәстәрлим...

Гәрәй җитештергән товарның сыйфатын әйтсәң, тавык көләр! Эшли белү – талант, ә эшләгән булып кылану – сәнгать дип, юкка әйтмәгәннәр икән!

Шулай уйлана биреп, җайлап кына атлый торгач, Зәбир җитәкче кабинетына килеп җиткәнен сизми дә калды. Хәзер нindирәк сөйләшү булачагын күз алдына китереп, буыннары җебеде.

– Кайда шул гомер йөрибез! Шәбрәк инде! – Яшь кенә сәркатип Зәбирне кабаландырып кертеп җибәрде.

Җитәкче бүлмәсенә керүчене күрмәмешкә салышып, башын да күтәрми, нидер яза-сыза.

– Мин килдем, Флорид Әгъзамович, – Зәбирнең тавышын ишеткәч, түрә башын күтәрде. Син басып торма, дигәндәй, үзенең өстәле янындагы утыргычка ымлады. Зәбир утырды. Йөрәге һаман да дөп-дөп тибә, әйтерсең лә, хәзер атылып чыгарга тора.

– Йә, эшләр ничек бара? – Флорид Әгъзамович берчә хезмәткәргә, берчә алдындагы кәгазьләр өеменә карап торды.

– Бара инде ул... – шуннан башка җавап табылмады.

– Сине чакыртуымның җитди сәбәбе бар бит әле. – Моны ишеткәч, Зәбирнең йөрәге жу итеп китте. Гәрәй хәбәрен тәки җиткергән дип уйлап куйды. Үзенең гаебен тоеп, бер сүз дә әйтә алмады. Җитәкченең күзенә карамас өчен стенадагы сәгатькә төбәлде.

Флорид Әгъзамович кәнәфиеннән тормыйча гына, сүзен дәвам итте:

– Иртәгә командировкага барам. Сине үзем белән алам. Уйладым-уйладым да синнән дә кулайрак кешене тапмадым. – Зәбир ишеткәненә ышана алмый торды. Җилкәсеннән бер өем ташны алып ыргыттылармыни! Авызы ерылып китте. Шулай да җитәкчесенең сүзен бүлдерергә кыймады. – Берсе кечкенә балам бар дип, сылтау таба, икенчесенең хатыны ирен кайда җибәргәннәрен төпченеп, теңкәне корыта.

Зәбир шатлыгыннан урыныннан сикереп торганын да сизми калды, теле дә ачылып китте.

– Һо-о-о, Флорид Әгъзамович! Юл йөрү миңа бер дә кыен түгел! Барам...

– Бик шәп, алай булгач. – Җитәкченең дә авызы ерылды. – Димәк, иртәгә Таулы районына юлга чыгабыз!

– Таулы районына?! – Бу хәбәр чынмы, дигәндәй яңгырады.

– Әйе, шунда. Нигә исең китте әле?

– Соң, минем кәләш[1] бит шул районнан, – диде Зәбир, горурланып. – Ул

[1] Башкорт телендә хатын мәгънәсендә.

якларны күптән күргән юк иде. Үзегез беләсез бит инде, Таулыга барып җитү – олы бәла.

– Ә-ә, менә кәләшеңнең туган ягын да күреп кайтырбыз. Район хакимияте башлыгы белән сөйләшеп куелган. Ул безне төшкә кадәр көтәчәк. Шуңа күрә иртә белән чыгу хәерлерәк. – Син берүк соңлый күрмә дигәндәй, Зәбиргә карап куйды. – Иртәнге алтыда ишек төбендә көтеп торырсың!

– Ярый, ярый, Флорид Әгъзамович.

– Яшьләр өчен төн кыска була, диләр. Син шулай да йокыңны туйдырып, алтыга килеп җит. Килештекме?

Җитәкчесенең шуклыгыннан Зәбирнең күңеле тагы да күтәрелеп китте. Кабинеттан Зәбир куанып чыкты. Менә нинди ният белән чакырткан икән! Ә ул, сантый, Гәрәй турында нәрсә генә уйлап бетермәде. Хезмәттәше хакында начар фикер йөрткәне өчен Зәбирнең үзенә уңайсыз булып китте.

Автобуста кайтканда да, аның бөтен уе иртәгәсе сәфәр хакында иде. Менә күр дә тор, шушы турыда Сәлимәсенә әйтсә, ышанмаган булыр әле:

– Куйчы, Зәбир, буш хәбәр белән нәфсене аздырма, – дияр сөеклесе. Билләһи, Сәлимә ышанмас. Алар бит соңгы тапкыр Таулы районына көз көне кайнәсенә бәрәңге алышырга кайтканнар иде. Шуннан бирле барып булмады. Яңа ел бәйрәмнәрендә дә кәләшен эшкә чакыртып алдылар. Табибның тормышы шундый шул инде. Авырулар ял үткәнен көтеп тора алмый. Әнисен күптән күрә алмаганга бигрәк тә Сәлимәсе борчыла. Кышны ялгызы ничек чыга икән, утыны беткәндер, су ташырга да кешесе юк, дип өтәләнә. Кәләше өзгәләнгәч, Зәбир дә үзен уңайсыз тоя. Ни машиналары юк. Автобус дигәннәре ул якка сирәк йөри, йә бөтенләй булмый. Һәм менә сиңа мә: бирәм дигән колына – чыгарып куяр юлына! Зәбир, иртәгәсе көннең ничек үтәчәген күз алдына китереп, татлы хыялларга чумды.

Иртәнге алты тулыр-тулмас алар кәләше белән ишек төбендә торырлар әле.

– Ну, Зәбир, башлысың да инде, – дияр аларны күргәч җитәкчесе. – Бездә барыбер ике урын буш. Кәләшеңне үзең белән алып шәп иткәнсең. Бер уңае кайнәңнең[2] хәлен дә белеп китәрсез. Үзем кичә кәләшеңне дә ал дип әйтергә онытканмын. Шуңа үкенеп йөри идем әле. Шуннан Флорид Әгъзамович алга утырыр, ә Зәбир Сәлимәкәе белән арткы яктан урын алырлар. Сөйгәне иркәләнеп, иңенә башын салыр да йоклап китәр...

***

Иртәнге алты тулыр-тулмас алар оешмага килеп тә җитте. Тышта суык иде, җылыда торыйк дип, вахтага керделәр. Менә хәзер оешма җитәкчесен шофёры алып килер дә, Зәбир белән Сәлимә машинага утырыр. Шуннан җилдерәчәкләр!..

Барысы да алар уйлаганча килеп чыкты. Сәлимә эштән көн алды, шуңа да шатлыгыннан нәрсә эшләргә дә белми.

Зәбир тәрәзәдән күзен алмый. Җитәкче килеп җитсә, аны көттереп тору килешкән эш түгел.

– Әнә, кап-кара төстәге «Волга» күренде. Флорид Әгъзамович килә! – диде Зәбир, елмаеп. – Машина китеп бармасын дигәндәй, алар, күчтәнәч тулы авыр йөкләрен күтәреп, тышка йөгереп чыкты.

Боларны күргәч тә, җитәкче машинаның алгы тәрәзәсен төшерде:

– Саумысыз! – диделәр икесе дә бер тавыштан.

– Әйдә, җәһәтрәк утыр! – Түрә Сәлимәне бөтенләй күрмәгәндәй, боерык

[2] Башкорт телендә хатынның әнисе.

бирде. Зәбир алдан ук кәләшен алып бару хакында килешмәгәне өчен уңайсызлана биреп сүз башлады:

– Флорид Әгъзамович, мин Сәлимәмне дә алган идем. Буш урын бар бит. Күптән әнисен күргәне юк.

Флорид Әгъзамович күзләрен акайтып карап куйды. Эш нидә икәнен аңлагач, шунда ук йөзе үзгәрде. Берчә Сәлимәгә, берчә Зәбиргә ачулы караш ташлады. «Килештердең, болай булгач» дигәндәй, тамак кырып алды.

– Кызык кына шушы яшьләр. Уйларында гел шәхси мәнфәгать. Әбичәбиләргә кереп йөрергә вакытым бардыр шул. Мине башлык көтә!

Җитәкчесенең бу кыланышыннан Зәбиргә кәләше алдында уңайсыз булып китте.

– Безгә район үзәгенә барып җитсәк тә хуш, – дип елмаерга тырышып, Сәлимә сүзгә кушылды. – Авылыбыз үзәктән ерак түгел ул. Анда үзем барып җитәрмен.

– Еракмы-юкмы – анда минем эшем юк, – дип кабалануларын белдереп, җитәкче сәгатенә карап куйды. – Әйдә, вакытны сузмыйк. Юл уңае тагы ике кешене утыртасы бар. Алар белән алдан килешенгән. Сезне, сеңлем, берничек тә ала алмыйбыз. Урын юк!

Сәлимәнең йөзе үзгәрде. Бар хыяллары чәлпәрәмә килгәнгә, менә-менә күз яше бәреп чыгар төсле. Ә Зәбирнең гарьләнүе чигенә килеп җитте! Кәләше алдында шул тиклем мәсхәрәгә калды бит. Җитәкчесе белән алдан килешмичә, тот та кәләшен алып кил, имеш. Ә машинада урын юк. Ичмасам, ничә кеше барачак дип, алдан сорамаган. Хәзер кәләшенең күзенә ничек карамак кирәк! Бу тиклем дә оятка калганы юк иде аның.

– Әйдә, Зәбир, кузгалдык! – Флорид Әгъзамович аңа, артка утыр, дип, кулы белән ишарәләде. – Ә сез, сеңлем, гаепкә бөкмәгез!..

Зәбир күзенә дә карамыйча, сөеклесен кочаклады да, битеннән үпте. Машинаның арткы ишеген ачкач, көч-хәл белән телгә килде:

– Көймә, зинһар, җаным. Барырбыз әле шушы арада, – Зәбирнең утыруы булды, машина ажгырып, урыныннан кузгалды.Кайда барырга, нәрсә эшләргә белми аптырап, Сәлимә юл уртасында ике сумкасын күтәреп калды.

Зәбир озак кына тын барды. Җитәкчесенә нәфрәтләнеп, ачуына чыдый алмый утырды. Әгәр Флорид Әгъзамович яшьтәше булса, билләһи, китереп бер сугар иде. Ә болай, җитәкчеңә ничек кул күтәрмәк кирәк? Шунда бер урын жәл идеме инде?

Юкка утырып киткәнмен, дип үкенде. Барсын иде әйдә үзе. Товарны ничек кулланырга кирәклеген шундагы башлыкка аңлата алмый, җыеп күрсәтә белми оятка калыр иде. Сәлимәсен калдырганына үзен юл буе сүкте дә сүкте Зәбир. Флорид Әгъзамович нәрсәдер сораса, «әйе» яки «юк» дип кенә җавап кайтарды. Юлда ике кешене утыртырга тиешбез, дигән хәбәре дә буш булып чыкты. Беркемне дә алмадылар.

Мондый хәлдән соң аңа Флорид Әгъзамовичның һәр сүзен ишетү үзе бер җәза кебек тоелды. Тонык тавышы, шоферга бертуктаусыз мыжып килүе Зәбирнең ачуын көчәйтте генә. Төш җитүгә алар район хакимиятенә килеп җиткән иде. Флорид Әгъзамовичның кушуы буенча Зәбир багажниктан авыр тартманы алды да җитәкчесе артыннан иярде.

Флорид Әгъзамовичның адымнарыннан ук түрәлеге күренеп тора. Дәрәҗәсен белеп кенә баса. Берчә туктап калып, як-ягына карап куя. Аннан, сәхнәгә күтәрелгәндәй, житез адымнар белән башын горур күтәреп алга омтыла. Ә Зәбир аның көчеге кебек, авыр тартма күтәреп, арттан теркелде.

Ишек төбендә каршы алучы булмады, әмма Флорид Әгъзамович кәефен төшермәде, туп-туры башлыкның кабул итү бүлмәсенә юл алды.

– Ә-ә, килеп җиттегезме? – Кунакларны күргәч, сәркатип кыз урыныннан торды. – Юл арыткандыр, мөгаен?

Ягымлы тавыш ишеткәч, Флорид Әгъзамовичның эченә җылы йөгерде.

– Көн ничектер бозылды да китте, – дип, форсаттан файдаланып, зарланып куйды ул. – Әмма якын дусларга барыр өчен җил дә, яңгыр да комачауламый. Җилеп килеп җиттек, дисәң дә була.

Без башлыкның бүлмәсенә үтик әле дигәндәй, кулы белән ишеккә ымлап куйды.

– Гафу итегез, көтелмәгән хәл килеп чыкты, – сәркатип кыз акланырга тырышты. – Башлыкны бик мөһим эш буенча Уфага чакыртып алдылар...

– Менә сиңа мә! – Флорид Әгъзамовичның авызы очлаеп китте. – Без бит алдан килештек!

– Мин сезне аңлыйм. Әмма аны югарыдан чакырттылар. Шуннан сезгә хәбәр итим дип шалтыраттым, тик сәркатибегез алар күптән юлда, диде.

– Бәрәкәт! – Оешма җитәкчесе, ачуыннан, кулындагы папкасын шапылдатып, өстәлгә бәрде. – Ерак арага изаланып йөрисе генә түгел шул! Килешкәнчә берничә товарның төрен дә алып килгән идем. Сезнең районга хуҗалык өчен бик кирәкле әйбер ул, беләсегез килсә!

– Анысын беләм. Хакимият башлыгы договорыгызны һәм товарны калдырырга кушты. Борчылмагыз, ул мәсьәлә уңай хәл ителәчәк. Тик башлык үзе бүген булмый.

Флорид Әгъзамовичның барлык уй-нияте юкка чыкты. Район башлыгы белән гәпләшеп чәй эчәрләр, сер уртаклашырлар, дип уйлаган иде. Үзе белән алган коньякны да йотып алсалар, эшләре харап шәп китәчәгенә шик юк. Башлык үзендә куна калдырыр дип гөманлады ул. Менә сиңа мә!

Алар тартманы һәм килешү кәгазен калдырып, урамга чыкты. Оешма җитәкчесенең сөмсере коелган иде. Яшь белгеч алдында уңайсыз хәлгә калганы өчен оялды. Ичмасам, берәр чынаяк чәй эчерергә дә башлары җитмәде бит. Ә бу район үзәге булып торган касаба сиңа Уфа түгел – адым саен буфет юк.

Кәефсезләнеп, ашыгыч рәвештә кайтыр юлга чыктылар. Хәерчегә җил каршы дигәндәй, көн дә шәптән түгел. Җәяүле буран күзне ачарга да ирек бирми. Юлны көрт күмә дә куя. Тирә-як ап-ак. Ун чакрым үттеләрме-юкмы, шофёр машинаны туктатты:

– Мондый шартларда кире кайтып җиту мөмкин түгел!

Флорид Әгъзамович көрсенеп куйды:

– Бу якта туганнар да юк...

Зәбир берәр сүз әйтмәсме, дип уйлады үзенчә. Ә хезмәткәре үпкәсен һаман онытмаган иде. Җитәкчесенең әйткәненә кылы да селкенмәде аның.

– Зәбир, синең кайнәң шушы яктан бит. – Җитәкчесе, хәйләкәр генә елмаеп, артка борылды. – Әллә шунда гына куныйкмы? Бу тирәдә, ичмасам, кунакханә дә юк. Буранда кайтуы да куркыныч.

– Әллә... – «Сез бит әби-чәбигә кереп йөрергә вакыт юк, дигән идегез, ә хәзер үзегез инәләсез», дип тә өстәп әйтәсе килде, тик соңгы мәлдә генә телен тыйды.

– Юл хәлен белеп булмый шул, дустым. – Флорид Әгъзамовичның ялварулы мөрәҗәгать итүе ят тоелды. – Нишләтәсең инде, бу очракта син генә коткара аласың...

Җитәкчесенең үтенечен кире какмады Зәбир. Үзенең дә кайнәсен күрәсе килә бит.

– Әйдә, алай булгач, – диде, шофёрның терсәгенә төртеп. – Ничек барырга икәнен күрсәтермен. Ярты сәгатьлек юл...

***

Ике тәрәзәле бәләкәй генә йортның алдына килеп туктагач, Флорид Әгъзамович аптырап карап куйды:

– Кайнәң шушында яшәмидер...

– Шушында. – Зәбирнең тавышы көрәеп китте. – Килеп җиттек. Әйдәгез, керик.

Флорид Әгъзамович теләр-теләмәс кенә машинадан чыкты. Тавык кетәгедәй генә өйгә керергәме-юкмы дигәндәй, йөзен җыерды. Шушындый йортка керүдән дәрәҗәсе кимер кебек тоелды аңа.

Шулчак каршыларына фуфайка кигән әби йөгереп чыкты. Кунакларны күрү сөенече йөзендә балкый.

– О-о, кунаклар килгән икән, – дип, башта Зәбирне кочаклап, аркасыннан какты. – Кияү балакаем килеп төшкән!

– Саумы, кайнәм. Әйе, менә Таулы якларына эш буенча килдек. Шуннан синдә тукталып китәргә булдык.

– Бик якшы иткәнсез, ату ялгызыма күңелсез булып тора иде. – Әби читтән генә күзәтеп торган иргә исәнләшәм дип, ике кулын сузды. – Сез киявем белән бергә эшлисездер?

Машинада килгәннәр арасыннан иң дәрәҗәле кеше белән таныштырырга онытканына Зәбир кызарып куйды.

– Ә-ә, кайнәм, онытып торам. Таныш булыгыз: мин эшләгән оешманың җитәкчесе – Флорид Әгъзамович.

– Ә бу – минем шофёр. – Машина тәгәрмәченә тибеп, тикшереп йөргән ир белән җитәкче үзе таныштырды.

– Бик хуп, бик хуп. – Менә таныштык та дигәндәй, әби барысына да елмаюлы караш ташлады. – Әйдәгез, өшеп тормыйк, керик.

Галимә әби чыжлатып, чәй кайнатып җибәрде. Күпертеп пешергән калачын телде. Үзе язган маен, җиләк кайнатмасын өстәлгә куйды, матур гына чынаякларга сөтләп, чәй ясады. Чәй эчеп утырганда, кунаклар авылдагы тормыш белән кызыксынган булды. Әби бер дә зарланыр кешегә охшамаган. «Аллага шөкер», «рәхмәт төшкере», «булганына ризабыз», дип кенә җаваплап торды.

– Ә Сәлимә нигә сезнең белән кайтмады? – дип сорап куйды Галимә әби. Зәбир, нәрсә дип җавап бирергә белми, кырын гына җитәкчесенә карап куйды.

– Үзең беләсең бит, кайнәм, – нинди сәбәп табарга дип, Зәбир аптыраушта калды, – килер иде дә шул, эшенән җибәрмәделәр...

– И-и! Балакаемны күптән күргән юк шул. Сагындым кызымны.

Флорид Әгъзамович бер сүз дә дәшми, икмәккә май сылап ашый бирде. Өйдәге җиһазларга да күз йөгертеп ала. Бер тимер карават, бер урындык, өстәл һәм савыт-саба өчен киштә. Китаплар, төрле гәзит-журнал матур итеп тәрәзә төбенә тезеп куелган. «Дә-ә, бу карчык фәкыйрь яши икән», – дип, эчтән генә уйлады җитәкче.

Кунакларга чәй эчергәч, Галимә әби җәһәт кенә аш куеп җибәрде. Зәбир шофёр белән мунча ягарга чыгып китте. Ә Флорид Әгъзамович суык тиюдән куркып, урамга чыгып тормады.

Аралашуга сусаган әби кунак белән иркенләп сөйләште.

– Менә шулай, дустым, өч бала үстердем ялгызым, – диде, стенадагы фотоларга күрсәтеп. – Әнә, хәзер барысы да университет тәмамлады. Барысы да үз көннәрен үзләре күрә, әле дә ярый күз нурларым-балакайларым бар, Ходайның биргәненә шөкер...

– Шушы өйдә өч бала белән?!. – Флорид Әгъзамовичның гаҗәпләнүе чиксез иде.

– Сыйдык, дустым. Аллага шөкер, хәзер дә җәен кызларым кияүләр, балалар белән кайтса, унаудан ашып китәбез. Барыбызга да урын җитә.

Ишеткәненә ышанмый, кунак янә күз йөгертеп алды:

– Кызык икән. Монда бер кешегә дә тыгыз...

– Күңелең киң булса, урын табыла ул, ди торган иде борынгылар. – Халык мәкален әйтте дә әби хатирәләргә бирелеп китте. – Мин менә балаларыма да гел шулай дип талкып тордым. Беркайчан да кешегә ашны да, урынны да җәлләмәсеннәр. Күңеле киңнең урыны ожмахның түрендә була, диләр. Безнең авылдан тагы егерме чакрым

ераклыкта Мөхәммәт дигән авыл бар. Төпкел инде. Анда җүнле юл да юк, машинафәләне дә бик сирәк йөри. Әнә шул төпкелдән күпләр район үзәгендәге СПТУда укый. Ял булса, кайта алмый калалар. Безнең авылга тиклем әле килеп җитәләр, ә теге якка берни дә йөрми. Торалар, бахырлар, ике-өч бала юл буенда күшегеп. Әңгер төшә башлый. Аларның монда кунар кешесе дә юк. Менә мин шул балаларны үземә алып кайта идем. Тамакларын туйдырып, йоклатып чыгарам. Шушы гадәтемне балаларыма да сеңдердем.

Теге тимер караваттагы төрле төстәге түшәкләрне күргәч, Флорид Әгъзамович түзмичә, барып, тотып карады:

– Үзегез ясадыгызмы, апай?

– Юк. Сәлимәмнең куллары алтын. Бу – аның яраткан караваты. – Кызының уңганлыгы белән горурланып, аның кул эшләрен күрсәтә башлады. – Менә шул юргандагы тышлыкны да үзе бизәде, ястыкны да Сәлимәм каз мамыгыннан үзе ясады. Авылга кайтса, гел шушы караватта йоклый.

Кунаклар мунчадан чыгуга, Галимә әбинең ашы пешеп өлгергән иде. Өйгә тәмле ис таралды. Тегеләр, бераз суынып алгач, өстәл янына утырды. Әби аш салды, корт куйды. Шунда мич артыннан шешәсен дә тартып чыгарды.

– Утын ярдырыр өчен алган идем, – дигән булды, акланып. – Хәзер шунсыз эшләмиләр бит. «Инәй, шул бармы, хәл юк», – дип сораналар.

Зәбир шешәнең бөкесен каерып ачты, барысына да тигезләп салып чыкты. Әби генә тотмады.

– Танышу хөрмәтенә, – дип тост әйтте Флорид Әгъзамович һәм «гөлт» итеп чәркәне күтәреп тә куйды.

Сала белмисең дип, савытны җитәкче кеше үз кулына алды. Тутырганчы салды. Янә тост яңгырады. Кызмача булып алгач, Флорид Әгъзамовичның күңеле күтәрелеп китте, аягүрә басып җыр сузып җибәрде:

Кайда гына барма дус-иш кирәк,
Каршы чыгып атың бәйләргә...

* * *

...Эт өрүгә Галимә әби дертләп уянып китте. Кунаклар рәхәтләнеп йоклый. Берсе дә тышка чыкмаган. Кем йөри икән төн уртасында? Менә берәү ишек алдына килеп басты. Нык итеп шакуы ишетелде. Әби чолангагы утны кабызды. Фуфайкасын гына элэктерде дә тышка омтылды.

– Кем йөри анда?

– Әни, мин!..

Ишекне ачып җибәрсә, дер калтырап, Сәлимәсе тора. Кызы тизрәк җылыга керде. Күчтәнәч тулы сумкаларын идәнгә куйды да, кулларын җылытырга тырышып, мичкә терәде.

– Ир, имеш! – Бозланып беткән чәчен сыйпап куйды Сәлимә. – Ичмасам, мине яклап бер сүз әйтсәче. Мәмәй!..

Галимә әби, эш нидә икәнен аңларга тырышып, төпчендe:

– Тынычлан, балакаем, нәрсә булды?

– Әй, болай гына әйтәм... – Сәлимә кулын селтәде. – Ярый әле, яхшы кешеләр очрады. Авылга тиклем илтеп куйдылар.

Галимә әби берни дә аңламады. Ахырдан:

– Шымрак бул, балам, кунакларны уятасың, – диде.

Сәлимә сискәнеп китте:

– Нинди кунаклар?

Мич өйне уртага бүлеп торганга күрә, керү белән теге якны күреп булмый. Сәлимә башта беркемне дә шәйләмәде.

– Әнә! – Кулы белән ишарәләде әнисе. Түргә үткән иде – «аһ» итте. Аның яраткан караватында бер гаепсез сабый кебек мыш-мыш килеп, Флорид Әгъзамович йоклап ята. Сәлимәнең ястыгына башын салган, аның юрганына уранган.

Сәлимә сак кына адымнар белән түргә үтте дә идәндә яткан Зәбиренең юрганын рәтләп ябып куйды...

*Башкортчадан* **Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ** *тәрҗемәсе.*



Рәмзия Әхмәтова 1953 елда Актаныш районы Уразай авылында туа.

Минзәлә педагогия училищесын, Казан дәүләт университетының география факультетын тәмамлый. Туган районындагы Яңа Әлем, Такталачык мәктәпләрендә рус теле, география фәннәрен укыта. Хәзерге вакытта лаеклы ялда.

2005 елда «Күңелем бизәкләре» исемле шигырь җыентыгы басылып чыга.

Рәмзия
Әхмәтова

# МИН КӨТӘМ ДӘ... ГОМЕР АШЫГА...

## Республикам

Татарстан – бөек татар иле,
Кол Гали, Тукайлар ватаны,
Чал тарихның туфрагыннан калка
Буыннардан күчкән хөр даның.

Урман-суга бай син, җирең – алтын,
Зур байлыгың – хезмәт кешесе.
Тыныч тормыш корган бар халкыңның
Бердәмлеге белән син көчле.

Дуслык җырын җырлый, сине зурлый
Һәр милләтең туган телендә.
Хезмәт юлы – казанышлар юлы,
Сабантуйның туган илендә.

Республикам, сине дөнья таный,
Имин еллар – изге теләгең.
Син – халкыңның күңел горурлыгы,
Ышанычы, бәхет терәге.

## Халык улы

Гасыр аша Тукай моңын
Тыңлыймын горурланып.
Шигъриятле киң мәйданда
Ул һәрчак горур Алып.

Җиңгән бәхетсез язмышын
Халкымның җырчы улы.
Күп гасырларга тиңләшә
Мизгелдәй гомер юлы.

Тукай сүзе хакыйкатькә,
Халык хыялына бай.
Тукай күңел күгебездә
Көндез – кояш, төнен – ай.

Шигърияттнең зур сереннән
Илаһи фикер үргән.
Киләчәктә милләтенең
Якты язмышын күргән.

Кыю, үткен теле белән
Елатып көлә алган.
Милли җанлы һәр күңелгә
Шигырьдән һәйкәл салган.

Онытмас халык, югалтмас
Шигъри моң сеңгән телен:
Йөрәк түрендә сакласа
Тукайның шигырь илен.

## Җаным эзли шигъри тылсым

Җаным эзли шигъри тылсым,
Күңел бушансын өчен.
Уй уйнаклый, фикер таркау –
Тапмыйм йомгакның очын.

Күңел тулган шигъри моңга,
Сүзләр эзлим тәңгәлен:
Ачып булмый сусау җанның
Илаһи хисле мәлен.

Халәтемне аңлатырга
Көче җитми каламы? –
Югала да куя шигъри
Күңелемнең каләме!

Сихерләгән шигърияттнең
Мин бит колы. Ә ул – хан.
Күңелемә түгелергә
Тел ачкычы бир, илһам!

## Иң кыска көн

Төннең зур кара пәрдәсе
Көн күзен япты кебек.
Елның иң кыска көне! – Тик
Күңелдә якты өмет.

Йолдыз булып балкый өмет,
Хыял канаты куйсаң,
Озын, салкын төннәр аша
Язның сулышын тойсаң.

Ни өчен җанны җылыта
Нурларга саран бу көн? –
Чиксез галәмдә туган җир
Язына атлый бүген.

Җир борыладыр Кояшка
Җылы, наз тату өчен;
Яшәртә Җирне, кешене
Мәңгелек тарту көче.

## Туган җир

Сагындырып төшкә керә
Җанга газиз туган җир,

Җирсеп кайткан һәр баласын
Сыендыра торган җир.
        Күпләр читтән бәхет эзләп,
        Туган капкасын япты.
        Кендек каным тамган җирдә
        Бәхетем эзләп тапты.
Киткәннәрнең сызып-сызып,
Җанын сагыш телгәндә,
Тыңлыйм былбыл моңын изрәп,
Таң сызылып килгәндә.
        Нинди рәхәт таң нурлары
        Күзләреңнән үпкәндә,
        Туган якның назлы җиле
        Чәчтән сыйпап үткәндә.
Аңкып тора алма исе
Һавасыннан көзләрен.
Акка күмә күңелемне
Кышның бәсле күзләре.
        Болын-кырның һәр чәчәге –
        Балачак танышларым.
        Башын иеп каршы ала
        Бәкилдем камышлары.
Туган җирдән аерылмады
Йөрәгем дә... Үзем дә.
Аның яме – җаннарымда,
Гаме – әйтер сүземдә.

## Моң

Мөлдерәмә өмет йолдыз кебек
Күңел күгебездә сүнгәндә,
Сөю тулган серләр балкыш булып,
Киек каз юлына сеңгәндә,

Бездән ялгыз калган язмышларны
Яшен кебек сагыш телгәндә,
Күктән моңнар иңәр, хәтер булып,
Ялкынланып янган төннәрдән.

Тамырларга, карашларга сеңеп,
Югалтулар булып сулкылдар.
Үзәк өзгеч моңнан үрелер дә
Җанны сихерләрләр шул кыллар.

Ятим калган хисләр иңрәгәндә,
Әрнү җанга булса җиһан тар,
Әле ярый яралардан саркып,
Шигырьләргә күчәр шул моң бар.

Мәңгелекнең сагышыннан саркып,
Күңелләргә иңәр шул моң бар.



Фәтхулла
Абдуллин

# ГЕРМАН ҖИРЕНДӘ МӘТРҮШКӘЛӘР ҮСМИ

хикәя

Мин мәктәпкә барганда да, эштән кайтканда да төзелә торган тугыз катлы йорт яныннан үтеп йөрим. Вакыт булганда, каравылчы, сугыш ветераны бабайның хәлен белеп чыгам. Аның бер гадәте бар. Тәмләп сөйләшергә исәбе булса, тәмәке көйрәтергә ярата. Бүген аның шундый халәте иде бугай, эчке кесәсеннән тәмәке алырга дип, телогрейка төймәләрен ычкындырды. Шулчак аның түшендәге ордены ялтырап китте.

– Нихәл, улым! – дип сүз башлады ул.

– Әйбәт кенә, Миңсалих бабай, үзең саумы?

– Аллага шөкер, Гомәр энем!

– Кызыл Йолдыз ордены?! Әле сезнең мондый бүләкләрегез дә бармыни, Миңсалих бабай?

Орден турында сүз чыккач, шуны гына көтеп торгандай, ул җанланып китте, тимер тешләрен елтыратып елмайды, хәтта баскан урынында таптанып алды.

– Әйе, ике көн элек кенә военкоматка чакырып бирделәр. Повестка килгәч, кай җирем кирәк булды икән, дим. Дөрес, сугыш ветераннарын онытмыйлар анысы. Бигрәк тә Җиңү көне алдыннан махсус чакырып рәхмәт әйтәләр, бүләкләр бирәләр. Әле бу арада гына бернинди бәйрәм дә юк, сәйран да юк. Нигә чакырдылар икән дип баш ваттым шуңа. Кердем. Полковник үзе аяк өсте басып каршы алды. Йомшак урындыкка утыртты. Хәл-әхвәлемне сорашты. Сугышта кайда булганымны сөйләтте. Ә сугышның без инде кайнап торган казанында булдык. Башта Сталинград, аннан килеп, Курск дугасына эләктем. Сугыш кан кою инде ул, кайда да җиңел булмагандыр. Әмма Курск дугасында җир белән күкнең чиге югалды, тирә-як тоташ мәхшәргә әйләнде. Утлы дуга гына булмады, җәһәннәм дугасы булды ул немецлар өчен дә, безнең өчен дә. Ул чорда кем санаган да, кем очына чыккан: безнең югалтулар күбрәк тә булгандыр әле. Һөҗүм итеп барганда күрдек инде сафтан чыккан немец танкларына караганда, «сәҗдә»гә киткән үзебезнең танклар күбрәк очрады.

Менә шундый мәхшәр көннәрнең берсендә, без өч кеше дошман тылына разведкага барырга задание алдык. Өчебезне дә рядовой итеп киендерделәр. Андый-мондый хәл булса (әсирлеккә эләгүең дә бар!), командирларын югалтып адашкан төркем генә булабыз инде, янәсе.

Мең бәла белән фронт сызыгын үттек. Хәвеф-хәтәрсез генә урман эчендә таң аттырдык. Беренче эш итеп, безгә ничек тә немецларның штабын табарга кирәк. Әйтүе генә ансат. Көпә-көндез кукраеп йөрергә без кияү егетләре түгел. Немецлар күреп алса, өч кешелек төркемне юк итү берни дә түгел.

– Әкрам, син безнең арада иң елгыры, бар, агач башына менеп карале, авылдагы берәр йортның кыегына эленгән немец флагы күренмиме? – дип Әкрамга куштым.

Немец флагларын штаб урнашкан йортның ишек өстенә генә элгәннәр икән. Чигенгәндә суырып алырга җайлы булсын дигәннәрдер инде. Йорттан ерак түгел сарай сыман нәрсәсе дә бар. Салкыннан калтырана-калтырана төне буе керфек тә какмый чыктык, әмма берни дә майтара алмадык. Гитлерчыларның әллә берәр офицерлары килгән көн булды, әллә берәр этлек эшләргә җыеналар иде, төне буе штаб тирәсендә тыз-быз йөреп чыктылар. Задание үтәмичә, сөмсере коелган сабый кебек кайтып булмый инде.

– Егетләр, катгый бер карарга килеп, штабка үтеп, документларын кулга төшерми кайтмыйбыз! Бетте-китте! – дидем.

Урман эчендә нинди сарай булгандыр ул, шайтан белсен. Сугыш афәте, туплар зилзиләсе аны да читләтеп үтмәгән, снаряд төшеп түбәсен алып ыргыткан, стеналарын тишкәләп бетергән. Исән калган бер почмагына кереп сыендык. Ике көн йокламау шактый йончыткан, берничә минуттан солдатларым изрәп йокыга киттеләр. Мин уяу. Якындагы сазлыкта бакалар бакылдаша. Нindидер кошлар, үзләре генә белгән телдә нәрсә турындадыр «серләшә»: чурр-чурр килә... Сугыш өчен гадәти булмаган тыныч төн. Югарыда, биектә-биектә йолдызлар җемелдәшә. Их, рәхәттер дә аларга күк йөзен иңләп-буйлап йөзүләре!..

Штаб тирәсендә тыныч кебек. Кичәге шикелле тыз-быз йөрүчеләр күренми. Шулай да ишек төбендәге баскычта муенына автомат аскан немец солдаты кукраеп басып тора. Тонык кына лампочка яктысында аның күләгәсе күңелгә шом салып үзеннән ике мәртәбә зуррак булып күренә.

Штабка керү өчен безгә ничек тә аннан котылырга кирәк. Бу хәтәр эшне тавыш-тынсыз гына башкару мәслихәт. Юкса, исән калуыбыз икеле. Бу үтә дә җаваплы бурычны егетләрнең кайсына тапшырырга? Егоргамы? Әкрамгамы? Икесе дә ут уйната торган егетләр! Әнә бит, кичә Әкрам ым кагу белән агач башына мәче кебек үрмәләде. Ни булса шул: Әкрамның колагына пышылдап кына тәвәккәлләргә әмер бирәм. Ул ялангач хәнҗәрен кулына кысып, түше белән шуыша-шуыша өй почмагына җитә язган иде инде. Берзаман сакчы баскычтан төшеп, Әкрам шуышкан почмакка килә башлады. Сизендеме әллә бу явыз дип, тын алырга да куркып торабыз. Менә ул почмакка килеп басты... Һәм Әкрам аңа һөҗүм итте.

Шыпырт кына эчкә үттек. Уртада өстәл. Анда телефон аппаратлары. Йокы үз эшен эшләгән, өстәлгә башын салып, немец офицеры гырылдый. Икебез ике ягына басып «дусларча» гына төрткәләп аны уятабыз. Уянгач, янәшәсендә таныш түгел кешеләрне күрүгә, офицерның куллары үзеннән-үзе пистолет кобурасына үрелде. Әмма берничә секундтан куллары артка каерып бәйләнгән немец чүпрәк чәйнәп, идәндә ята иде инде.

Без төргәге-төргәге белән карталар, документлар һәм өстәвенә тере немец офицерын да үзебез белән алып, тизрәк моннан шылу ягын карыйбыз.

Ниһаять, без кайтыр юлда! Караңгы, күзеңә китереп төртсәләр дә, берни күренмәслек көзге төн. Чама белән генә барабыз да барабыз. Ә яңгыр коя гына.

Өс киемнәребез соңгы җебенә кадәр лычма су. Никадәр генә сакланып атларга тырышсак та, аяклар «лык!» итеп йә иңкү җиргә төшеп китә, йә түмгәккә абына. Шулай абына-сөртенә барабыз да барабыз. Бераздан шикләндерә башлады. Дөрес юлдан кайтабызмы? Уйлавыбызча, без урманга җитәргә тиеш идек инде. Ә ул һаман юк та юк.

Таң атуга, бер аяныч хәлне абайладык. Көнчыгышка барабыз дип, төнге караңгылыкта көньякка таба киткәнбез. Без әле һаман дошман басып алган җирдә, ә урман безнең сул якта калган! Ул инде еракта, офыкта гына шәйләнә. Кояш нурларын сипкәнче берничек тә барып җитәрлек түгел. Яктыда хәрәкәт итеп тә булмый. Күреп алсалар, эш харап! Ныклап яктырганчы хәвефсезрәк, аулаграк урын карап туктарга булдык. Хәвефсез дип сайлаган урыныбыз да шул ничарадан бичара гына. Уйсулыктагы түмгәкләргә, куе булып үскән камышларга ышыкланып ятабыз. Ярый әле штабтан немец офицерын гына түгел, ипи белән консервалар алырга баш җиткән. Тын. Һәркем үз уена чумган. Сизеп торам, егетләр дә борчыла. Бер тәүлектә әйләнеп кайтырга тиеш солдатлар дүртенче көнебезне дошман тылында үткәрәбез.

Әсир немецны карарга беркетелгән Әкрам кинәттән генә зарлана башлады:

– Ничу бу Мәккә кяфере белән интегергә. Дөмектерергә дә китәргә. Монда үзебезнең җан кадерлерәк. Өч яшьлек сабыймыни? Аның ыштанын төшер, ыштанын күтәр...

– Мәккә кяфере түгел, Берлин кяфере бит ул. Безнең бурыч – аны исән-сау алып кайтып тапшыру, – дим.

– Ә тапшыра алмасак? Немецлар безне эләктереп алсалар, нишлибез?

– Соң, эләкмәскә тырышып ятабыз бит инде.

– Бездән алда киткән разведчиклар да эзсез югалды. Үле гәүдәләре дә табылмады, – дип, күңелгә шом сала Әкрам.

Мин берара ни әйтергә белми сүзсез калам. Шулай да бераздан фикерләремне туплап:

– Ил азатлыгы өчен барган сугышта корбаннарсыз булмый, – дип, үземчә нәтиҗә ясыйм.

– Сез теләсәгез нишләгез, немецлар чолганышында калсак, мин коралымны ташлыйм да кулымны күтәрәм, – диде кинәт Әкрам.

– Ә мин синең арт чүмечеңә пуля җибәрәм. Ватан, ул бер генә! Аңлыйсыңмы, Әкрам, Ватан, ил – ул газиз Ана кебек бер генә! Аны сатып та, сатып алып та булмый. Ярамый. Әллә син Герман җирендә безне бәлеш пешереп көтеп торалар, дисеңме? Без анда килмешәкләр генә булабыз. Ни дисәң дә, безнең бит әле кайтып, борын төртер җиребез – ата-баба яшәгән илебез бар!

Мин тагын өстәп ни әйтергә белми, Әкрам ни уйларга белми, берара икебез дә тынып калабыз.

– Миңсалих, син, ни... безнең арадагы сүзне оныт инде, яме? Ни күрсәк тә бергә күрербез.

– Ә син, Әкрам, борчылма! Боларның берсе рус, икенчесе немец. Татарча исәнләшә дә белмиләр. Безнең сөйләшкән ике арада гына калыр. Борчылма!

***

...Минем тизрәк вакыйганың ахырын ишетәсем килә.

– Ә сез, Миңсалих бабай, үзебезнекеләр ягына ничек исән-сау чыга алдыгыз соң? – дим.

– Ә-ә, әйе. Хәзер...

Ул сагызы чыгып торган нарат такталарга карап алды да будкасына кереп китте. Мин разведчик карт тагын нинди сюрприз күрсәтмәкче икән дип, уйлап алдым. Ул анда озак тормады: термос белән чәй алып чыкты.

– Картлык галәмәтедер инде, авыз кипте. Әйдә, иң әүвәл сусынны басып алыйк әле.

Һәм без хуш исле мәтрүшкә чәе эчә-эчә әңгәмәбезне дәвам иттек. Аның хуш исе борынны ярып, сулышларымны киңәйтеп җибәрде.

– Карале, Миңсалих бабай, син сугышта булган, байтак җирләрне күргән кеше. Герман җирендә мәтрүшкәләр үсәме ул?

Сугыш ветераны бер мәлгә тынып калды. Бераздан:

– Юк! Очратмадым! – диде ул, ныклы карарга килеп. – Мәтрүшкә безнең илебездә, татарлар яшәгән җирдә генә үсә ул! Герман җирендә мәтрүшкәләр үсми.

– Ә теге әсир фашист белән кайтып җитә алдыгызмы соң?

– Фронт сызыгын үтәсе генә калды. Әмма таң алдыннан көтмәгәндә, җир белән күкне бер итәрдәй мәхшәр ясап, артиллерия канонадасы башланды. Аңарга самолётлар, танклар гөрелтесе кушылды. Туплар ярылган саен, урман йөрәк өзгеч тавыш белән ахылдап куя. Барыбыз да аяк өстендә, йокы качты. Ике арада аяусыз бәрелеш башланганын сизеп торабыз. Хәлиткеч минутларда иптәшләр арасында була алмавыбыз гына үкенеч. Дошман тылында булсак та, эчкә җан керде. Хәзер инде пышылдап кына түгел, курыкмыйча, кычкырып сөйләшәбез. Үзебезнекеләргә без көн кичкә авышкач кына барып эләктек. Анда да башка частьныкыларга. Совет солдатларын күргәч, егетләрем урманнан йөгереп чыкмакчылар иде, туктаттым:

– Ашыккан ашка пешкән. Араларында таныш солдатлар юк икәнен күрмисезмени? Ничек кабул итәселәрен белгән юк. Башта мин үзем генә күреним. Сез әнә теге куаклар артына яшеренеп торыгыз. Мин сигнал биргәч кенә чыгарсыз.

Чыннан да яшь кенә бер совет лейтенанты пароль сорап, теңкәмә тиде. Мин үзебезнең парольне әйтәм:

– Дөрес түгел! Совет формасы кигән сатлыкҗандыр син! – ди. Кызулык белән мине сугып та екты.

– Самосуд ясарга хакың юк. Сезнең алдыгызда совет сержанты, разведчик Нуриев басып тора!

– Докажи! – ди лейтенант, һаман кыдрачланып.

– Сейчас докажу, мәйтәм. – Шуннан соң посып калган егетләргә сызгырдым. Куллары бәйләнгән немец офицерын күргәч, күзе маңгаена менде лейтенантның.

Кайткач, рота командирыбыз:

– Молодец, Нуриев, егет икәнсең. Сине обязательно бүләккә тәкъдим итәрбез, – дигән иде.


Шуннан соң күп тә үтмәде, сул кулым яраланып, госпитальгә кердем. Савыккач, бөтенләй икенче фронтка эләктем. Сугыша-сугыша илебезне, Варшаваны дошман яуларыннан азат иттек. Гитлерчыларның өненә дә күп калмаган иде инде. Фашист ядрәсе шул сул кулга каныкты бит. Бу юлы снаряд кыйпылчыгы аны терсәктән өзеп алып китте.

Ә безнең рота командирыбыз сөйләнеп кенә калмаган, чыннан да, бүләккә тәкъдим иткән икән. Менә, ничә дистә елдан соң булса да, китереп бирделәр... Онытмаганнар...

# «БЕЗ – АВЫЛ БАЛАЛАРЫ...»

## ТУФАН МИҢНУЛЛИН ТУРЫНДА МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ

**– Минтимер Шәрипович, Сез Туфан Миңнуллин белән яшьтәшләр үк булмасагыз да, замандашлар дип әйтик: республикабыз өчен хәлиткеч тарихи вакыйгалар эчендә бергә кайнаган, гомумән, янәшә атлап барган кешеләр. Өстәвенә, Сез – әдәбият-сәнгать, театр сөюче кеше. Әйтегез әле, күңелегезгә кайсы Туфан якынрак: язучы, драматургмы яисә депутат, җәмәгать эшлеклесеме?**



*«Без фикер уртаклыгына якын идек...»*

– Мин иң элек аны халкыбызның иң булган, иң лаеклы улларының берсе дип саныйм. 2005 елның ноябрендә, Камал театры сәхнәсендә аның 70 еллык юбилей бәйрәме вакытында, республикабызның иң югары бүләген – «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен» орденын тапшырганда, нәкъ шушы сүзләрне үзенә дә әйттем. Мин аны төрле чалымнардан торган бербөтен шәхес итеп кабул итәм. Минем уйлавымча, аны Ходай бу дөньяга татар халкының яклаучысы, аның телен, моңын, җанын саклаучы итеп яраткан. Халык күңеленең гел чыңлап торган сизгер бер кылы дип әйтер идем хәтта. Үзе сайлаган шушы юлдан – халыкка хезмәт юлыннан баруының әмәлләре генә төрле иде: каләм, театр сәхнәсе, депутат трибунасы... Әйе, янәшәбездә тере классик яшәде. Аңа Туфан исеме дә очраклы бирелмәгән дигән фикер белән килешәм. Зур шәхес. Көчле шәхес. Һәм аның туфанына түзәргә дә кирәк иде. Чөнки бу давыл безне сискәндерер өчен, яшәешнең без күрә белмәгән якларын ачар өчен куба иде ләбаса. Белүемчә, ул ниндидер мактаулы исемнәргә, титулларга каршы иде. Кешенең исеме яхшы эшләре аша мәгълүм булса, аңа өстәп яңгыравык исемнәр тагу кирәкми, ди иде. Дан-дәрәҗәгә мөнәсәбәтен дә хәтерлим. Үзе турында бер фильмда ул болай дигән иде: «Югары дәрәҗәгә ирешү – бүтәннәргә яхшылык эшләү мөмкинлеге арту». Дөрес бит. Һәм ул үзе – моның үрнәге. Иманым камил, үзен татар дип санаган бер генә кеше дә Туфан Миңнуллин кем ул, дип сорамас.

**– Сез аның белән танышу мизгелен хәтерлисездер?**

– Шәхсән ничек танышып киткәнне, мөгаен, төгәл генә әйтә алмам. Чөнки Туфан Миңнуллинны мин тормышта сирәк очрый торган шундый шәхесләр исәбенә кертәм – алар янәшәбездә һәрвакыт булган, һәрвакыт бар һәм һәрвакыт булыр кебек

тоела... Ә инде чын иҗат кешесенең, бигрәк тә язучының үзеннән алдан әсәрләре йөри, бу – табигый хәл. Шуңа күрә иҗаты белән якыннан танышлыгым 1960 нчы еллар башында, Минзәлә театрыннан башланды, дисәм, ялгыш булмас. Мөслимнән Минзәләгә, «Сельхозтехника» районара берләшмәсе җитәкчесе булып күчкәч, әз-мәз буш вакыт булганда, театрга йөри идек. Анда «Безнең авыл кешеләре» дигән кызык спектакль караганыбыз исемдә. Инде Казанда яши башлагач, 70-нче елларда, Камал театры сәхнәсенә, кояш шикелле, «Әлдермештән Әлмәндәр» балкып чыкканы хәтеремә сеңеп калган. Мин бу спектакльне үз гомеремдә берничә кат карадым, караган саен мәгънәсенә тирәнрәк төшенә бардым. Ә инде Камал театрына премьераларга йөрү гадәтемә кергәч, аның пьесалары буенча спектакльләрнең барысын да карадым диярлек, чөнки премьераларның күбесе аныкы иде. Шул рәвешчә, театрның баш режиссёры Марсель Сәлимҗанов белән Туфан Миңнуллинның иҗади берлегеннән туган шедеврларны беренчеләрдән булып карау бәхете тиде безгә. Ул заманнарны сагынып искә алам. Сәкинә ханым белән премьерага килүебез театр халкыннан бигрәк үзебез өчен зур вакыйга иде. Гадәттә безне Марсель белән Туфан каршы ала, хәл-әхвәл сорашабыз, театр проблемалары турында сөйләшәбез, әмма яңа спектакль турында ләм-мим. Бусы да махсус эшләнә, интрига саклый болар. Безне шулай берни дә аңлатмыйча, әзерлексез хәлдә спектакль кочагына ташлыйлар. Тәнәфестә дә бу хакта сүз куермый – спектакльнең ахыры көтелә. Пәрдә ябылган мизгелдә туган хис-тәэсирләребезне күрү, тәүге фикерләребезне ишетү кадерле иде аларга. Фикер алышу кайчак төн урталарына кадәр сузыла...

Туфан пьесалары безне, тамашачыларны, һич көтелмәгән, ләкин бик тормышчан вазгыять эченә тартып кертә, уйланырга, хәтта үзеңдә нидер үзгәртергә мәҗбүр итә, иң мөһиме – яхшылыкка өметне сүндерми. «Диләфрүзгә дүрт кияү», «Монда тудык, монда үстек», «Моңлы бер җыр», «Әниләр һәм бәбиләр», «Илгизәр + Вера», «Хушыгыз», «Шулай булды шул», «Җанкисәккәем», «Гөргөри кияүләре», «Мулла» – әлеге камил сәнгать әсәрләрендә халкыбыз яшәешенең асылы – көчле, күтәренке рух чагыла. Мин Туфан геройларының җыелма образы итеп, Әлмәндәр картны саныйм. Безнең халык Әлмәндәр кебек булганга күрә яшәүчән, өметле һәм зирәк. Туфан безнең күңелләргә шуны сеңдерергә омтылды.

**– 1989-1991 елларда Сез дә, Туфан Миңнуллин да СССР Халык депутатлары идегез...**

– Әйе, Мәскәүгә съездларга бергә йөрдек, еш кына янәшә утыра идек. Хәтерләсәгез, ул заманда СССР халык депутатлары съездлары гаять актив уза иде, чөнки сайлаулар альтернатив нигездә үткәрелде, депутатлар арасында демократия, ирек рухы ургылып тора. Съездлар телевидение аша турыдан-туры трансляцияләнә. Утырышлар залы шаулый, тәртип юк, барысы да үз сүзен әйтеп калырга ашкына, трибунага чәчрәп чыгып, кайнарланып чыгыш ясыйлар, кем кул чаба, кем сызгыра, кем кычкыра... Туфан белән без шул тамашаның эчендә утырабыз. Мин аннан: «Сез хәзер шундый кызыклы вакыйгаларның шаһиты, Казанга кайткач, бу турыда язып чыгарга җыенасызмы?» – дип сорадым. Ул болай дип җавап бирде: «Юк, язмыйм, карап утырам. Шул моментта ук язып булмый. Һәм кирәкми дә. Билгеле бер вакыт узарга тиеш, уйланырга кирәк. Шулай да әз-мәз төрткәләп барам, кирәге чыгуы бар...»

Нәкъ менә шул елларда, шул чактагы вазгыять турында искиткеч бер тасвирлама әйткән иде Туфан. Республика кайный, матбугатта республика җитәкчелеген кинәнеп тәнкыйть итәләр. Журналистлар да, журналист булмаганнар каләмгә тотынды, вакыйгаларны теләгәнчә шәрехлиләр, теләгәнчә фараз итәләр, теләгәнчә гаеплиләр... Туфан Миңнуллин очрашуларның берсендә, зур трибунадан болай диде: «Авылда яз җиткәч, карлар эрегәч, кышын туып, гел абзарда яки өйдә яткан яшь бозауны беренче тапкыр аланга чыгаралар. Ул якты дөньяны күреп шакката: күзен тондырып

чаба, сикергәли, тибенә, сөзешә, кыскасы – нишләгәнен белми. Матбугат әһелләре дә хәзер үзләрен нәкъ шулай тоталар». Искиткеч төгәл билгеләмә. Мин аны үземнең интервьюларымда еш кулланам.

**– Туфан Миңнуллинны депутат буларак ничек бәяләр идегез?**

– Аның һәрчак үз фикере бар, ул аны кыю белдерә, нигезли һәм яклый белә иде. Әмма күтәрелеп бәрелми, җае белән әйтә. Үз сүзеңне әсәрләр, матбугаттагы язмалар аша җиткерү – ул бер хәл, ә менә депутат трибунасыннан аның кебек оста файдалана белү – бөтенләй башка талант бит ул. Ул – гаделлек яклы, тынгысыз кеше, һәрнәрсәдән хәбәрдар, бернәрсәгә дә битараф түгел, борчыла, трибунага чыгып сөйләгәндә, акылына йөрәге дә кушылып китә. Ләкин ул бервакытта да республика җитәкчеләренә тота-каба гаеп ташламады. Бик борчылып, «давылланып» йөрсә дә, безнең белән аңлашу юлларын тапты, фикер алышты, кешелек чикләрен узмады, безнең эшләргә тап төшерергә ашыкмады. Сүз дә юк, аның тәнкыйте көчле, әмма ул теләктәш тәнкыйть иде.

**– Аның фикере җитәкчелек фикеренә еш кына туры килми иде. Сүзгә килгән чаклар да булгандыр, бәлки...**

– Фикерләр төрлелеге әле ул ачуланышыр, дошманлашыр өчен сәбәп түгел. Чөнки Туфан белән икебез дә – авыл балалары, шуңа күрә дөньяны һәм тормышны күзаллавыбыз, аңлавыбыз, кабул итүебез охшаш. Ул, мәсәлән, авылда үскән кеше табигатькә, матурлыкка якын тора, аның күңеленә матурлык бала чактан ук күбрәк сеңә, кеше җиргә якынрак булырга тиеш дип саный иде. Мин үзем дә шундый фикердә. Авыл баласын җир, табигать тәрбияли, хезмәткә өйрәтә, күптөрле сәләтләрен үстерә. Һәм без беркайчан да үзебезнең авыл балалары булуыбызны яшермәдек, моның белән горурландык һәм горурланабыз. Туфан тумышым белән дә, уйлавым белән дә мин – авыл кешесе дип әйтә торган иде. Шушы табигый, авыл акылы белән ул теләсә нинди мәсьәләнең сәяси хикмәтенә бик тиз төшенеп ала. Бер генә мисал китерәм. ТР Дәүләт Советының 2005 елның февралендә узган сессиясендә, республика җитәкчеләрен сайлап кую урынына үзәк хакимият тарафыннан вәкаләтләр бирү тәртибе кертелгәндә, Туфан Миңнуллин моны бик каты тәнкыйтьләп чыгыш ясады. Тәнкыйте нигезле иде, әмма законга төзәтмәләрнең барыбер кертеләсен дә аңлый иде ул, чөнки бу вазгыятьтә үзәк хакимияткә каршылык күрсәтү республика өчен кулай түгел иде. Шуңа да карамастан, ул чыгыш ясап, искәртеп куюны кирәк тапты. Мин үзем дә республика, край, өлкә җитәкчеләренең сайланып куелырга тиешлеге фикереннән беркайчан да кайтмадым, законны үзгәрткәннән соң да бу турыда ачыктан-ачык әйтә килдем. Һәм вакыт моның хаклыгын үзе раслады: күрәсез, җиде елдан соң төбәк җитәкчеләрен сайлап кую тәртибе яңадан кертелде. Моның белән тагын шуны әйтәсем килә: Туфан Миңнуллинны күпләр татар халкы мәнфәгатьләрен генә кайгыртучы депутат дип беләләр. Әлбәттә, ул милләт язмышына, татар теленә кагылган бар нәрсәне игътибар үзәгендә тотты. Ләкин ул гомум әһәмияткә ия мәсьәләләргә дә бик сизгер иде. Аның 1995 елдан башлап, барлык дүрт чакырылышка да депутат булып сайлануы моның ачык дәлиле. Сөйли торгач, шунысы исемә төште – бервакыт, чираттагы сайлаулар алдыннан ул безгә: «Кабат сайланырга кирәк микән миңа, мин бит четерекле депутат, гел әйтеп-төртеп торам, түзә алмыйм», – дигән иде. Сездән башка булмый, хәлиткеч карарлар кабул иткәндә, ялгышуыбыз мөмкин, дип тынычландырдык үзен һәм дөресе дә шул иде.

**– Димәк, аның актив сәяси-иҗтимагый эшчәнлеге шәхси мөнәсәбәтләргә зыян китермәде?**

– Без аның белән һәрчак дустанә мөнәсәбәттә идек. Соңгы елларда, мин Президент вазифасыннан киткәч тә, сессия тәнәфесләрендә минем янга килеп исәнләшмичә,

сөйләшмичә китми иде ул. Гомумән, без бер-беребезне тигез күреп, үзара ихтирам итеп аралаштык. Минемчә, без фикер уртаклыгына гаять якын идек.

2011 елның март аенда ул минем янга махсус килде. Без ике сәгатьләп иркенләп сөйләшеп утырдык. Бик күп мәсьәләләргә кагылдык. Минем янга, гадәттә, нindидер гозер белән яисә киңәш-табыш итәргә керәләр. Ә ул болай гына килгән булып чыкты. Кама Тамагында музей төзү эшендә ярдәм иткән өчен рәхмәт әйтте. Инде әңгәмә ахырга якынлашкач кына, чыгып китәр алдыннан: «Мин сезгә шуны әйтергә килдем. Президент турында пьеса язарга ниятләдем. Ул шәхсән Сезнең хакта түгел, гомумән, Татарстан Президентының минем күзаллавымдагы образы булачак. Беренче булып бу юлны Сез уздыгыз, Сезнең тәҗрибәгә нигезләнәчәкмен. Шуңа күрә көтелмәгән хәл булмасын дип, алдан ук әйтеп куюны кирәк санадым», – диде... Мин шул чакта аның гаҗәеп әдәплелегенә, нечкә күңеленә кабат сокланып куйдым. Алай-болай хәтере калмасын дип уйлаган, күрәсең...

**– Туфан Миңнуллин вафат булгач, күпләр милләтебез ятим калды дип белдерде...**

– Һичсүзсез, аның йөрәген сызлаткан иң әһәмиятле мәсьәлә, әлбәттә, туган телебезне, милләтебезне саклап калу иде. Әйткәнемчә, ул моңа бөтен гомерен багышлады. Шулай да, ул заманча дөньяви процессларны, глобальләшү үзенчәлекләрен яхшы аңлаган хәлдә бу проблемага ераккарак китеп карый белә иде. Җир шарында ни генә булмасын, кеше барыбер үзенең тамырларын эзләячәк дип санады ул. Тагын бер фикере исемдә калган, сүзгә сүз китерә алмам, ләкин мәгънәсе шундый: бәлки, бөтен җир шары киләчәктә бер телдә сөйләшә башлар һәм бу яшәр өчен иң күңелсез вакыт булыр, шуңа күрә кешеләр яңадан үз тарихларында казынырлар, шуннан килеп чыгар үзләренең борынгы бабалары теле һәм шуңарга кайтыр өчен тырышырлар, дигән иде ул. Нәкъ Әлмәндәрчә!

Барыбыз да беләбез: ул авылны бик ярата, Олы Мәрәтхуҗага еш кайта иде. Ишеткәнем бар, күршесендәге бер апа: «Туфан, син Казанга киткәндә, лампочкаңны сүндермә, тәрәзәңдә ут янса, сине монда дип беләбез, күңелебез тыныч», – дип әйтә торган булган. Менә ул безнең яннан бөтенләйгә китеп барды. Ләкин утын кабызып калдырды: әсәрләрендә, мәкаләләрендә, театрларыбыз сәхнәләрендә бара торган спектакльләрендә, кылган гамәлләрендә аның зирәк фикерләре безгә васыять булып яна. Аларны истә тотып, ул әйткәнчә эшләү һәм яшәү хәзер үзебездән – һәрберебездән тора.

Бервакыт телевизордан Нәҗибә Ихсанова белән әңгәмәне тыңлап, Сәкинә Шакировна белән икебезнең күзләребез яшьләнгәнен, күңелебез тетрәнгәнен тапшыру беткәч кенә тулысынча сиздек-аңладык. Чыннан да, Туфанга – Нәҗибә, Нәҗибәгә – Туфан кирәк булган бу дөньяда. Минемчә, ике бөек талантның бер-берсенә тәэсире – ул җырланмаган җыр, язылмаган әсәр булып кала...

*Әңгәмәдәш* – **Нурсөя ШӘЙДУЛЛИНА**.



*Башкортстанда татар әдәбияты көннәре. Уңда – Әмирхан Еники. 1987 ел.*



*Туфан Миңнуллин – СССР Югары Советы депутаты.*




*Чыңгыз Айтматов белән.*




*Хельсинки. Язучыларның халыкара Пэн-үзәге утырышында. 1998 ел.*



*Уфа. Мостай Кәрим хозурында.*



*Үлемсез Әлмәндәр*
*(Шәүкәт Биктимеров) янәшәсендә.*



*Марсель Сәлимҗанов белән бәхәсләшеп тә була.*




*Гаиләсе җылысында.*




*Фәндәс Сафиуллин биләмәсендә кунакта.*
*Сулдан уңга: Фәндәс Сафиуллин, Марсель Галиев,*
*Туфан Миңнуллин, Разил Вәлиев. 2010 ел.*

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *һәм* **Зимфира ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА** *әзерләде.*

# ИЛ АГАСЫ ИДЕ УЛ

Туфан Миңнуллин белән танышу, тәүге аралашулар аның Татарстан Язучылар берлеге рәисе вазифасында Балтач районына килүеннән башланды. Бергәләшеп төрле авылларда, китапханәләрдә, мәдәният йортларында, мәктәпләрдә булдык, халык белән очраштык. Беренче күрешүебездә үк үзенә җәлеп иткән иде ул. 1986 елда исә икебез дә партиянең XXVII съезды делегатлары булып сайландык, Мәскәүдә бергә чакта якынаеп киттек. Казанга килеп эшли башлагач, очрашулар, күрешүләр ешайды, әмма ни гаҗәп: ешрак аралашкан саен аның хакындагы сораулар арта гына бара иде. Туфан абыйның күңеленә юл табу җиңел түгел: ул очсыз, буш, җиләс фикерле кешеләр белән аралашмый, үзенә тиң булырдай, уртак сүз табардай, аны аңлый алганнарны гына якынайтты.



*КПССның XXVII съезды делегатлары. 1986 ел. Мәскәү.*

Туфан абый белән байтак төрле эшлекле сәфәрләргә бергә чыгарга, рәсми җыелыш-чараларда катнашырга, эш арасындагы чәй табыны янында утырырга, мәҗлесләрдә катнашырга туры килде. Кайда гына, кайчан гына, кем каршында сүз алмасын, аның һәр әйткәне саллы, үтемле, урынлы була иде. Гомере буе милләтенең, халкының сулышын тоеп яшәгән чын мәгънәсендәге ил агасы иде ул. Күңелемдә ихлас кеше булып сакланып калды һәм аны һәрчак шулай искә алам. Беркайчан кеше кушканга эшләмәде, аның үз кыйбласы бар. Хәтта ул юл синекенә туры килсә дә, Туфан Миңнуллинның сукмагы барыбер аерым, үзгә, үзенчәлекле була иде. Шуның өчен аны халкыбыз да яратты, үз улы, үз туганы, үз агасы кебек якын итте. Ә моның сере – Туфан аганың үзенең дә кешеләрне яратуында, алар белән бер телдә сөйләшерлек дәрәҗәдә гадилегендә, халыкчанлыгында, уртак язмыш кичерүендә яки шул язмышларны тоярлык зирәклегендә.

Туфан Миңнуллинның туры сүзле булуына бәйле рәвештә, безнең яшьрәк чактагы бер вакыйга, төгәлрәге, Рәис Кыям улы Беляев язмышына бәйле КПССның өлкә комитеты бюросы хәтергә сеңеп калган. Әле партиянең кырыс, көчле, дилбегәне нык тоткан вакытлары, күпләрнең билеттан колак кагудан котлары очып торган чаклар. Мин ул чакта Балтач райкомының беренче секретаре. Татарстан Өлкә комитетының беренче секретаре Гомәр Исмәгыйль улы Усмановның чыгыш ясаганда, аудиториядән, залдан үзенең әйткән сүзенә, фикеренә хуплау тартып ала торган гадәте бар иде. Ул заманнарда аның: «Дөресме, шулаймы?» – кебегрәк сорауларына: «Юк, алай түгел», – дип җавап бирүчеләрне хәтерләмим. Гадәттә: «Дөрес, шулай!» – дип баш селкиләр яисә дәррәү алкышлыйлар иде. Шушы җыелышта Гомәр Усманов Беляевка карата чара күрү мәсьәләсендә ни сәбәптәндер Туфан абыйга мөрәҗәгать итте. Әйе шул, дип тә әйтмәде агабыз, башын да селкемәде, хупламады да. «Поживём – увидим!» – диде Туфан Абдуллович кырыс кына. Өч йөздән артык кеше җыелган зал гөр килеп алды, гөжләде дә тынып калды. Әле демократия җилләренең исе дә булмаган залда беренче тапкыр

үз фикерен яңгыраткан кеше табылды. Ул чагында без аның кыюлыгын, үз фикерле булуын, куркып калмавын гаҗәпсенеп кабул иттек. Югыйсә күпләр: «Барыбызда да гаеп бар инде, гафу итегез, зинһар, бүтән кабатланмас», – дип акланырга тырышыр иде. Ә ул селкенмәде дә. Фикер ныклыгы, сүзенең төплелеге, акыл тирәнлеге белән тирән тамырлы имән баганасы кебек иде шул ул, мәрхүм.

Туфан абый белән безне бәйләп торган тагын бер җеп – ул да булса, авыл тормышы, татар авылының язмышы иде. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры вазифасын башкарганда, мин беркайчан авылга җитештерүче күзлегеннән генә карамадым. Авыл ул – азык-төлек кенә түгел, ул – илнең яшәү рәвеше. Авылларга эш сәфәре барышында шушы ноктадан чыгып фикер йөртә идем. Менә шундый карашны Туфан абый бик ошата иде, шуның өчендерме, ул мине: «Халык министры», – дип атап йөртте. Ул үзе дә авыл тормышына, яшәешенә вак ихтыяҗлар яссылыгыннан түгел, зур фәлсәфә ноктасыннан, масштаблы карый иде. Шунлыктан, безнең авыл тормышы һәм язмышы турындагы сөйләшүләребез югары дәрәҗәдә, ихлас, эшлекле үтә иде. Туган авылын – Кама Тамагы районындагы Олы Мәрәтхуҗасын бик яратты бит инде ул! Җае чыккан саен кайтып, авыл тормышына чумып, галилек һәм гадилек белән яшәп алырга тырышты. Авыл кешеләренең фәлсәфәсен, зирәклеген, эшчәнлеген, җор теллелеген, тормышны яратуын, көнкүрештәге авырлыкларын – һәммәсен дә үзенә сыйдырган «Әлдермештән Әлмәндәр» пьесасын язып, гаҗәеп чагыштырулар белән татар авылын ачты, халыкка яшәү дәрте бирә алды, уйландырды, сызландырды. Минем фикеремчә, ул шушы әсәрне генә язган булса да, тарихка кереп калыр иде.

Халык белән бер телдә сөйләшкәч, бер дулкында булгач, аның уй-фикерләре аңлаешлы, җитәкчеләр өчен дә үтемле иде. Урыны-урыны белән чөй каккан кебек әйтеп куя иде бит ул. Хәтерлим, бер сессия вакытында җәмгыятьтәге эчкечелек, сугышу кебек тискәре күренешләр турында сүз бара иде. Шунда Туфан абый саллы чыгыш ясады. «Әйтик, театрдан спектакль карап чыкканнан соң, тамашачыларның җыелып сугышканын ишеткәнегез бармы? Юк. Ә сез мәдәниятkә акча кызганасыз», – диде ул. Гади генә фикерләрендә дә тормышның барлык катлаулыклары бар катламнары белән ачыла иде. Депутат буларак, тәҗрибәм зур түгел, шулай да ышаныч белән әйтә алам: бүген безнең арада Туфан абый кебек шәхеснең юклыгы үзен нык сиздерә. Озак еллар аның таянычы булган Разил Вәлиев тә җитми. Менә Ркаил Зәйдулла ышанычлы адымнар белән сәясәткә кереп бара. Шулай ук талантлы язучы, кыю фикерле, белемле, эрудицияле шәхес. Милләт трибунасын тотуда Туфан абыйның алмашчысына әверелсен иде, дип телим. Безгә, рәсми дәүләт эшлеклеләренә, күңелдә булып та, әйтергә килешми торган фикерләрне аларга кычкырып әйтү ярый. Тагын да тәвәккәлрәк, кыюрак булырга кирәк. Гомумән, язучыларның иҗатта гына түгел, милли тормышта да активлашуын теләр идем мин. Алар – халык күзалдындагы кешеләр, сүзләре үтемле. Әгәр телебезне саклауда битарафлык күрсәтсәләр, язганнарын кем укыр? Мин яздым, укысыннар, дип кенә булмый. Китапларың укучыларга барып җитсен, әсәрләрең халык күңеленә керсен өчен, үзең дә тырышырга тиешсең. Менә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе төзелде. Аның эшендә мин язучыларыбызның да актив катнашуына өметләнәм. Бүген безнең республикада яшәгән ике миллионнан артык татарның миллион ярымы үз телендә иркен сөйләшә алмый икән, бу соңгы вакытта гына туган мәсьәлә түгел, аның сәбәпләре күптөрле, шул исәптән мәгариф өлкәсендәге үзгәрешләр вазгыятьне аеруча катлауландырды. Халкыбызның киләчәк язмышы өчен безгә әле бергәләшеп күп эшләргә туры киләчәк. Менә шушы шартларда гомерен татар милләтен саклауга һәм үстерүгә багышлаган Туфан Миңнуллин исеме безнең өчен үрнәк, берләштерүче, зур эшләргә илһамландыручы якты истәлек булып торсын иде!

**Марат ӘХМӘТОВ,**
*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы*
*Рәисе урынбасары*

# ҖАН ИРЕГЕ

***(Туфан Миңнуллинның иҗат портретына штрихлар)***

XX гасырның икенче яртысы – XXI гасыр башы татар драматургиясенең үсеш-үзгәрешен, сәнгати эзләнүләр юнәлешен, тормышчанлык һәм халыкчанлык белән сугарылуын билгеләгән әдипләрнең берсе – Туфан Миңнуллин. Татар драматургиясе һәм театры башлангычында торган Г.Камал һәм Г.Исхакый, М.Фәйзи һәм К.Тинчурин, Ф.Борнаш һәм Т.Гыйззәт, Н.Исәнбәт һәм Х.Вахит кебек классиклар традициясен уңышлы дәвам итеп, ул татар сәхнә әдәбиятын үзенчәлекле тема-мотивлар, кабатланмас образлар, сәнгати алымнар белән баета, татар яшәешенә караган әхлакый һәм фәлсәфи мәсьәләләрне гомумкешелек кыйммәтләре яссылыгында сурәтләп, татар әдәбиятын-сәнгатен ил күләмендә, күпсанлы халыклар арасында танытуга зур көч куя.

Иҗат гомерендә Т.Миңнуллинның өч дистәдән артык китабы басылып чыга, иллегә якын әсәре сәхнәгә куела, йөзләгән мәкалә-язмалары дөнья күрә. Аларның һәрберсе сәнгатьчә югарылыкта язылып, әдәби процесска зур йогынты ясый, укучы-тамашачы ихтирамын казана. Әдипнең байтак әсәрләре башка телләргә тәрҗемә ителеп, Татарстаннан читтә дә танылу ала. Иң уңышлы пьесалары Башкортстан, Бурятия, Дагыстан, Чечня, Калмыкия, Латвия, Литва, Марий Эл, Казакъстан, Кыргызстан, Осетия, Таҗикстан, Удмуртия, Эстония милли театрлары, шулай ук Россиянең Омск, Воронеж, Әстерхан, Мичурин, Мурманск, Түбән Новгород, Новокузнецк шәһәрләре рус театрлары сәхнәләрендә зур уңыш казана. Әдипнең әсәрләре белән чит ил театр сөючеләре дә таныша. Г.Камал театрының Германия, Финляндия, Төркиядәге гастрольләре вакытында «Әлдермештән Әлмәндәр» (Финляндия, 1996; Төркия, 1999), «Җанкисәккәем» (Германия, 1996; Финляндия, 2000), «Йөрәк маем» (Финляндия, 1997) спектакльләре тәкъдим ителеп, җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәяләнә.

Т.Миңнуллин әдәби иҗатка килгән 1960 еллар ил-халык тормышында җитди үзгәрешләр белән характерлана. Татар әдәбияты да милли яшәешкә йөз белән борылып, тормышчанлык юнәлешендә һәм сәнгатьчә эшләнештә яңа баскычка күтәрелә. Драматургиядә Н.Исәнбәт, Р. Ишморат, М.Әмир, Ю.Әминев һ.б. янәшәсендә Х.Вахит, А.Гыйләҗев, Ш. Хөсәенов, И. Юзеев кебек авторлар үсеп чыга, театр дөньясы җанлана. Т.Миңнуллин әнә шундый шартларда шигырьләр, юмористик хикәяләр, скетчлар язып, каләмен сынап карый һәм «Безнең авыл кешеләре» (1962), «Комиссия» (1966), «Күрше кызы» (1967), «Бәхетле кияү» (1967) кебек беренче пьесаларын яза. Яшь автор заман үзгәрешен оста сиземләп, тамашачының рухи ихтыяҗларына йөз тотып, тормыштагы актуаль, җитди, төрле буын кешеләрен борчыган мәсьәләләрне алга куеп иҗат итә. Чор мәсьәләләрен яктыртуны әдип табигый рәвештә кешенең уй-хыялларын, яшәү максатын, кешелек сыйфатын ачуга бәйли. Т.Миңнуллинны киң җәмәгатьчелеккә драматург буларак танытккан «Нигез ташлары» (1968), «Миләүшәнең туган көне» (1968) пьесалары шәхеснең каршылыклы рухи дөньясын чор билге-төсмерләре контекстында күрсәтәләр. Драматург үз заманына, тормышчан хәл-күренешләргә мөрәҗәгать итә һәм шулар аша яшәешнең каршылыклы мәсьәләләренә килеп чыга. «Миләүшәнең туган көне» драмасында дусларның туган көн уңаеннан очрашуы әкренләп социаль эчтәлек ала һәм җитди мәсьәләләр турында бәхәскә әверелә. Үз иҗатында реализмга өстенлек биргән драматург сәнгать әсәрендә дә тормыш дөреслеген, реалистик детальләрне яклап чыга. Әлеге пьесаның дәвамы язылып, персонажлары белән генә түгел, билгеле бер эчке моң, олы идея белән сугарылган «Дуслар җыелган җирдә» (1975), «Хушыгыз» (1990) драмаларын берләштергән трилогия туа. Анда тулы бер буын кешеләренең тормыш-яшәеше эзлекле рәвештә ачылып, чор рухы җәмгыятьтә кабул ителгән рухи һәм матди кыйммәтләр белән бергәлектә тикшерелә. Драматург совет системасының кешене бер төрле уйларга, эш-гамәл кылырга мәҗбүр итүен, рухи богауда тотуын тәнкыйтьли. Тамашачыны шәхес ирегенә омтылып, мөстәкыйль фикерле булып яшәргә чакыра. Сәнгать кешеләре тормышын чагылдырган әлеге трилогия – җәмгыятьтәге иҗтимагый һәм социаль шартлар йогынтысында хәтта якын

дуслар арасындагы мөнәсәбәтләрнең үзгәрүен, әхлакый кыйммәтләрнең җимерелә баруын гыйбрәтле мисалларда чагылдыра.

Т.Миңнуллин үз чоры сәхнә әдәбиятын жанр формалары белән баетып, аларның эчке хасиятләрен ачуга, төрләндерүгә җитди өлеш кертә. Ул драма һәм комедия жанрларында бердәй тигез эшли. Арада комедия жанрының шаян («Бәхетле кияү», 1967), җитди («Нигез ташлары», 1968), лирик («Яшьлегем-юләрлегем», 1978), водевиль («Диләфрүзгә дүрт кияү» (1972), моңсу («Әлдермештән Әлмәндәр», 1976); сатирик («Бәйләнчек», 1982; «Кәҗә туган түгел, бажа мал түгел», 1989), музыкаль («Гармун белән скрипкә», 1987; «Гөргөри кияүләре», 1995) төрләре, драма жанрының интеллектуаль («Миләүшәнең туган көне», 1968; «Дуслар җыелган җирдә», 1978), тарихи («Канкай углы Бәхтияр», 1975), социаль («Әниләр һәм бәбиләр», 1981), фәлсәфи-публицистик («Моңлы бер җыр», 1981) кебек жанр формалары бар. Автор өчен әсәрнең эчтәлегенә салынган төп фикерне ачык, мәгънәле, тамашачыга тәэсирле итеп җиткерү юлларын табу мөһим, жанрлык хасиятләре шул максаттан урынлы файдаланыла.

Драматургның геройлары гаять тормышчан һәм үзләренә генә хас характерга ия булулары белән аерылып тора. Аларның күңел халәтен ачуда әдип психологизм алымнарына нигезләнә, хис-кичерешләрен укучы-тамашачыга җиткерүнең яңадан-яңа юлларын, алым-формаларын таба. Т.Миңнуллинның күпсанлы язмаларында, әңгәмәләрендә чагылыш тапкан тормыш-яшәеш концепциясе пьесаларында да киң урын ала – ул битараф булмау, үҗәтлек дәрәҗәсендәге тырышлык, үз-үзеңә ышану, оптимизм, милләт язмышын кайгыртып яшәү һ.б. Шуңа да драматургны, беренче чиратта, көчле рухлы, ихтыяр көченә ия булган, тормыш каршылыкларында куркып калмаучы, үзен, гаиләсен кайгырта алучы геройлар кызыксындыра. Әмма бу һич тә тормышта гел уңай герой гына эзләү дигән сүз түгел. Җәмгыятьтәге каршылыклар, явызлык һәм әхлаксыз күренешләре дә, тормышта үз урынын таба алмыйча, аптырап-югалып калган геройлар да аның пьесаларында урын ала һәм әдип аларның сәбәпләре турында җитди сүз алып бара, булдырмау юллары турында уйлана, укучы-тамашачысын да уйланырга мәҗбүр итә («Үзебез сайлаган язмыш», 1973; «Ай булмаса, йолдыз бар», 1977 һ.б.).

Драматургның бөтен иҗаты милләт гаме белән сугарылган. Ул кыю рәвештә татар милләте, аның яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре, традицияләре сагында тора. Барлык әсәрләрен дип әйтерлек иңләп үткән, үзе бөтен барлыгы белән яклаган, милли менталитетның асылын билгеләгән сыйфатлар булып хезмәт ярату, өлкәннәргә хөрмәт, буыннар арасында рухи бәйләнеш саклану, борынгыдан килгән әхлакый кануннарга тугрылык, туган җирне ярату һ.б. тора. Шуңа әдипнең «Йөрәк янар өчен барелгән» (1970), «Уйланыр чак» (1972), «Әлдермештән Әлмәндәр» (1976) һ.б. пьесалары тормышчанлыгы һәм образларның логик яктан ныклы, бөтенлекле булып ачылуы белән җәлеп итә. Драматургның иҗаты төрлеләнгән саен, аның үзенә хас стиль үзенчәлеге ачыла һәм ул яңа алым-чаралар белән байый бара. Ә инде реаль тормыш материалын шартлылык һәм фантастика элементлары белән кушып сурәтләүдә җитди казанышларга ирешә. Т. Миңнуллин иҗаты үзенчәлеген генә түгел, чор әдәбиятының йөзен билгеләгән әсәрләрнең берсе булган «Әлдермештән Әлмәндәр» моңсу комедиясе яшәешнең мәңгелек төшенчәләрен гыйбрәтле образлар аша ачуы белән киң яңгыраш ала. Драматург яшәү һәм үлем, мизгел һәм мәңгелек, яшәү мәгънәсе һәм аның асылы турында уйлана, вакыйгалар аша укучы-тамашачыны да шулар турында уйланырга этәрә. Татар драматургиясенең иң матур традицияләрен дәвам итеп, шартлылык алымына мөрәҗәгать итә һәм Үлемне мөстәкыйль образ буларак сәхнәгә чыгарып, кешенең рухи көчен, мөмкинлекләрен ачуга хезмәт иттерә. Әлмәндәрне мәңгелеккә алып китәргә дип килгән Әҗәл үз алдында гомере буе кешеләрне яратып яшәгән, матурлык тудыруга бөтен көчен салган, тынычлыкны саклауга канын түккән, хәзер дә сүзе-фикере белән әйләнә-тирәдәгеләрне матур яшәешкә дәртләндергән олы йөрәкле картны күрә. Әлмәндәр карт – милләтебезгә хас иң матур сыйфатларны үзенә туплаган ил карты, нәселенең үзәк тамыры булып күзаллана. Әсәрдәге конфликт чишелешендә, ягъни Әлмәндәрнең үзе сорап алып, Әҗәл дәфтәренә кул куюында, мөселман Шәрык һәм Урта гасыр төрки-татар әдәбиятында киң чагылыш тапкан мотив – фани дөньяда мәгънәле яшәгән кешенең бакый дөньяга – Аллаһы белән очрашуга шат күңел белән китүе чагылыш таба.

Т.Миңнуллин иҗатында авыл, аның табигате, милли рухта тәрбияләнгән авыл кешесе аерым урын алып тора. Әдип авылны татар милләтенең нигезе, бишеге, рухи таянычы дип саный. Авыл гасырлар дәвамында татар халкының күмәкләшеп яшәгән урыны, монда тел саклана, байый, монда гореф-гадәт яши, кеше кечкенәдән татар рухында, татар моңында тәрбияләнеп үсә. Драматург «Бәхетле кияү» (1967) комедиясендә үк татар авылының матур образын тудыра. Ә инде соңрак язылган «Кырларым-тугайларым» (1980), «Без бит авыл малае« (1983) кебек төп вакыйга авыл тормышы белән бәйләнгән әсәрләрендә генә түгел, бәлки, яшәешнең төрле якларын ачып салган дистәләрчә пьесаларында («Диләфрүзгә дүрт кияү», «Ир-егетләр», «Әлдермештән Әлмәндәр» һ.б.) татар авылына мәдхия укый, аны үзенең дә «тормыш бишеге» дип белдерә. Авылны сурәтләгәндә, драматургның карашлары, чынбарлык хәлләренә бәйле, билгеле бер үзгәреш тә кичерә. Югарыда аталган пьесаларында татар авылы халыкның чын рухын, иң матур сыйфатларын саклый торган урын буларак сурәтләнә. Автор милли яшәешне, татар кешесенең үзара ачык мөгамәләсен, ярдәмчеллеген, күрше хакын санлап яшәвен гаять үзенчәлекле күренешләрдә, образларда ача. Ә инде әдип иҗатындагы ике гасыр чиге татар авылы җитди сынаулар өермәсендә тасвирлана. Базар мөнәсәбәтләренә бәйле халыкның бер өлеше үзен яңа шартларда таба алмыйча, рухи кыйммәтләрдән читләшә. Яңа гасыр башында язылган «Шулай булды шул» (2002), «Мулла» (2006) кебек пьесаларында әлеге борчулы хәлләр калкулана. «Мулла» драмасында Т.Миңнуллин авылның үз асылын югалта бару сәбәпләрен ача һәм әлеге аяныч хәлдән котылу юлын кешенең иманга килүендә, Аллаһы Тәгалә каршына басуында күрә. Пьеса ахырында Әсфәндияр укучысы Илдарның мәчет манарасыннан азан әйтүен белдерү – яшь мулла яклаган иманлы яшәешкә йөз белән борылу билгесе булып тора.

Драматургның иҗат эволюциясе аеруча шәхес концепциясендә тулы чагылыш таба. Билгеле булганча, әдәби герой бирелешендә авторның дөньяга, чынбарлык күренешләренә мөнәсәбәте, яшәештәге әхлакый һәм фәлсәфи сорауларны аңлауда әдәби-эстетик карашлары чагылыш таба. Тормыштагы вакыйга-хәлләргә гаять игътибарлы драматургның иң уңышлы әсәрләрендәге әдәби образлары – яшәү фәлсәфәсен үзләрендә чагылдыручы олы характерлар, үз язмышларын халык язмышы белән тыгыз бәйләгән милли типлар. «Нигез туздыручылар»ындагы Гарифулла, «Ир-егетләр»ендәге Мәрвән, «Үзебез сайлаган язмыш»ындагы Илгиз, «Ай булмаса, йолдыз бар»ындагы Мәдинә, «Монда тудык, монда үстек» әсәрендәге Саттар, «Әлдермештән Әлмәндәр»ендәге Әлмәндәр, «Әниләр һәм бәбиләр»ендәге Гөлфинә кебекләр эш-гамәлләренең күпләргә үрнәк булуы, укучы-тамашачы күңелендә киләчәккә өмет-ышаныч тәрбияләве белән әдәби барышта аерылып тора. «Әниләр һәм бәбиләр» (1982) драмасында халыкның гасырлар дәвамында буыннан-буынга күчеп килгән традицияләре, гореф-гадәтләре, милли үзенчәлекләре югала баруы сурәтләнә. Нәкъ менә әлеге язылмаган кануннар кешене кеше итеп саклый, күңелендә яхшылыкның өстенлек алуына китерә, дип саный автор, шуңа да пьеса герое Гөлфинә буыннарны тоташтыручы Ана булып ачыла. Драматургның бу юнәлештәге эзләнүләрендә, тарихка мөрәҗәгать итеп, билгеле шәхесләрнең әдәби образларын тудыруы аерым игътибарга лаек. «Канкай углы Бәхтияр» (1975), «Моңлы бер җыр» (1981), «Без китәбез, сез каласыз» (1986), «Агыла да болыт агыла» (2001) кебек драмалары, тарихи вакыйгаларны торгызу белән бергә, татарның ерактагы һәм якындагы тарихына яңача бәя бирүнең һәм танылган шәхесләрнең әдәби образларын иҗат итүнең матур үрнәге булып тора. Т.Миңнуллин үзенең истәлекләрендә Тукай һәм Җәлил иҗаты, аларның яшәеше белән горурлануын, баш июен һәм әлеге ике зат турында ике пьеса язарга тиешлеген әйтә. Шартлы-абстракт алымнардан файдаланып язылган «Моңлы бер җыр» публицистик драмасында Җәлил һәм җәлилчеләр батырлыгының тирән тамырлары ачыла, алар батырлыгына үз чорыннан һәм бүгенге көн биеклегеннән торып бәя бирелә. Драматург җәлилчеләрнең намус белән ил-халык каршындагы бурычларын үтәп, башны горур тоткан хәлдә мәңгелеккә атлавын «моңлы бер җыр» буларак сурәтли. «Без китәбез, сез каласыз...» тарихи-биографик драмасында Тукайның Идел буенда мануфактуралар тоткан Акчуриннарга сәфәре вакыйгасы үзәккә алына. Автор XX гасыр башы вакыйгаларында калкып чыккан мәсьәләләрнең гасыр ахырында да гаять актуаль булуын искәртә. Үз чорында зур үзгәрешләр уртасында калган

Тукай да даими уйланган, эзләнгән, еш кына икеләнеп тә калган. Әмма төп мәсьәләдә аның иманы нык һәм ачык: милләт язмышын үз язмышы итеп яшәү генә кешегә рухи ныклык, фикер ачыклыгы, яшәү яме бирә.

Т.Миңнуллин үз иҗаты белән 1980 еллар уртасында җәмгыятьнең барлык өлкәләрендә башланып киткән үзгәртеп коруларны әзерләшә, аның котылгысызлыгын дәлилли, шуңа да тормышның демократик юнәлештә үсешенә, фикер төрлелегенә, кеше ирегенә ирешүгә әсәрләре белән дә, иҗтимагый-сәяси позициясе белән дә ярдәм итә. Драматург иҗатында яңа этап башланып, ул тема-мотивлар төрлелегенә, публицистик пафоска, укучы-тамашачы белән җитди әңгәмә коруга нигезләнә. Гасыр ахырында язылган әсәрләре әлеге катлаулы чорны аңлау омтылышы белән бәйле булып, әдип икътисади һәм сәяси яңалыклар йогынтысында кеше аңында барган шактый авыр үзгәрешләрне чагылдыруга йөз тота («Без китәбез, сез каласыз» (1986), «Тал бөресе имәндә» (1987), «Вөҗдан газабы» (1987), «Гармун белән скрипкә»(1988) һ.б.).

Т.Миңнуллин алдагы традицияләргә таянып, халык рухына тәэсир итәрдәй темалар эзли, яңа эчтәлеккә, заман мәсьәләләрен чагылдыруга омтыла. Җәмгыятьтәге үзгәрешләр нәтиҗәсендә милли үзаң үсү, дәүләтчелекне торгызу идеясенең киң яклау табуы әдәбиятта милли тематиканың киң чагылуына китерә. Милләтебезне инкыйраздан ничек коткарырга? Аның телен, яшәү рәвешен, традицияләрен ничек саклап калырга? Әлеге сораулар бу чор драма әсәрләренең күпчелеген иңләп үтә. Әдипнең «Илгизәр плюс Вера»(1991) драмасы катнаш никах кебек гаять җитди, четерекле мәсьәләне сәнгать чаралары ярдәмендә тәэсирле итеп сурәтләве белән генә түгел, бәлки яшь геройларның рухи йөзен, психологиясен гыйбрәтле күренешләрдә ачуы белән җәмәгатьчелекнең хөрмәтен казана. Драматург «Шәҗәрә»(1995) драмасында морза нәселенең төрле вәкилләре тормышын гыйбрәтле вакыйгалар аша күрсәтеп кенә калмый, бәлки, аларны үзара якынайту, берләштерү юлларын да эзли. Ә инде керәшеннәр турындагы «Гөргөри кияүләре» (1995), мишәрләр тормышыннан алып язылган «Йөрәк маем» (1996) кебек комедияләре халыкның җанлы тормышын эчтән торып сурәтләве белән тамашачы тарафыннан яратып каршы алына.

XX гасырның 90 нчы елларындагы икътисади торгынлык, матди һәм рухи кыйммәтләрнең үзгәрүе, әфган һәм чечен сугышы нәтиҗәләре йогынтысында тулы бер буын рухи кризис кичерә. Әлеге «югалган буын», аның сәбәпләре турында уйланулар Т.Миңнуллин иҗатында бөтен кискенлеге белән куела. Әдип каршылыклы, еш кына фаҗигале язмышлардан гыйбрәт алырга, андыйларга миһербанлык күрсәтергә чакыра. «Эзләдем, бәгърем, сине» (2000) драмасында төрле сәбәпләр аркасында инвалид коляскасына беркетелгән яшь геройлар Рәхимҗан белән Нурсинәнең җан сыкрануларын, катлаулы һәм каршылыклы күңел тибрәнешләрен укучы-тамашачы алдына куя, яшәеш кыйммәтләре турында уйланырга этәрә.

Т.Миңнуллин иҗатында реализм өстенлек итсә дә, ул һич тә романтик сурәтлелекне, аның җете буяуларын кире какмый. Сентименталь кичерешләргә киң урын бирелеп, җыр-музыка үрелеп барган мелодрама жанрына да мөрәҗәгать итә. Шуның белән бергә, әдип модернизм алымнары ярдәмендә яшәешнең серле якларын ачуга да килеп чыга. Кеше күңелен аңлап һәм аңлатып бетерү мөмкин түгел, шуңа да ул аны төрле шартларга куя, төрле сынауларга дучар итә. Иң мөһиме: пьесаларда хәрәкәт итүче геройлар кемнәр һәм ниндиләр булуына карамастан, автор аларга хөрмәт белән карый, аңларга һәм ярдәм итәргә омтыла. Иҗатының соңгы елларында басылып чыккан яисә төрле сәхнәләрдә куелган «Саташу» (2001), «Аерылабыз – хуш инде» (2005), «Алты кызга бер кияү» (2005), «Гашыйк буласым килә» (2005), «Мулла» (2006), «Дивана» (2006), «Син мине күрәсеңме?» (2009), «Нәзер» (2010) пьесалары тема-проблемалары, яшәеш мәсьәләләренең милли һәм гомумкешелек кыйммәтләре яссылыгында чагылыш табуы, һәрберсендә дип әйтерлек индивидуаль сыйфатлары белән аерылып торган замандашыбызның характерын иҗат итүе һәм әдип кулланган сурәт чараларының, форма-алымнарының төрлелеге, байлыгы, еш кына кабатланмаслыгы белән аерылып тора. Драматург яшәештәге актуаль мәсәләләрне укучы-тамашачыга җиткерүнең яңадан-яңа алым-чараларын табу буенча даими эзләнүләр алып бара. Әгәр «Шәҗәрә»дә вакыйга-күренешләрне «оялап» урнаштырса, «Шулай булды шул...»да әсәрнең төп герое вакыйга-

күренешләрдә катнашып кына калмый, аларны сөйләп-аңлатып та бара. «Тәнзиләкәй» монодрамасы исә «бер артист театры» формасында булуы белән игътибарга лаек. Ә инде «Галиябану, сылуым-иркәм» (2005) пьесасы интертекстуальлек алымына нигезләнеп, авторның үзенчәлекле әдәби-эстетик концепциясен чагылдыруга хезмәт итә.

Балалар өчен театрның әһәмиятен яхшы аңлаган драматургның «Азат», «Айга сәяхәт», «Кайда хаклык, кайда дөреслек» (1976), «Иптәш командир» (1977) кебек пьесалары фикер ачыклыгы, акцентларның төгәллеге, әхлак-тәрбия мәсьәләләрнең уңышлы куелышы белән игътибарга лаек. Драматург алдагы эзләнүләрендә балалар күңеленә әдәп-әхлак орлыклары салуга хайваннар дөньясының үзенчәлекле якларын ачу, алар арасындагы мөнәсәбәтләрне сурәтләү аша килә. Әдипнең Акбай турындагы тулы бер цикл пьесаларында – «Авыл эте Акбай» (1989), «Акбай нигә күңелсез?» (1991), «Акбайның яңа маҗаралары» (1991), «Акбай белән Кыш бабай» (1991), «Акбай, Тәмлетамак һәм Этбүрләр» (1992), «Акбай һәм сарык малае» (1993), «Акбай, SOS!» (1994), «О'кей, Акбай!» (1995) – хайваннар дөньясының серле, гыйбрәтле яклары ачылып, балалар өчен дә гаять кызыклы һәм бай мәгълүмат бирелә. Автороста психолог буларак эш итә, сиздерми генә бала күңеленә миһербанлык, туган җирне, телне ярату сыйфатларын сеңдерә. Сәхнәдән балалар белән кызыклы да, гыйбрәтле дә әңгәмә алып бара, бала күңелендәге күпсанлы сорауларга бергәләп җавап эзли.

Драматург буларак киң танылу алган Т. Миңнуллин әдәбиятның башка төрләрендә дә уңышлы эшли. Ул иҗатын юмористик хикәяләр язудан башлый һәм бу жанрга караган әсәрләре аерым җыентыкларда басыла(«Дуслык хакына» (1965), «Чишмә җыры» (1968), «Кеше бул!» (1975). Татар тормышыннан алып язылган хикәяләр матур, сыгылмалы, еш кына юморлы тел белән язылган. Аларда яшәеш матурлыгы, тормыш фәлсәфәсе, буыннар арасындагы бәйләнеш, дуслык-ярату, ярдәмчеллек, миһербанлык турында җитди сүз бара. Т.Миңнуллинның проза әсәрләре арасында «Минһаҗ маҗаралары» (1998) аерым игътибарга лаек. Беренче карашка ил сәясәтенә пародия булып торган әсәр, әдипнең сәнгати фикерләвендәге яңачалыклары, гыйбрәтле дөнья моделе тудыруы белән игътибарны җәлеп итә.

Әдип иҗатының мөһим бер тармагын публицистик әсәрләре тәшкил итә («Утырып уйлар уйладым», 1997, 2001, 2005, 2010);«Татарның бер баласы», 2003), «Сайланма әсәрләре»нең 7-10 томнары, 2002). Сәяси, иҗтимагый, мәдәни хәл-күренешләргә нисбәтле уй-фикерләре чагылыш тапкан язмаларда халкыбызның бүгенгесе һәм киләчәге өчен җан атучы, матур сыйфатларына шатланучы, ямьсез якларына тирәнтен борчылучы шәхесне күрәбез. Т.Миңнуллин укучысы белән чын күңелдән сөйләшү алып бара. Ул купшы сүзләрне, төчелекне кабул итми. Шуңа да җәмгыятьтәге кыйммәтләрнең үзгәрүе, тормыш каршылыклары, татар язмышына янаган куркынычтурындаачыктан-ачык һәм гыйбрәтле мисалларга нигезләнеп яза. Тагын бер үзенчәлек булып публицистик аһәңнең лиризм белән өретелүе тора. Бу бигрәк тә аның остазлары, каләмдәшләре, үзе белгән һәм аралашкан кешеләр турындагы язмаларында чагыла. Тормышны гаять оста күзәтүче буларак, яшәештәге вакыйга-күренешләрне сәбәп-нәтиҗә бәйләнешендә карый. Бу исә аңа үткәнне, бүгенгене һәм киләчәкне фәлсәфи яссылыкта бәяләү мөмкинлеге бирә. Автор өчен яшәү мәгънәсе ул – үз язмышыңны милләт язмышы белән тыгыз бәйләп, аның гаме белән яшәү. Моның өчен һәр кешедә милли үзаң уятырга, чын шәхес тәрбияләргә кирәк. Иң мөһиме, үзе язганча, «ул рухының, җанының иреген саклау. Җаны ирекле кешене бер генә тупас көч тә буйсындыра алмый».

Шулай итеп, Т.Миңнуллин халкыбызның каршылыклы үткәне һәм бүгенгесе, яшәешнең милли һәм гомумкешелек кыйммәтләре, кешенең асылы һәм рухи иреге, яшәү мәгънәсе кебек фәлсәфи, милли, әхлакый мәсьәләләрне бөтен каршылыгында куеп, аларны реализм һәм романтизмга хас алым-чаралар, модернизмның үзенчәлекле формалары, сурәт-тасвирлары аша чагылдыруга килә, укучы-тамашачы белән җитди әңгәмә алып бара.

Әдипнең фикер көрәшенә, кискен конфликтка, җанлы һәм җор телгә ия пьесалары тормыш материалының җитдилеге һәм әһәмияте, милли рухы һәм мәгънә тирәнлеге белән әдәбият тарихында лаеклы урын алып тора.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ,**
*филология фәннәре докторы*

## Туфан Миңнуллин

# ӘТИ

Мин бик кызыклы гаиләдә үстем. Бер-берсе белән ни холык, ни белем мәсьәләсендә капма-каршы булган ир белән хатын минем әтием һәм әнием иделәр. Характерлары килешмәгән, шуңа аерылышканнар, дигән уйдырмага мин ышанмыйм. Әгәр алай булса, минем әти белән әни бер генә сәгать тә яши алмаган булырлар иде. Ә алар кырык биш ел бергә яшәделәр һәм...

Юк, мин аларның икесе турында да аерым-аерым языйм әле, шуннан барысы да аңлашылыр.



*Миңнуллиннар гаиләсе.*

Әти Казанда туган. Бабай, үзебезнең яктан китеп, Ягодная бистәсендә яшәп, «пырхавай» заводта эшләгән. Документларда әтинең туган елы 1903 дип язылган. Әмма, әтинең туганнан-туганы мәрхүмә Зөләйха апаның әйтүенә караганда, ул 1901 елларда туган булырга тиеш. «Митрикәгә дөрес язылмаган», – дип әйтә иде Зөләйха апа.

Мин Гафур учительнең школасында укыдым, дип сөйли иде әти. Гафур учитель ул Гафур Коләхмәтев була инде, дип горурлана да иде. Хәтта школага Габдулла Тукай килгәнен, яхшы укучы бер балага читек бүләк иткәнен дә тәмләп сөйләргә ярата иде. Әйтерсең лә, ул читекне үзе алган. Алдаша белми иде әти. Алдаша белсә, читекне Габдулла Тукай миңа бүләк итте, дип тә әйтә ала иде югыйсә. Без карап тормаган.

Школада ничә ел укыгандыр, анысын белмим, һәрхәлдә, өч-дүрт елдан артмагандыр. Ләкин шул белем әтигә гомере буена җитте. Русча шәп белә иде. Гарәпчә язуны да су кебек эчә иде. (Анысын ничек өйрәнгәндер, сөйләгәнен хәтерләмим.) Авылда русча язылырга тиешле гариза, белешмәләрне – барысын да әти язып барган. Хәтта укымышлы, ягъни мәсәлән, унынчы классны тәмамлаган яшьләр күбәйгәч тә, өлкән агайлар, аларга ышанып бетмичә, «язу яздырырга» әти янына киләләр иде. «Габдулла өстәгеләр аңларлык итеп яза, аның кулы җиңел», – диләр иде. Илле ел туктаусыз хуҗалык көтүен көткән Җиһанша бабайга пенсия сорап язгач һәм сораган пенсиясе килгәч, Җиһанша бабайның безнең өстәл артында әтигә рәхмәтләр әйтә-әйтә елап утырганы хәтеремдә.

Әти янына гарәпчә язылган дини китаплар да тотып киләләр иде. Укып бирүен үтенәләр иде. Әти беркайчан да аларны укымады. Дин белән алыш-биреше юк иде аның. Денсезләр кебек, Алланы сүкмәде дә ул, аңа ялварып, дога да кылмады.

Без, әти, Алла бармы, дип сорасак, үскәч, үзегез эзләрсез, дип шаярта иде. Пәри бармы, дип сораганга, ишегалдында йөргән кәҗәгә күрсәтә иде, кәҗәне үлеп яратмый иде. Дога-фәлән укылган җирдә утырмады, җитмештән узгач, әни бик бәйләнгәч («Картайдың бит инде, картлар янына баргала»), Гарифулла абыйлар өенә картлар җыелып, намаз укыган җиргә киткән иде, көлеп кайтып керде. «Кирәген бирәләр гарәп сүзләренең, яшәсен, диясе урынга бетсен, дип укыйлар. Мөхәммәт пәйгамбәр тыңлап торса, андагыларның барысын да мәңге тәмуглы итәр иде», – дип көлә-көлә сөйләде миңа.

Иске китаплардан ул «Йосыф-Зөләйха»ны безгә кычкырып укый иде, Гали батыр, Салсаллар турында да укыганы хәтеремдә. Әмма ул аларны безгә әкият дип аңлата иде.

Унҗиденче елларда ятим калгач, әти дөнья гизәргә чыгып китә. Пароходта табак-савытлар юып та йөри, сал агызучылар тирәсендә дә бөтерелә. Гомумән, ул еллардагы биографиясе аның Идел белән бәйләнгән. Бик кәефе килгән чакларда ул үзен бурлак дип атый иде. Әни дә, ачуы чыкканда: «Гумерем үтте шушы бурлак белән», – дип зарлана иде. Әтигә мондый чакта рәхәт була, зәп-зәңгәр күзләренә елмаю тула, мин әле хәзер дә Иделне аркылы йөзеп чыгам дип, әнинең ачуын тагын да кабарта. Идел-су әтинең җырланып бетмәгән җыры булган, күрәсең, аны еш искә алды. Хәтта безнең беренче өйнең чоланы да иске баржаның агач кабыргаларыннан корыштырылган иде.

Әйе, әтинең характерында зимагурлык бар иде. Ул йорт-җир, мал-туар, байлык дип, алар артыннан кумады. Әни тыкырдатып торганга гына, иске өй урынына яңа өй салырга ризалашты ул.

24-25 нче елларда әти безнең авылга килеп юлыга. Кемгәдер ияреп кайтканмы шунда, әтисе шушы яктан булгангамы, безнең авылда төпләнеп кала. «Грамотный егет» икәнен белгәч, авыл советына секретарь итеп куялар үзен. Нинди секретарь булгандыр, билгесез (һәрхәлдә, яманлап сөйләгәннәрен хәтерләмим), әмма авылга бөтен яңалыкны ул беренче алып кайткан. Велосипедны авыл халкы беренче тапкыр әтидә күргән, детектор радиоалгыч чыккач, авылның күпне белергә омтылган кешеләре, әти янына килеп, детекторның колакчыннарын колакларына куеп, дөнья хәлләрен тыңлаганнар.

Чыгып ычкынмасын бу кирәкле егет, дип булса кирәк, өйләндергәннәр әтине. Өй дә әмәлләп биргәннәр. Ләкин күпмедер торгач, әти ул өйдән чыгып киткән һәм бүтән кайтмаган.

Әтинең бу чаклары минем өчен билгесез. Үзе, билгеле, сөйләми иде, әни дә, әлбәттә, дәшми иде. Үзенең балаларына әтиләренең беренче хатыны турында ничек сөйләсен инде! Миңа ул хакта авыл агайлары әйткәли иде. Әмма әтине хурлап, яманлап түгел, мактап. Чөнки әти, өйдән чыгып киткәндә, «шырпы да алмаган». Чыгып китүенең сәбәбе, имештер, теге апаның әтигә «хәерче» дип әйткән сүзе булган. Нигә алай дип әйткәндер, югыйсә авыл советы секретаре булу ул чакларда зур мәртәбә саналган.

Моннан бер-ике ел элек, көтмәгәндә, әтинең беренче хатынын күрше авылда очраттым. Шул авыл кешеләре әйттеләр. Картайган булуына карамастан, зифалыгын, чибәрлеген югалтмаган. Яшь чагында тагын да чибәр булгандыр. Менә шуны бер сүз өчен ташла инде!..

Юаш иде әти, ләкин үзсүзле, принципиаль кеше иде. Бер генә эшне дә

намусына каршы барып эшләмәде, һәрхәлдә, мин үзем дә, авыл халкы да хәтерләми. Юашын юаш, ләкин юаштан юан чыга. Әти дә ычкынгалап алган. Үз гомерендә ике тапкыр. Ләкин аларның икесе дә әдәби әсәр итеп язарлык.

Берсендә бер апаның күрсәтүе – яла ягуы аркасында, 37 нче елны авылның уналты кешесен кулга алалар. Алар арасында «кулак тегермәненә су коючы» әти дә була. Ике көн тикшерәләр дә (бәхеткәйләре булгандыр инде), кулга алынганнарның гаебен тапмагач, кайтарып җибәрәләр. Әтиләрне милиция алып киткәч, теге апа «Күрсәттем күрмәгәннәрен, төрмәдә башлары чериячәк», дип кычкырып йөргән. Әтиләр кайткач, куркудандыр инде, мөгаен, әти янына – колхоз идарәсенә килеп (әти ул чакта колхозның хисапчысы), боргалана-сыргалана гаебен юарга маташа икән. Шуннан юашыбыз кызып китмәсенме! Канцеляриядә бер генә исән утыргыч калмаган, кәгазьләр очкан, өстәл чәлпәрәмә килгән, тәрәзәләр коелып төшкән, ишек күгәненнән чыгып атылган, хәтта колхоз идарәсенең тирәсен уратып алган рәшәткәләр дә тетелеп беткән. Дүрт ир кеше тыя алмаганнар үзен. Теге апага орынмаган орынуын. Әмма ул хатын шул көннән соң куркудан акылга җиңеләеп калган, имеш.

Икенче тапкыры мин олыгайгач, Мәскәүдә театр училищесында укыган чагымда булган. Кыш көне әти белән әни тәрәзә каршында чәй эчеп утыралар икән. Безнең өйнең каршында бәләкәй генә бакча бар иде, шунда өч төп алмагач үсә иде. Шул бакчага кар күмгән рәшәткә өстеннән күршеләрнең кәҗәсе кергән дә алмагач ботагына ябышкан. «Бар әле, куып чыгар шул мөртәтне», – дигән әни. Әти бер куып чыгарган, ике, өч, дүрт, тик кәҗә һаман кәҗәлеген иткән. Әни әтине ачулана башлаган, «рәтләп куа белмисең», дигән бугай. Шуннан әти чәй тулы чынаягын идәнгә атып бәргән дә атылып, ишектән чыгып киткән. Әтинең бу юлы хәерлегә чыкмаганын сизеп алган кәҗә урамнан элдертә икән, әти аның артыннан... Шактый чапкач, әти кәҗәне куып тоткан. (Бу вакытта аңа алтмыш сигез яшьләр иде инде.) Куып та тоткан, сыртыннан эләктереп, күтәреп тә алган. Күтәреп өйгә алып кайткан, өйгә кергән дә: «Мә, теләсәң нишләт!» – дип, кәҗәне әни алдына ыргыткан. (Яратмый иде шул әти кәҗәне. «Әгәр дә аңа өч класс образование бирсәң, адәм баласына чыдар хәл калмас иде», – дип сүгә иде үзен.)

Әти үзе әллә ни көчле дә кеше түгел иде. Уртача буйлы, какча гына гәүдәле иде. Күрәсең, сабырлыкның да бер чиге була. Сабырны шул чигеннән чыгарсаң, үзен-үзе белештермичә, әллә ниләр эшләп ташлавы ихтимал.

Сабыр иде әти. Әнигә, безгә, гомумән, берәүгә дә кулын күтәрмәде. Кызмача кайткан чакларында, әни пыр тузынганда да, гөнаһсыз зәп-зәңгәр күзләрен елтыратып:

«Не ругай меня, Фатима, что акча мало тащил», – дип җырлап тора иде. «Шушы бурлакка әйткән сүзем әрәм», – дип, әни дә тынычлана иде. Ә без, хатыннарыбызның юк-бар сүзләренә чәпчеп китеп, вакланып, хатын-кызлардан битәррәк талашырга тотынабыз. Безнең кул белән тел акылдан алда йөри, әтинең киресенчә булгандыр – башта уйлагандыр. Уйлагандыр да сабыр итәргә кирәк тапкандыр.

Сугышка хәтле булган хәл әле дә хәтеремдә. Миңа биш яшьләр булды микән? Әти белән берничә кеше безнең рәшәткә буендагы бүрәнәдә утыралар. Без, малайлар, ерак түгел су буенда пычранабыз. Бездән шактый олыраклар мине үртиләр, котырталар. Шушы мулатаны (юшкын, ләмне безнең авылда шулай диләр) әтиеңнең битенә сылый алмыйсың, диләр. Мин батыраеп китеп, кулыма уч тутырып ләм алдым да, йөгереп барып, әтинең битенә сыладым. Ычкынырга өлгермәдем, әти янындагы берәү эләктереп алды. Шәп кенә

итеп арт якка сыламакчы иде абзый, эти: «Кирәкми, тимәгез балага!» – диде. «Олыраклары ахмак булгач, кечкенәләр нишләмәс», – диде. Ун, унбиш, егерме яшьтә күргән, ишеткән, үзем белән булган вакыйгаларның әллә ни чаклысы онытылган, ә менә этинең шул сүзләре мәңгелеккә күңелдә уелып калган. Аннан эти белән су буена барып, аның битендәге пычракны икәү бергә юдык. Әниең ачуланмасын, юыйк, диде эти. Әтине җирләгәндә, гүргә иңдергәндә, шушы сүзләре искә төшеп, тыела алмыйча еладым...

Берәр ярамаган эш эшләсәк, эти безне, әниегезгә әйтәм, дип куркыта иде. Гадәттә, киресенчә була бит. Әнине өйнең хуҗасы итеп таный иде эти. Ләкин колларча буйсынып түгел, әнинең хуҗалыкны, өйне тәртиптә тота белүенә ышанып, аны яратып, хөрмәт итеп. Без, олыгая барып, әнигә берәр кыек сүз әйтсәк, әниегезгә каршы дәшмәгез, дип тора иде.

Әнигә эти утызынчы елда өйләнә. Әни ярาткандыр этине. Югыйсә үзеннән алты яшькә өлкән, хатын аерган кешегә чыкмаган булыр иде. Хәзер генә бит ул өч-дүрт хатын аерганнар да егет булып йөри. Ул чакта... Җитмәсә, әни – бабайның бердәнбер иркә кызы. Һәм бик чибәр. Таза хәлле авыл кешесенең практик кызына шигъри күңелле эти ошагандыр шул. Әни үзе чыкылдап торган җир кешесе булса да, күңеленең кайсыдыр бер почмагында сәнгать, әдәбиятка омтылыш бар иде.

Эти, олыгаеп, шигырьләр яза башлады, әни аның бу эшеннән ояла иде. Күрәсең, шигъриятне ул изге нәрсә, дип табынгандыр. Бер тапкыр этинең шигырьләре район газетасында басыла башлады. Әни еларга җитешеп, мине үгетләде: «Әйт әле шул җүләргә, кеше көлдермәсен. Урамга чыгарлыгымны калдырмады, – диде. – Кибеткә кергән идем дә, Халисә апа, Габдулла абый язганны укыдыңмы әле дип, гәҗит селкеп көлделәр».

Эти язган шигырьләр, әлбәттә, чын әдәбияттан шактый ук ерак торалар иде. Хәер, андыйлар безнең зуррак газета-журналларда да күренгәли. Этигә әнинең үтенечен җиткергәч (минем сүз белән бик исәпләшә иде ул), этинең шигырьләре район газетасында күренми башлады. Ташлагандыр ул эшне, дигән идем, эти үлгәч, иске китапларны актарганда, шигырь язылган дәфтәр битләре килеп чыкты. Үлгәнче язган, мәрхүм. Качырып язган, әнидән, миннән яшереп язган.

Вакытында үз юлыннан киткән булса, кем белә, бәлки, әдәбият, сәнгать өлкәсендә эшләүче кеше булган булыр иде эти. Үз юлыннан диюем шуның өчен, авыл кешесе түгел иде ул. Ничә дистә ел яшәп, авылга ияләшә алмады. Ят иде авыл аның өчен. Хуҗалык эшен белмәде, аңламады. Юк, аңларга теләмәде түгел, булдыра алмаганнан, күңелендә булмаганнан. Югыйсә ат җигүнең ние бар инде? Ә менә эти, күпме генә өйрәтсәләр дә, өйрәнә алмады. Атка утырып, үзе генә каядыр барасы булса, әни җигеп бирә иде һәм, барасы җиренә барып җиткәч, ничек итеп атның алдына печән салырга, ничек тезгенен чишәргә, ничек аркалыгын төшерергә өйрәтә иде. Эти, ярар, ярар, дип тыңлап тора, арбага утырып чыгып китә, әмма кайтып кергәндә, ат ашатылмаган да, эчертелмәгән дә була. Аркалык, тезген әни ничек бәйләгән – шулай. Тик ни өчендер бавыргалыгы чишелгән, йә арба көпчәгенең чөе төшеп калып, тәҗ ычкынган була. Шуңа күрә эти күбрәк җәяү йөри иде. Үзе колхозның бухгалтеры, үзе, район үзәгенә отчёт белән барганда, җәяү бара. Аңлый торган председательләр ат белән илттереп куялар, барып алдыралар иде. Ләкин аңламаганнары да шактый булды шул председательләрнең.

Этинең авыл кешесе түгеллеген исбатлый торган тагын бер деталь. Бервакыт эти кулына чыбык тоткан да капка төбендә пыр туздырып, бер сыерны куып йөри.

– Бар әле, чык әле, этиең нишли анда? – ди әни. Чыктым.

– Әти, нишлисең, ә? – дип сорыйм.

– Менә, керми бит, – ди.

– Ә нишләп ул керсен?

– Әниең алып кайтырга кушты. Саварга вакыт, диде.

– Безнең сыер түгел ич ул, – дим.

– Корсагында агы бар дип әйтте ич әниең.

Рәхәтләнеп көлдек әни белән. Авылда яшәп, үз сыерын танымаган крестьян гайре табигый хәл ич! Сарык, казларны әйткән дә юк. Әйе, авыл кешесе түгел иде әти.

Стихиясе кәгазь һәм каләм иде аның. Һәм счёт төймәсе. Счетта ул, оста гармунчы шикелле, төймәләргә карап тормыйча гына, куша, ала, тапкырлый, бүлә һәм процентлар чыгара иде. Төннәр буе санап утырган чаклары була иде. Отчетны бөтен колхозлардан алда тапшыра, үз отчётын тәмамлагач, башка колхозларга ярдәмгә җибәрәләр иде. «Мине Габдулла абый өйрәтте», – дигән бухгалтерларны шактый беләм мин.

Дөньяда намуслы кешеләр бик күп. Ләкин әти кебек чиста, намуслы кешене үз күзләрем белән күргәнем юк, дисәм, ялган булмастыр. Якты дөньяга туганчы ук, ана карынында чакта ук табигать тарафыннан бүләк итеп бирелгән намус булгандыр ул. Намус мәсьәләсендә бер генә карышка да читкә тайпылганын хәтерләмим. Тормышта эшләгән бердәнбер хилаф эше беренче хатынын ташлап чыгып китүе булгандыр, бәлки. Хәер, анысын да кем белә, «хәерче» дип юкка гына әйтмәгәндер теге апа – әтинең намусына каршы килә торган берәр эш эшләргә кушкандыр да, әти каршы килгәндер.

Коммунист нинди булырга тиеш, дигәндә, минем әти кебек, дип җавап бирәсем килә. Үзе ул партия члены түгел иде түгелен. Нигә партиягә кермәдең, дип сорагач, Лениннан оялам, ди иде, аның белән тиң булыр өчен, беләсеңме, кем булырга кирәк, ди иде. Мин партиягә кергәндә: «Кара аны, өстеңә зур йөк аласың, күтәрә алсаң гына кер», – диде.

Әти кебек булырга тырышам мин. Тик барыбер сизәм, алай булдырып булмый. Тормышның катлаулылыгына сылтап, акланмакчы булам, әмма...

Зур гөнаһ эшләгән юк югын, тик менә, вак булсалар да, кайвакыт ычкынгалый ялгышлар. Намус мәсьәләсендә әти ялгыша белми иде шул.

Мин кечкенә чакта ул миңа Ленинның газеталардагы фотоларын күрсәтә иде. «Син аның күзләренә кара», – ди иде. «Аның читкә карап ваемсыз гына төшкән бер рәсеме дә юк, ул һәрвакыт туп-туры күзгә карап тора», – дип әйтә иде.

Чынлап та, Ленинның фотоларына карыйм да хәзер әтинең ничаклы хаклы икәнен күрәм, һәр рәсемдә Ленин синең күңелең белән сөйләшеп тора. Читкә караган, адашкан, гамьсез карашлы яки үзеннән-үзе канәгать булып кәпрәеп төшкән бер генә рәсеме дә юк. Кайбер язучыларның Ленин турында әсәрләрен укыйм да, ничек оялмыйча алыналар шундый изге эшкә дип, алар өчен оялам. Ленин турында язар өчен, ай-яй, нинди булырга кирәк!

Сугышта әти элемтәче булган. «Батырлык өчен» медале бар иде. Кадерләп саклады ул медален. Тик ни өчен алганын сөйләмәде. Мин төпченә башласам: «Син аны барыбер аңламыйсың, үзе сугышып караган кеше генә аңлый аны», – ди иде. Сугыш бетәр алдыннан аны склад мөдире итеп куйганнар. Сугыштан кайтканда, әтинең солдат капчыгында ике кисәк шикәр, егермеләп сохари һәм бер кисәк шпиг бар иде. Хәтерлим, кайбер малайлар әтиләре алып кайткан әйберләр белән мактанышалар иде. Шул турыда ничектер бер тапкыр әни әтинең исенә төшергәч:

– Син беләсең ич, мин сугышта идем, базарда түгел идем, – дигәч, әни бүтән ул турыда сүз кузгатмады.

Кырык алтынчы елларда без ачыктык. Әти колхозда бухгалтер, ул вакытча итеп әйтсәк, читават, ягъни счетовод, ә без ачыктык. Әни нишләргә белми.

– Дүрт ел сакладым малайларыңны, инде үзең кара, – ди.– Булсаң да булырсың икән, кеше ышанмый, кычыткан җыйганны күргәч, юри генә кыланасыңдыр, диләр. Ирең читават килеш кычыткан ашыйсыз, дип әйтәләр.

Әти тыңлап-тыңлап тора да:

– Амбарда он юк бит, каян аласың, – ди. Әни тук яшәүче берәүне этинең исенә төшергәч:

– Каян ала соң он? Бөтен документлар миндә, колхозда бер грамм да он күренми, – ди.

Ул тук кеше безгә кергәли, этигә тормышның нәрсә икәнен аңлата.

– Син бер әйбер дә аңламыйсың, Гаптул, – ди.– Докуминнарда күренмәгән нәрсәләр күп ул, – ди. – Син мине урлый, дип уйлыйсыңдыр инде, – ди.– Мин урламыйм. Урлаган кеше кем ул? Эшләмичә ашаган кеше. Ә мин көне-төне чабам. Аксак аягым белән чабам. Мин бит колхоз өчен чабам. Чаба-чаба егылсам, колхоз нишләр? Барыбыз да егылсак, колхоз нишләр? Син укыган булсаң да, тукымаган, Гаптул...

Ләкин мондый дәлил белән генә этине иманыннан яздырып булмый иде шул, без ачыктык.

Ниһаять, әни түзмәде – абый белән мине өлгерә башлаган арышның башагын уарга җибәрде. Башак уу өлкәсендә сугыш вакытында туплаган тәҗрибә зур иде инде, ярыйсы гына «эшләп» кайттык. Яшел арышны мич алдында – табада куырып маташканда, әти кайтып керде.

– Кайдан алдыгыз моны?– диде.

– Эшең булмасын, чут төймәсен тартуыңны бел, – диде әни.

Әти өйдән чыгып китте, без арышны ашап бетергәч кенә кайтты.

– Хәзердән үк урлаша башлагач, үсә төшкәч, нишләрләр? – дип рәнҗеп сөйләгәне хәтеремдә.

Беркөнне өйгә районнан килгән уполномоченный белән колхоз председателе килеп керде. Председатель бер шешә аракы чыгарып, өстәл өстенә куйды.

– Кайда, сеңел, кабарга берәр нәрсә куй әле, – дип, почмак якта кайнашкан әнигә дәште.

– Нәрсә куйыйм, каян алып куйыйм, балалар ач утыра, – диде әни.

– Ничек инде – ач утыра?

Әти өйдә юк иде, рәхәтләнде генә әни. Әллә ниләр әйтеп бетерде. Әни тузынганда, уполномоченный:

– Әйдәле минем белән, – дип, шул тирәдә болганучы мине чоланга алып чыкты. Бөтен җирне тикшерде. Аннан өйгә кереп, кирәген бирде председательнең: – Син, пнимаешь, бер счетоводыңны да ашата алмагач, нинди председатель?! – диде шикелле.– Хәзер үк, мин монда утырганда ук он китерт! Амбарда булмаса, өеңнән китерт, чоланыңда ике капчык он торганын күрдем, – диде.

Он китерделәр. Без куандык. Әти генә күңелсез – оялган сымаграк йөрде. Районнан кушканга каршы килә алмагандыр, күрәсең, тик ул кушуның гадел түгеллеген белгәндер. Чөнки эти дә, бүтән колхозчылар кебек, хезмәт көненә эшли иде, ә хезмәт көненә күпме, нәрсә бирелгәнен аңардан да яхшырак кем белсен?!

Кырык сигезенче елларда этиле гаиләләрнең малайлары сигезенче класста

150 сум түләп укыйлар иде. Минем (безнең инде) шуны түләрлек акча булмагач, чак кына мәктәптән борып кайтармадылар. Көч-хәл белән генә юнәттеләр.

Табигате белән актив кеше түгел иде әти. Үз хакын ул беркайчан да дауламады. Ни дә булса таләп итеп, беркая бармады. Ялынырга, соранырга аңа горурлыгы кушмагандыр. Намуслы кеше буларак, авыр булса да, түзә иде. Беркем өстеннән бернинди сүз әйтмәде, кырын-мырын яшәргә яратучыларга да, йөзләренә бәреп, син шундый, дип әйтми иде. Андыйлар белән аралашмый, сөйләшми генә иде.

Соңгы елларда шигырь яза башлавы да шул үзе белән сөйләшүе булгандыр. Шигырьләре үгет-нәсихәттән генә тора. Матур яшәргә кирәк, тату яшәргә кирәк, кеше хакына кермәскә кирәк... – гел шундыйлар.

Соңгы елларда ул, гомумән, сәерләнде. Кеше белән аралашмый башлады. Күбрәк өй тирәсендә йөри иде. Мин язганнарның кайберләрен укып бара иде, ләкин фикерен әйтми иде. Кем белә, бәлки, ошамагандыр да. Миңа әйтергә яхшысынмагандыр. Ләкин миңа хөрмәте зур иде. Әни кызып киткән чакларда да:

– Әниеңә әйт әле, бик тавышланмасын, – ди иде.

Хәзер уйлап-уйлап утырам да: «Кем булган соң безнең әтиебез, аның төп асылы нидә, әгәр аның образын тудырырга кирәк булса, тулаем ул ничек күз алдына килергә тиеш?» – дим. Һәм әти – тормышта үз-үзен таба алмаган, саф күңелле олы шәхес булырга тиеш кеше, дигән фикергә киләм. Хәер, шәхеснең олылыгы аның тормышта ниндидер чинга ия булуында гына түгел. Әти болай да шәхес иде. Ләкин ул тормышта үзенең эзен генә түгел, юлын калдырырга сәләтле кеше иде. Табигать биргән кешелек сәләтенең күбесен файдалана алмады әти. Күрәсең, ул кайвакыт шуны сизгәндер дә. Мин яшүсмер чакта миңа биргән бер тәрбиясе бик гыйбрәтле. Белмим нинди уңай беләндер инде, мине каршына утыртты да:

– Син карак булсаң да, кесә карагы булма, карак булсаң да, зуррагы бул – банк бас, – диде.

Мин аның бу киңәшен еш искә төшерәм, вакланмаска тырышам. Чөнки кешене ваклык бетерә.

Менә, эскиз формасында гына булса да, әти турында уйлануларым. Әле алар болар белән генә төгәлләнмәс, теге яки бу уңай белән әти һәрвакыт мин язганнарда төрле яклары белән күренми калмас.

# ӘНИ

Кайчандыр әни миңа бары тик әни генә иде. Иң элек мине ашатырга тиешле әни, аннан соңрак матур итеп киендерергә мәҗбүр әни, аннан да соңрак, мин теләсә нишләп йөрсәм дә, кисәтеп, миңа сүз әйтергә хакы юк әни. Әни һәрвакыт миңа тиешле булды. Картайгач, эшкә ярамый башлагач та тиеш иде әле ул миңа – дәшми-тынмый, сукранмый-зарланмый гына үз өендә көн итәргә һәм мине мәшәкатьләмичә генә үлеп китәргә тиеш иде.

Мин, дип язгач, мин генә шундый начар, әнинең бүтән балалары, башка әниләрнең үз балалары бик әйбәт, дип әйтергә җыенмыйм. Балалар, күрәсең, әти-әниләренә мөнәсәбәттә эгоист булалардыр. Ихтимал, монда без белеп, аңлап җиткермәгән ниндидер рәхимсез закончалык та бардыр. Ни генә булмасын, без исән әниләребезнең кадерләрен белеп бетермибез – монысы аяныч факт.

Әниләр бары тик тиеш кенә. Дөрес, гомеребезнең башлангыч өлешендә, чыннан да, алар безгә тиештер. Дөньяга китергән икән, ул үз баласын дөньяда, кешеләр арасында йөрерлек, яшәрлек итеп тәрбияләргә бурычлы. Аннан соң инде – ике аякка нык басып йөри башлагач, бары тик без генә тиешледер. Әгәр шушы мораль кагыйдәне йә ана, йә бала боза икән, фаҗига туадыр.

Башкаларны хөкем итәргә алынмыйм, үзем һәм әнием мөнәсәбәтләре турында уйланганда, әни үзенә тиешлесен артыгы белән үтәде, мин аңа мәңгелек бурычлы булып калдым, дип саныйм. Бүтәннәр минем хакта алай ук уйламыйлардыр, әнине кулымнан килгәнчә тәрбияләвем, кадерләп җирләвем өчен кайберәүләр рәхмәт тә әйтәләр. Ләкин мин үземне үзем күбрәк беләм. Минем әнием, бик күп әниләр кебек үк, зуррак хөрмәткә лаеклы әни иде.

Бу сүзләрне мин кыланып та, акланыр өчен дә язмыйм. Нигә кирәк? Башны ташка орсаң да, әни юк инде. Ни язсам да, ни сөйләсәм дә, ул инде ишетми. Күңелне шул гына юата – ул, бу дөньядан киткәндә, риза-бәхиллеген әйтеп китте. Әниләр киң күңелле шул алар.

Әни турында язарга утыруым шуның өчен: беренчедән, каләм кыштырдатырга күпмедер сәләтем бар икән, бурычымның бик азын гына булса да түләү йөзеннән, әниемнең үзенә лаеклы яхшы сүз язып калдырырга тиешмен дип саныйм; икенчедән, әни мине дөньяга китергән әни буларак кына түгел, хатын-кыз образы буларак та миңа кызык. Үткәннәргә борылып карап, әнине искә төшерәм дә, аның турында бүтәннәргә дә сөйлисем килә.

Әни яшәгән ара илебезнең шактый ук катмарлы чорына, тормышыбызның бик киеренке чагына туры килгән заман. 1909 елда туып, 1976 елда вафат булды әни. Шул еллар арасында Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы, 21 нче елгы ачлык, колхозлашу, Бөек Ватан сугышы, сугыштан соңгы илнең яраларын төзәтү вакыты үтеп, авыл әкренләп тарала башлады. Болар барысы да безнең әниләр язмышы аша узды. Элекке заманның оеткысында өлгергән килеш яңа заманда яшәргә, бала үстерергә туры килде аларга.

Минем әнинең характер буларак формалашуына аның җиде ир бала уртасында бер кыз бала булып үсүе дә күпмедер роль уйнагандыр. Ир балалар белән уйнап үскәнгә, ирләр холкы, ирләр тәвәккәллеге бар иде аңарда. Өстәвенә, бабай да үзенең бердәнбер иркә кызын үзенчә иркәләгән – аны өйдәге хатын-кыз эшеннән аерып, үзе белән бергә йөрткән, ирләр эшенә өйрәткән. Әни картайганчы, өй арасындагы хатын-кыз эшенә караганда, ирләр эшен ошатыбрак эшләде. Печәнне ул оста парикмахерлар сокланырлык итеп чаба иде, ат җиксә, иң йолкыш ат та тәртә арасында көяз булып күренә иде, утын ярырга тотынса, иң ботаклы түмәр дә өлгерүе килгән карбыз шикелле шартлап ярыла иде... Гомумән, эшләгән эшен коеп куя иде әни. Безне дә ул эшләмәгән өчен түгел, ә рәтсез итеп, әштер-өштер генә эшләгән өчен ачуланды.

Хатын-кыз эшенә килгәндә, әнинең үзенә дә «бәйләнеп» була иде. Сугыш чорында оекка, күлмәк-ыштанга, бишмәт-бүреккә салган ямаулары шактый ук тупас булып, кеше күзенә төртелебрәк торалар иде. Ничә бала үстереп, аларның өс-башын ничә еллар карап та өйрәнә алмады әни ямау осталыгына. Яшьлегендә ямаулы кием кимәгәнгә, ямаулы киемгә эчке бер нәфрәте дә бар иде аның. Безгә дә, «ямаулы күлмәк киярга язмасын» дип, теләк тели иде.

Ашарга пешергәндә, әнинең кулы ирләр кулы кебек мул иде. Шуңа күрә пешергән ашы ашап туймаслык тәмле була иде.

Әнидә ирләр характеры булу безне сугыш вакытында ачлык-ялангачлыктан саклап калды. Ачыксак та, шешенмәдек, капчык тотып соранырга чыкмадык,

ямаулары матур ук булмаса да, өстебездә бишмәт, башыбызда бүрек булды. Сугыш башланганда, сыерсыз калган булганбыз, бозаудан алып үстереп, берике елдан соң әни безгә үз сыерыбызның сөтен эчертте.

Кайчакларда ялкауланып китеп, эшләргә тиешле эшем эшләнми торса, әнине искә төшерәм дә оялып, эшкә тотынам. Эшкә уңганлык мәсьәләсендә әнинең иң борчылган баласы мин идем. «Йокыны бигрәкләр дә яратасың, үзең генә калгач, ачка үләрсең инде, хәерсез», – дип ачулана иде мине. Иртән йокыдан уятканда: «Тор, оятсыз, өстеңә кояш төшкән бит. Кешедән оялмасаң, кояштан оял», – дип уята иде.

Без хәзер бала тәрбияләүдәге бөтен кимчелекләребезне мәктәпкә сылтыйбыз, еш кына үзебезне оста итеп аклыйбыз. Безнең әни, безнең белән ни генә булмасын, үзен йә гаепле итеп, йә бәхетле итеп тоя иде. Үзенчәлекле итеп ярата иде ул безне. Аның балаларына булган мәхәббәтендә аз гына да ясалмалык юк иде, хәтта аның яратуы кыргыйларча иде бугай. Ул беркайчан да, беребезнең дә башыннан сыйпап, и тәтием, и бердәнберем, улым, кызым, дип әйтмәде шикелле, безгә исемнәребез белән генә эндәшә иде. Кыек эш эшләсәк, шактый ук саллы итеп арт якка сыларга һәрвакыт әзер иде. Ләкин ул суккан саен, үкереп җылап, аның итәгенә ныграк ябыша идек. Бераз тынычлангач: «Яле, ни булган икән?» – дип, күлмәк итәгебезне күтәреп карый иде дә: «Берни дә булмаган, икенче тапкыр сүземне тыңларсыз, кушканны эшләрсез», – дип, суккан җиренә тфү, тфү әйтеп, елмаеп куя иде.

Бала чакта, әни мине яратмый, дип уйлый идем. Чөнки тал чыбыгы күбрәк миңа эләгә иде сыман. Хәзер уйлап-уйлап торам да, тал чыбыгы әзрәк эләккән, дигән фикергә киләм. Бигрәк тиктормас идем шул. Әле дә хәтеремдә, кая да булса киткәндә, мине абый кулына тапшырып, «бу тәре кисәвен карап тор, берәр нәрсә эшләмәсен», дип борчылып китә иде. Әмма мин барыбер «берәр нәрсә эшләргә» җай таба идем шикелле. Шундый «егетлекләр»емнең берсе өчен әнидән миңа шактый ук нык эләкте. Хәтта ничаклы гына түземле булсам да, җыладым. Һәм кыйналган гарьлектән, әнигә үч итеп, өйгә кайтмаска тәүбә итеп, чормага тутырылган печән астына кереп качтым. Башта мине эзләгәннәрен көтеп яттым. Эзләүче булмагач, кире чыкмакчы идем дә, йокыга кителгән. Озак йоклаганмын, ахрысы, әни тавышына уянып киткәндә, караңгы капкан иде инде. Әни мине эзли иде. «Кайларга гына китте соң, Ходаем? Эзләмәгән җир калмады бит.» Озак эзләде әни, миңа күз-колак булмаганы өчен абыйны да ачуланып ташлады. Ә мин, явыз, шуннан тәм табып, печән астында ятам. Чормага да менеп төште әни, тынымны да чыгармадым. Төн буе абый белән эзләде мине әни, барыбер чыкмадым. Шуннан әни: «Нигә генә тидем икән, ниләр генә булды икән?» – дип җыларга тотынды. Аннары да чыкмадым. Әнине кызгандым шикелле кызгануын, тик рәнҗүем басылмаган иде әле.

Белмим, озак газаплаган булыр идемме әниемне, печән тузаны мине тоттырды. Әни: «Нишләргә инде, нишләргә, әллә соң күл төбеннән эзләп карыргамы?» – дип, баскыч төбендә җылап утырганда, мин төчкереп җибәрдем... Печән астыннан абый мине казып алды, әни кулына тоттырды. Әнинең кыйнаячагына әзерләнеп, куырылып килдем. Ләкин әни «хәерсез»дән башка сүз әйтмәде. Мине гаҗәпләндереп, үзем белгән гомеремдә беренче тапкырдыр, мине кочаклап җылады. Шуннан соң әни, миңа сугарга дип кизәнгәндә дә, сукмый кала иде. «Кыйнап, игә китереп булмый бу кире тәрене», – дия иде. Аналарга хас сизгерлек белән ул минем йомшак ягымны белеп алды. Миңа эш кушканда, мине мактый иде. «И, безнең Туфанга әйттеңме, ул аны хәзер эшли, безнең Туфанга әйтеп

тә торасы юк, казларны үзе алып кайтып яба ул», – дип эшләтә иде. Һәм мин, ни хикмәттер, йөгереп-йөгереп эшли идем. Ул гадәтем әле дә сакланып калган. Мине ачуланып, сүгеп, приказ биреп бер эш эшләтә алмыйлар, мине эшләтер өчен «җил ягына салам кыстырыбрак» эш итәргә кирәктер. Ә бит ул холык миңа әнинең үзеннән күчкән. Әгәр бригадирлар: «Фәлән эшкә барасың», – дип кенә тәрәзәдән кычкырып китсәләр, әни өйдән дә чыкмый иде. Әгәр инде: «Халисә яки Халисә апа, фәлән эшкә чыгарсың инде, ярыймы», – дисәләр, өйдәге бөтен эшен ташлап, колхоз эшенә китә иде һәм пәри шикелле эшли иде. Мондый холык әнидә генә түгел, әнинең мин белгән абыйларында да, энесендә дә бар иде. Барысы да горурлар, әз генә кимсетүгә дә түзә алмый торганнар. Ул горурлык хисенең үземдә булуына сөенеп бетә алмыйм.

Әни үз нәселе белән горурланырга, хәтта мактанырга да ярата иде. Безне ул һәрвакыт, кешедән ким булмагыз, дип өйрәтте. Менә бер мисал. Бервакыт абый белән бәләкәй арба тартып, урманга утынга бардык. Безнең белән күрше малае да бар иде. Кайтып килгәндә, тыкрыкта безне әни куып тотты. Арба тәртәсен безнең кулдан тартып алып, арбаны җилтерәтеп алып китте. Без көчкә арба артыннан өлгердек. Ишегалдына кергәч: «Ике күсәк, икесенә бер карга оясы төяп кайтып киләләр бит. Шәһитнең берүзенә икегезнекеннән күп. Ничек оялмый авылга кердегез?» – дип, безне ачуланды. Абый: «Ничек төйик, арбаның күчәре чатнаган бит», – дигәч кенә тынычланды. Безне болай итеп ачуланганда, әнинең күңелендә малга хирыслык, күбрәк булсын, дигән комсызлык хисе ятмаган, әлбәттә. Үз балаларының бүтәннәр алдында сынатуына гына ачуы чыккан. Бервакыт ишетеп калдым – фронттан кайтып, берничә айлар өйдә торганнан соң, этигә дә әйтеп куйды әни: «Дүрт ел йөреп, бер урдин да тагып кайтмагансың», – диде. Әти аңа сугышның нәрсә икәнен сабыр гына аңлаткач та, әни килешмәде. «Үзем барган булсам, икедән дә кимне алмыйча кайтмый идем», – диде. Бу сүзләрне ул әтинең үзенә генә әйтте. Ә башкалар алдында әтинең «За отвагу» медален күкләргә чөеп мактады. Ул аны медаль димәде, урдин дип атады. «Ул урдинны иң куркынычлы сугышта җиңгән өчен генә бирәләр икән», – дип сөйләп йөрде.

Абыйны укытып, зур кеше итә алмаганына бик үкенде әни, сеңелнең укымавына да борчылды. Минем укуыма сөенеп туя алмады. Мин Мәскәүгә укырга киткәч: «Безнең Туфан бик зур кешегә укый, райком сиклитарыннан да ким урынга куймаячаклар», – дип мактанып йөргән. Мин районыбызга кайтып, «зур кеше» була алмагач, бераз кәефе төшеп йөрде. «Мәскәүдә биш ел укып, колхоз председателе дә була алмадың», – дип әйткәли иде. Газета-журналларда бәләкәй-бәләкәй хикәяләрем күренә башлагач, әни ул газеталарны урам буйлап кеше саен күрсәтеп йөргән, мине күккә чөеп мактаган. Әгәр дә минем «бөеклегемә» тел тидерүче булса, аңа инде сүзнең матурын сайлап тормаган.

Бервакыт шулай кибеткә шикәр алырга кергән дә, кибет эчендәгеләргә минем хикәя басылган гәҗитне күрсәткән. Шунда бер агай-эне саксызлык күрсәтеп: «Ни, Туфан да булдымы язучы! Аның кебек кенә мин дә язам», – дигән. Эләккән тегеңәргә әнидән! Кибеттән чыккач, этигә сөйләгән: «Бер сүз әйтеп үтердем үзен», – дигән. «Нәрсә дип әйттең соң?» – дип сораган әти. «Минем улым синең сыман кибет төбендә баш төзәтергә ялманып тормый. Кирәк икән, яшьнегә белән ала аракыны, синең сыман бирәннәргә эчерергә, дип әйттем», – дигән әни. Мондый «аргументтан» соң, әлбәттә, теге агай-эне хурлыкка калган, миңа хөрмәт бермә-бер арткан.

Мин авылга кайтканда, әни һәрвакыт «әйбәт кәчтүн-чалбар киеп кайт,

эшләпә киеп кайт, фифирусның җуанын авызыңа кабып кайт», – дип, кабат-кабат тукый иде. Акчаны үзем белән алып кайтмаска, почта белән җибәрергә куша иде. Нигә икәнен соңрак белдем. Миннән килгән акчаны почтага барып алганчы, әни укый белмәгәнгә салынып, кибеттә акча язуын кешеләргә укыта икән. «Бу җитмәсә, тагын җибәрәм, дип әйткән әле Туфан», – дип сөйләнә икән. Белмим, ничә тапкыр җибәргәнмендер (һәрхәлдә, күп түгел) әниләргә акча, әмма авыл халкының хәтерендә миннән акча явып кына торган кебек булып калган. Барысы да әни аркасында. Безне яхшы итеп күрергә һәм күрсәтергә теләве бик көчле иде аның. Ул әдәби, фәнни китаплар укып, философик категорияләр белән фикер йөртми иде. Философиясе бик гади иде аның: «Ил алдында хур булма, кеше көлдермә, яманатың дөньяга чыкмасын» – аның безне тәрбияләүдәге төп принциплары шул булды. Балаларының кимчелекле яклары өчен бик борчылды. Икейөзлелекне яратмады әни. Хәер, икейөзлеләнүне күпләр яратмый, әмма яратмасалар да, кайберәүләр еш кына үзләре икейөзлеләнәләр. Кешенең алдында бер төсле сөйләп, артында икенче төрле сөйлиләр. Әнидә ул булмады инде. Әгәр җененә туры килмәгән кеше булса, ул кеше әллә кем булса да, аның белән исәнләшми иде. Әти белән бергә өйгә төрле кешеләр кайта иде. Әни аларның күбесен белә. Кайберләрен ул ачык йөз белән каршы ала, хәзинәдә булганын барын да өстәлгә куя, кайберләренә «закуска»ны да ярты телем ипидән арттырмый. Әле аны да өстәлгә почмактан гына ыргыта иде. Соңыннан әти сабыр гына әнигә алай ярамаганлыгын аңлата.

Төчеләнүне белмәде әни. Безгә ни генә эшләсәк тә, рәхмәт әйтми иде. Бүтән әниләр: «И балам, менә рәхмәт, күчтәнәчләр алып кайткансың», – дигәндә, әни, бер сүз әйтми генә, күчтәнәчне алып куя иде. Ул хакта бер тапкыр үзенә дә әйттем. «Шул сүзне ишетер өчен генә алып кайттыңмыни?» – дип, авызымны томалады. Үзе дә ул яхшылыкны рәхмәт ишетер өчен яки әҗәткә эшләми иде. Эшли икән яхшылыкны, болай гына эшли. Аның өчен яхшылык эшләү гап-гади, табигый бер нәрсә иде. Хәер, әни генә түгел, аның бөтен туганнары да, кеше алдында таралып китеп, кешегә мактау сүзләре яудырып, сөйкемле сөяк булып күренә белмиләр иде. Алар үзләренә карата эшләгән яхшылыкны, изгелекне күңелләре белән кабул итеп, эчтән генә рәхмәт укыганнардыр, күрәсең. Шуңа күрә кемдер биргән бүләк яки күчтәнәчне кадерләп саклап тота иде әни. Бервакыт күрше Җиһан апа белән бергәләп, сандык актарганнарын читтән генә күзәтеп торырга туры килде. Мин әнине алай матур итеп сөйли белә дип уйламый идем. Ул сандыкта ничә еллар буе сакланган яулыклар, сөлге-тастымаллар, оеклар, күлмәкләрне кайчан кем алып биргәнен әйтеп, аларга рәхмәтләр укыды. Сандыктан алган һәрбер әйберне шундый итеп сыйпап-сыпырып куя барды, аның кул хәрәкәтләренең салмаклыгында күңелендә әйтелми калган әллә ничаклы рәхмәт сүзләре ята иде. Табигый кыргыйлык бар иде шул әнидә.

Әтигә карата мөнәсәбәте бик кызыклы иде әнинең. Ул турыда мин әти турында язганда яздым, монда кайбер вакыйгаларны гына өстәп куям. Беренчедән, шуны әйтергә кирәк – безнең әтиебезнең ир буларак дәрәҗәсен төшерерлек, күңел рәнҗетерлек кечкенә генә дә кыек эш эшләмәде. Әтинең фронттан кайтканын өзелеп көтте. Безгә һәрвакыт әтине олылап кына сөйли иде. Әти кайткач, еш кына аны теге яки бу уңай белән битәрләргә ярата иде, тик беркайчан да чамадан чыкмады. Әтинең безгә кулы белән кагылу түгел, теле белән бер мыскал ачулы сүз әйтмәячәген белгән хәлдә дә, «әтиегезгә әйтәм» дип «куркыта» иде. Тормышның вак-төяк, әмма җанны ашый торган

мәшәкатьләреннән еракта, әнинең ышыгында яшәде әти. Безне дә әтине олыларга өйрәтте әни. Бервакыт, алтмыш ничәнче елда бугай, абый белән авылда очраштык та, бакчага чыгып, әти-әни күзеннән кура җиләкләре арасына качып, очрашуны билгеләп үтмәкче булдык. Шешәнең бөкесен генә ачкан идек, әллә каян әни килеп чыкмасынмы! «Оятсызлар, – диде ул, – тапканнар урынын! Әтиләреннән качып, эчеп утыралар. Әтиегез юкмыни сезнең, зинадан тудыгызмыни сез? Олы кеше булганнар, имеш, әтиләрен онытканнар». «Үзең бит әтигә күрсәтмәскә кушасың!» – дигән булдык без. «Мин ни әйтмәм, үз башыгыз юкмыни?» – дип, пырлап китеп тә барды. Әтине чакырып китердек. Стаканны кулына гына алган иде әти, әни тагын пәйда булды. «Оятсыз, – диде ул әтигә, – намазлык өстендә утырасы башың белән малайларың алдында авыз күтәреп эчеп утырасың», – диде. «Үзең әйттең бит әтине чакырырга», – дидек. «Мин ни әйтмәм, үз башы юкмыни аның?» – дип, тагын пырлап китте әни.

Әнинең өстән генә караганда һичнинди логикага сыймый торган сүзләрендә гаҗәеп төгәл эзлеклелек ятканын соңрак аңладым мин. Олылый белергә һәм олы була белергә өйрәтү дәресе иде ул.

Икенче тапкыр әни мине әти үлгәч шаккатырды.

Әти караватта ята. Әни аның баш очында утыра. Беркемгә бер сүз әйтми, әтигә караган да тып-тын гына утыра. Шунда ул кинәт, өйдәге бөтен кешене аптырашта калдырып: «Бәхетең булган икән, миннән алда үлдең», – диде дә тагын тынып калды. Бөтенебез бер-беребезгә карашып куйдык.

Әтине җирләгәч, бу турыда әнинең исенә төшердем. «Нәрсәсенә аптырадың? – диде ул. – Мин алдан үлсәм, йөрер иде кая барып бәрелергә белмичә. Кайсыгызга кирәк? Монда кайтканда да, китәргә генә ашыгасыз. Әти-әни кайгысымыни хәзер, балагызны карарга да вакытыгыз юк».

Әнинең ничаклы хаклы икәнен еллар үткән саен ныграк аңлый барам. Карчыклары үлгән кайбер язучы агайлар, чыннан да, кая барып бәрелергә белмичә интегәләр. Хатын-кызсыз без бигрәкләр дә булдыксыз икәнбез шул.

Әни бик озак чирләде. Сулышы кысыла иде, ягъни бронхиаль астма. Каһәр төшкән чир икән ул. Бу чир белән чирләүче кайберәүләр яхшы тәрбия күреп, үз җайлары белән бик озак яшиләр. Безнең әни андый түгел иде шул, тыныч яши алмый иде, һәм шуның нәтиҗәсендә, авыруы көчәйде. Чирләве белән һич кенә дә килешә алмыйча, чирне җиңеләйтү өчен әни бик күп дару эчте. Дару күп эчүнең зарарлы икәнен әйтеп торсак та, килешмәде...

Интегеп үлде әни. Һәм без аңа берничек тә ярдәм итә алмадык. Хәзер уйлап-уйлап утырам да, ярдәм күрсәтеп булгандыр, мәгънә, теләк җитеп бетмәгәндер сыман тоела. Беләм, бу бары тик үз-үзеңне юату гына. Әгәр дә әни исән булса...

Сулар үргә таба акмый. Хәерле булсын. Әни безгә рәнҗеми китте – бердәнбер юаныч шул гына.

Авыл зиратында әти белән әнинең каберләре янәшә. Икесе бер чардуган эчендә. Икесенә бер таш...

# ТЕАТРЫБЫЗНЫҢ ӘЛМӘНДӘРЕ

Кем турында гына яза башласаң да, әлбәттә, үзең турында килеп чыга. Менә хәзер дә Туфан абый хакында дигән булып, үзем турында язам.

Без бала чакта көз көне әти-әниләр кырдан көнбагыш җыялар иде. Беркөн иртән капчыклар, агач тукмаклар алып чыгып китәләр дә көн кичкә авышкач, 4-5 капчык көнбагыш җыеп алып кайталар. Ул капчыклар кышка кадәр мич башында саклана. Озын кышкы кичләрдә без бөтен гаиләбез белән (7 кеше) тезелешеп утырып, көнбагыш чиртә-чиртә, татарча спектакльләр карый идек. Шул чорлардан күңелгә кереп калган унлап әсәр бар. Алар арасында Туфан Миңнуллин пьесаларыннан «Авыл эте Акбай», «Әниләр һәм бәбиләр» һәм, әлбәттә, «Әлдермештән Әлмәндәр». Аларны кабат-кабат күрсәтәләр иде – ничә капчык көнбагыш чиртелгәндер әлеге әсәрләргә хозурланганда. Иртән, кем эшкә, кем мәктәпкә таралышып бетәләр. Мин – бәләкәй, әби белән өйдә калам. Кич утырудан соң келәмгә анда-санда коелган көнбагыш кабыкларын тузан суырткычы белән суырту – минем вазифа. Кичтән караган спектакльне тагын бер кат башымда әйләндерә-әйләндерә мин фирүзә төсендәге «Ракета» тузан суырткычы белән келәмне суыртам. Ул чакларда мин үзем дә «Ракета» сыман, Туфан абыйның һәрбер фикерен йотып, сеңдереп бара идем.

Сигезенче сыйныфта укыганда, мәктәптә татар теле укытучысы Розалия апа җитәкчелегендә «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрен спектакль итеп куя башладылар. Өлкән сыйныфтагы актив кызлар бу эшкә җиң сызганып тотынганнар, егетләр катнашырга атлыгып тормаганга, рольләрне үзара бүлешкәннәр. Кеше җитмәгәч, мине дә чакырдылар. Минем шулкадәр Әлмәндәр картны уйныйсым килә иде, аны егет кеше уйнарга тиеш, кызлардан нинди Әлмәндәр инде дип, әрсезләнеп, әлеге рольне миңа тапшыру дөрес буласына барысын да күндердем һәм уйнадым. Камал театры спектакленең һәр мизгелен яттан белгәнгә, Шәүкәт абыйның тавышы колакта яңгырап торганга, мин бу рольне бик җиңел башкардым – авылдашлар да яратып карадылар дип истә калган.

Әлеге спектакльне әзерләгәндә, бөтен драматургия законнары буенча минем күңелемдә каршылык туды (каршылык – драматургиянең нигезе!): «Нишләп әле без кайдадыр Казанда яшәп яткан Туфан Миңнуллин әсәрен уйныйбыз?» «Үзебез турында үзебез язып, шуны уйнарга кирәк!» – дигән фикергә килдем мин һәм төннәрнең берсендә инде йокларга яткан җиремнән торып, иске дәфтәрләрдә калган чиста битләрне ертып алып, карандаш белән пьеса яза башладым. Шул төнне яткан җиремнән тормаган булсам, мөгаен, киләчәктә драматург булып китмәс тә идем. Яза башладым, әмма яза белмим. Кабат Туфан агага мөрәҗәгать итәргә туры килде. Мин аның пьесаларын кабат-кабат укып, пьеса ничә биттән торасын, репликалар, ремаркалар ничек языласын өйрәндем. Һич арттырусыз әйтәм, мин Туфан абыйның пьесаларындагы хәреф санына кадәр санадым, чөнки кульязма белән басмада күләм төрле. Нинди күләмдә кирәк икәнен аңлар өчен мин Туфан абыйның бер биттә ничә юл, бер юлда уртача ничә хәреф икәнен санадым һәм математик формулалар кулланып, аның бер басма бите минем ничә бит кульязмама тәңкәл килгәнен исәпләп чыгардым! Беренче пьесам шулай туды, «Җәйге төннәрдә» дип исем бирдем, ул чакта миңа 14 яшь иде.

Соңрак, артистлыкка укырга кергәч, Туфан абыйны Камал театрында еш күрергә

туры килә иде. Иң кызыгы: без аның белән бер мәртәбә дә утырып, иҗат турында сөйләшкәнебез булмады. Бер яктан – үкенечле, икенче яктан – ә нәрсә турында сөйләшәсең? Ул әйтәсе сүзләрен әсәрләрендә әйтә, мин ул сүзләрне хәрефенә кадәр санап өйрәндем. Минем премьераларыма ул һәрчак килә иде, кулны кысып котлый, елмая, күзгә туры карый – ә Туфан ага яратмаган кешеләренә борылып та карамый иде, дип беләм. Шуңа мин моны хәер-фатиха итеп кабул иттем.

Тагын бер хатирә. 2007 елда миңа Язучылар берлегенә әгъза итеп керергә тәкъдим иттеләр, аның өчен өч язучыдан тәкъдимнамә кирәк. Берсен Юныс абый Сафиуллин бирде, икенчесен – Данил абый Салихов. Тагын берәү кирәк. Кемнән сорарга? Камал коридорында Туфан абыйны очраттым да куркып кына мөрәҗәгать итәргә булдым. Туфан Абдуллович: «Илгиз, иртәгә Дәүләт Советына кил, язып куярмын, алып китәрсең!» – диде. Мин инде оныткандыр дип, анда кертмәсләр дә дип уйлап, Дәүләт Советына бардым, бүлмәсенә керттеләр. Туфан абый бер бит кәгазь алды да тәкъдимнамәсен укып та бирде – онытмаган!

Мин дә онытмыйм. Туфан ага белән бәйле бер мизгелне дә. Күзне йомсам, хәзер дә Камал театрында «Дивана» спектаклендә утырган кебек булам (Режиссёры Ф.Бикчәнтәев). Мин ул премьераны өч көн рәттән, залның өч төрле җиреннән утырып карадым – өч көн рәттән бер үк урыннарда еладым. Туфан аганың теле тормыштагыдан да чынрак кебек. Бер җөмләсе белән ул тамашачыны аяктан егып салырга, дөньяңның астын өскә әйләндерергә мөмкин. Сәйдәшев көйләре кебек Туфан абыйның сүзләре татар кешесенең күңел ишекләренә шакып тормыйча гына үтеп керә.

Бүгенге көндә без Татар Дәүләт «Әкият» курчак театрында «Әлдермештән Әлмәндәр» пьесасын сәхнәләштерәбез. Эш дәверендә тагы бер кат инанам, Туфан абый диалогны шулкадәр оста үрә, ул аның чигү чиккән сыман килеп чыга: бер сүз артык та, ким дә түгел. Артистлар аның текстларын бер-ике укып чыгуда истә калдыралар – димәк, автор фикерен төгәл, аңлаешлы итеп, тормышчан тел белән әйтеп бирә алган.

2012 елның апрель азагы иде бугай. Камал театры каршында чия төсендәге автомобиль тора. Ишек ачылды да, аннан Туфан абый төште, мине үз янына чакырып алды. Ни әйткәнен хәтерләмим, хәлләр сорашты бугай, бик җылы сөйләште. Бу соңгы очрашуыбыз иде...

Ничек шулай булган соң: тормышның ачысын-төчесен шактый татыган өлкән яшьтәге әби дә, физик хезмәт белән көн күргән әти-әни дә, төрле яшьтәге дүрт бала да телевизордан күзләрен алмыйча «Әлдермештән Әлмәндәр»не караган? Мөгаен, күңелләрне сафландыру өчен, җаныбызны бераз назлар өчендер... Үзебез дә моны аңламастан, без аксакалыбыз, чын мәгънәсендә Ил агасы булган Туфан абыебызның зирәк фикерләрен ишетеп, милли кыйблабызны барлаганбыздыр.

**Илгиз ЗӘЙНИЕВ,**
*драматург*

*Казакъ әдәбияты аксакалы Абайның тууына 175 ел*

# АКЫН АБАЙ ИҖАТЫ БЕЗГӘ БИК ЯКЫН

Кардәш казакъ халкының бөек шагыйре һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе Абай Конанбай улы Татарстаннан бик еракта – Алтай тауларының бер өлеше булган Чыңгызтау тирәләрендә туса да, безгә бик якын шәхес. Олуг шагыйрьләребез аның иҗатын белгән, хөрмәт иткән. Хәзер дә беләләр. Хәер, Абай үзе дә яшьли татарлар белән аралашып үскәнлеген искә ала. Язмыш татарны ерак-еракларга тараткан бит. Унсигезенче йөзнең икенче яртыларыннан Россия биләмәсенә кергән Җидепулат (Семипалатинск) өлкәсендә дә солдат яки тәрҗемәче вазифасын үтәүчеләр дә, хәлфә-муллалар да, сәүдәгәрләр дә шактый күп булган. Ыруг солтаны вазифасын үтәүче рәвешендә Каркаралы шәһәрчегенә баргалап йөргән Конанбай да анда татар сәүдәгәрләре өенә төшүне хуп күргән. Башлыча шуларның теләген дә үтәп, ул биредә мәчет салдыруга да рөхсәт алган. Нигездә, үз хисабына шул мәчетне төзеткән. Мәчет ачылышында яшүсмер Абай да катнаша. Шунда ул беренче мәртәбә шушы төбәктә яшәп иҗат иткән Шөҗе, Балта кушаматлы акыннар белән очраша. «Балта» дигәч тә, күзалдына «үткер телле» сатирик шагыйрь килеп баса. Тормышта ул кем булгандыр – әйтә алмыйм.

Абайның үз заманына кагылышлы уй-фикерләрен чагылдырган «Гаклия» хезмәтен искә төшерик. (1981 елда чыккан китапта мин аны «Хикмәтле сүз» рәвешендә тәрҗемә иттем.) Анда татар-нугай солдат буларак та, бик күп хезмәт куеп, мал табучы сәүдәгәр сыйфатында да, хәлфә һәм мулла буларак та, уңай яктан искә алына. Әйе, әлеге язманы укыгач, Абайның Евразия буйлап таралып яшәргә мәҗбүр ителгән милләтемнең авыр язмышын аңлавын да, аларның һәрчак белемгә омтылганлыгын чамалавын да тоясың. Киләчәктә дә безгә бөек акыннарыбыз – Абай, Тукайларыбыз әйтеп калдырганча, дус, тату яшәргә насыйп итсен.

Абай Конанбаев 1845 елның июль ахырларында, казакъча әйтсәк шилде (чиллә) белән тамыз айлары аралыгында туган. Ул чорда казакъ халкы кыш айларында бер-ике дистә чамасы саман өйдән торган кечерәк авылда – кышлакта яшәгән. Җәй айларын җәйләүләрдә уздырган. Абай Чыңгызтау тезмәләре аралыгындагы Каскаболак җәйләвендә туган. Аның элекке карт мулла кушкан исеме – изге китапларда теркәлгән Ибраһим. Авылчарак итеп әйткәндә – Ибрай. Әмма аны тәрбияләгән әбисе белән әнисе яшьтән үк, яратып, «Абаем» дип йөрткәнлектән, ул шагыйрь буларак та шул исем белән таныла. Аның чордаш һәм якташ акыннарының үз атамалары тагын да үзенчәлеклерәк: Шөҗе (чебеш), Балта булган.

Атасы, солтан Конанбай оештырган кышлак мәктәбендә Абайга беренче хәреф танытучы мулла да – Габитхан исемле татар. Бу яшь мулла җәй айларында да солтанның анасы Зәрә (мулла кушкан исеме Зөһрә буладыр), уртанчы хатыны Олҗан җәйләвенә еш килеп йөргән. (Олҗан – олы җанлы мәгънәсендәге исем. Без кулланган Гөлҗан, Батырҗаннар кебек.) Абайны һәм аның ике бертуганын тәрбияләп үстергән бу ике ана шигъри җанлы шәхесләр була. Болар Габитханны кичләрен китап укыр өчен дип чакыралар (Иван Тургеневның әнисенең – татар карчыгының да кичләрен хезмәткәрләреннән китап укытып «тинтерәтүен» искә алалар ич). Мулла боларның иркен тирмәсендә җыелган кешеләргә «Йосыф-Зөләйха,» «Идегәй», «Кыз җибек» (Ефәк кыз) кебек борынгы китапларны кычкырып укый торган була. Абай беренче төрки әдәбияты үрнәкләре белән шушы рәвешле таныша. Шактый кырыс холыклы Конанбай солтан икенче хатыны җәйләвенә ике-өч көнгә бер генә килеп чыккалаганлыктан, Абай шушы ике ана (каенана белән килен) тәрбиясендә, шушы мохиттә үсә.

Абайга ун яшь тулгач, аны Җидепулат шәһәрендәге «укымышлы нугай мулла»

Әхмәт Риза хәзрәт мәдрәсәсенә урнаштыралар. Бу шәһәргә илтүче өч көнлек юлда аны атасының ярдәмчеләренең берсе белән Габитхан озатып бара. Әлбәттә, мәдрәсәдә ул «Абаем-Ибраем» дип түгел, Ибраһим буларак теркәлә. Шушы Әхмәт Риза мәдрәсәсендә укыган вакытта чын-чынлап иҗат итә башлый. Монда ул борынгы төрки һәм фарсы әдәбияты үрнәкләре белән тирәнтенрәк таныша. 1850-1860 елларда бу шәһәрдә берничә мәдрәсә булган дип язалар. Бу мәдрәсә шәкертләре үзара да аралашканнар. Казакъ әдәбиятына хас рәвештә, алар арасында шигъри әйтеш-ярышлар да оештырылгандыр. Абай кылкубыз (скрипка) һәм думбрада уйнарга да оста булган. Ул тудырган берничә җырның озак вакыт халык арасында таралган булуын да искә алалар.

Һәрхәлдә, Абайның беренче җитди шигырьләре шушы шәһәрдә языла. Булачак ыру җитәкчеләренең берсе рәвешендә ул русча да белем үзләштерергә тиеш саналган. Шул ук елларда ул казакъ-рус  мәктәбенә дә йөргән. Анда ул рус әдәбияты үрнәкләре белән таныша. Һәм соңрак А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов вә алар дәрәҗәсендәге рус шагыйрьләре әсәрләрен казакъчага тәрҗемә дә итәчәк әле. Пушкинның «Евгений Онегин» поэмасындагы «Татьянага хат» өлешен көйләп җырлау рәвешенә дә китерәчәк. Һәм казакъ яшьләре ул җырны бик яратып кабул итәчәкләр.


Абайның кайбер әсәрләре Акмола каласында  чыга башлаган «Дала вилаяте газетасы»нда нәшер ителгән. Казакъ галиме Бабаш Әбелкасыймов бу газетаның 1888 елдан чыгуын, гасыр ахырынарак аның тиражы 1300 данә булганлыгын белдерә. «Анда акын Абай, Шөҗе шигырьләре, Ибрай Алтынсарин хикәяләре басылган» дип яза. Бу газетаның мөхәррирләре кем булганлыгын ачыкламаганмын. И.Алтынсарин казакълардан беренче рәсми хикәяче буларак танылa. Аның байтак вакыт Оренбург каласындагы казакъ-рус мәктәбендә укытканлыгы мәгълүм. «Дала вилаяте...»ндә татарча әсәрләрнең тәрҗемәләре нәшер ителгәнлеген дә хәбәр итә Бабаш әфәнде. Әмма кемнәрнең нинди әсәрләре икәнлеген язмый.

1870-1883 елларда Ташкентта казакъ телендә атналык «Төркестан вилаяте газетасы» да нәшер ителгән. Мөгаен, Абай шигырьләре әле анда чыгарга өлгермәгәндер. Үзбәк телендә шул ук исемдәге атналык газета 1917 елда гына чыгудан туктый. Бу газеталар безнең галимнәр тарафыннан өйрәнелмәгән. Анда татар әдип һәм журналистларының әсәрләре дә нәшер ителгәндер, шәт. Газета мөхәррирләренең кайберләре безнең милләт вәкилләре булган бит...

Абай Конанбаевның шигырьләре бик соң туплап чыгарыла. «Казакъ акыны Абай Конанбаевның өлеңі» китабы 1909 елда, автор вафатыннан соң биш ел үткәч чыга. Ул Санкт-Петербургта кырым татары Ильяс Браганский басмаханәсендә нәшер ителә. Казакъ телендә икенче китабы – «Абай тирмәсе» җыентыгы 1916 елда Оренбургта бертуган Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсендә чыга. Дәрдемәнднең Абай шигырьләрен үз иткәнлеген берничә кеше искә алган. Акынның өченче китабы: «Абай Конанбай өлеңнері» Казанда 1922дә һәм дүртенчесе шул ук елда Ташкентта «Таңдамалы өлеңнер» исеме белән нәшер ителәләр.

Татар телендә әлегә Абайның ике җыентыгы нәшер ителгән. Казанда 1947 елда шагыйрь Мәхмүд Максуд тәрҗемәсендә акынның «Шигырьләр һәм поэмалар» китабы басылган иде. Ә 1981 елда «Шигырьләр һәм поэмалар.  Хикмәтле сүз» җыентыгын мин туплап чыгардым. ( Соңрак нәшер ителгән «Абай энциклопедиясе»ндә ул җыентыкны төзеп чыгаручы, дип ялгыш «А.Хәмидуллин» дип күрсәтелгән. Әсгать ага Хәмидуллин ул елларда сәяси әдәбият нәшрияты «Казахстан»да баш мөхәррир иде.) 1980 елда мин Сабит Мокановның 80 еллыгына багышланган чараларда катнаштым. Башкортстаннан анда Равил Бикбаев та килгән иде. Шушы юбилей алдыннанрак кына Казакъстанда Абайның тууына 135 ел тулу уңаеннан чара да уздырылган икән. Шуны искә төшереп, кайбер каләмдәшләр: «Без Г.Тукай, М.Җәлил, М.Гафури  китапларын һәр биш ел саен нәшер итәбез. Татар, башкорт кардәшләребез безнең классикларыбызны сирәгрәк искә ала», дигәнрәк сүзләр дә әйткәләде. Шуннан соң мин Абайның 1977 елда «Гылым» басмасында нәшер ителгән ике томлыгын  алып кайттым. Республика җитәкчеләреннән рөхсәт алгач, Абай әсәрләренең бер томлыгын тиз арада әзерләдек.

Бу эштә миңа иң күп ярдәм итүче Нури ага Арслан иде. Казакъ телен һәм әдәбиятын иң камил белүче буларак, кереш сүзне язуны да аңа йөкләмәкче идек. «Сибгат Хәкимне




үгетлә, ул язса, отышлырак булыр», – диде. Һәм Сибгат абый да ул бурычны үтәргә бик теләп алынды. Шул ук Нури ага: «Абайның берничә шигырен Хәсән Туфан да тәрҗемә итте. Барып ялын әле, шуларны табып бирсен. Җыентыкның дәрәҗәсе арта төшәр», –дигән иде. 1950 еллар ахырында Казакъстанда татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре уздырыла. Анда безнең күп кенә дәрәҗәле шәхесләребез катнаша. Алар арасында яңарак кына сөргеннән кайткан Хәсән Туфан да була. Күптән түгел генә Хәсән абыйны яңа фатирга – А.Вишневский белән хәзерге Ә.Еники урамнары чатындагы яңа йортка күчерешүдә катнашкан идем. Үзара мөнәсәбәтләр әйбәт иде. Бер йомышым бар, дип хәбәрләшеп, өенә бардым. Абай китабын нәшер итәргә алынуыбызга сөенде. Казакъ, үзбәк, азәрбайҗан әдәбияты әһелләре белән даими аралашып яшәргә кирәк, дигән фикерләрне кат-кат искә төшергәләдек. Әмма ләкин яңа күченгән фатирдагы өстәл тартмаларында да, шкаф киштәләрендә дә Хәсән ага тәрҗемә иткән шигырьләр табылмады. «Хәзер минем архив белән Мәсгуд Гайнетдинов шөгыльләнә. Аңа әйтермен», – дигәч тә аерылыштык. Әмма Мәсгуд та ул шигырьләрне тиз генә табып бирә алмады.

1981 елда «Абай» исеме белән нәшер ителгән  ул томлыкка керүче әсәрләрне туплашуда казакъ телен яхшы белүче шагыйрьләр Нури Арслан, Мәхмүт Хөсәен, Әхмәт Исхаклар актив эшләде. М.Максуд тәрҗемәләреннән иң уңышлыларын Н.Арслан сайлап алды. Казакъстанда чирәм җир күтәрүдә катнашып, бераз сөйләм телен үзләштергән Әхмәт Рәшит белән нәшрият мөхәррире Марс Шабаев та ул китапны чыгаруда катнаштылар. Мин Абайның «Гаклия» («Хикмәтле сүз») хезмәтен тәрҗемә иттем. Тарихи эчтәлекле «Бераз сүз казакъның төбе кайдан чыкканы туралы» язманы да тәрҗемә итә башлаган идем. Ул хезмәтнең рөхсәт ителгән томлык күләменә сыймавы сәбәпле, аны тәмамламадым. Менә шул рәвешле туды ул «Абай. Шигырьләр һәм поэмалар. Хикмәтле сүз» исеме белән дөнья күргән бер томлык (рөхсәт ителгән күләме 11 табак иде). Ул томга акынның 1887 елда иҗат ителгән, иртә вафат булган улы Мәсгудкә багышлап язылган поэмасы да керми калды. Ул поэманы Казакъстанда үскән М.Хөсәен тәрҗемә итте.

Китап басылып чыгуга, аның берничә данәсен мин Казакъстан язучылар оешмасына җибәрдем. Аерым данәләрен шул яктан килгән әдипләргә дә бүләк иткәләдем. Ә 2014 елда Казанда төрки әдәбиятлар форумы узды. Аны «Тюрксой» оешмасы уздырды. Ул оешманың генераль-секретаре Дусен Касеинов Казакъстан вәкиле булганлыктан, «Абай» китабын мин аңа да бүләк иттем.

Абайның шушы җыентыгы чыгуга багышлап каләмдәшебез Тәүфикъ Әйди 1982 елда күләмле генә мәкалә язды. Китапның чыгуын бик хуплаган һәм тәрҗемәләрнең уңышлы булуын билгеләп киткән иде ул анда. «Үз йөзен саклап» дигән исем белән ул мәкалә «Казан утлары» журналының шул елгы  7 нче санында һәм шул ук җәйдә Казакъстан Язучылар берлегенә караган «Казакъ әдәбияты» газетасында нәшер ителде.

**Лирон ХӘМИДУЛЛИН,**
*Татарстанның Г.Тукай исемендәге*
*Дәүләт премиясе лауреаты*

# ХАТ ЯЗАР ИДЕМ СЕЗГӘ...



*Ниязи Бигашев әнисе Нәҗия белән.*

Дәһшәтле сугыш еллары ачы тамга салмаган гаилә юктыр бу илдә. Быел Бөек Җиңүнең 75 еллыгында һәркем үз гаиләсенең тарихын барлый. Безнең әле бүгенге көндә шул вакыйгаларның шаһиты булган өлкән буын вәкилләре белән аралашу бәхетебез бар. Сугыш елы балалары буларак, алар үзләренең истәлекләре, онытылмаслык хисләре белән уртаклаша ала. Ә фронтта ятып калган каһарманнарыбыз белән без алардан килгән өчпочмаклы хатлар аша аралашкандай булабыз.

Сугыш чоры баласы дәү әниебез Бигашева-Кәрамова Рәйсә Ниязи кызы әтисенең фронттан килгән хатларын киләчәк буын өчен кадерләп саклаган. Дәү әтиебез Бигашев Ниязи Кыям улының әнисе Нажия – Иж-Буби мәдрәсәсе мөгаллимәсе Мөхлисә Бубый тәрбияләп үстергән ятим бала, гомерен балаларга белем бирүгә багышлаган. Әтисе Кыям – Мордыбый авылында мөгаллим, Иж-Буби мөгаллимнәренең ярдәме белән укыту эшләрен алып барган. Үзләренең дүрт баласын – Ниязи, Өлфәт, Әнәс, Әнисәне дә белемгә омтылучан итеп үстергәннәр. Олы уллары Ниязи 1912 елның 4 декабрендә Әгерҗе районы Мордыбый авылында туган. 1928 елда Лубян урманчылык техникумына укырга керә, 1931 елда аны тәмамлый – урманчы-техник квалификациясен алып чыга. Сугыш башланганчы, үз һөнәре буенча эшли, гаилә кора, балалар үстерә. 1942 елда үз теләге белән сугышка китә. Гаиләсенә еш кына хатлары килеп тора.

Бигашев Ниязи Кыям улы 1943 елның 18 августында Курск дугасында батырларча һәлак була. Кызганычка каршы, каберенең төгәл урыны билгеле түгел.

Аның фронттан җибәргән хатларын тәкъдим итәбез.

*«Кадерле Җиһаным һәм балаларым!*

*Барыгызны да бик сагынып, күп сәламнәр җибәреп калам. Мин сезгә 30 августта Глухово шәһәреннән бер хат язган идем. 31 августта аннан чыгып киттек. Син акча җибәргән булсаң, кире кайтыр. Сугышка кермәдем әле. 50-60 чакрым чамасы артта ятабыз. Бер җирдә урман эчендә торабыз, сахрадагы кошлар белән бергә гомер итәбез. Үзем һаман миномётчик, ефрейтор. Ашаулар начар, бик ябыктым. Күрсәгез, таный да алмассыз инде. Шушы көннәрдә сугышның эченә кертмәкче булалар. Нәрсә булып калыр инде. Комиссияләр еш була, һәрвакыт таза дип чыгаралар.*

*Сездән бер хат та ала алмадым, хәлегезне белмим. Бу урында адрес юк, хат язмый тор. Мин хат яза алмасам, Заинский военкоматына хәбәр итәрләр, шуннан белешеп тор. Конюх карт белән карчыкка, Юныска, Антиповка, Нюрага, Нафиговка, Мифтаховка, Илһамга һәм башка мине сораганнарга сәлам әйт. Бабай килдеме?* (Бабай – каенатасы, Ниязиның олы кызы Рәйсә сугыш елларында Кукмара районы Төркәш авылында әби-бабай карамагында кала. – **К.Г.**). *Әнкәй хат язамы?* (әнкәй – Бигашева Наҗия, Мөхлисә Бубыйның кызы. – **К.Г.**) *Хушыгыз. Ниязи.*

*Исән булсак, бер күрешербез әле.»*

05.09.1942



*Ниязи Бигашев хатыны Җиһан һәм кызы Рәйсә белән.*

*«Кадерле Җиһаным һәм акыллы кызларым! Барыгызга да гвардия Кызыл Армия сәламе җибәреп калам. Үзем бик исән-сау. Фронттан бераз арттарак бер авылда ял итеп ятабыз. Ял бик кыска булды. Бүген-иртәгә тагын фронтка чыгып китәбез. Синең Яңа ел бәйрәме көнне язган хатыңны бүген алып укыдым һәм бик сөендем. Аннан сон бүген бабайдан бер хат алдым. Ул хатны синнән кайткач язган. Шулай, Җиһан, беренче сугышта чыдадым. Алдагы сугышларда ничек була инде. Сезне бик сагынам. Ашаулар яхшы, үзем хәзер бик тазардым. Партиягә кергәнне элекке хатымда язган идем. Дошманны бик нык кудык. Яхшы сугышкан өчен Сталин приказ язып, безгә благодарность җибәрде, аннан соң төрле бүләкләр килде. Исән булсам, Җиһан, җәйгә кайтырга өметләнеп торам. Син Төркәшкә кайтмасаң, берәр колхозда йә лесхозда эшлә. Олыжҗыда, Кызыл юлда йә Байракка күч. Тотсалар, гел тора торган өйдә тор әле. Районда булгач, сиңа зыян юк.*

*Маллар күп икән, кәҗәне күп калдыргансың, бер кәҗә җиткән. Җәй көне үзең аптырарсың ул кәҗәләр белән. Алар бәрәнләгәч, бер көтү булалар. Лучше сарыкларны берәр баш артык калдырасың калган. Ярый инде. Заданиесе булса, шунда бер кәҗәне бирерсең.*

*Кызларым мине сагыналардыр. Мин аларны бик сагынам. Алар сиңа эшләшә торганнардыр инде дип уйлыйм. Җиһан, син минем бар хатларымны да аласың микән? Минем хатларны көт тә, үзең дә хат язып тор. Хатың бик сирәк килә. Адрес шулай: 2483 полевая почта часть 84, Бигашеву Ниязию Киямовичу. Хат яз.Ниязи.»*

30.01.1943

*«Кадерле Җиһаным!*

*Сиңа һәм акыллы кызларым Римма белән Рәшидәгә бик күп сәламнәр җибәреп калам* (олы кызы Рәйсәнең хәлен бабай белән хат алышып белешеп торган – **К.Г.**). *Җиһан, мин сиңа бер айдан артык инде хат яза алмадым, монда күп сәбәпләр булды. Бик каты канлы сугышларда булдым, вакыт булмады. Почта да артта калган иде.*



Фронттан килгән өчпочмаклы хатлар...

*Менә хәзер ялга чыгабыз, бер җиргә җыелдык.*

*Бик күп җирләрдә булдым. Донбассны, Харьков өлкәсен, Ворошиловград һәм Воронеж өлкәләрен кыш буена бик нык таптадык.*

*Җиһан, мине орденга яздылар, шушы арада орден алам, яхшы сугышкан өчен. Минем бу хат исәнлек хаты гына булыр инде. Күп язып булмый. Яңадан яхшылап язармын әле. Синең үзеңнән ике ай инде хат алганым юк. Сыер бозаулагандыр инде. Сарыклар, кәҗәләр бәрәнләп беттеме? Ничә бәрән? Бозау үгезме, танамы? Хәзергә исән-сау гына торасызмы? Шуларның барысын да әйтеп, хат яз. Бүген 8 нче Март. Хатын кызлар бәйрәме. Башка елларны бу көнне бәйрәм ясый торган идек. Хуш, сау булыгыз. Ниязи Бигашев.»*

08.03.1943

*«Кадерле Җиһаным һәм акыллы кызларым! Барыгызга да гвардия Кызыл Армия сәламе җибәреп калам. Үзем исән-сау әле. Җәйге сугышка кермәдем әле. Ялда ятабыз. Мин хәзер кече командир. Һаман да миномётчик. Орден алдым. Партиягә кердем. Илне саклауда яхшы уңышлар күрсәттем. Әгәр дә исән-сау кайтырга туры килсә, мин бик зур кеше булырмын, Җиһан! Үзем турында бетте.*

*Ничек торасыз? Кызлар үсәме? Синнән инде дүрт ай булды хат юкка. Хәбәреңне бик беләсем килә. Кайда торасың? Җир чәчтеңме? Бәрәңге утырттыңмы? Нинди маллар бар? Ничә сарык, кәҗә, бәрәннәр, тәкәләр, тавыклар һәм башка малларны әйтеп яз.*

*Барча мине белгәннәргә сәлам әйт. Әнкәйдән һәм бабайдан хатлар юк. Хатыңны озынрак яз. Минем кәгазь юк. Бу арада сине һәм кызларымны төштә күрәм. Озакламый тагын сугышка керәбез. Сау бул. Ниязи Бигашев.»*

20.04.1943

*«Кадерле Җиһан һәм кызларым! Барчагызга да бик сагынып күп сәлам. Үзем исән-сау, үзебез ясаган лагерьда торабыз. Бу арада фронтларда каты сугышлар юк. Шуңа күрә без артта торып торабыз әле. Мин сезне төшләремдә гел күрәм. Син мине юлга хәзерләп, кайдадыр йөрисең икән, дим. Синең берничә хатың килде. Җибәргән кәгазьләреңне алдым. Моннан соң кәгазьләр җибәрмә инде, шушындый конвертлар бирәләр хәзер безгә. Әнкәйдән хат юк. Бабайдан да юк әле бу арада. Әнәстән* (Әнәс – Ниязиның бертуган энесе. – **К.Г.**) *бер хат алдым, үзенә дә яздым. 3-4 көн элек мин сиңа да озын хат яздым, справка да җибәрдем. Шуларны алганыңны хәбәр ит. Элекке бер хатта карточка җибәргән идем, алдыңмы? Мин синекен алдым. Барча эшчеләргә дә сәлам. Хуш, Ниязи Бигашев.»*

04.07.1943

*«Кадерле Җиһаным һәм кадерле акыллы кызларым!*

*Барыгызга да миннән күп сәлам. Җиһан, синнән бу арада хатлар юк. Үзем өченче хатымны язам инде, ә синнән җавап юк әле. Мин һаман фронтта исән-сау әле.*

*Белгород алганда, Курск шәһәрендә дә булдым. Тагын башка җирләрдә дә булдым. Дошман бик нык каршылык күрсәтә. Шулай булса да, без бирешмибез, әкренләп алга барабыз. Шулай итеп без быел җәй көнендә аны җибәрмәбез. Озакламый бөтенләй җиңеп чыгарга тиешбез. Исән калсам, кайткач зур бәйрәм ясар идек. Үзем һаман да миномётчик, кече сержант, буш вакытларда уземнең үткән тормышларны бик уйлыйм. Заинский һәм Олыҗы кордоннарында торган вакытлар һәм ашап-эчеп күңелле үткәргән гомерләр искә төшә. Вакыт үткән саен сезне ныграк сагынам.*

*Кызларым Рима белән Рәшидәне ифрат сагындым. Җиһан, мин бабайдан бер хат алдым, Рәйсә дә язган.*

*Үзең тора торган җирдә тор әле. Элекке хатларыңда үземнең монда икәнлегемне язган идем, алгансыңдыр. Бер хатымда карточка җибәрдем, икенче бер хатта Булыгинга бер язу җибәргән идем. Ул булыштымы сиңа печән чабарга? Печән күп чаптыңмы? Мин җибәргән справканы алдыңмы әле? Шуларны әйтеп яз. Минем адрес болай языла: Полевая почта, 35685 Бигашеву Ниязию Киямовчу. Барча белеш, танышларга күп сәлам.*

*Актүбәдән Касимов Якәү исән, Биклән авылыннан Семяков та исән, Түбән Арбашның Газизов Гыйльметдин дә исән. Чаллы районы Сидоровка авылыннан берәү бар. Башка якташлар юк. Бабай синең яныңа барам шушы арада дип язган. Ул килгәч, сыерны карагыз. Әгәр дә чынлап та сөте кимесә, берәр яшьрәк малга алыштырыгыз. Тана үсәме? Әгәр дә яхшы булса, шуны гына пләмәгә калдырыгыз. Ашаулар яхшы, өс-баш нык, чиста.*

*Өйдән чыкканнан бирле 2 шинель туздырдым инде, хәзер тагын яңаны алдым, өченче шинелем. Киемнәр нык булса да, фронтта һәм тылда бик озакка чыдамыйлар, шуңа күрә әледән-әле алыштырып торабыз. Мин хәзер партиягә член булып кердем инде, кандидатлыктан чыктым.*

*Хуш, сау бул.Ниязи Бигашев»*

27.07.1943

Кызганычка каршы, дәү әтиебез башка миллионлаган ватандашларыбыз белән бергә яу кырында башын салган.

*«Кайта алмасам, кызларымны укыт!»* – дип язган хатларында Ниязи. Хатыны Бигашева Хурлыҗинан (Җиһан) шул васыятьне үти: олы кызы Рәйсә (28.12.1934) – югары белемле математика укытучысы, Россиянең халык мәгарифе отличнигы; уртанчы кызы Рима (1937-1954) әтисе укыган Лубян урман хуҗалыгы техникумына укырга керә, укыган елларында ук яшьтән вафат була; кече кызы Рәшидә (30.08.1938) гомер буе авыл халкына фельдшер булып хезмәт күрсәтә. Кызлары үз гаиләләрен корып, балалар, оныклар үстерделәр: Рәйсә – 3 бала, 8 онык, 6 оныкчык; Рәшидә – 3 бала, 11 онык, 1 оныкчык. Барысы да бабалары Ниязи белән горурланалар!

Без, дәү әтиебезнен күпсанлы дәвамчылары, аңа кагылышлы материалларны эзләп табып, тәртипкә салдык, латин графикасында язылган хатларны кирилл хәрефләренә күчердек. Бу – безнең гаилә тарихы. Менә шушындый шәхси тарихлардан илебезнең шанлы үткәнен күзаллау мөмкинлеге бар безнең. Үзенең кыска гына 30 еллык гомерендә Ниязи Кыям улы Бигашев шул тарихта эз калдырган. Безнең ул эзләрне җуярга хакыбыз юк.

*Хатларны* **Камилә ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА** *әзерләде.*

# «ШӘҮЛӘ КҮЛӘГӘ БУЛАЛМЫЙ...»

Җиһанга яз килеп, табигать уянуга, хәзерге кешеләргә һәм, әлбәттә инде, заманыбыз әдәбиятындагы геройларга да төрле яклап куркыныч яный. Безнең һәммәбезне дә ниндидер җан ияләре «тешли» башлый: «каз тешли», «елан тешли», «шөпшә тешли», «талпан тешли», «бал корты тешли» һ.б. Әйтерсең, һәммәсе дә, кыш айларында теш табибында булып, протезлар ясатканнар да, халыкны умырып-умырып тешләргә дип, җәмгыятебезгә таралганнар.

Болай сөйләшеп яки язып, тел байлыгыбызның сайлыгын гына түгел, сүзнең мәгънәләрен аңламыйча кулланып хаталану һәвәслегебезне дә исбатлыйбыз. Алда аталган очраклардагы «тешли» сүзен алыштырырдай кәлимәләрне барлыйк әле. Ата-бабаларыбыз аларны борын-борыннан камилләштерә килгән һәм әдәби телебез хәзинәсенә әвереләдергән. Гадәттәгечә, «аңлатмалы сүзлек»кә мөрәҗәгать итик.

**Талау** – һөҗүм итеп, тешләре, томшыгы яки тырнаклары белән эләктереп йолыккалау (хайваннар, кошлар турында); тешләп, каныңны эчеп борчу (бөҗәкләр турында). **Чуку** – томшык белән эләктерү; томшык белән эләктереп алу. **Чагу** – ук белән җәрәхәтләү, чәнчеп агулау (кайбер бөҗәкләр, чаян, елан һ.б. шундыйлар турында). **Кадалу** – тәнгә ябышу, керү (бөҗәкләр турында).

Һәм, ниһаять, төп «гаепле» сүз – «тешләү». **Тешләү** – тешләр белән эләктереп кысып, тешләрне батырып яралау, авырттыру (хайваннар, җәнлекләр турында); хортумын яки угын кадап авырттыру, яралау (бөҗәкләр турында).

Мәгънә төсмерләре белән бергә китерелгән фигыльләрне «тешли торган» җан ияләре янәшәсенә куеп, ата-бабаларыбыз сөйләшкәнчә һәм грамматик яктан дөрес нәтиҗәләр ясыйк.

**Каз, күркә, әтәч – *талый*** (һөҗүмгә күчмәгәндә, ***чукып ала***), ягъни томшыгы яки тырнаклары белән эләктереп йолыккалый. **Елан, шөпшә, төкле тура, бал корты – *чага***, ягъни угы белән җәрәхәтли, чәнчеп агулый. **Чебен, черки, кигәвен, борча – *талый***, ягъни хортумын яки угын кадап авырттыра, яралый, ясканып-ясканып, каныңны эчеп борчый. **Талпан – *кадала***, ягъни тәнгә ябыша, керә. **Эт, ат – *тешли, талый***, ягъни тешләре белән эләктереп кысып, тешләрен батырып яралый, авырттыра.

Күргәнебезчә, теше булган җан ияләре генә тешли. Шулай да кайбер урынчалыклардагы җирле сөйләшләрдә чебен, черки, кигәвен, борча кебек бөҗәкләргә карата «тешли» дип әйтү бар – диалектологик сүзлекләр ачык күрсәтә. Әдәби әсәрләр дә моннан арына алмый. Шуңа күрә туган телебез сагында торучы каләм ияләренә язганда уяурак булу мәслихәт.

Күрәбез ки, сүзләрнең урынсыз кулланылышы «замана җөмләләре»ндә үзен шактый сиздерә. Бу хилафлык асылда фигыльләргә бәйле очраса да, башка сүз төркемнәре дә читтә калмый. Мәсәлән, авторлар әдәби әсәрләрдә «күләгә» белән «шәүлә» сүзләрен еш бутый башладылар. «Күзләрдән төшкән шәүлә», «бәдәнемнең шәүләсе бик кыска», «кояштан коелган нур күләгәләре», «керфегең какканда, күз алдымда биешкән күләгәләр» һ.б. мантыйкка сыймастай гыйфрит гыйбарәләр әдәбиятыбызны чүпли. Күрәсең, образлырак итеп әйтергә тырышу аркасында чыккан мөгезләрдер бу, ләкин авторның әсәрен мүкләк калдыра торган «телбизәкләр». Аларны редакторлар да тотып бетерә алмый.

Рабит Батулла «Кылдан нечкә, кылычтан үткен» кыйссасында әлеге ике кәлимә хакында кызыклы гына фәлсәфә тәкъдим итә: *«Агачның күләгәсе була. Койманың күләгәсе була. Кешенең дә була күләгәсе. Күләгә ул хуҗасына ияреп йөри. Яки хуҗасы янында тик тора. Шәүлә күләгә булалмый. Шәүлә ул – җисемнең үзе. Кояш баеп беткәч, офыкта агачларның күләгәсе түгел, шәүләсе кала. Шул мохиткә, ягъни кояш баешка берәр кеше килеп керсә, кешенең күләгәсе түгел, шәүләсе күренәчәк. Күләгә куркыныч түгел. Күләгә кояш яктысында гына була ала. Көндез. Ә шәүлә шомлы, шәүлә куркыныч, чөнки шәүлә, кеше шәүләсе, һәрвакыт куркыныч җинаятьләр тирәсендә йөри».*

Инде тел хәзинәбез тупланган сүзлекләргә мөрәҗәгать итик.

«Синонимнар сүзлеге» Батулла тәгълиматын дәлилли: **күләгә** – *ышык; күләнкә (диал.); күләткә (диал.)* һәм **шәүлә** – *сурәт; кыяфәт; рәвеш; образ; сын; гәүдә.*

«Аңлатмалы сүзлек»тә «күләгә» кәлимәсенең җиде мәгънәсе бар. Төп өчесенә тукталыйк. **Күләгә** – 1. Бер яктан яктыртылган зат, предметның икенче ягында барлыкка килгән караңгы чагылышы. Мисал: *«Биле бөгелгән – үз **күләгәсеннән** ары берни күралмаган». (Мөхәммәт Мирза)* // Кояш, ай яктыртудан җир өстендәге предметларның икенче ягында барлыкка килгән караңгы чагылыш. Мисал: *«Кыенсынма, кил, яшь яфрак, / Учыма куй учыңны. [...] Җәйге челлә ышыкланыр / **Күләгәң** салкынына, / Яңгырлар елар сыенып / Ямь-яшел ялкыныңа». (Сания Әхмәтҗанова)* 2. Нәрсә белән дә булса капланып, кояш нурларыннан сакланган пространство, урын. Мисал: *«Кояш яктысыннан кинәт **күләгәгә** кергәч, күзе алмашынып киткәнгә генә танымыйча торган икән Миңнулла, хәтерли ул бу агайны». (Вакыйф Нуруллин)* 3. Караңгыда ачык күренмәгән кеше, хайван яки берәр предмет; аларның ачык булмаган шәүләсе. Мисал: *«Озын **күләгә** җиргә сузаеп сузыла да, кинәт сынып, өй каршындагы рәшәткәләргә кыйгачлап киртләч-киртләч булып сылана». (Мәгъсум Хуҗин)*

«Шәүлә» сүзенең дә «аңлатмалы»да җиде мәгънәсе тәкъдим ителә. Төп мәгънәләре – бишәү.

**Шәүлә** – 1. Кара фонда, караңгылык эчендә тоныкына күренгән яктылык, якты әйбер. Мисал: *«Шәһәрнең ерактан балкып чакырып торган ут **шәүләләре** яктырганнан яктыра барды». (Марат Кәбиров)* 2. Караңгылык эчендә яки бик ерактан караганда ачык күренмәгән, аз-аз гына шәйләнгән әйбер; силуэт. Мисал: *«Караңгылык куерган саен, капка төпләрендә дә кешеләр арта бара. Һәр утыргычта бер-ике **шәүлә** шәйләнә». (Факил Сафин)* 3. Нинди дә булса якты әйбердән (янгын, ут көлтәсеннән) төшкән яктылык. Мисал: *«Учак яна... Ап-ак каеннарда / Төн буена **шәүлә** биеде». (Нур Әхмәдиев)* // Нәрсәдән дә булса чыккан яктылык нуры. Мисал: *«Дулкыннардан күчә төн карасы, / Ай **шәүләсе** төшкән елгага». (Марсель Галиев)* // Нәрсәдән дә булса кире кайткан нур, кайтарылган нур. Мисал: *«Өйдә кояш... Тәрәзә төбендәге яран гөленең йодрык кадәрле чәчәгеннән ак буяулы борыска алсу **шәүлә** төшкән» (Габделхәй Сабитов)* 4. Нәрсәнең дә булса икенче бер әйбердә (су, шома өслектә) чагылышы, чагылган рәсеме. Мисал: *«Кояш баеп беткәч, офыкта агачларның күләгәсе түгел, **шәүләсе** кала». (Рабит Батулла)* // Нәрсәнең дә булса күз алдына килгән, кабат гәүдәләнгән сурәте. Мисал: *«Кул сузымы ара ераклашты – / Ерагайды синең буй-сының. / Эреп барган **шәүлә** җылытмас шул / Керфекләрнең бәсле тоҗымын». (Гөлүсә Батталова)* 5. Хис, тойгыларның йөздә, чырайда чагылышы, төсмерләнеше. Мисал: *«Кемнәр өчен ап-ак йөзләреңдә / Сөю **шәүләләре** чагыла». (Җыр)* // Йөздә, кыяфәттә чагылган начар тәэсир, ямьсез күренешнең күләгәсе. Мисал: *«Фәизнең кыяфәтендә авыру **шәүләсе** һаман беленсә дә, күзләрендә инде яшәү елтыравы барлыкка килде». (Зөлфәт Хәким)*

Алтынчы санда **аныклагычлар янында тыныш билгеләренең** өч кагыйдәсенә тукталган идек. Бу санда калган икесенә игътибар итик.

**1. Аныклагыч фигыль белән белдерелгән кисәкне аныклап килсә, аныклагычлы кисәк алдыннан ике нокта куела.** Мисал: *«Гөлназа апаның хәле никадәр авыр булса да, хәсрәтне дин кушканча, сабырлык белән **күтәрергә тырышты: әнкәсе рухына көн-төн дога кылды».** (Фирүзә Җамалетдинова)*

**2. Аныклагычлар, тиңдәшләнеп килсәләр, мәгънә буталчыклыгы килеп чыкмасын өчен, аныкланмыштан сызык белән аерылалар.** Мисал: ***«Алда утыручылар – башлап йөрүчеләр, җитәкчеләр*** *– үз якларына;* ***без – җитәкләнүчеләр, ияреп йөрүчеләр*** *– үз ягыбызга киттек». (Туфан Миңнуллин)*

**Рамил ХАННАНОВ,**
*филология фәннәре кандидаты*



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Разил ВӘЛИЕВ**

## Кәнәфи бәйрәме

Язучы Туфан Миңнуллин белән шагыйрь Разил Вәлиев, Татарстан Дәүләт Советына депутат булып сайлангач, икесе бер Комитетта эшлиләр. Атна буе, айлар-еллар буе гел янәшә алар: бергәләп җыелышлар үткәрәләр, бергәләп командировкаларга йөриләр, төрле әдәби-мәдәни чараларда катнашалар, бергәләп бәйрәм дә итәләр.

Шундый бер олы бәйрәм алдыннан, гадәттәгечә, дуслар, фикердәшләр Разил бүлмәсенә җыела. Ә бүлмә хуҗасының – Комитет рәисенең өстәлендә өем-өем котлау открыткалары, дистәләгән телеграммалар. Разил, кунакларга бәйрәм табыны әзерләргә ниятләп, өстәлдәге открытка-телеграммаларны кочагына ала да үзе утыра торган кәнәфигә илтеп сала. Моңа аптырап карап торган Туфан шулчак, кызыксынып, Разилдән болай дип сорап куя:

– Нигә кәнәфигә куясың бу котлауларны, бүлмәдә урын беткәнмени?

Разил, кәнәфинең аркасын сыйпап, болай дип җавап кайтара:

– Туфан ага, татарның иң олпат аксакал язучысы булып та, шуны белмисеңмени? Бу котлауларның туксан тугыз проценты миңа түгел, менә шушы кәнәфигә килә бит. Бу – минем бәйрәм түгел, аның бәйрәме, әйдә, сөенсен әле! Иртәгә бу эштән китсәм, мине котлауларның саны йөз мәртәбә кимиячәк. Яңа хуҗа килгәч, кәнәфи тагын открытка-телеграммаларга күмеләчәк. Димәк, без монда вакытлыча гына, ә кәнәфи мәңгелек!

Әйдә, кәнәфи өчен берне күтәреп куйыйк әле!

**Марсель ГАЛИЕВ**

## Җәяүле Туфан

Гәрәй Рәхим белән Марсель Галиев Кукмарага барырга хыялланып йөриләр. Тик менә машина табу мәсьәләсе генә…

– Туфан Миңнуллинның машинасы бар да бит, шофёры да тыңлаучан. Иртән эшкә тугыз белән уннарда гына килә шул Туфан. Ә безгә таң белән китәргә кирәк. Биреп тормас шул, син сорап кара әле, сине тыңлый ул. Халык язучысы дигән исемнән дә баш тартты бит ул, син әйткәч, – ди Гәрәй Рәхим.

Кичтән Марсель Галиев телефоннан Туфан Миңнуллин номерын җыя.

– Исәнмесез, Туфан әкә!

– Ярыйсы әлегә. Живой, – ди Туфан.

– Сәламәтлекләр ничек, Туфан әкә? Нәҗибә ханым еш елмаямы? Сез бит Нәҗибә ханымга гына түгел, безгә дә бик кирәкле шәхес, Туфан әкә.

– Йә… йә… – дип куя Туфан Миңнуллин, рәхәт изрәгән тавыш белән.

– Безгә генә түгел, бөтен халыкка кадерле шәхес бит сез, Туфан әкә. Шуңа күрә сәламәтлегегез турында халык кына түгел, үзегез дә бераз кайгыртырга тиеш. Хәтерлисездер, элек машинага гына утырып йөргән түрәләрдән көлә идегез, аяклары бетә бит бу бичараларның, дистрофикка әйләнә баралар бит болар, дип… Менә хәзер, депутат булгач, сез дә гел машинада... Әзрәк җәяү дә йөрергә иде, Туфан әкә. Бигрәк тә иртәнге якта... Сез бит Казансу буенда торасыз хәзер. Менә шуннан саф һава сулап, иртән эшкә җәяүләп барулары үзе бер шифа ич... Әйтүемчә, сез бит халыкка кирәк язучы, Туфан әкә... Шекспирдан кала икенче зур драматург.

– Йә, йә, – дип куя Туфан Миңнуллин, иркә мырылдауга күчеп. Марсель Галиев-

тән болай ук кайгыртучан, җылы мактау сүзләрен еш ишетергә күнекмәгән Туфан Миңнуллинның зиһене таралып китә, каш арасындагы өч ермачлы җыерчыгы языла, күңеле тула.

– Рәхмәт инде җылы сүзеңә, хак әйтәсең, иртәләрен җәяү йөрергә бик кирәк тә соң... Тукта әле! Син нишләп болай... аек баштан үзең... Хискә бирелеп киттең әле... Берәр йомышың бар мәллә?

– Йомышым дип, Туфан әкә, әллә ни йомыш юк инде анысы. Шул... машинаңны биреп торсаң, дигән идем, иртәгә, иртәнге якта...

– Гомер булмаганны, нигә бик җаелеп сөйли, дисәм... Баштан ук йомышыңны әйтергә иде аны.

– Ул хакта бит Ризван Хәмиднең беренче һәм соңгы язган хикәясе бар, Туфан әкә, – дип, сикәлтәле көлә Марсель Галиев. Пауза бирмәскә, Туфан әкәне мактау иләслегеннән айнытмаска кирәк дип, тизрәк сөйли башлый.

– Күршесе Гайҗан бабайга Мансур исемле малай йөгереп керә дә: «Бабай, Рәмиснең велосипедын алып торыйм әле?!» – ди. Шулчак Гайҗан бабай: «И-и, улым, улым, йомышыңны алай ордым-бәрдем хәбәр итмә син, – ди. – Башта хәлне белеш, сихәтлегең ничек, бабай, башың авыртмыймы, аякларың сызламыймы, диген. Сыерыгыз сөт бирәме, Хөсни әби коймак пешерәме үзеңә, дип сора. Минем күңелне тәмам йомшарткач инде, оныкның биләсәпитен үзем китереп куярмын алдыңа», – дигән. Берничә көннән соң теге – Мансур исемле малай тагын шулай йөгереп кергән дә: «Исәнме, Гайҗан бабай, исән-сау гына торасыңмы, аякларың сызламыймы, Хөсни әби тәмле итеп коймаклар пешерәме үзеңә...» – дип тезеп киткән. Моңа бик күңеле булган Гайҗан бабай, малайның башыннан сыйпап: «Хәзер инде төп сүзгә күчсәк тә була. Йомышың ни иде, олан?» – дип сорап куйган.

– Гайҗан бабай, бакча башында мунчагыз яна! – дип кычкырып җибәргән малай.

Бу кыйссаны тыңлый-тыңлый Туфан Миңнуллин бик рәхәтләнеп көлеп куя да:

– Хикәяң шәп! Ризван Хәмид язгандырмы-юкмы, әмма хикәяң әйбәт! – ди. Бераз уйланып тора да, саранлыкка юмартлыгын, юмартлыкка саранлыгын бизмәнгә куеп карый да: – Болай булгач, иртәгә иртән эшкә җәяү барырга туры килә инде... – ди.

## Пыт-пыт

Бөтен депутатлар да юри генә уйный, ә Туфан Миңнуллин чынлап уйный... Шулай итеп, ул, СССР Югары Советы сессиясендә законнар кабул итеп утыра торгач, 17 кило 658 граммга кимеп, тәмам ябыгып кайтып төште. Бөтен дөньясына кул селтәде дә туган авылына юл тотты. Трактор сатып алды. Үзенекен дә, күрше-тирә карчыкларның да бакчаларын сөреп-тырмалап чыккан быел. Бәрәңге, чөгендер, кишер, суган, помидор, кыяр утырткан. Кориандр, әнис, борыч, тәмәке, тмин һәм тагын әллә ниләр чәчеп бетергән.

– Тракторыңның маркасы нинди? – дип кызыксына язучылар.

– Дүрт тәгәрмәчле инде, – ди ул, сорауны бик өнәмичә.

– Ә маркасы нинди?

– Арткы тәгәрмәчләре зуррак, алгылары бәләкәйрәк.

– Юк, маркасы нинди, дим?

– Маркасы дип... Пыт-пыт итеп эшли инде!..

**Туфан МИҢНУЛЛИН**

## Бәхәс

«Минем казылык», – ди Тычкан,
Күсе әйтә: «Минеке!».
Ә бит урланган казылык
Миңлебикәнеке.

Язып тормыйм мәсәлнең ахырын,
Шунысын гына әйтәм:
Бәхәс объекты – Кырым...

*2010*

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*

### КАЗАН – ХЕЗМӘТ БАТЫРЛЫГЫ ШӘҺӘРЕ

Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин Указы белән Татарстанның башкаласы Казанга «Хезмәт батырлыгы шәһәре» дигән исем бирелде. Ул моңа шәһәр халкының 1941 – 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүгә сизелерлек өлеш керткәне, сәнәгать предприятиеләрендә хәрби һәм гражданнар продукциясе җитештерүне өзлексез тәэмин иткәне, хезмәттә батырлык һәм фидакарьлек үрнәге күрсәткән өчен лаек булды.

Казаннан тыш, «Хезмәт батырлыгы шәһәре» дигән исем Боровичи, Екатеринбург, Иваново, Ижевск, Иркутск, Магнитогорск, Түбән Новгород, Түбән Тагил, Новосибирск, Новокузнецк, Омск, Пермь, Самара, Саратов, Томск, Ульяновск, Уфа, Чиләбе, Ярославль калаларына да бирелде.

### «ТАТАР ДӨНЬЯСЫ» КИТАБЫ

ТАССРның 100 еллыгына «Татар дөньясы» дигән саллы китап басылып чыкты. Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов үзенең Instagram аккаунтында «Иң яхшы китап. Халкыбызның тарихы, гореф-гадәтләре, мәдәни җәүһәрләре анда чагылыш тапкан!» дип язды. Тарихи документлар, тикшеренүләр һәм фәнни эшләр нигезендә язылган бу басма дүрт бүлектән тора: «Тарих һәм хәзерге заман», «Татар цивилизациясе», «Традицион мәдәният: гасырлар бәйләнеше», «Милли мәдәният: мәңге яшь иҗат». Китапта күп рәсемнәр, картографик материаллар, уникаль документлар, фоторәсемнәр, репродукцияләр урын алган. Ул киң даирә укучыларга тәкъдим ителә.

### ПРЕЗИДЕНТ МӘКАЛӘСЕ

Республика матбугатында ТР Президенты Рөстәм Миңнехановның программ мәкаләсе басылып чыкты. Анда сүз татарның дөньядагы роле, әһәмияте, милли үзаң, традицияләргә тугрылык, киләчәккә ышаныч тудыру турында бара. Җәмәгатьчелек бу мәкаләне татар дөньясында зур вакыйга буларак бәяләде. Әлеге язма белән «Казан утлары» журналының сайтында танышырга мөмкин.

### КОМИССИЯНЕҢ БЕРЕНЧЕ УТЫРЫШЫ

Татарстан Республикасы Президенты каршында Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе оештырылды. Аңа дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре, министрлыклар, ведомстволар җитәкчеләре, иҗтимагый оешмалар вәкилләре, депутатлар, галимнәр, язучылар, мәгариф хезмәткәрләре кертелде. Алар арасында Разил Вәлиев, Ркаил Зәйдулла, Дания Заһидуллина, Искәндәр Гыйләҗев, Ким Миңнуллин, Рөстәм Галиуллин, Рамил Төхвәтуллин кебек әдәбият-сәнгать әһелләре, галимнәр бар.

ТР Дәүләт Советында комиссиянең беренче утырышы булды. Аны комиссиянең рәисе, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов алып барды. «Вакыт һәм тормыш шуны раслады: татар теле татардан башка беркемгә дә кирәкми. Телебезне саклап калу – бары тик татар халкының эше. Аны бер кеше дә читтән килеп якламаячак», – диде ул үзенең чыгышында. Утырышта дүрт эшче-төркем оештырылды. Беренче төркем (җитәкчесе ТР Премьер-министр урынбасары – мәгариф һәм фән министры Рафис Борһанов) мәгарифне, укыту программаларын камилләштерү, дәреслекләрне яңарту юнәлешендә эшли. Икенче төркемгә (ТР мәдәният министры Ирада Әюпова) – массакүләм матбугат һәм мәгълүмат чаралары, мәдәният оешмалары, иҗат берләшмәләре эшен, социаль челтәрләрне камилләштерү бурычы куелды. Өченче төркемнең (КФУ ректоры Илшат Гафуров) максаты – урта һәм югары һөнәри белем бирү, фән өлкәсендә татар теленең кулланыш даирәсен киңәйтү, милли кадрлар әзерләү, фәнни эзләнүләр. Дүртенче төркем (ТР Президенты аппараты җитәкчесе урынбасары Илнур Гарипов) дәүләт органнары, муниципаль берәмлекләр, хакимият структуралары белән хезмәттәшлек итә.

Утырышта чыгыш ясаган ТР вице-премьеры – Бөтендөнья Татар конгрессы Милли шурасы рәисе Васил Шәйхразиев комиссия белән кулга-кул тотынып эшләячәкләрен белдерде, татар телен үстерү һәм милли үзенчәлекләрне саклау максатында финанслауны 100 миллион сумга арттыру күздә тотылуын әйтте.

## «АДӘМНӘР» ТӨРКИЯДӘ ДӨНЬЯ КҮРДЕ

Галимҗан Ибраһимовның «Адәмнәр» повесте Төркиядә төрекчәгә тәрҗемә ителеп, китап булып басылып чыкты. Әсәрне Кавказ университеты доценты Чулпан Зарипова-Четин тәрҗемә иткән. Мөхәррире – Кыркларәли университеты галиме Бүләнт Бәйрәм. Китап Евразия Язучылар берлеге рәисе Якуп Өмәрогглу җитәкләгән «Бәнгү» нәшриятында дөнья күргән.

## МӘҺДИЕВ МУЗЕЕНА – 20 ЕЛ

Арча районы Гөберчәк авылындагы татар әдәбияты классигы, Татарстан Республикасының халык язучысы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Мөхәммәт Мәһдиев музее ачылуга 20 ел (быел июнь аенда әдипнең вафатына да 25 ел тулды). Шушы уңайдан район җитәкчеләре һәм авылга кайткан бер төркем кунаклар әүвәл язучы йөргән юлны (Арча – Күпербаш – Казиле – Масра – Гөберчәк) велосипедларда үтүчеләрне алкышладылар. Гөберчәктәге юбилей чаралары Мәһдиевнең каберен зиярәт кылудан башланды. Монда аның рухына дога багышланды. Аннары барысы да музейга килде, язучы, галим турында истәлекләр белән уртаклашты, экспонатларны карады, табигатькә чыгып, кыр-болыннарда, урман-тугайларда Мәһдиев эзләреннән үтте. Юбилейга багышланган чараларда Арча муниципаль районы башлыгы Илшат Нуриев, район башкарма комитеты рәисе урынбасары Алинә Мөхәммәтшина, «Казан утлары», «Безнең мирас» журналлары редакцияләре вәкилләре, язучылар Камил Кәримов, Вакыйф Нуриев, Ләбиб Лерон, язучы-публицист Риман Гыйлемханов, музей экспозициясен төзүче Флүрә Дәминова, педагог Фидания Леронова, Мәһдиевнең кызы, ТР Фәннәр академиясенең бүлек мөдире, язучы-тәрҗемәче Гәүһәр Хәсәнова-Мәһдиева, әдипнең бертуган апасының кызы Җәүһәр Галимова катнашты һәм чыгыш ясады. Кунакларны Арчадагы «Казан арты» тарих-этнография музее директоры Радик Яруллин, төбәкне өйрәнүче Ленар Гобәйдуллин, Мәһдиев музее җитәкчесе Халидә Габидуллина каршы алды һәм озатып йөрде.

## ДЕРЖАВИН ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

Шагыйрь, дәүләт эшлеклесе Гавриил Державинның тууына 277 ел. Шул уңайдан аның Казанның Лядской бакчасындагы һәйкәленә һәм Лаешның үзәк мәйданындагы бюстына чәчәкләр салынды. Быелгы вазгыятьне истә тотып, бу чараларда катнашучылар саны чикләнде. Лаешта Г.Державин премиясенең быелгы лауреатлары игълан ителде. Бу олы бүләккә «Негде яблоку упасть» һәм «Алмазная гора» китаплары өчен шагыйрь Борис Вайнер, юриспруденция өлкәсендә ирешкән казанышлары өчен юридик фәннәр докторы Марина Ефремова лаек булды.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

ТР Президенты Указы белән хезмәттә югары нәтиҗәләргә ирешкәннәре өчен «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы генераль директоры **Әнәс Тәлгат улы Әскаров** – Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены медаленә, «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары **Эльвира Фәнис кызы Әхмәтова** «Фидакарь хезмәт өчен» медаленә лаек булды.

2020 елның 2 июлендә 81 нче яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган юристы, прозаик, детектив әсәрләр авторы **Фәнил Ислам улы Галиев** вафат булды.

Мәрхүм Теләче районы Орымширмә авылы зиратында җирләнде.

2020 елның 19 июлендә 91 нче яшендә татар әдәбияты галиме, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, Җ.Вәлиди исемендәге әдәби премия лауреаты **Фәрит Миргалим улы Хатипов** вафат булды.

Мәрхүм Самосыроводагы Мөселман зиратында җирләнде.

2020 елның 19 июлендә 70 нче яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрь, журналист, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Г.Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты **Рөстәм Габдрахман улы Фәйзуллин (Акъегет)** вафат булды.

Мәрхүм Балык Бистәсе районы Юлсубино (Балтач) авылы зиратында җирләнде.

2020 елның 21 июлендә 74 нче яшендә педагог, Татарстан Республикасының атказанган укытучысы, Г.Тукайның тормыш юлын, иҗатын өйрәнүгә һәм пропагандалауга зур өлеш керткән **Фәрхәт Гани улы Зыятов** вафат булды.

Мәрхүм Арча районы Чиканас авылында җирләнде.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман Ф.САДРИЕВА «Трудный возраст», роман Ф.ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ «Место, где птицы свили гнёзда», рассказ А.БАЙМУХАММЕТОВА «Место»; стихи Р.МУХАМЕТШИНА, М.КАБИРОВА, А.ШАРИПОВА, Р.МУХИЯР.*
*Литературный конкурс «Помни о Родине»: рассказ А.ГАРАЕВОЙ-АКЧУРЫ «Безнадежность», рассказ Ф.АБДУЛЛИНА «На германской земле душица не растет».*
*«Новые имена»: стихи Р.АХМЕТОВОЙ.*
*85 лет со дня рождения Туфана Миннуллина: М.ШАЙМИЕВ. «Мы – деревенские…» (интервью подготовила Нурсюя Шайдуллина).*
*Фотоархив: моменты из жизни Туфана Миннуллина.*
*Статья М.АХМЕТОВА «Он был почитаемым человеком страны».*
*Статья А.ЗАКИРЗЯНОВА «Свобода души» (штрихи к творческому портрету Туфана Миннуллина).*
*Т.МИННУЛЛИН. «Папа. Мама» (из дневников).*
*Статья И.ЗАЙНИЕВА «Альмендер нашего театра».*
*«175 лет со дня рождения аксакала казахской литературы Абая»: статья Л.ХАМИДУЛЛИНА.*
*«75-летие Победы в Великой Отечественной войне»:«Я написала бы вам письмо…» (письма подготовила Камиля Гильмутдинова).*
*«Красными чернилами»: рубрику ведёт Р.ХАННАНОВ.*
*«Страницы юмора»: подготовил М.ГАЛИЕВ.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: Страда. Фото А.Арахамия; поэтесса Эльмира Джалилова.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and Poetry»: novel by F.SADRIEV «Difficult Age», novel by F.ZAMALETDINOVA «The place where the birds nested», story by A.BAIMUKHAMMETOV «The Place»; poems by R.MUKHAMETSHIN, M.KABIROV, A.SHARIPOV, R.MUKHIYAR.*
*Literary contest «Remember the Motherland»: story by A.GARAYEVA-AKCHURA «Hopelessness», story by F.ABDULLIN «Oregano does not grow on the German land.»*
*«New Names»: poems by R.AKHMETOVA.*
*85th anniversary of Tufan Minnullin*
*M.SHAIMIEV. «We are village people…» (interview prepared by Nursia Shaydullina).*
*Photo archive: moments from the life of Tufan Minnullin.*
*Article by M.AKHMETOV «He was a revered man of the country.»*
*Article by A.ZAKIRZYANOV «Freedom of the soul» (touches to the creative portrait of Tufan Minnullin).*
*T.MINNULLIN. «Dad. Mom» (from the diaries).*
*Article by I.ZAYNIEV «Almender of our theater».*
*«175th anniversary of the Kazakh literature aksakal Abay»: article by L.KHAMIDULLIN.*
*«The 75th Anniversary of Victory in the Great Patriotic War»: «I would write you a letter…» (letters prepared by Kamilya Gilmutdinova).*
*«In red ink»: column led by R. KHANNANOV.*
*«Pages of humor»: prepared by M. GALIEV.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: Harvesting. Photo by A.Arakhamia; poet Elmira Jalilova.*

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Татарстанда печән өсте.
*А.Арахамия фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрә Эльмира Җәлилова.